# Әбелгазый Баһадир хан

# Шәҗәрәи төрек

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007

УДК 821.512.145–94 (093)
ББК 63.3 (2 Рос = Тат)
Ә13

Гарәп графикасындагы текстны гамәлдәге язуга күчерүчеләр, искәрмәләр һәм күрсәткечләрне төзүчеләр:
**Марсель Әхмәтҗанов, Әдибә Сабирова**
**Әбелгазый Баһадир хан**

Шәҗәрәи төрек / Әбелгазый Баһадир хан; кереш мәк. авт. М.Әхмәтҗанов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 271 б. — 1000 д. — ISBN 978–5–298–01528–8

XVII гасырда Урта Азиянең Өргәнеч һәм Хива ханлыкларында яшәп иҗат иткән, Алтын Урда дәүләте ханнарының нәселеннән булган Әбелгазый Баһадир хан бине Гарәб Мөхәммәд әл-Чыңгызый әл-Хәрәзминең Чыңгыз хан нәселе шәҗәрәсен тасвирлап язган «Шәҗәрәи төрек» (1664–1665) әсәре басмага текстологик яктан Габделгалләм Фәезханов тәрҗемәсе буенча әзерләнде.

ISBN 978–5–298–01528–8
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© М.И.Әхмәтҗанов, Ә.М.Сабирова, текст, искәр., аңлат., 2007

## Әбелгазый Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрек» әсәре турында

XVII йөздә Хива ханлыгында хөкемдарлык иткән, Алтын Урда татар ханнары нәселеннән булган Әбелгазый Баһадир хан бине Гарәб Мөхәммәд хан әл-Чыңгызый әл-Хәрәзминең (1603–1663)[1] «Шәҗәрәи төрек» исемле тарихи китабы Урта Азия халыклары өчен генә түгел, татар халкы тарихына да зур бер чыганак базасы булып хезмәт итә. Мөгаен, бу китап Идел-Урал буе татарларына инде XVII гасырның ахырында ук таныш булгандыр. Чөнки Урта Азия белән татарлар арасында XVII гасыр дәвамында шактый тыгыз мәдәни-икътисади бәйләнешләр барлыгына дәлилләр җитәрлек. Татар уллары бу дәвердә дә Бохара якларына укырга барганнар, сәүдә һәм дипломатия эшләре белән йөргәннәр[2]. Мәсәлән, XVII гасырда Урта Азия мәдрәсәләрендә белем алган татар укымышлыларыннан Кадыйр Гали би, Мансур бине Габдерахман бине Әнәс әл-Борындыкый, Йуныс бине Иванай кебек шәхесләр мәгълүм[3].

Тюркология фәнендә Әбелгазый Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрек» әсәрен беренче мәртәбә Ф.И.Страленберг исемле швед офицеры Себер татарлары арасында якынча 1720 елларда табып алып, аны татар ахуны ярдәмендә урысчага тәрҗемә иттерүе, соңыннан урысчадан немец теленә күчереп, бастырып чыгаруы хакында хәбәрләр бар[4]. Касыйм ханлыгы башкаласы Хан Кирмән шәһәренең Иске бистә зиратында бүген дә әле кызыл кирпечтән эшләнгән бер тәкыя-мавзолей саклана. Ул тәкыядә һиҗри 1058, милади 1648 елның 9 рамазанында вафат булган Әфган Мөхәммәд солтан Гарәб Мөхәммәд хан улы күмелгән[1]. Аны 1622 елда, 11 яшьлек чагында, агасы Хәбеш солтан исән калдыру максаты белән Мәскәүгә озата. Мәскәүдә Әфган Мөхәммәд солтан 26 ел яшәп, 37 яшендә вафат була. Ул солтан Әбелгазый Баһадир ханның иң кече бертуган энесе иде. Касыйм ханлыгында Әфган Мөхәммәд солтан Бохара, Өргәнеч якларыннан килгән беренче генә кеше булмаган. Бу ханлык вакытында ук оешкан Бастан һәм Әҗи авылларында Өргәнеч һәм Хаҗи Тарханнан килеп утыручыларның нәселләре булуы хакында татар генеалогик әдәбиятында хәбәрләр бар[2]. Ул хәбәрләрдән күренгәнчә, Хан Кирмән шәһәренә Өргәнечтән һәм Хаҗи Тарханнан шактый халык килеп утырган. Мәсәлән, Әҗи авылында сакланган мәгълүматларга караганда, Өргәнечтән Габделгазиз солтан, үзенә буйсынган ике меңләп сугышчысы белән атасыннан качып, Мәскәү патшасына баш игән, һәм алар Әҗи авылында яшәп калганнар.

Әбелгазый хан Өргәнеч каласында туган һәм соңыннан Урта Азиядә үзбәкләр арасында булган феодал таркаулыкны бетерү өчен каты көрәш алып бара. Үзе дә сугышларда катнашып, берничә мәртәбә үлемнән чак котылып кала. Бо-

ларны ул үзенең «Шәҗәрәи төрек» китабында да яза. Аның безнең замангача ике тарихи китабы сакланып калган. Беренчесе — укучыларыбыз өчен әзерләнгән әлеге «Шәҗәрәи төрек», икенчесе — «Шәҗәрәи төрекмән» китабы.

Әбелгазый хан — үз заманының шактый укымышлы һәм каләм һәвәслеге булган затларның берсе. Аның әсәрендә Урта Азиядә яшәгән үзбәк, мангыт (татар) һәм казакъларның тарихи этнографиясенә кагылышлы бай мәгълүмат кергән; матур чагыштырулар, фразеологизмнар, тарихи топонимнар, төрки этнонимика, антропонимнар, шәхесләр турындагы мәгълүматлар әсәрнең бай тукымасын тәшкил итәләр. Шуның белән бергә, Түбән Иделдән Үзбәк ханга ияргән бер зур төркем татарларның, хан үлгәннән соң, үзләренә үзбәк исемен этноним буларак кабул итеп, Урта Азия — Хива, Бохара, Өргәнеч якларына китеп, андагы җирле төркиләр белән нинди мөнәсәбәтләрдә яшәүләре тасвирланган картиналар да тарихи әһәмияткә ия. Шунысы кызыклы: Әбелгазый хан әсәрендә XVII гасырда үзбәкләр белән төрекмәннәр арасында булган киеренке мөнәсәбәтләрнең тамырлары аңлашылмый. Үзбәкләр ул елларда хәтта фарсылар белән дә чагыштырмача тыныч яшәгәннәр.

Европалылар Урта Азияне бик артта калган илләр рәтеннән тасвир итәргә тырышалар. «Шәҗәрәи төрек» әсәрен укыгач, бу фикернең дөреслегенә шик төшә. Мәсәлән, XVII гасыр уртасында Урта Азиядә һәм Иранда утлы коралмылтык, туплар да шактый дәрәҗәдә мөселман гаскәрләре кулында булган. Хива, Өргәнеч, Бохара гаскәрләренең үзара бәрелешләре вакытында «мылтыкчылар» дигән аерым гаскәри төркемнәрнең шактый ук күплеге китапны укыганда хәтердә кала. Димәк, Әбелгазый Баһадир ханның хезмәте тормышның күпкырлы картиналарын бай һәм эчтәлекле сурәтләр белән тасвирлый. Анда мәкер дә, идеалга тугрылык та, беркатлылык та, батырлык та күп мисалларда күренә. Бу китап — татар халкының да урта гасырлардагы мөстәкыйль дәүләтләрендә хөкем сөргән тормыш картиналарын күз алдына китерерлек ышанычлы чыганак.

Татар тарихчылары өчен әлеге әсәрнең нинди тарихи чыганакларга таянып язылуын белү бик мөһим. Чөнки үз тарихи чыганакларыбыз булган хәлдә дә, татарның коллыкка төшерелгән ватанында китап сакларга да мөмкинлекләр чикле булу сәбәпле, борынгы дәверләрдән безгә бу заманнарга килеп җитмәгән тарихи чыганакларның XVI–XVII йөзләрдә Урта Азия китап репертуарында эзәрлекләнүсез саклану мөмкинлеге Әбелгазый Баһадир хан хезмәтендә бик ачык күзәтелә.

Әбелгазый Баһадир хан үз заманының тарихи-гыйльми өлкәсендә артта калуына офтанып яза. Ханның кул астында аның дәүләте һәм хакимият эшчәнлеге тарихын төгәл язып барырлык белгеч булмый. Шулай ук Әбелгазый Баһадир ханның нәсел-ыруы эченнән дә, XIV–XVI гасырларда яшәгән ничә буыннар арасыннан да тарихны тәртипләп барлаучы кеше килеп чыкмаган. Шунлыктан хан үзеннән гайреләрнең бу эшкә сәләтсезлегенә басым ясый.

Әбелгазый Баһадир хан борынгырак дәверләрдә мөселман ханнар арасында тарих язарлык кешеләр булып, ул дәверләрдән дистәләрчә тарихи әсәрләр сакланып килүен дә хәбәр итә. Ләкин XVII гасыр уртасында вазгыять үзгәрә. Шибан хан токымнарының тарихында XV гасыр башларыннан соң үзләренең бердәм шәҗәрәләре сакланмый, кардәшләкләрен тойсалар да, аның чылбырын һәм кайсы бабадан бүленә башлаганлыкларын раслап күрсәтә алмыйлар.

Мәсәлән, Әбелгазый Баһадир ханның язмаларында аның үз нәселе шәҗәрәсе чылбыры тулы рәвештә күрсәтелә. Аның бабасы Хаҗи Мөхәммәд — Вәзир шәһәрендә идарә иткән хан — 1602–1603 елларда 83 яшендә вафат була. Аның кардәше — Бохара ханы Габдулла — 1597 елда үз йортында вафат. Аларның кардәше — 1601 еллар чамасында вафат булган Себер ханы Күчүм. Бу өч тармак ханнар, бер нәселдән булсалар да, уртак бабаларының кемнән башлануын белмәгәннәр.

Үз тарихын язганда, Әбелгазый Баһадир ханның кул астында Чыңгыз хан нәселенә нисбәтле 18 том китап тупланган була. Ул аларны чагыштырып өйрәнә һәм тарих язу буенча кайбер аналитик фикерләргә килеп нәтиҗә ясый. Хива ханының бу казанышы аның үз хезмәтендә аеруча күзгә ташлана. Әбелгазый Баһадир хан үзеннән элгәреге тарихчыларның заказ үтәүчеләр икәнен, тарихны бизәп язуларын, арттыруда тыйнаксызлыкларын хезмәтендә искәртеп уза.

«Шәҗәрәи төрек» әсәренең әһәмияте гуманитар белемнең күп тармакларына җәелә. Ул — тарих кына түгел, нәсәб фәне дә: әдәбият, этнография, фольклор, икътисад, тарихи география һ.б. фәннәргә дә тарихи чыганак була ала. Бу хезмәт — татар халкы белән Урта Азиядә яшәүче халыклар арасында бик якын кардәшлек, тарихи берлек барлыгын күрсәтүче документ.

Әбелгазый Баһадир хан 1663 елда Хива шәһәрендә вафат булган. Ул, үзенең «Шәҗәрәи төрек» әсәрен тәмамларга өлгермичә, аны төгәлләүне балаларына васыять итеп әйтеп үлеп китә. Китапны, аның васыятен үтәп, һиҗри 1076, руми 1665–1666 елларда балалары тәмамлыйлар.

Татар мәгърифәтчесе Габделгалләм Фәезханов (1850–1910) бөек тарихчының бу данлыклы әсәрен 1891 елда Казанда яңа татар әдәби теленә якынайтып бастырып чыгарды. Күрәсең, аның кулында әсәрнең кульязма тексты булган. Болай дип уйларга тулы нигез бар, чөнки Г.Фәезханов бастырган текст белән «Шәҗәрәи төрек»нең 1906 елда Казанда урысча һәм 1992 елда Ташкентта үзбәк телендә басылган текстлардагы кайбер исем-атамалар язылышында һәм тулылык җәһәтеннән аермалар бар. Әлбәттә, Әбелгазый Баһадир хан әсәренең академик басмасы булганда, татар басмасындагы аермаларның кыйммәтен бәяләп булыр иде. Г.Фәезханов, «Шәҗәрәи төрек»не чыгарып, халкыбызны агарту юлында матур истәлек калдырган. Хәзер инде аның басылып чыгуыннан соң 120 еллап вакыт узган, татарда бу дәвердә ике графика алышынган, телдә яңалыклар өстәлгән һәм бу китап турында мәгълүматлы милләттәшләребез юк диярлек санда гына. Шунлыктан татар тарихына кагылышлы бу борынгы әсәрне укучыларыбызга җиткерүне үзебезнең бурычыбыз итеп куйдык. Хезмәтне басарга әзерләүдә Г.Фәезханов басмасында очраган кайбер тел кытыршылыклары очраклары төзәтелде, борынгы кеше исемнәренең язылышы унификацияләнде, авыр аңлаешлы сүзләргә аңлатмалар һәм алфавитлы исемнәр күрсәткече төзеп бирелде. Бу хезмәтне матбугатка әзерләү вакытында 1891 елгы басмада җибәрелгән сүзләр язылышындагы байтак техник хаталар төзәтелеп, укучыларга борынгы әсәрне үзләштерүне җиңеләйттек. Эш процессында Г.Фәезханов басмасыннан тыш Әбелгазыйның 1992 елда Ташкентта басылган «Шажарай-

и-турк» һәм 1906 елда Казанда Г.С.Саблуков, Н.Ф.Катановлар тарафыннан урыс теленә тәрҗемә итеп чыгарылган «Родословное древо тюрков» басмасыннан да атамаларның дөрес язылышын ачыклаганда файдаланылды.

*Марсель Әхмәтҗанов,*
филология фәннәре докторы, академик

# Кереш

Бисмилләхир-рахмән ир-рахим.

Ибтидасыз[1], вә интиһасыз[2], вә шәриксез[3] җиде кат күк вә җиде кат җирне, унсигез мең галәмне бул дигәндә булдырган Тәнренең хәмеденнән[4] соң. Дусты вә барча Адәм фәрзәндләренә[5] җибәргән илчесе вәли әл-газыйм вә рисаләт вә нәбүвәт вә хатимәт бу дүрт мәртәбәне гыйнаять[6] кылып биргән Рәсүле Мөхәммәд Мостафаның дәрвәденнән соң. Бу китапны чыгармакның сәбәбе Гарәб Мөхәммәд хан углы Әбелгазый Баһадир хан Чыңгызый вә Хәрәзми әйтәдер ки, Чыңгыз ханның әба вә әҗдадлары[7] һәр вилаятьләрдә падишаһлык кылып торалар. Язучылар төрки вә фарсы теле илән аларның барчаларының туган вә үлгән тарихларын яхшы вә яман кылган эшләрен язып торалар. Падишаһның исеменә бер данишмәнд[8] кеше бер китап тасниф кыла вә янә берничә еллардан соң шул падишаһның әүлядыннан бер падишаһ булганда дәхи бер данишмәнд язучы пәйда булып, мин ул борынгы язучыдан яхшырак язармын дип, бу падишаһның исеменә дәхи бер тарих язадыр. Шулай кыла-кыла, Чыңгыз әүлядыннан һәр йортта үткән падишаһларның атларына бәгъзеләренә — ун тарих, вә бәгъзеләренә — егерме тарих, вә бәгъзеләренә утыз тарих язалар. Иран илән Туранда үткән Чыңгыз хан угланнарының исемнәренә чыгарылган тарихлардан ошбу заман фәкыйренең алдында унсигез мөҗәлләд[1] әзердер. Әмма безнең ата вә агаларыбызның бипәрвалыгы[2] вә Хәрәзем халкының бивакыйфлыгы[3], бу ике сәбәптән безнең җәмәгатебезне Габдулла ханның аталары илән безнең аталарыбызның аерылган җиреннән безгә килгәнче тарихларын язмаганнар иде. Бу тарихны бер кешегә тәклиф[4] кылаек дип ничә кәррә фикер кылдык, һич мөнасиб кеше тапмадык. Ул сәбәптән үзебезгә язарга зарур булды. Төрекнең мисалы бар: «Үксез үз кендеген үзе кисәр» дигән. Адәм заманыннан бу вакыткача тарихлар бик күп язылгандыр, хисапсыз, мәгәр Ходa белер. Һич падишаһ, вә әмир, вә һич хаким данишмәнд үз тарихын үзе язмаган. Безнең йортыбызның һәвәсеннән вә әһле Хәрәземнең сәләтсезлегеннән һичбер заманда булмаган эш булды. Күңелегезгә килмәсен ки, фәкыйрь үз тарафын яклап ялган әйткән яки үзен мактап тәгъриф иткән дәю. Мин фәкыйрьгә Ходай Тәгалә гыйнаять кылып күп нәрсәләр биргәндер. Хосусән өч һөнәр биргән. Әүвәл: сипаһилекнең[5] кануны вә кагыйдәсен ки: ничек атланмак, вә йөрмәк, вә яуга каршы тормак, күп булып йөргәндә ничек кылмак, аз булып йөргәндә ничек кылмак, дуска, дошманга ничек сүзләшмәк. Икенче: мәснәвият[6], вә кыйссаяд, вә газәллият[7], вә мокаттагат[8], вә робагыять, вә барча әшгарьне фәһемләмәклек, гарәби, вә фарсы, һәм төрки лөгатьләренең мәгънәсен белмәклек. Өченчесе: Адәм заманыннан үлгән падишаһларның исемнәре вә гомерләре, вә солтанәтләренең кимү вә ишәюләрен белмәклек. Бу вакытта әшгарь фәһемләмәктә вә тарих белмәктә фәкыйрь кеби кеше, шаять, Гыйракта вә Һиндстанда булса булыр. Юк, дисәм, ялган булыр. Әмма сипаһиның кагыйдәләрен белмәктә бу чакта мөселманнан, кяфердән без күреп ишетә торган җирләрдә вә йортларда юктыр. Җир йөзе киңдер, ишетмәгән җирләребез дә булса гаҗәп имәс.

Инде максудтан калмаек. Тарих һиҗри мең җитмеш дүрт иде ки, без бу китапны ибтида кылдык, дәхи «Шәҗәрәи төрек» дип исем кылдык. Тугыз бабка бүлдек. Әүвәлге баб: Адәмнән Могул хангача; икенче баб: Могул ханнан Чыңгыз хангача; өченче баб: Чыңгыз ханның туганыннан үлгәненәчә, дүртенче баб: Чыңгыз ханның өченче углы Үгедәйнең вә аның әүлядының вә Чыңгыз хан угланнарының нәселеннән һәркем Могул йортында падишаһлык кылган булса, аның зикере[1]; бишенче баб: Чыңгыз ханның икенче углы Чыгтай ханның әүлядыннан Мавәраәннәһердә вә Кашгар йортында падишаһлык кылганнарының зикере; алтынчы баб: Чыңгыз ханның кечек углы Тули ханның әүлядыннан Иран мәмләкәтендә хөкүмәт кылганнарның зикере; җиденче баб: Чыңгыз ханның олуг углы Җүчи ханның әүлядыннан Дәште Кыпчакта падишаһлык кылганнарының зикере; сигезенче баб: Җүчи ханның углы Шибан ханның әүлядыннан Мавәраәннәһердә, вә Кырымда, вә Казакъта, вә Туранда хан булганнарның зикере; тугызынчы баб: дәхи Шибан хан әүлядыннан Хәрәзем мәмләкәтендә падишаһлык кылганнарның зикере. Бу тугыз баб гаҗәеп мөнасиб төште. Аның өчен хакимнәр әйткәннәр, һичбер нәрсәнең мәртәбәсе тугыздан югары булмас, ниһаяте тугыз булыр, дәю.

# Әүвәлге баб

### Ходай Тәгалә Адәм галәйһиссәламне яратканының зикере

Ходай Тәгалә Адәмне яратырга теләгәндә Җәбраил галәйһиссәламгә боерды: җир йөзеннән, барып, туфрак алып килергә. Ул җир йөзенә килеп туфрак алганда, җир хәл[1] теле илән аннан: «Ни эшләргә килдең?» — дип сорады. Җәбраил вакыйганы бәян кылгач, җир аңа Тәңре Тәгалә исеме илән ант итте: киләчәктә Адәм балалары күп булганнан соң, бере кяфер, вә бере гасый[2], вә бере залим, вә бере гөнаһкяр булырлар, анларны Ходай Тәгалә газап кылыр. Мин Тәңре Тәгаләнең газыбына[3] вә газабына дучар булмага теләмимен, дигәч, Җәбраил, туфрак алмый кайтып, Ходай Тәгаләгә җирнең гарызын[4] җиткерде. Аннан соң Микаил галәйһиссәламне җибәрде, ул һәм, кайтып килеп, шул сүзне әйтте, аннан соң Исрафил галәйһиссәламне җибәрде, ул һәм, кайтып килеп, ишеткәнен гарыз кылды. Аннан соң Газраил галәйһиссәламне җибәрде, аңа һәм туфракны алмаска үтенде. Газраил әйтте, Тәңренең хөкеме синең ялварып тормаганнан вә хәтереңне сындырмактан артыктыр, дип. Хәзерге вакыттагы Кәгъбәтулла өстендә торган урыннан туфракны алды, шуның өчен инсанның әрвахын[5] алмакны Газраилгә хәвалә кылды[6]. Аннан соң Ходай Тәгалә кодрәт кулы илән ул туфракны камыр кылып, Адәмнең сурәтен ясап, утыз тугыз көн Мәккә илән Таифәнең арасында куйды. Кырык көн булганда аңа җан бирде. Иблиснең Адәмгә сәҗдә кылмаганы вә Адәмнең оҗмахка барып янә кайтып дөньяга килгәне айдан рушан вә кояштан мәшһүррәктер, мең ел бу дөньяда торып, теге дөньяга китте. Адәм ләфызы[1] гарәп теледер. Гарәпләр җирнең кыртышын «адим» диләр. Газраил туфракны җирнең эченнән алмады, бәлки кыртышыннан, ягъни тышкы катыннан алды, шуның өчен инсанны Адәм диделәр, ләкабе[2] Сафиулладыр. Адәм үз угланнарыннан кырык мең кешене күреп үлде. Үләр алдыннан Шиш исемле углын үзенең урынына куйды, аннан соң Ходай Тәгалә Шишне пәйгамбәр кылды, ул тугыз йөз унике ел гомер сөреп җәннәт сараена китте. «Шиш» мәгънәсе «Һибәтулла» дигән мәгънәдәдер, ул дәхи үләр алдыннан углы Әнүшне урынына тәгаен кылды, ул, дәхи олуг атасы Адәмнең шәригате буенча гамәл кылып, тугыз йөз унике елда бу дарелфанидан күчеп дарелбакыйга китте. Әнүшнең мәгънәсе «садыйк» мәгънәсендәдер, ул дәхи үләр алдыннан углы Кыйнанны урынына насыйб итеп куеп, нәсыйхәт вә васыятьләр кылды. Кыйнан дәхи сигез йөз кырык ел атасы юлында йөреп, углы Мөһляилне урынына утыртып, Тәңре Тәгалә дәргаһына[3] юнәлде. Мөһляил заманында Адәм фәрзәндләре күбәйделәр. Мөһляил Бабел икълимендә[4] бер шәһәр салды, исемен Сус куйды, там[5] өйләр вә гайре биналар салдырды вә кәндләр[6], кальгалар кылдырды, аннан элгәре өйләр юк иде, тауларның куышында вә чоңгыллар ышыгында утыралар иде, илгә хөкем кылды: җир йөзенә җәелергә вә һәр җирдә муафикъ җир табылса, иген игәргә вә шәһәрләр, авыллар салырга. Халык аның фәрманы буенча эш кылдылар. Мөһляил, тугыз йөз егерме ел бу җиһанда торып, теге җиһанга сәфәр кылды, вафаты алдыннан углы Бирдне үз урынына утыртты. Бирд дәхи, тугыз йөз алтмыш ел яшәп, углы Әхнухны үз урынына калдырды. Ул дәхи атасы артыннан китте, сиръяный теле илән исеме Әхнух иде.

Гыйльме дин, вә хөкем, вә тыйбтан күп дәрес әйтер иде, ул сәбәптән гарәп аны Идрис дип атады. Ходай Тәгалә аны үз заманындагы халыкка пәйгамбәр итеп җибәрде, сиксән ике ел пәйгамбәрлек кылып, халыкны тугры юлга өндәде. Аннан соң Тәңренең әмере илән Газраил килеп, Идрис галәйһиссәламне биһишткә[1] алып очты. Ул көннән бу вакыткача биһиштә мәкам[2] тотадыр. Идрис биһишткә барганнан соң, углы Мәтәвешләх атасы урынында утырып, гадаләт[3] үзрә хөкем кылмак илән мәшгуль булды. Гомеренең саны мәгълүм имәс, күп еллар үткәннән соң, углы Ләмәкне урынына утыртып, үзе ахирәткә кадәм кылды[4]. Ләмәк һәм бу дөньяда күп еллар торды, әмма гомеренең хисабы мәгълүм имәс, ул дәхи вафаты алдыннан углы Нухны урынына утыртты. Ул ике йөз илле яшенә җиткәндә, Ходай Тәгалә аны пәйгамбәр кылып үз заманындагы халыкка җибәрде. Җиде йөз ел халыкны мөселманлыкка тәргыйб кылды[5]. Ир вә хатын сиксән кеше иман китерделәр, җиде йөз ел дөнья тулы халыкка йөреп, Тәңрегә иман китерегез, дигәндә, сиксән кемсәдән артык иман китермәгәннәренә бик ачугы килеп бәддога кылды. Җәбраил галәйһиссәлам килеп әйтте, Ходай Тәгалә синең догаңны кабул кылды, фәлән вакытта барча җир йөзендәге халыкны суга гарык кылмак булды, көймә ясасын, дип әмер кылды, көймәне ничек ясарын өйрәтте. Нух пәйгамбәр үзенә иман китергән кешеләр илән көймә ясады. Аннан соң җирдән су чыкты вә асманнан[6] ягъмур яуды. Нух пәйгамбәр очар кошлардан вә аяк илән йөргән җанварлардан һәркаюсыннан бер мөзәккәр[7] вә бер мөәннәс[8] алды вә үзенә иман китергән кемсәләр илән көймәгә керде, вә башка җир йөзендәге җан ияләре һәммәсе суга гарык булды. Аннан соң Аллаһы Тәгаләнең әмере илән җир суны үзенә тартты. Гыйрак йортында Мосул шәһәре якынында Җөдә тавында көймә туктады. Рәҗәб аеның әүвәл көне көймәгә менгәннәр иде, мөхәррәм аеның әүвәл көнне алты ай ун көн булганда, көймәдән чыгып, тау төбендә утырдылар, барчалары шат булдылар. Нух пәйгамбәр, вә кауме, вә өч угыллары, вә өч килennәре — һәммәсе туфан һәлакәтеннән хәляс булдылар[9].

Берничә вакытлар үткәч, үзләре барчасы да Хак рәхмәтенә киттеләр. Аннан соң Нух пәйгамбәр өч углының һәркаюсын бер җиргә җибәрде. Хам исемле углын Һиндстан йортына җибәрде, Сам намлы углын Иран зәмингә[1] җибәрде вә Яфәс атлы углын котып шимале тарафына җибәрде. Дәхи өчесенә дә әйтте ки, Адәм балаларыннан сез өчегездән гайре кеше калмады, инде өчегез өч йортта торыгыз, һәркайчан бала-чагаларыгыз күбәйсә, ул җирне вә мәмләкәт итеп утырыгыз, диде. Яфәсне бәгъзеләр пәйгамбәр вә бәгъзеләр

пәйгамбәр имәс диделәр. Яфәс атасының хөкеме илән Җөдә тавыннан китеп, Идел вә Җаек суларының буйларына барды, ике йөз илле ел анда торып, үзе вафат булды.

Әүляде бәсияр[2] күп иде. Үзеннән сигез углы калды. Аларның исемнәре болардыр: Төрек, Хазар, Саклаб, Хытай, Кимәри, Тарих, Җапун, Манҗур. Яфәс вафат булыр алдыннан олуг углы Төрекне урынында утыртып, башка угылларына әйтте ки: «Төрекне үзегезгә падишаһ белеп, аның сүзеннән чыкмагыз». Төреккә Яфәс угланы дип ләкаб куйдылар. Бәсияр әдәпле вә гакыллы кеше иде, атасыннан соң күп җирләрне гизеп вә күреп йөрде, шуннан соң бер җирне хушлап, анда утырды. Бу чакта ул җирне Эссе күл диләр. Мичле өйне ул чыгарды. Төрекләрдә бәгъзе хас булган рәсем[3] вә гадәтләр аннан калды. Төрекнең дүрт углы бар иде. Әүвәл — Түтәк, икенче — Чигил, өченче — Барсаҗар, дүртенче — Әмлак. Үләр алдыннан Түтәкне үз урынына падишаһ кылып, кайтмас сәфәргә чыгып китте. Түтәк гакыллы вә дәүләтле яхшы падишаһ иде. Төрек эчендә күп рәсемнәрне ул пәйда кылды. Гаҗәм падишаһларның әүвәле Каюмарс илән могассыйр[4] иде. Көннәрдән бер көн ауга чыкты. Бер киек үтереп, кәбаб[5] кылып җийеп утырганда, кулыннан бер калҗа ит җиргә төште, аны алып җийгән иде, авызына бер тәм килде, аның өчен ул җир тозлы иде, ашка тоз салмакны ул чыгарды, бу файдалы рәсем аннан калды. Ике йөз ел гомер сөреп үткәргәннән соң, Илҗә ханны үз урынына утыртып, ахирәт сәфәренә китте. Илҗә хан дәхи күп еллар падишаһлык кылып, ашларны ашап, яшьләрне яшәп, атасы киткән җиргә китте. Үләр вакытында Диб Бакуй ханны урынына утыртты. «Диб»нең мәгънәсе — «җир». «Бакуй»ның мәгънәсе «ил олугы» дигән сүздер. Ул, дәхи күп еллар падишаһлык кылып, дусларының көлгәнен вә дошманнарының егълаганын күреп вә сөенеп, күп сәнәләр падишаһлык дәверен сөрде. Үләр алдыннан Киюк ханны урынына калдырып, барса кайтмас дигән шәһәргә китте. Киюк хан дәхи атасы тәхетендә утырып, ничә еллар гаделлек илән хөкем кылып, углы Әленҗә ханны урынына куеп, халык бара торган җиргә кадәм кылды. Әленҗә хан күп сәнәләр халыкка падишаһлык кылды. Нух галәйһиссәлам заманыннан бу Әленҗә ханның заманынача барча Яфәс әүляды мөселман иделәр. Әленҗә заманында йорт абад[1] вә ил дәүләтле булды. Үзбәкнең мәсәле бар: «Эт симерсә, иясен кабар» дигән сүз; шул заманда һәр кеше, бер сөйгәне үлгән булса, углы вә кызы вә ага-энесе кеби аңа охшатып өендә курчакны ясап куяр булдылар. Бу безнең фәләннең сурәте дип, аны сөяр булдылар. Ашның әүвәлен аның алдына куеп, ашның алдында һәм ахырында аны үбәр булдылар вә, йөзләрен һәм күзләрен сөртеп, аңа баш орып сәҗдә кылыр булдылар. Шулай кыла-кыла, бөтпәрәстлек[2] пәйда булды.

Әленҗә ханның ике игез туган угыллары бар иде. Олуг углының исеме Татар, кечесенең исеме Могулдыр. Әленҗә хан картайгач, илен ике углына бүлеп бирде. Ошбу икесе бер-бере илә яманлык кылмый яхшылык илән дәүләт сөреп гомер кичерделәр. Әүвәл Татарны әйтим, аннан соң, Тәңрем боерса, Могулны әйтерем.

# Икенче баб

## Татар ханның зикере

Үзеннән башлап җиде углынача падишаһлык кылдылар. Татар хан күп еллар падишаһлык кылып вафат булды, углы Бука хан атасы урынына калып, күп еллар падишаһлык кылып, ахирәт йортына юнәлде. Аннан соң углы Иленчә хан атасы тәхетенә утырып, берничә еллар илгә хөкүмәт кылып, дарелбакыйга рихләт әйләде[1]. Аннан соң углы Атлы хан падишаһ булып, берничә еллар гыйш вә гошрәт[2] кылып, атасы артыннан теге дөньяга газим сәфәр кылды. Аннан соң углы Атсыз хан атасы урынына утырып, берничә еллар яуны җиңеп, ауны аулап, атасы артыннан мәңгелек йортка китте. Аннан соң углы Урду хан падишаһ булып, берничә еллар буза вә кымыз эчеп, куркак хытайны печеп, көймәсез суларны кичеп, атасы артыннан китте. Аннан соң углы Банду хан падишаһ булды, берничә еллар падишаһлык кылып, Могул илән Татар падишаһ булганнан соң, Табайду заманынача һич араларында низаг юк иде. Могул угланнары — үз илләренә вә Татар угланнары үз илләренә падишаһлык кылырлар иде. Байду фикерсез, уйсыз егет булды. Могул хан угланнары илән яу булды, дәхи аларның илләрен чаба башлады. Ул арада әҗәл килеп, якасыннан тотып, атасы катына алып китте. Аннан соң углы Сөенеч хан атасы урынына утырды. Сөенеч хан заманында Могул илән Татар илләре арасында дошманлык уты шулкадәр янды ки, әгәр Аму-Дәрьяның суын салсалар, сүндермәс иде, күбрәк вакытта могул җиңәр иде. Ходай Тәгалә Сөенеч ханның кылган эшләрен могул ханнары соңында зикер итсәм кирәк.

## Могул ханның зикере

Чыңгыз ханның дөньяга килгәненчә Могул ләфызы, асылда, «моң ул» булган, гавамның теле килмәгәннән бара-бара «могул» дигәннәр. «Моң»ның мәгънәсене барча төрек белерләр — «кайгы» мәгънәсендәдер, «ул»ның мәгънәсе «садәдил»[1] мәгънәсендәдер, ягъни «кайгылы садә» дигән мәгънә чыгар. Бу таифәдән[2] тугыз кеше падишаһлык кылдылар. Әүвәле — Могул хан, ахыры — Ил хандыр. Шәрәфетдин Йезди «Зафәрнамә»сенең мөкаддәмәсендә[3] әйтәдер ки: төрек халкының эчендә гадәт һәрнәрсәне тугыз кылмак. Ул тугызны могулның тугыз ханы санывннан алмыштыр, дәхи китапның башында мәзкүр булды ки, Хак Тәгалә яраткан нәрсәләрен дә, мәртәбәләрен дә, һичнәрсәнең мәртәбәсен  тугыздан ашу яратмады. Могул хан күп еллар падишаһлык кылды. Дүрт углы бар иде. Олугы — Кара хан, икенче — Үз хан, өченче — Күз хан, дүртенче — Күр хан. Могул хан вафаты алдында олуг углы Кара ханны үз урынына тәгаен кылды.

## Кара ханның зикере

Атасыннан соң тәмам илгә падишаһ булды. Эр тавы вә Кер тавы; бу заманда аларны Олуг Тау, Кече Тау диләр. Анда җәйләр иде, кыш булганда Караком вә Сыр-Дәрья якасында кышлар иде. Кара хан заманында ил шулкадәр каралган иде ки, араларында Ходаны танып бирелгән бер мөселман калмады.

## Угыз хан дөньяга килгәненең бәяны

Кара ханның олуг хатыныннан бер угыл туды. Күрергә бик гүзәл, ай илән кояш кеби йөзе нурлы иде. Өч тәүлек анасын иммәде, һәр кичне ул углан анасының төшенә иңеп әйтә иде: «И ана, мөселман бул, әгәр мөселман булмасаң, үлсәм үләрем, синең имчәгеңне иммәм», — дир иде. Анасы углының хәтерен калдырмады, Тәңре Тәгаләнең берлегенә иман китерде, аннан соң ул углан сөтне имде. Анасы күргән төшен һәм мөселман булганын һичкемгә әйтмәде, яшерде, аның өчен төрек халкы Яфәстән Әленҗә хан заманынача мөселман иделәр. Әленҗә хан падишаһ булгач,  халыкның башы вә малы күп булды, дәүләткә мәгърур булдылар, Тәңрене оныттылар вә барча ил кяфер булдылар. Кара хан заманында кяферлектә шулкадәр мөкайяд[1] иделәр ки, әгәр атасының мөселман булганын ишетсә, углы үтерер иде вә углының мөселман булганын белсә, атасы үтерер иде. Ул вакытта Могулның  рәсеме шулай иде ки, углан бер яшенә җитмәенчә аңа ат куймаслар иде. Кара ханның мәзкүр углы бер яшенә  җиткәч, илгә яр-хәбәр салдырды, бик олуг туй кылды. Туй көнне угланны мәйданга китереп, бәкләренә әйтте ки: «Безнең бу углымыз бер яшенә җитте, инде моңа исем куегыз», — дип. Бәкләр җавап биргәннән мөкаддәм[2] углан әйтте: «Минем исемем Угыздыр», — диде. Бәете шул:

Бер яшәр углан анда рәван[3]
Килеп телгә, диде, белегез гаян[4]:
Атымдыр Угыз хәсыр вә намдыр[5],
Белегез якын барча әһле һөнәр.

Туйга килгән олуг-кечек һәммәсе угланның бу сүзенә таң-гаҗәпкә калдылар, дәхи әйттеләр: «Бу углан үзе исемен әйткәч, аннан артык исем булырмы?» — дип. Исемне Угыз куйдылар. Дәхи әйттеләр: «Бер яшәр угланның болай сүзләшкәнен һичбер заманда беркем дә ишеткәне вә күргәне юктыр, — дип, моны әрүм[6] итеп әйттеләр ки — озак гомерле, олуг дәүләтле вә эшләренең очы озайган вә яны җәелгән булыр», — диделәр. Угызның теле чыгып йөргәндә «Алла, Алла» дип әйтер иде. Һәркем ишетсә әйтерләр иде ки, углан булганга теле килмәенчә мондай ләгатьләр илән лыкырдыйдыр, дәю. Аның өчен ләгате Алла гарәп теледер. Могулның һичбер атасы гарәп телен ишеткәне юктыр. Угызга Ходай Тәгалә тыйфел[7] вакытында вәлилекне[8] биргән иде. Аның күңеленә һәм теленә Алланың исмен саладыр иде.

Угыз буйга җитеп егет булгач, Кара хан энесе Үз ханның кызын алып бирде. Угыз кеше юкта кызга әйтте: «Барча галәмне, вә сине, вә мине яраткан бардыр, аның исеме Алладыр, аны бар бел вә бер бел, аның боергыныннан башка эшне кылма», — дигәч, кыз аны кабул итмәде. Шул заман аннан ихласы кайтып, кыздан башка ятты, кичләрдә башка ятып, көндезләрдә асла сүзләшмәс иде.

Берничә вакыттан соң Кара ханга әйттеләр ки: «Углыгыз яшь киленне сөймидер, сөймәгәнлектән алган көннән бирле бер җирдә ятмыйлар». Кара хан бу сүзне ишеткәч, дәхи бер энесе Күз ханның кызын алып бирде. Аңа һәм иман гарыз кылды, ул кыз һәм кабул кылмады, аның илән бер җирдә ятмады. Бу вакыйгадан берничә ел үткәннән соң Угыз хан ауга чыгып кайтып килә иде, күрде ки: суның якасында берничә кызлар кер юалар. Атасының энесе Күр ханның кызы һәм боларның эчендә иде. Кызга кеше җибәреп сүзләшмәккә серем заһир булыр[1] дип курыкты. Шуның өчен кызны бер читкә чакырып, ант биреп әйтте ки: «Атам миңа ике кыз алып бирде, аларны сөймәгәнемнең сәбәбе будыр ки, мин мөселман, алар кяфирәләр,

ничаклы, мөселман булыгыз, дип әйтсәм дә, кабул кылмадылар. Әгәр син мөселман булсаң, сине алыр идем», — дигәч, кыз: «Син нинди юлда булсаң, мин шул юлда булыр идем», — диде. Аннан соң Угыз хан атасына әйтте, атасы Күр ханның кызына олуг туй кылып, Угыз ханга алып бирде. Ул мөселман булды. Угыз хан аны бик сөяр иде.

Моннан соң күп еллар үтте. Беркөн Угыз хан ерак җиргә ауга китте. Кара хан барча карендәш-ыругын вә киленнәрен чакырып аш бирде. Шул мәҗлестә сүздән сүз китеп, хатыныннан сорады ки: «Моның сәбәбе нидер, Угыз соңгы хатынын сөя, әүвәлге ике хатынын сөймидер?» Хатын әйтте: «Мин белмимен, киленнәр яхшырак белерләр», — диде. Хан киленнәрдән сорады. Олуг килен әйтте: «Углыгыз мөселман булган, без икебезгә, мөселман бул, диде, әмма кабул кылмадык. Кече киленегез мөселман булды, шуңа күрә углыгыз аны бик сөя», — диде. Кара хан, бу сүзне ишеткәч, бәкләрне чакырып киңәште, сүзләре шуңа беректе ки, Угызны ауда йөргәндә тотып үтерәләр. Кара хан илгә кеше җибәрде, тиз килсеннәр, ауга чыгабыз, дип. Бу сүзне Угыз ханның кече хатыны ишетеп, Кара ханның кылган киңәшләрен һәммәсен әйтеп, Угыз ханга бер кеше җибәрде. Угыз хан, бу сүзне ишеткәч, илгә кешеләр җибәрде. «Атам гаскәр тартып мине үтермәгә киләдер, минем ягымнан торган миңа килсен, атам ягыннан торган атама барсын», — диде.

Илнең күбесе Кара ханга барды вә азрагы Угыз хан катына бардылар. Кара ханның энеләренең күп угланнары бар иде. Аларны Кара ханнан аерылырлар дип һичкемнең күңеленә килмәс иде, аларның һәммәсе дә Угыз хан катына килделәр. Угыз хан аларга уйгур дип исем куйды. Уйгур —төркидер, «барчага мәгълүм ябышучы» мәгънәсендәдер. Мәсәлән, әйтәләр, сөт оеды, дип, сыек хәлдә берсе-берсеннән аерыла иде, катык булганнан соң бере-беренә ябышты. Вә дәхи әйтәләр ки, имамга оеды, имам утырса утыра, торса торадыр, бәс, ябышканы булмыйммы? Алар килеп, Угыз ханның итәгенә куллары илән мөхкәм[1] ябышкач, хан аларга «уйгур» диде, «ябышучылар» дигән сүздер. Кара хан илән Угыз хан саф тартып сугыштылар, Ходай Тәгалә Угыз ханны галиб[2] кылды, Кара хан качты. Орышта Кара хан башына ук тиде, вә кем атканны белмәделәр, шул җәрәхәттән вафат булды. Угыз хан атасы тәхетенә утырды.

## Угыз ханның хан булганының зикере

Угыз хан илнең барчасын мөселманлыкка дәгъвәт кылды, мөселман булганнарын хөрмәтләде, сыйлады, булмаганнарын чапты, үзләрен үтерде, угланнарын әсир кылды. Ул вакытта Кара ханга тәгаллекъле[3] илдән башка илләр күп иде. Бер олуг илнең бер башка падишаһы бар иде, кечек илләр аларга кушылырлар иде. Кара ханның мөселман булган илләре Угыз ханга кушылды, мөселман булмаганнары үзгә ханнарга барып кушылдылар. Угыз хан һәр елда Могул йортында утырган илләр илән сугышыр иде һәм галиб булыр иде. Шулай итә-итә ахирел әмер[4] барчасын алды вә качып котылганнары татар ханына барып сыендылар. Татар халкы ул вакытта Чөрчеткә якын утырыр иде. Чөрчет дигән җир олуг йорттыр, шәһәрләре вә кәндләре күп булып, Хытайның Тимер Казык йолдызы тарафында иде. Һинд вә таҗик кавемнәре аны «чин» дип әйтәләр. Угыз хан барып, татарны чапты, татар ханы күп гаскәр илән килеп сугышты. Угыз хан җиңеп, гаскәрен кырды. Угыз хан гаскәренең кулына шулкадәр күп мал төште ки, хәтта йөкләп алып китәргә күлүк җитмәде. Бер яхшы остаз кеше бар иде, ул фикер йөртеп арба ясады. Аннан күреп һәммә кешеләр арба ясап, өлҗәдән[5] тигән малларын йөкләп кайттылар. Арбага Кангъ ат куйдылар, аннан элгәре аты да юк иде, үзе дә юк иде. «Кангъ» дип шуңа күрә әйттеләр ки, йөргәндә «кангъ-кангъ» дигән кеби тавыш чыгар иде. Аны ясаган кешене Кангълы диделәр, барча Кангълы иле ул кешенең угланларыдыр. Угыз хан җитмеш ике елгача үз сөяге, үз төркисе могул, татар илән сугышты. Җитмеш өч ел булганда, һәммәсен үз авызына каратып, җиңеп, барчасын мөселман итте. Аннан соң барып, Хытайны алды вә Чөрчетне һәм Тангутны алды. Тангутны таҗиклар Тибет диделәр. Аннан соң барып Кара-Хытайны алды. Ул һәм олуг йорттыр, кешесенең чырае һинди кеби карадыр, Һиндстан илән Хытайның арасында вә Мохит диңгезенең якасындадыр, Тангутның кыш вакытында кояш чыгышында вә яз вакытында төшлектә вакыгдыр. Хытайның аргы ягында, диңгез якасында, биек таулар эчендә күп илләр бар иде, аның падишаһының исеме Итбрак дирләр иде. Аның өстенә атланып барды, орыштылар. Итбрак хан галиб булды, Угыз хан качты. Орышкан җирнең бире ягында ике олуг агым су бар иде, ул, ике суның арасында берничә көн торып, качкан гаскәренең алдын вә артын җыйды. Олуг падишаһларның гадәтләре шул иде ки: ерак сәфәргә барганда үзе һәм якын бәкләре өй җәмәгатьләрен бергә ияртеп баралар иде. Угыз ханның бер бәге өй җәмәгатен алып барган иде. Үзе орышта үлде, хатыны котылып, ике суның арасында хан артыннан җитте. Йөкле иде, тулгагы тотты: көн суык иде, керергә өй таба алмады, бер черек агач эченә кереп углан тудырды, моны ханга мәгълүм кылдылар. Хан әйтте, моның атасы безнең алдыбызда үлде, тәрбияләп асрарга кешесе юк, дип, үзенә угыл итте, исемен Кыпчак куйды. Кадим төрек телендә эче куыш агачны «кыпчак» дирләр иде, шуның өчен, ул

углан агач эчендә туды дип, исемен Кыпчак куштылар. Бу чакта һәм эче куыш агачны «чыпчак» дирләр, кара халыкның теле килмәгәннән «каф»ны «чим» укыйлар, шул кыпчакны чыпчак дип тәкәллем кылалар[1].

Ул угланны хан үз кулында асрады. Егет булганнан соң, урыс-улак һәм маҗар вә башкорт илләре яу иделәр. Кыпчакка күп ил вә гаскәр кушып ул якка — Дон вә Идел суларының буйларына җибәрде. Дон вә Идел икесе һәм олуг суларның исемнәредер. Өч йөз ел ул җирләрдә падишаһлык кылып утырды, барча Кыпчак иле аның нәселеннәндер. Угыз хан заманыннан Чыңгыз хан заманынача Дон вә Идел һәм Җаек — бу өч суларның буйларында кыпчактан үзгә ил юк иде, дүрт йөз елгача ул җирләрдә утырдылар, аның өчен ул җирләрне Дәште Кыпчак диләр. Угыз хан Итбрак ханга җиңелгәннән соң унҗиде ел үткәч, дәхи атланып барып, Итбрак хан илән сугышып, басып, Итбрак ханны үтереп, йортын алды. Мөселман булганнарына тимәде, үз хәлләренә куеп, Тәңрегә иман китермәгәннәрен үтереп, угланнарын әсир кылып, кайтып өенә төште.

## Угыз ханның Туран вә Һиндстанга барганының зикере

Угыз хан тәмам Могул вә Татар иленең гаскәрен җәмгъ кылып[1], Теләш вә Сирамга килде. Ташкент, вә Сәмәрканд, вә Бохара падишаһлары саф тартып орыша алмадылар, олуг шәһәрләр вә мөхкәм кальгаларга бикләнделәр. Угыз хан Сирам вә Ташкентны үзе камап алды, Төркестан вә Әндиҗанга угылларын җибәрде. Алар, алты айда Төркестан илән Әндиҗанны алып, аталары хезмәтенә кайттылар. Угыз хан, мәзкүр вилаятьләрнең барчасына хакимнәр куеп, Сәмәрканд өстенә барды. Сәмәркандны алып, хаким куеп, Бохарага барды. Бохараны алып, Бәлхкә барды, Бәлхне һәм алып, Гур вилаятенең өстенә йөрде. Кыш көннәре каты суык иде. Гурның тауларына янә кар күп төшкәннән, гаскәр халкы үтәргә кыенсындылар — хан һичкем моннан калмасын дип хөкем кылды, соңра барып Гурны алгач, яз булды. Ләшкәрне[2] хисап кылды, берничә кеше ким килде, аларны сорады, һичкем белмәде. Берничә көннән соң ул кешеләр хан хезмәтенә бардылар, хан әхвәлләрен сорагач, әйттеләр ки: «Без ничә кеше гаскәр артыннан калыбрак киләдер идек, тау эчендә бер кичә хәтсез күп кар яуды, аның сәбәпле йөри алмый шул җирдә яттык. Атларыбыз вә төяләребез һәммәсе үлде. Яз булгач, җәяү киләбез», — диделәр. Хан ул җәмәгатькә Карлык ләкабен биреп, барча Карлык иле аларның нәселеннәндер. Аннан үтеп Кабул вә Газнинне алды, аннан Кашмир өстенә йөрде, ул вакытта Кашмирның падишаһы Егъма исемле иде. Кашмирның биек таулары вә олуг сулары күптер. Егъма шуңа таянып Угыз ханга баш салмады. Бер ел сугыштылар, ике тарафтан күп кешеләр тәлаф булды[3]. Гакыйбәт[4], Кашмирны алды һәм Егъманы үтерде, гаскәрен кател гам кылды[1]. Берничә вакыт анда торып, кайтып, Бадахшан аркылы Сәмәркандка килде, аннан Могулстанга кайтып өенә төште.

## Угыз ханның Иран, вә Шам, вә Мисыр тарафына барганының зикере

Бер ел йортта торып, икенче ел Иран сәфәренә чыгарга дип яр салдырды. Ничә еллык гамнәрен җыйсыннар, кирәк-яракларын әзерләсеннәр дип мәгълүм иттерде. Икенче ел атланып Теләш шәһәренә килде. Ханның гаскәре артында куйган кешеләре бар иде. Арыган вә ачыккан, адашкан вә шунлар кеби йөдәп калганнарны карап йөрергә тәгаен кылган иде. Ул кешеләр гаскәрдән аерылып калган бер өйлек кешене хан алдына алып килделәр. Хан ул кешедән: «Ничек болай артка калдың?» — дип сорады. Ул әйтте: «Көнлек ризкым азлыктан гаскәрдән артта калдым, хатыным хамилә[2] иде, тудырды, ачлык сәбәбеннән анасы сөте угланга җитмәде. Юлда килгәнемдә күрдем ки, бер шигал[3] коргаулны[4] алды. Бер күсәк илән шигалны суккан идем, коргаулны ташлап качты, аны алып, кәбаб кылып хатыныма биреп торганымда, арттан йөрткән кешеләрегез очрап алып килделәр», — диде. Хан ул фәкыйрьгә ат, вә азык, вә мал биреп, гаскәргә «барма, кал ач» диде. Барча Калач иле шул кешенең нәселеннәндер, аны бу вакытта Халаҗ диерләр, Мавәраәннәһердә елга аръягында күптер, Аймак иленә кушылмыштыр, Хорасан вә Гыйракта да һәм күп булыр.

Угыз хан Теләштән үтеп, Сәмәрканд вә Бохарага килеп, Аму-Дәрья суыннан үтеп, Хорасанга барды. Ул чакта Иран йортында яхшы падишаһ юк иде. Каюмарс үлеп, Һушәңне һәнүз падишаһ итеп күтәрмәгәннәр иде. Гарәб андый вакытны «мөлүк таваиф» дир, мәгънәсе будыр ки: һәрбер илдә бер түрә булыр димәк. Төрекләр андый вакытны «өй башына кара хан» дирләр, мәгънәсе һәр өйдә бер хан димәк булыр, ул чакта Иран йорты шундый иде: Хорасанны алды, аннан үтеп, Гаҗәм вә Гыйрак-Гарәб, вә Азәрбайҗан, вә Әрмән, вә Шам, вә Мисыргача алды. Бу әйтелгән вилаятьләрнең берничәсен үзенә каратты. Угыз хан Шам вилаятендә торганда яшертен бер нөкеренең[5] кулына бер алтын җәя вә өч укны бирде, дәхи әйтте: «Җәяне кояш чыгышында бер чүлдә, кеше аягы җитмәс җирдә, туфракка күмеп, бер очын чыгарып куй, укларны кояш

батышы тарафына илтеп җәяне ничек куйсаң, моны шулай куй», — диде. Ул кеше боерылганча гамәл кылды.

Бер ел үткәч, өч олуг углы — Көн, Ай, Йолдызны чакырып әйтте: «Ят йортка килдем, эшем күп, ау ауларга кулым җитмәйдер. Кояш чыгышында фәлән чүлнең авы күп, имеш, дип ишеттем, үз нөкерләрегез илән анда барып киек сугып килегез», —диде. Аннан соң өч кече углы — Күк, Таг, Диңгез — бу өчесен чакырып, агаларына әйткән сүзне әйтеп, көн батышы тарафына җибәрде. Берничә көннән соң олуг угланнары бер алтын җәя илән күп ауны хан алдына китерделәр вә өч кечек угланнары дәхи өч алтын ук илән китерделәр. Ул ауларның итләренә күп итләр вә төрле ашларны кушып, халыкны чакырып, җәянең һәм укның табылганнарын ырым кылып[1] үзләренә кайтарып бирде. Өч олуг углы җәяне сындырып бүлештеләр, өч кечек углы һәркайсысы бер укны алдылар. Алган вилаятьләрдә күп еллар торып, дошманнарны һәлак кылып вә дустларны сыйлап, башы Сирам, аягы Мисыргача алган вилаятьләренең һәммәсенә хакимнәр куеп, кайтып үз йортына төште.

## Угыз ханның, йортына кайтып, туй кылганының зикере

Угланнарым вә халкым илән аман исән йөреп кайттым дип, әсбапларын әзерләп, бер мичле сарай салдыртты. Барча агачларының башына алтын каплатты. Ләгыль, вә якут, вә зәмрут, вә фирүзә, вә дөррә[2] илән мөрәсегъ кылдырды[3]. Бу бәетне ул өйне тәүсыйф кылып[4] әйткәннәр. Бәет:

Бер өй тикте алтындыйн ул шәһри яр.
Ким ул өйү фәләк өендин кылды гарь.
Тугыз йөз елкы вә тугыз мең куй үлтерде.

Болгарыйдыйн туксан тугыз хәвыз[5] кылдырды. Тугызыга гарәкъ[6], туксаныйга кымыз тутыртты. Барча нөкерләрен чакырып кертте. Ул алты углына күп вәгазь вә нәсыйхәтләр әйтеп, йортлар, вә шәһәрләр, вә илләр, вә ингамнар[1] бирде, бу бәетләрне аның тәүсыйфында әйтмешләр. Бәет:

Угыз кыйлды ул туйда җыр гамәше[2].
Бу алты углыны сөю гамәше.
Болар күрсәтеп йөрде мәрданәлек[3].
Ата бирелә күп төрле фәрзанәлек[4].
Атага бәс кылдылар.
Ярлык, орыш көнендә барчасы барлык.

Аннан соң барча бәкләренең аткан, вә чапкан, вә кылган хезмәтләренә лаек шәһәрләр вә сәрхәдләр[5], вә кәндләр, вә ингамнар бирде. Дәхи угланнарына: «Инде сез өч олугыгыз алтын җәя табып китердегез, дәхи аны бозып бүлештегез, сезнең исемегез Бозук булсын, сездән булган угланнарны һәм та кыяматкәчә Бозук дисеннәр. Өч кечек угылны вә анлардан булган угланнарны бу көннән та кыямәт булганча Өчук дисеннәр. Җәяне вә укларны табып китердегез, ул кешедән булмады, Ходайдан булды. Бездән борын үткән халыклар җәяне падишаһ урынында белеп, укны илче урынында йөрткәннәр. Аның өчен җәя укны кайсы тарафка тартып җибәрсә, ук ул тарафка барыр. Имде мин үлгәннән соң, Көн хан минем тәхетемдә утырсын. Аннан соң Бозук нәселеннән һәркем кабил булса[6], халык аны падишаһ кылсыннар. Дөнья ахыры булганчы Бозукның бер яхшысы падишаһ булсын, үзләре уңга утырсыннар, Өчуклар сул булсыннар, өйнең сул тарафына утырсыннар, дөнья ахыры булганчы бәклеккә разый булсыннар», — дип әйтте. Угыз хан, йөз уналты ел падишаһлык кылып, Хак рәхмәтенә китте.

## Угыз ханның олуг углы Көн ханның падишаһлыгының зикере

Угыз ханның уйгур таифәсенең аксакалының углы бар иде, исеме Иркол Хуҗа иде. Угыз хан тәхетендә утырып, үлгәнче вәзире, вәкиле ул иде. Гакыллы вә мәгърифәтле кеше иде вә Көн хан дәхи аны вәзир кылып, үзе үлгәнче аның сүзеннән чыкмады. Иркол Хуҗа бәк озак яшәде.

Көннәрдә бер көн хан ялгыз утырганда әйтте: «Атаң йөз дә уналты ел җәйнең эсселегендә күләгәдә утырмый вә кышның суыгында өйдә тормый, кылыч орып күп йортларны ачып сезнең алтыгызга куеп китте. Әгәр сез алтыгызның һәм сездән булган угланнарыгызның барчагызның авазы бер булса, озак еллар вә күп көннәр бу йортлар кулыгыздан чыкмас, әгәр авазларыгыз бер булмаса, алган йортыгыз да һәм үз йортыгыз да китәр вә малыгыз да, җаныгыз да тәләф[1] булып чыгарсыз», — диде. Көн хан әйтте: «Атама киңәш

бирә торган идегез, атам урынына инде атам сез буласыз, сез ни эшне мәгъкуль күрсәгез, мин аны кылырым», — диде. Иркол хуҗа әйтте: «Угыз ханнан күп йортлар вә күп шәһәрләр вә күп илләрдә үлек вә терек маллар калыптыр. Сез алты угылның һәрберегездән дүрт угыл булып, үзегездән башка егерме дүрт падишаһзадә мәүҗүдтер[2]. Бу кадәр ишле ханзадәләр арасында иттифакыгыз[3] китмәгәй иде дип куркамын». Бәет:

Алтыннар һәм йортлар, яхшы кием, көтүдәге маллар
Аерым тамга белән тамгалансын.
Һәркемнең үзбилге һәм тамгасы булсын.
Ул тамгалар исем һәм кушаматны алыштырыр.
Шуның буенча һәрберсе үзенә тияр өлешен белер.
Кеше әйберенә сузылудан үзен тыяр.
Үз нәселен сездән алып баручылар
шушы кагыйдә буенча яшәсеннәр.

Көн Иркол хуҗаның сүзен тыңлаган, картның киңәшләрен мактаган.

Көн хан Иркол хуҗа сүзен кабул кылып, олуг мәҗлес корды. Яхшы вә яман халык барчасы килгәннән соң, ул Угыз ханнан калган вилаятьләр, вә илләр, вә үлек, һәм терек маллар барчасы бу әйтелгән падишаһзадәләрнең олугына — олугча вә кечесенә кечечә бирде. Бу егерме дүрт угыл никахлы хатыннардан иде. Бонлардан башка кече хатыннардан булган угланнар дәхи күп иде. Аларга һәм хәлләренә лаек нәрсәләр бирде. Аннан соң Угыз хан ясаткан алтын өйне тиктерде[4], вә дәхи уң якка алты ак өркә[5] вә сул якка алты ак өркә тиктерде, вә дәхи уң якта башына алтын туг[1] беркеткән кырык колач агачны кадатты, вә сул якта башына көмеш тук беркеткән кырык колач агачны кадатты. Соңра хан ярлыгы илән Бозук угланнары вә нөкерләре илән алтын тугны ат илән чабып, Өчук угланнары вә нөкерләре илән көмеш тугны ат илән чабып аттылар һәм ордылар, орган кешеләргә күп әнгамнар бирде. Көн хан атасының рәвешенчә гамәл кылып, тугыз йөз елкы вә тугыз мең куй бугазлатты, тугыз болгар хәвызига буза салды вә туксан болгар хәвызига кымыз салды, кырык кичә-көндез гыйш вә гошрәт кылдылар.

## Угыз ханның угланнары, нәбирәләренең[2] исемнәренең зикере

Угыз ханның алты углы бар иде. Олугының аты Көн хан, икенче — Ай хан, өченче — Йолдыз хан, дүртенче — Күк хан, бишенче —Таг хан, алтынчы — Диңгез хан. Бу алтының һәркайсының дүртәр углы бар иде. Болар олуг хатыннан туганнар иде вә кече хатыннан булган угыллары дәхи бар иде, вә аларны һәм әйтербез. Көн ханның дүрт углы бар иде. Беренче — Калый, икенче — Баят, өченче — Алка-Өйле, дүртенче — Кара-Өйле. Ай ханның дүрт углы бар иде. Олугның аты Язир, икенче — Ябир, өченче — Дудырга, дүртенче — Дүкәр. Йолдыз ханның дүрт углы бар иде. Әүвәле — Үшәр, икенче —Кырнык, өченче — Бикдәли, дүртенче — Каркыйн. Күк ханның дүрт углы бар иде. Беренче — Баиндар, икенче — Биҗнә, өченче — Җавылдар, дүртенче —Җабни. Тау ханның дүрт углы бар иде. Әүвәле — Салур, икенче — Имир, өченче — Алаюнәтле, дүртенче — Өркир. Диңгез ханның дүрт углы бар иде. Беренче — Икдәр, икенче — Бәкдуз, өченче — Ава, дүртенче — Кынык.

Угыз ханның бу алты углының һәркаюсының мәзкүрләрдән башка яшь хатыннан янә дүртәр угыллары бар иде, әммә кайсы каю атаның углы икәне мәгълүм түгел, исемнәре болардыр: Көнә, Күнә, Турбатлы, Кирәйли, Солтанлы, Уклы, Күкле, Суҗли, Хөрәсәнле, Йортчы, Җамчы, Торумчы, Комый, Суркый, бу вакытта аны «Сурхый» дирләр, Куырчык, Сорачык, Карачык, Казгорт, Кыргыз, Тегәнләлә, Мәрдәшуй, Саир.

Угыз ханның егерме дүрт нәбирәсенең мәгънәләре: Калый — «мәхкәм» мәгънәсендә, Баят — «дәүләтле» мәгънәсендә, Алка-Өйле — «мауфикъ» мәгънәсендә, Кара-Өйле — «һәркайда утырса, мичле өй илән торучы» мәгънәсендә, Язир — «илләр агасы» мәгънәсендә, Ябир — «алдына нәрсә очраса, шуны егар» мәгънәсендә, Дудырга — «йорт алмакны һәм аны сакламакны белүче» мәгънәсендә, Дүкәр — «түгәрәк» мәгънәсендә, Үшәр — «эшне тиз эшләүче» мәгънәсендә, Кырнык — «букә»[1] мәгънәсендә, Бикдәли — «сүзе яхшы» мәгънәсендә, Каркыйн — «ашлы димәк» мәгънәсендә, Баиндар — «нигъмәтле» мәгънәсендә, Биҗнә — «сәгый[2] кылучы» мәгънәсендә.

Җавылдар — «намуслы» мәгънәсендә, Җабни — «баһадир» мәгънәсендә, Салур — «кылычлы» мәгънәсендә, Имир — «байлар бае» мәгънәсендә, Алаюнәтле — «ала атлы» мәгънәсендә, Үркир — «яхшы эш кыйлучы» мәгънәсендә, Икдәр — «олуг» мәгънәсендә, Бәкдуз — «хезмәткәр» мәгънәсендә, Ава — «мәртәбәсе бәләнд[3]», Кынык — «газиз» мәгънәсендә.

Көн хан, җитмеш ел падишаһлык кылганнан соң, энесе Ай ханны үз урынына утыртып, Хак рәхмәтигә китте.

## Ай ханның падишаһлыгының зикере

Ай хан яхшы, гадел, вә агыр, вә әдәпле кеше иде. Ата вә агасының әйткән нәсыйхәтләре илә гамәл кылып, күп еллар атасының эзе илән йөреп, Хак рәхмәтенә китте.

## Йолдыз ханның зикере

Йолдыз хан һәм яхшы падишаһ иде. Әмма аны кыйтга[4] белмәймен ки, ул Ай ханның нәбирәсеме йә бертуганымы иде. Йолдыз исемле бер энесе бар иде, ул һәм булмаска кирәк, кем булса да Угыз хан нәселеннән иде, берничә ел падишаһлык кыйлып, углы Менглене тәхетенә утыртып, вафат булды.

## Менгле ханның зикере

Менгле хан дәхи яхшы падишаһ иде. Ул дәхи берничә еллар ит җыеп, кымыз эчеп, кояш, ай кеби сылуларны кочып, күнә суы кеби юргаларны вә җил кеби йөгрекләрне менеп, Менгле теләгән җирләргә очып, углы Диңгез ханны үз урынына утыртып, теге дөньяга сәфәр кыйлды.

## Диңгез ханның зикере

Диңгез хан дәхи күп еллар падишаһлык кылып, озын гомерле булды. Карт булганнан соң, Ил ханга падишаһлыкны тапшырып, берничә ел Тәңрегә бәндәлекне кыйлып вафат булды.

## Ил ханның зикере

Ил хан Могул иленә падишаһ булды. Югарыда әйткән идек ки, татар ханнарының тугызынчысы Сөенеч хан иде, дип. Ил хан илән Сөенеч икесе замандаш иделәр. Һәрвакыт икесе бер-берсе илә орышып вә талашып торырлар иде. Күбрәк вакытта Ил хан галиб булыр иде. Шул сәбәптән Сөенеч хан кыргыз-казакъ ханына илче җибәреп, күп нәрсәләр һәдия биреп вә башкаларына күп нәрсәләр вәгъдәләр кылып, аны үзенә яр вә ил кылды. Ул җирләрдә ил (халык) күп иде. Могул ул илләрнең барчасыннан күбрәк иде. Һәр заман орыш вә талашлары булганда, бер ыругка могул галиб килер иде. Ул төрек илләрендә могулның угы үтмәгән вә кулы тимәгән ил юк иде. Бу сәбәптән һәммә илләр могулга хөсет[1] кылып: «Ах сине!» — дип янарлар иде. Сөенеч хан кыргыз-казакъ ханын үзенә яр кыйлгач, илләренең барчасына илчеләр җибәреп, үзенә куәт җыеп, фәлән айның унынчы көнендә фәлән җирдә табышып могулдан үчебезне алаек, дип, шул тәгаен кылган җирләрендә һәммәсе бергә кушылып, Могул иленең өстенә йөрделәр. Могул өйләрен вә малларын бер җиргә өеп, гаскәре өйләренең тирәсендә үр казып утырдылар. Сөенеч хан барып орышты, һәр көндә могул галиб булды.

Беркөн сәр[2] гаскәр Сөенеч хан барча илләрнең ханнары вә бәкләре илән аулакта киңәштеләр вә әйттеләр, Могулга хәйлә кылмасак, эшебез яман булыр, дип. Икенче көн иртә илән качкан гаскәр кеби агыр йөкне вә яман хәлне ташлап күчеп киткән булдылар. Могул аны орышка тәкать тота алмый качканга хәмел[3] кылып артларыннан куа барып җиттеләр. Татар халкы могулны күргәч, шул хәл кайтып, анлар илән каты орыштылар, ахирел әмер татар могулны җиңде. Үтерә-үтерә өйләренә җитте. Барча могулның өйләре бер җирдә иде, өйләрен вә малларын шулкадәр таладылар ки, бер могул өе сәламәт калмады. Олугларын барчасын кылычтан үткәреп вә кечекләрен кол кылып, һәркем берсен алып китте вә могулдан кеше калмады һәм кешенең ишегендә бәндә[1] булды. Хуҗасы ни ил булса, шул ил исемендә йөрде, дошман булган могул калмады.

## Кыян илән Нөкүзнең, Әркинәкунга барып, йорт итеп утырганнарының зикере

Сөенеч хан могулны чабып кайтты. Ил ханның угланнары бик күп иде. Һәммәсе орышта үлделәр. Кыян атлы бер кечек углы бар иде, аны шул сугыш елында гына кәдехода кылып[2] иде. Ил хан энесенең Нөкүз ат-

лы бер углы бар иде, ул һәм шул елда гына кәдехода булып иде. Бу икесе бер куыштагы кешеләрнең кулына төшеп иделәр. Ун көн булганнан соң, бер кичне икесе хатыннары илән атка атланып качтылар, үз йортларына йөрделәр. Адашкан вә яудан кире качкан дүрт төрле ат, сыер, дөя, куй, маллардан күп таптылар вә икесе киңәштеләр вә бер-беренә әйттеләр: әгәр Илгә барсак, дүрт тарафтагы илләрнең барчасы безгә дошман, әгәр Илгә кушылмый үз йортыбызда утырсак, бер йөргән вә тузганга очрамай булмабыз, инде яхшысы шул ки, тауларның эчендә кеше аягы төшмәстәй җир эзләп, тауга таба малларын сөреп киттеләр. Тауга барып җиткәч, эченә киткән бер тар гына сукмак юл табып, шул юл илән акыртынлап тауны ашып, теге ягына төштеләр, дәхи төрле яктан әйләнеп карап йөрделәр, үзләре кергән юлдан гайре юлны тапмадылар. Үзләре кергән юл шундый тар вә җайсыз иде ки, дөя аннан йөз имкәк[3] илән үтәр иде, әгәр аягын яңлыш читкә басып җибәрсә, тау астына кулап китеп парә-парә булыр иде. Ул тау эченең киңлегенең һич ниһаяте юк иде, агым сулары, вә чишмәләре, вә төрле утлар[4], вә мивәле дәрәхтләр[5], вә төрле-төрле аулар туп-тулы иде. Ул җирне күргәннән соң, Тәңрегә шөкерләр кылдылар, малларының кышта итен җыйдылар вә язда сөтен эчтеләр вә тиресен киделәр. Ул җиргә Әркинәкун дип исем куйдылар. «Әркинә»нең мәгънәсе «тауның кәмәре[1]» димәктер, «кун»ның мәгънәсе «төз вә үткен» димәктер, бу җир тауның кыры, даласы иде.

Бу ике ага-энедән бала-чагалар бик үрчеде. Кыянның әүләды күп булды, Нөкүзнең аннан азрак булды. Кыян әүлядына «кыят» диделәр, Нөкүз әүлядына ике исем куйдылар: берничәсенә «нөкүзләр» диделәр, вә гайре берничәсенә «дүрелгән» диделәр. Кыянның мәгънәсе «сил»[2] димәктер ки, тау түбәләреннән язлыкта сулар арык-арык булып елдам шавылдап төшәләр. Ил ханның углы көчле, тиз, елдам кеше иде. Шуның өчен аны Кыян диделәр. Кыят Кыянның җәмгысыдыр. Күп еллар бу ике кешенең угланнары Әркинәкунның эчендә тордылар, буйга озайдылар, аркылыга җәелделәр, һәр җәмәгать башка-башка аймак булдылар вә ыруг атын күтәрделәр. Тәңрем боерса, барчасын әйтәчәкмен. «Аймак» дигән сүз «сөяк» мәгънәсендәдер. Төрек халкы бер кешедән сораса, аймакың нидер, дип, «нинди сөяктән» дигән мәгънәдәдер. Дүрт йөз елдан күбрәк Әркинәкун эчендә утырдылар, үзләре вә маллары шулкадәр күп булды ки, хәтта сыя алмадылар, шул сәбәптән бер җирдә җыелып утырып киңәш кылдылар, анда әйттеләр, ата-бабаларыбыздан ишетәдер идек: Әркинәкунның тышкы ягында киң җирләр вә яхшы йортлар бар, имеш. Безнең йортыбыз кадимге заманда ул җирләрдә булган, имеш. Татар башлыгы үзгә илләр илән бергә безнең ыругыбызны кырып, йортыбызны алган, имеш. Хакка шөкер, бу чакта башыбыз андый имәстер ки, дошманнан куркып тагу эчендә камалып утырырга тауның арасыннан юл эзләп табып күчеп чыгаек, һәркем дуст дисә, аның белән күрешәек вә, дошман дисә, аның илән көрәшәек, диделәр. Барчасы бу сүзне мәгъкуль күреп чыкмакка юл эзләделәр, әмма тапмадылар бер тимерче әйтте: «Монда бер тимер кяне, ягъни тимер чыга торган җир бар, шуның тимерен эретсәң, юл булыр иде». Ул җирне барып вә күреп килделәр, дәхи ул эшне мәслихәт күрделәр. Илгә утын вә күмер җыярга әмер кылдылар. Тауның киң җиренә бер кат утын вә бер кат күмер салдылар, тауның өстен вә аргы ягын вә бире ягын тутырганнан соң, җитмеш тиредән өргеч ясап, җитмеш җиргә кордылар һәм берьюлы өрдерә башладылар. Ходай Тәгаләнең кодрәте илән тау кызганнан соң, тау тимер булып ага бирде, һәм йөкле дөя чыгардый юл ачылды, көннең, айның сәгатен карап тышка чыктылар. Шуннан бирле могулның шул көзне гайд[1] кылып бәйрәм итмәге гадәт булып калды. Бер парә тимерне утка салып кызыл булганчы кыздырырлар. Әүвәл ханнары әнбүр, ягъни тимер кыскыч илән тимерне тотып сандал өстенә куеп чүкеч илән орыр, аннан соң бәкләре шулай кылыр, аннан соң — гайреләре. Ул көнне гаҗәеп газиз тоталар, камаудан чыгып ата йортына килгән көн дип сагынып сөйлиләр.

Ул вакытта могулларның падишаһы Буртачина исемле кыян нәселе вә Корлас ыругыннан иде. Ул, барча илләргә илче җибәреп, Әркинәкуннан чыгып килгәнен мәгълүм кылды, бәгъзеләре яхшы күрделәр вә бәгъзеләре яман күрделәр. Татар халкы яман күреп яу булды. Татар илән могул икесе саф тартып орыштылар. Могул галиб килеп, олугларын кылычтан үткәреп, кечекләрен бәндә кылды. Дүрт йөз илле ел булганда канны вә малны алды һәм ата йортына утырды. Ул җирдә утырган төрек халкы арасында татардан күплесе юк иде. Әркинәкуннан чыгып, татарны кырып ата йортында утырганнан соң, могул Татар йортына, барча илләргә вә ыругларга баш булды. Бәгъзе илләр могулга буйсынып, могул булмасалар да, могулбыз дип, үзләрен могулга куштылар.

## Могулның вә башка төрек ыругларының бәяны һәм асыллары[2], вә атлары, һәм ләкабләре ни икәненең зикере

Казвинлик Хуҗа Рәшид әйтәдер: «Иранда Чыңгыз әүлядыннан падишаһлык кылган җәмәгатьтән әүвәл кеше мөселман булды. Чыңгыз хан углы Тули хан, аның углы Һөләкү хан, аның углы Абак хан, аның углы Аргын хан, аның углы Газан хан иде. Ходайның рәхмәте булсын, ул, падишаһ булгач, бер җирне пайтәхет

кылды, мине чакырып гыйнаять[3] итеп вәзир кылды, тәмам Иран мәмләкәтенең ихтыярын минем кулыма бирде. Бер ел булганнан соң беркөн мине чакырып әйтте: «Әлхәмделилла, без мөселман булдык, безнең олуг атабыз Һөләкү хан Могулстаннан килгәннән бирле ике-өч буын үтте. Инде бездән соң дөньяга килгәннәр могулның телен, вә гадәтен, вә җирен, вә йортын, вә ыругларын онытырлар, белмәсләр. Могул йортында утырган ил күптер, аларның кайсының сөяге могул, кайсының татар, кайсының кыргыз кеби — боларның һәммәсен бер җиргә җәмгъ кыл», — дип хөкем кылды. Мин гарыз кылдым бер кешенең кулыннан бу эш килерме, миңа олуг хезмәт бирдегез, дип. Хан әйтте: «Бу эш синнән башка кешенең кулыннан килмәс, бездә могул теле илән язган китаплар бар, языლмаган сүзләрне күңелдән белә торган кешеләребез бар», — дәю.

Биш-алты могулның телен яхшы белә торган кешеләрне минем катыма куйдылар, дәхи ханның бер олуг бәге бар иде, исеме Пулад вә ләкабе Җөнкәсаң иде, аны һәм миңа ярдәмгә куштылар. Ул вакытта могулның асыл нәсәбен аннан артык белгән кеше юк иде. Могулның телен камил белеп, китабын да бәк яхшы укыйдыр иде. Шуннан соң Пулад Җөнкәсаң Баһадир башлыкның һәм тәгаен кылынган могулларның ярдәме илән тарих хиҗри җиде йөз икедә иде ки, мин бу тарихны яздым вә исемне «Җәмигъ әт-тәварих» куйдым». Хуҗа Рәшид сүзе монда тәмам булды. Шул тарих фәкыйрьнең алдындадыр, китапның әүвәлендә һәм зикер иткән идем, моннан башка унҗиде данә «Чыңгызнамә» алдымда әзердер, анлардан һәм күчереп язамын. Кятиблар[1] мөрәвәтсез ахмаклар, мәзкүр тарихлардан гайре нөсхәләргә күчереп ала-ала, ул заманнан бирле өч йөз җитмеш ике ел булган. Ходa белер, егерме йә утыз нөсхәгә язылмыштыр, һәр нөсхәгә күчереп алган саен берничә сүзне галәтъ[2] кыла-кыла, тарихларның өчтән берен, бәлки, ярымын яңлыш язмышлар. Тарихларда язылган тауларның, вә суларның, вә җирләрнең, вә кешеләрнең атлары могул йә төрек теледер. Китап чыгарган мосаннифлар[3] вә анларны язган кятиб кемсәләр фарсы вә таҗиктыр, анлар нә төрки телен вә нә могул телен беләләр. Могулның бәгъзе кешеләренең исемнәрен бер таҗикка әгәр ун көн өйрәтсәң, теле күнмәс, бәс, ул ничек дөрес яза белсен. Бу фәкыйрь төрки вә фарсы телләрен вә лөгатьләрен һәм истыйляхларын[4] белмәктә Ходай Тәгалә шулкадәр биргәндер ки, бу вакытта төрек вә таҗикта кирәк кем булсын фәкыйрьгә биргәнчә бер кешегә бирмәгәндер. Вә дәхи бер сәбәп буенча калмыкка барып, анда бер ел тордым. Могулның телен вә гадәтен вә истыйляхларын яхшы өйрәндем, бу тарихны яхшы вә яман барчасы да белсен дип, төрки теле илән яздым, төрки булганда һәм шундый мөстәгъмәл[5] вә җиңел лөгатьләр илән яздым ки, хәтта биш яшәр углан аңлар, мәгънәләрен фәһемләргә рушан вә заһир булсын өчен гарәп вә фарсы теленнән, хәтта чыгтай төркисеннән мәшһүр лөгатьләреннән гайре бер кәлимә кушылмады. Әгәр әҗәлнең өндәүчесе өнди килмәсә, ошбу китапны фарсы теле илән дәхи язмак күңелемдә бардыр. Әйтә торган сүзләремне әйттем инде, хәзер максудка киләем, хәзер могулдан башка булган ыругларны белгәнемчә бәян кылаем, могулны соңыннан сөйләрмез.

Угыз ханның дастанында әйтеп идек ки. Төрек илендә әүвәл ил исемен күтәргән биш ыруг бар: Уйгур, Кангълы, Кыпчак, Калач, Карлык дигәннәр. Угыз угланнары Төрекмәннән аерылмый Мавәраәннәһер вә Хорасанга төштеләр. Кыпчак, Дон, вә Идел, вә Җаек суларының буйларында вә араларында утырдылар. Кангълы Төрекмән илән бергә утыра иде. Төрекмән вилаятьне үз кулына алганнан соң, Кангълы Эссе күл, вә Чуда, вә Теләш суларының буйларында ватан тотып күп еллар утырдылар. Өргәнеч падишаһларыннан Текеш хан Кангълының бер олугының Теркән исемле кызын алды. Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһ ул кыздан туды. Солтан Мөхәммәд бик олуг падишаһ булды, йортының бер тарафы Һиндстан, вә бер тарафы Әндиҗан вә Төркестан, вә бер тарафы Гарәбстан, вә бер тарафы Рум пайтәхете иде. Өргәнеч Кангълы халкыннан һәркем ул торган хатынга якын карендәш исә, берсе артыннан берсе Солтан Мөхәммәд хезмәтенә килеп, иманга мөшәррәф[1] булдылар һәм хезмәтендә тордылар. Теркән хатынның Хәмәр исемле бертуган агасы бар иде. Ул, солтан хезмәтенә килеп, мөселман булды. Солтан аңа даругалык ләвазимен[2] бирде. Теркән хатынның атасының энесе углы бар иде, Айналҗаек исемле, ул һәм килеп мөселман булды. Аңа тәмам Төрекстан вилаятен бирде, дәхи хөкем кылып мәгълүм Филдикә, бу көннән соң һич аны Айналҗаек димәсен, Гаюр хан дисеннәр диде. Аннан соң Кангълының Күк исемле бер яхшы кешесе бар иде, аңа Күк хан ат куеп, Бохараны бирде. Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһка Кангълыдан килеп табигъ[3] булган илле-алтмыш мең өй бар иде. Чуда вә Теләштә калганнары һәм ун мең өй бар иде. Чыңгыз хан килеп, ул Теләштә утырган Кангълыны алды, барча йортларны алып, халыкны кырды, Кангълы һәм шул халыклар илән бергә юк булды. Бу йөргән кангълылар соңыннан җыелып ил булганнардыр.

## Карлык иленең зикере

Карлык иле Могулстанда мөхкәм тауларның эчендә йорт кылып утырдылар. Иген игеп, маллар асрарлар иде. Бер яхшыны араларыннан падишаһ кылырлар иде, ул үлсә, янә берсен күтәрерләр иде, үзләре күп

имәсләр иде. Сугыш булмаган төзек заманда ике мең өйгә кариб[1] булырлар иде. Дүрт мең елга якын ул йортта утырганнан соң, Чыңгыз хан, Могул иленә падишаһ булып башка илләрне үзенә караткач, Барлас, Кубилай ноян дигән кемсәләрне илче кылып миңа итагать кылсыннар дип Карлык иленә җибәрде. Ул чакта Карлык илендә падишаһ Арслан хан дигән зат иде. Ул, Кубилай ноянга кушылып, үзенең кызына баш кылып, күп бүләкләр илән килеп, ханны күрде, әзһәр[2] итагать итеп гомер буена бәндә булып буйсынмакка ант эчте.

Хан дәхи үз җәмәгатеннән бер кыз бирде, гыйнаять вә шәфкать кылып кайтарды, дәхи Чыңгыз хан бәкләренә карап әйтте: «Моны ничек Арслан хан димәк дөрес булыр, бу көннән соң аны Арслан-сыйрак тәсмия кылсыннар», — дип хөкем кылды. Могулның лөгатендә таҗикны сыйрак дип әйтерләр, имеш.

## Уйгур иленең зикере

Уйгурның мәгънәсе Угыз хан дастанында үтте. Мөәрихләр шулай риваять кылганнар ки: Могул йортында ике тау бардыр, озынлыклары кояш чыгышыннан кояш баешынача тартылмыштыр, биниһая олуг таулардыр. Берсенең аты Тукрату Бозлык вә икенчесенең аты Оскунлык Тирәм. Бу ике тау арасында Могул йортының көнбатышында дәхи бер тау бардыр ки, аны Кот тау диләр. Ошбу мәзкүр тауларның арасында бер җирдә ага торган ун сай бардыр вә икенче җирдә тугыз сай дәхи мәүҗүдтер, бу сайларның барчасы олуг сулардыр. Кадимге заманда Уйгур иле шул сайларның арасында утыралар иде. Ун сайда утырганны — Ун уйгур вә Тугыз сайда утырганны Тугыз уйгур диерләр иде. Шәһәрләре, вә кәндләре, вә игеннәре күп булыр иде. Йөз егерме ыруг ил иделәр, бер кешене падишаһ күтәреп, аның хөкеменә итагать кылмаслар иде, бу сәбәптән бер-берсе илә яу булып бозылыр иделәр.

Беркөн барчасы җыелып киңәштеләр вә әйттеләр: «Без ике төрле илбез, һәркайсыбыз бер кешене түрә кылаек, һәркем аның сүзен кабул кылмаса, башын кистерсен вә малын алдырсын», — диделәр. Ун уйгур ыругыннан Мәнгүтай атлы кешене түрә күтәреп Илилтер дип ләкаб куйдылар. Тугыз уйгур үз ыругыннан бер кешене түрә күтәреп, Күл Иркин дип ләкаб куйдылар, бу икесенең угланнары йөз елгача түрәлек кылдылар. Аннан соң дәхи бер уйгур булды, ун уйгурга һәркем түрә булса, Илилтер вә тугыз илгә түрә булса, Күл Иркин диделәр. Күп илләр түрәләренең исемнәрен шулай әйтерләр иде вә, аннан соң һәркем түрә булса, аңа «әйдикот» дип әйтер булдылар. Әйдинең мәгънәсе «барчалар белер, җибәрде» димәктер; мәсәлән, «йепне әй» «йепне җибәр» дигән мәгънәдәдер. Сыгыр әйде, ягъни сөтен сакламады, җибәрде. «Җан»ны төрек халкы «кот» дир. Бер кешегә әйтергә атың вә йә туның котлы булсын, ягъни җанлы булсын димәк булыр, иясенең җаны булмаса, ул ничек мөбарәк[1] булыр. Бәс, «әйдикот» барча халыкка «җанны җибәргән» мәгънәсендә булыр, бу вакытта үзбәк иреклек кеше дидер. Икесенең мәгънәсе бердер.

Өч мең елга якын ошбу әйтелгән йортта утырдылар, аннан соң бозылдылар, өлҗә[2] вә әсир булып тордылар, берничәсе йортында утырып калды вә берничәсе Иртыш суының буена килделәр һәм өч бүлеккә аерылдылар. Бер бүлеге Бишбалык шәһәренә барып, иген игеп, вилаятьне абад[3] кылдылар вә икенче бүлеге елкы вә куй асрап, Бишбалык якынында күчеп вә кунып тордылар, өченче бүлеге Иртыш суы тугаенда һич мал асрамый, фәкать балык, вә кондыз, вә кеш, вә сусар аулап, итләрен җийеп, тиреләрен киярләр иде. Җанлы малны вә ефәктән булган мәтаг вә комашны[4] гомерләрендә бер күрмәсләр иде. Анлары кызларын каргасалар, елкылы вә куйлы кешегә төшеп ит җийеп, кымыз эчеп, башыңа яман көннәр тусын, дип әйтерләр иде. Чыңгыз хан заманында Бавырчык дигән әйдикот иде, ул Чыңгыз ханга кеше җибәреп һәм итагать кылып һәр елда мал бирер иде. Чыңгыз хан атланып Мавәраәннәһер өстенә килгәндә, Бавырчык әйдикот гаскәре илән килеп, юлда Чыңгыз ханга кушылып яхшы хезмәтләр кылды. Уйгур халкында төрки теле укыган кешеләр күп була иде, дәфтәрдарлыкны[1] вә диван хисапларын яхшы беләләр иде. Чыңгыз ханның нәбирәләре заманында Мавәраәннәһер, вә Хорасан, вә Гыйракта диваннар вә дәфтәрдарлар барчасы да уйгур иде. Хытай йортларында һәм Чыңгыз хан угланнары диван вә дәфтәрдарлыкны уйгур халкыннан куялар иде. Чыңгыз ханның үз урынында утырган углы Үгедәй хан Хорасан, вә Мазандаран, вә Гилянны уйгур Күркүз дигән кемсәгә тапшырмыш иде. Ул яхшы хисап белүче иде, өч йортның малын яхшы забит[2] кылып, һәр елда Үгедәй ханга җибәрәдер иде.

## Текрин иленең зикере вә аны Мекрин һәм диләр

Боларның йортлары Уйгур иленә якын мөхкәм тауларның эчендә иде. Аслый могулга һәм уйгурга кушылмаган башка бер ил иде. Чыңгыз хан заманында мең өйле иде. Хан илче җибәрде вә әйтте: «Тәңре Тәгалә миңа олуг дәүләт бирде, дүрт тарафтагы ил барчасы тәбәга булды[3], син ни әйтәсең?» Ул чакта Текрин-

нең түрәсе Җинанҗ исемле иде. Бәүкәй атлы бер гүзәл кызы бар иде, аны баш кылып, күп һәдияләр биреп, ханны күреп итагать кылды. Хан дәхи күп ингамнар кылып сыйлап кайтарды. Ул кызны хан алды һәм барча хатыннарыннан артыграк сөйде. Хан үлгәч, углы Үгедәй хан алды, ул дәхи һәммә хатыннарыннан артык сөйде.

## Кыргыз вә Кемкемҗөт иленең зикере

Угыз ханның Кыргыз исемле бер нәбирәсе бар иде, шуның нәселеннән иде. Әмма бу вакытта Кыргыз нәселеннән кешеләр аздыр. Могулдан, татардан вә гайре ыруглардан хайваннарын асрамак өчен ут вә су эзләп, Кыргыз йортына барып утырып, кыргыз исемен күтәрмешләрдер. Үзләре кайсы ыругдан икәннәрен беләләр. Кыргыз вә Кемкемҗөт ике вилаять булып бер-беренә якыннардыр. Бер тарафы Сөләнгер исемле вә икенче тарафы Анкара-Муран исемле, икесе һәм олуг агым сулардыр. Әбир вә Сибир дигән ике вилаять бар. Кыргыз йорты аңа якындыр, Кыргыз иле түрәсенә Әйнал (Инал) дир иде. Могул вә таҗик падишаһ дигән кеби ул вакытта түрәләре Ырыс Әйнал (Инал) дигән кемсә иде. Чыңгыз хан Бора дигән кемсәне илче кылып, миңа тәбәга булсын дип, Кыргыз иленә җибәрде. Ырыс Әйнал илчене яхшы сыйлап, үзе бармый күп бүләк-санак илә яхшы кешеләрен кушып җибәреп баш салды, бүләкләренең мәшһүре — бер ягы, вә борыны, вә күзе кызыл ак шонкар кош иде.

## Урманкот иленең зикере

Бу илнең йортлары калын вә куе агачларның эчендәдер, шуның өчен Урманкот дип исем куйдылар; боларның йортлары Кыргыз вилаятенә якын була. Чыңгыз ханга тәбәга булдылар. Болардан башка дәхи бер Урманкот атлы ил бардыр, икесенең бер-берсе илә карендәшлекләре юктыр. Соңыннан әйткән Урманкот, Могул, Нөкүз угланнарыннандыр. Урман эчендә күп утырганлыктан, анларга һәм Урманкот дип ат куйдылар.

## Татар иленең зикере

«Татар» исеме кадимге заманда һәм бу вакыт бик мәшһүрдер. Кадимге заманда җитмеш мең өйле күп ыруглы иделәр, һәркайсы фәлән илемез дип әйтәләр иде. Һәр ыруглары башка-башка бер җирдә утыралар иде, әмма күбрәге вә яхшылары Хытайга якын Боюрнавыр дигән җирдә утыралар иде вә Хытай падишаһларына итагать кылып хезмәт итәләр иде, кайвакытларда Хытай илән яу булыр иде. Шул вакытларда Хытай аларга гаскәр җибәреп, көч илән яуга нәсыйхәт илән дәхи үзенә каратадыр иде. Берничә көн илләр Анкара-Муран дигән суның буенда утыралар иде. Анкара-Муран Кыргыз вилаяте чигеннән үткәч, күп сулар аңа кушылыр, шуннан соң олуг су булып бара-бара Ачы диңгезгә коелыр. Койган җирендә диңгез якасында бер олуг шәһәр бардыр ки, кәндләре вә дәхи күчеп йөргән иле вә малы биниһая күптер. Елкысы эре, аларның бер яшендәге тае безнең ике яшендәге таебыз кеби буладыр. Елкысының һәммәсе ала, үзгә төсле юктыр. Ул шәһәрнең исемен Алакчин диләр. Аның якынында көмеш кане[1], ягъни көмеш чыга торган җире бардыр, ул илнең казаны, вә аяк-табагы, вә кашык-савыты — һәммәсе көмештән булыр. Үзбәкнең алалы елкылы, алтын учаклы ил булыр, имеш, дигәне болардыр. Чыңгыз хан үлгәннән соң, Кыргыз йорты вә аның дүрт тарафындагы йортлар барчасы Тули ханга карады, Тули хан үлгәч, угланнарына күчте. Тули ханның олуг хатыны барча угланнарының анасы Сөюркүктай бикә, ихтыяр аның кулында иде. Ул хан хатын өч бәкне, мең кешегә баш кылып, көймә илән Алакчинга җибәрде. «Барыгыз, кулыгыздан килсә — чабыгыз, килмәсә — хәбәр алып килегез», — диде.

Күп вакытлар үткәннән соң, җиде йөзе үлеп, өч бәк, өч йөз кеше илән кайтып килеп хәбәр бирделәр, аларның турысыннан ишеткән хәбәрләр һәммәсе дә рас, имеш. «Көмешне күп алган идек, көймәне су агышына каршы йөртә алмадыгыбыздан ташлап калдырдык, һавасы бик яман исле булыр, имеш, шул сәбәптән кешебез кырылды», — диделәр. Татар халкының Чыңгыз ханга ничек итагать кылганын Чыңгыз хан дастанында сөйләячәкмен.

## Ойрат иленең зикере

Агып бара торган олуг суны төрки телендә сай диләр вә таҗик киҗкинруд олугыйнрудханә дир, вә гарәп вади дир, вә могул муран дир. Могул йортының көнчыгышында сигез су булып, аларны сигез муран дирләр, шул суларның араларында утыралар иде; ул суларның һәммәсе, килеп, Анкара-Муранга кушылыр. Ул сигез суның исемнәре болардыр: Күк Муран, Он Муран, Кара Усун, Сәбни Кун, Әкри Муран, Үр Муран, Чаган Муран, Җүрҗә Муран. Чыңгыз хан заманында Ойрат падишаһы Котука бикә иде. Аның ике углы бар иде, олугының исеме Инәлҗи вә кечегенең исеме Түрәлҗи; ул Чыңгыз хан илән яу булган иде. Соңыннан ил булды, кыз бирде вә кыз алды, ханга буйсынды. Тургаут, Курый, Төләс. Бу әйтелгән өч ыруг илнең аслый һәм Ойраттандыр. Һәркайсы Ойратның бер ыругыдыр, «Тургаут» мәгънәсе «аргы як» димәктер. Могул йортының аргы ягын Силенгә дирләр. Ошбу илләр Силенгәнең ул ягында утырырлар иде, шул сәбәптән Тургаут диделәр.

## Тумат иленең зикере

Тумат — Ойратның бер ыругыдыр. Баркучин-Тукум дигән җирләрдә утырырлар иде. Кыргыз вилаятенә якындыр. Чыңгыз хан заманында бәкләре исеме Татула-Сукар дигән кемсә иде, ул, килеп, Чыңгыз ханны күреп багынды[1]. Булгаҗин, Кармүҗин — бу ике ыруг бер-берсе илә карендәш булырлар, йортлары Кыргыз йортына чиктәштер, Чыңгыз ханга ил булдылар. Түләнгүт, Урасут, Кустымай — бу өч ыруг ил бер-бере илә карендәш булалар, боларның эчендә табиб күп булыр, ярачылыкны[2] яхшы белерләр вә даруларны яхшы танырлар; йортлары куе агач урман эчендәдер; һәммәсе аучылык кәсебе илән көн күрерләр — кеш, вә сусар, вә ас, вә тиен, вә кондыз, вә суда балык, вә кырда киек — җанлы нәрсәләрне барчасын ауларлар.

## Найман иленең зикере

Бу кадимге илдер, башлары вә маллары күп була иде. Борынгыларын белмибез, фәкать безнең ишеткәнебездән бер падишаһлары бар иде. Каркыйш исемле, ул үлгәннән соң, энесе Инат атлыны падишаһ кылдылар. Чыңгыз хан заманында падишаһлары Тияң хан дигән зат иде. Көчлүк исемле углы бар иде, йортлары Могул йортында Кара-Кором дигән җирдә торып, игенне икмәсләр иде.

## Кирәет иленең зикере

«Кирәет»нең мәгънәсе «кара борын» димәктер. Бер кешенең җиде углы бар иде, җидесе һәм каратутлы булып, аларны халык кирәетләр диделәр. Алардан туганнарга Кирәет ыругы дип әйттеләр. Борынгы ил башлары вә маллары күп, падишаһлары башка иде; ул заманнарда Кирәеттән көчле ил юк иде, йортлары Найманга якын булдыгыннан, һәмишә Найман илән гяһ[3] сугышып вә гяһ татулашып торырлар иде. Кирәетнең Маргуз исемле бер олуг падишаһы бар иде вә аның дәхи Курчакор исемле Боерык ләкабле бер углы бар иде. Курчакорның угланнары күп булды, беренең исеме Тагрыл иде, Хытай падишаһлары Уң дип ләкаб куйдылар. «Уң»ның мәгънәсе «вилаять падишаһы» димәктер. Чыңгыз хан илән орышкан Уң хан шул иде.

## Онгут иленең зикере

Хытай халкы йортының чигеннән бер бәләнд дивар тартып, ике очны диңгезгә җиткереп өйделәр, аны кеше бозып ватардай түгел иде. Кәрван кереп чыкмак өчен бер-ике төштә тимер капкалары бар иде, андай диварны гарәб халкы «сәд» дир, төрки халкы «бур-курга» дир вә хытай халкы «өнкү» дир. Искәндәр яәҗүҗ-мәәҗүҗнең алдына сәд салды, Ануширван Шәмәхада сәд кылды. Бу чакта аны Тимер Капы дирләр, шул сәднең ишегедер. Хытай падишаһлары төрек халкыннан берничә җәмәгатькә сезгә һәр елда фәләнчә кадәр нәрсә бирермен дип сәднең дәрвазәләрен[1] саклата иде. Төрекләр биргән нәрсәләрен алып саклар булдылар. Атадан угыл вә анадан кыз берсе артыннан берсе шулай саклый килделәр. Шул җәмәгатькә Онгут диделәр. Могул телендә Онгутның тасый, «яй, нисбәт» кеби булыр, нитәк өргәнчи, вә табакчы, вә ишекче сүзләрендәге кеби сәдне саклаганнарын Онгут диделәр, «сәдчы» дигән мәгънәдәдер. Чыңгыз хан заманында дүрт мең өйлек иделәр, бәкләренең аты Алакош дигән ирде. Чыңгыз хан Хытай өстенә йөргәндә, Алакош бәккә кеше җибәрде, миңа итагать кылсын дип. Ул Чыңгыз ханга баш салды, аннан соң хан Хытай

өстенә атланды. Алакош бәк, каршы килеп, Онгутның дәрвазәләрен ачты, Чыңгыз хан илән кушылып, Хытай өстенә барды.

## Хытай иленең зикере

Хытай йорты ике кыйсемгә бүленер, берсенә Кара-Хытай дирләр. Кара-Хытайдан күп җәмагать бер сәбәп илән падишаһларына яу булдылар һәм күчеп качтылар, Кыргыз вилаятенә килделәр, анда утырган кадимге илләр, аларны мосафир белеп, малларына кулларын озайта башладылар. Анда һәм утыра алмый Имил дигән җиргә күчеп килеп, шәһәр салдылар, шул урында утырып иген иктеләр, җирләрен рабад кылдылар. Һәр җирдә малыннан аерылган ач, вә арык, вә йөдәгән кемсәләр барысы да бу шәһәргә җыелдылар, кырык мең өйлек ил булдылар. Шул вакытта Чөрчет дигән бер олуг йортның падишаһы Кара-Хытай падишаһы (Менг. — *М.Ә.*) илән сугышты һәм галиб килде, йортны алды, падишаһын үтерде. Чөрчет падишаһының Туси Тайфыр исемле бер бәге бар иде, ул күп нөкер вә иле илән качып, Кыргыз вилаятенә килде. Тарих биш йөз унөчтә аннан Имил шәһәрендә утырган хытайларга килде, гакыллы вә данишмәнд кеше иде. Бер-ике ел анда утырганнан соң, исеме вә авазәсе[1] дүрт якка мәшһүр булды. Ул Әфрасияб нәселеннән иде. Баласагун дигән шәһәрдә бер хан бар иде, исеме Илек, үзе фәкыйрь кемсә иде. Ул шәһәрне могул Губалык дир иде. «Гу»ның мәгънәсе «яхшы» димәк вә «балык»ның мәгънәсе «шәһәр» димәк, һәр икесенең мәгънәсе «яхшы шәһәр» димәк булыр. Ул кальганың әтрафында төрек халкы күп иде. Хосусән Кангълы иле талар вә чабар вә игеннәрен җыеп алырлар иде. Ул сәбәптән Илек хан Хытайдан килгән Туси Тайфыр бәккә кеше җибәрде, килсен, вилаятькә ия булсын, диде. Ул килде һәм вилаятькә хуҗа булды. Илекне үзенә нөкер кылды, дәхи хөкем итте ки, бу көннән соң һичкем аны Илек хан димәсен, Илек төрекмән дисеннәр, бәгъдә[2] үзенә Гүр хан дип ләкаб куйды. «Гүр»нең мәгънәсе хытай телендә «олуг падишаһ» димәктер.

Аннан ары барып Әндиҗанны алды, аннан соң Төркестан вә Ташкентны алды. Атланып Сәмәркандны камады вә бирергә солых иттеләр. Соңра кайтып, өенә төште. Бер олуг бәге бар иде, Арыйз атлы, аны баш кылып Өргәнечкә җибәрде. Өргәнечне чапты, өлҗә вә әсир алды, кальгасын камап утырды. Өргәнечнең падишаһы Хәрәзем шаһлары җөмләсеннән Атсыз дигән зат иде. Һәр елда егерме мең әшрәфи[3] алтын бирмәк булды. Арыйз аңа разый булып кайтты, үлгәнче һәр елда бирде. Атсыз үлгәч Тигеш дигән углы падишаһ булды, ул һәм үлгәнче бирде. Ул үлгәннән соң, углы Солтан Мөхәммәд падишаһ булды. Ул бирмәде, яу булды. Солтан Сәнҗар Мазый Румнан бире вилаятьләренең гаскәрен алып, Төркестан өстенә барып, Кара-Хытай, Гүр хан илән сугышты, җиңелде, тәмам гаскәре кырылып, үзе качып Мәрвәгә килде.

## Торкак ыругының зикере

Сөяге мәгълүм имәс, кайсы төректән икәне, мәгънәсе «сакчы» димәктер. Падишаһлары үзләрен саклатмак өчен берничә кешене тәгаен кылалар иде. Алар килеп, ишектә ил яткач, нәүбәт илән күзәтеп утырырлар иде һәм нәүбәт илән йокларлар иде. Утырганнары табел[1] вә йә ике агачны кагарлар иде, сакчыларның уяу икәнен белеп, дошман килмәсен дип, бу эшне кылырлар иде. Йокламый утырганы йоклаганына әйтер иде, минем нәүбәтем булды, инде син тор, килеп как дип, шул сәбәптән падишаһны саклаган кешеләрне торкаклар дирләр иде.

## Могул илләренең зикере

Ил ханның углы Кыян вә энесенең углы Нөкүз — бу икесе Әркинәкун тавы эченә кергәч, угланнары күп булды. Кыян угланнарына Кыят диделәр. Нөкүз угланнарына Дөрләгин диделәр. Бара-бара һәр җәмәгать бер ил атын күтәрделәр. Кыят аты да югалды, Дөрләгин аты да югалды. Кыян нәселеннән Корлас ыругыннан Аланкува исемле бер хатын ирсез өч (Адәмнән имәс) углан тудырды. Хода гуаһласа[2], бу сүзләрне әйтербез, бу җирдә әйтмәкне мөнасиб[3] күрдек. Ул өч угылның нәселе гаҗәеп күп булды, аларга Нирун диделәр, мәгънәсе «солеб[4] пакь» димәктер, төркичә ару «тохым»[5] мәгънәсендәдер. Бу атны шуның өчен куйдылар кем, могул ул өч угыл нурдан яратылды дип зәгым[6] кылдылар. Чыңгыз ханның өченче атасы Кабул ханның алты углы бар иде, барчасы булдыклы, вә баһадир, вә елдам, ягъни сәригылфәһем[7] бу егетләргә кыят диделәр, аның өчен могул таудан агып төшүче силне кыян дир, кыят аның җәмгысыдыр. Кабул хан угланнарының олугы Бартан хан иде, аның углы Чыңгыз ханның атасы Исүгәй Баһадир хан иде. Исүгәй Баһадирның күзе коңгырт иде. Могул коңгыртны бурчыгыйн дир, ул сәбәптән Исүгәй Баһадирның нәселе

Бурчыгыйн Кыятмыз диделәр. Кыят аты Кабул хан угланнарыннан соң дәхи яңарды. Барча төрекләрнең ыругын берсенбер калдырмый белмәк вә әйтмәк бер кешенең кулыннан килмәс, үзебезнең әхвәлемезгә лаек анча белгәнемезчә башка төрекләрнең ыругын әйттек, инде Могул нәселеннән булган ыругларны әйтим.

## Меркит иленең зикере

Меркитне мөкрит һәм дирләр, икесе дә бердер. Чыңгыз хан заманында илгә баш булып йөргән кешенең исеме Туктабики иде. Бу ил һәмишә Чыңгыз хан илән яу иде. Бер кәррә Чыңгыз ханның өен чаптылар, хатынын өлҗә кылып алдылар, дәхи бер  кәррә Чыңгыз хан сахрада ялгызы йөргәндә әсир алып, хун[1] бәһасен алып кайтарды.

## Коңгырат иленең зикере

Кыян нәселеннән бер кеше бар иде, аның өч углы дәхи бар иде: олугының аты Җорлык мәргән, икенчесенең аты Кобай-Ширә, өченчесенең аты Тосбодай. Олугы Җорлык ук атарга бәк маһир иде. Беркөнне энесе Кобай-Ширә илән орышты. Икесе һәм ат өстендә иде, җәясен алып, угын төзәде, Кобай-Ширә иңкәеп башын атның муенына ышыкландырды, берзаманнан соң башын күтәрде, Җорлык энесен аяды һәм күңленнән әйтте моны шулай атаем, курыксын, әмма зарар булмасын. Колагында олуг хилкасы[2] бар иде, аны касд[3] кылып атты, хилканың эченнән үтеп китте. Җорлык мәргәннең бур углы бар иде Коңгырат атлы. Барча Коңгырат иле аның нәселеннәндер.

## Ингәрәс иле вә Әлканут иленең зикере

Кобай-Ширәнең ике углы бар иде: олугының аты Ингәрәс вә кечегенең аты Әлканут иде. Ике ыруг ошбу икесенең нәселеннәндер. Чыңгыз хан анасының исеме Олун (Кучин. — *М.Ә.*) иде, Әлканут ыругыннан иде.

## Каранут иленең зикере

Тосбодайның ике углы бар иде, олугының аты Карануттыр. Барча Каранут иленең нәселе шуннан булды.

## Корлас иле илән Илчигән иленең зикере

Икенче углы Куныклутның бер углы бар иде. Мир атлы, аның дәхи ике углы булып, олугының аты Корлас, барча Корлас ыругы аның нәселеннәндер. Кечегенең аты Илчигән. Һәммә Илчигән ыругы аның нәселеннән килер.

## Урмаут иленең зикере

Бу вакытта аны Уймаут дирләр. Барча Урмаут ыругы ул кешенең нәселеннәндер.

## Кунықмар иленең зикере

Урмаут ыругыннан бер кеше бар иде, аның өч углы булып, олугының исеме мәгълүм имәс, әмма егет булгач, халык Куныкмар  дип ат куйдылар. «Кунык»ның мәгънәсе «олуг» димәктер, бу вакытта һәм олуг карганы «кунык карга» дирләр, «камәр»нең мәгънәсе «борын» димәктер, ул кешенең борыны бик олуг иде. Шуңа күрә Куныкмар дип ләкаб бирделәр. Һәммә Куныкмар ыругы бу кешенең нәселеннәндер. Бу вакытта Камәр углыбыз дип әйтерләр. Минглек Ичигә Куныкмар ыругыннан иде. Менглек — атасы куйган исемдер. Могул атаны ичигә дир, төрек халкы газиз кешене ата дир. Мисле Хәким Ата, Сәед Ата кеби. Минглек

могулның газиз кешесе иде. Шуның өчен аңа Ичигә дирләр иде. Чыңгыз ханның атасы үлгәннән соң, анасы Минглек Ичигәгә барды. Кирәет падишаһы Уң хан Минглек Ичигәгә кеше җибәрде. «Мин — эчтән, син тыштан булып Чыңгызны юк итәек. Калган иле вә малының ярымы синең вә ярымы минем булыр», — диде. Уң хан Чыңгыз ханның атасы һәм үзе илән дус иде, Чыңгыз хан аның дошманлыгын белмәс иде. Ул Чыңгыз ханга кеше җибәрде. «Олуг углы Җүчигә кызымны бирәм, үзе безнең өйгә килсен, икебезнең дә максудымыз вә морадымыздыр, туй итәек вә дәхи туй бәһанәсе[1] илә берничә көн гыйш-гошрәт илә мәшгуль булаек», — диде.

Чыңгыз хан, бу сүзгә ышанып, Уң ханның өенә китте, юлда Минглек Ичигә очрады, дәхи Уң ханнан ишеткән сүзләрне барчасын әйтте һәм ханны үлемнән коткарды. Минглек Ичигә Чыңгыз хан хезмәтеннән асла аерылмас иде. Чыңгыз ханның анасын алганда, хан унөч яшендә иде, ул вакыттан үзе үлгәнче сугышлар вә яман көннәрдә вә яхшы көннәрдә һич ханнан аерылмый, барчадан югары ханның уң тарафында утырыр иде. Борынгы хатыныннан өч углы бар иде. Олугының исеме Күкчә иде. Халык аны Тәңренең йөзе дирләр иде. Чыңгыз хан тәхеткә утырган дастанында Күкчәнең ниндәй кеше икәнен әйтермен.

## Эрлат иленең зикере

Икенче углы Эрлат исемле иде, мәгънәсе «ананың сөекле углы» димәктер. Эрлат бер кешенең исемедер, аны анасы бик сөяр иде, шуның өчен Эрлат диделәр. Һәммә Эрлат иле шуның нәселеннәндер.

## Келкит иленең зикере

Өченче углы Келкит иде. Кешенең телендә бер кимлеге булса, аны төрек халкы пелтек яки сакау дир. Могул аны келки дир. Бу кешенең телендә кимлек бар иде, шуның өчен Келкит диделәр. Барча Келкитләр иле ул кешенең нәселеннәндер.

Югарыда һәм әйттек: могул телендә «та» хәрефе «лы» нисбәт мәгънәсендә килер; бу сүзнең мәгънәсен һәркемгә белерлек әйтәем, «атлы», «тунлы» дигән сүзләрнең ахырындагыча «лы» хәрефен «лы» нисбәт дирләр.

## Бадай вә Кыйшлык иленең зикере

Келкит ыругыннан бер кешенең ике углы бар иде. Олугының исеме — Бадай, кечегенең исеме Кыйшлык иде. Бу икесе Кирәет Уң ханның бер бәгенең елкысын багарлар иде. Беркөн Бадай елкыдан сөт китереп, өйнең ишегенә килде, эчтә бәкләр сүзен ишеткәч, «ни сөйләрләр икән?» дип, тыштан колак салып торды. Соңра хатынына әйтте, савытны вә сабаны чыгарып куй, Уң хан, атланып барып, Чыңгыз ханны өендә тиз басачактыр.

Ике ханның өйләре якын иде. Уң хан — ата, Чыңгыз хан угыл булып гамьсез утырыр иделәр. Бадай эчкә кереп сөтне бирде һәм, елкыга килеп, энесенә әйтте, бонлар могул иде, Чыңгыз хан һәм могул. Үз падишаһларының үлмәгенә тәкать кыла алмый, кирәет халкы башка ят ил булдыгыннан бу серне Чыңгыз ханга килеп әйттеләр. Моның хикәяте озын дастандыр, моның сәбәпле Чыңгыз хан үлемнән котылды. Бу икесен тархан кылды. «Тархан» мәгънәсе будыр ки: ул кемсәдән һичнәрсә алым алмаслар, һәркайчан хан ишегенә килсә, аны һич кеше мәнгъ кылмас, сөальсез-җавапсыз үзе керер, үзе чыгар, әгәр гөнаһ эш кылса, тугызгача җәзасын бирмәсләр, аннан соң җәза бирелер, тугыз буынгача шулай булыр.

## Уйшун иленең зикере

Боларның сөяге һәм могулдыр.

## Сөлдус иленең зикере

Бу илнең һәм сөяге могулдыр.

## Илдүркин иленең зикере

Илдүркин Сөлдус иленнән аерылгандыр.

## Көнкит иленең зикере

Бонлар һәм могулның бер ыругыннандыр.

## Дурбан иленең зикере

Могул Бичин Кыян исемле падишаһы бар иде вә аның дәхи биш углы мәүҗүд иде. Кечесе һәммәсеннән яхшырак иде. Атасы, үлгән вакытта, кече углымны түрә кылыгыз, дип васыять кылды. Халык һәм кече углын түрәлеккә лаек күреп хан күтәрделәр. Аның исеме Кычый Мәргән иде. Дүрт олугы халыкка күп әйттеләр, безнең дүртебездән беребезне түрә кылсагыз разыйбыз, әмма кечеккә разый имәсбез, диделәр. Әмма халык ул дүртенең сүзләрен кабул кылмадылар. Шуның өчен илгә үпкәләп, йорттан китеп, ят илнең эченә барып утырдылар. Могул бу дүрт борадәрне Дурбан дип тәсмия кылды. Ят илләр шул ләкаб илән атаганлыклары сәбәбеннәндер, мәзкүр дүрт кемсә шунда ят ил арасында вафат булдылар, әмма угланнары кайтып, карендәшләре эченә килделәр.

## Барыйн вә Сокыт иленең зикере

Бер Дурбанның өч углы бар иде, олугының исеме Барыйн  дигән иде. Барча Барыйн иле аның нәселедер. Кечек энесе кәдхода[1]  булды. Хатыны углан тапмады, аннан соң кәнизәк хатынына мәел[2] куйды. Кәнизәк хамилә булды. Олуг хатыны кәнизәкнең карынына һәр көндә сугар иде, төшсен дип, әмма төшмәде.

Бер кичә ярым төнне ир углан тудырды. Атасы тунының итәген кисеп алып, аңа угланны чолгап, өйнең артындагы тубылгы эченә илтеп куйды. Иртә илән атасы тәһарәт сондырырга барса, углан авазы килде. Барып күрде, үзенең тунын таныды, аннан соң үз углы икәнен белде һәм күтәреп анасы катына алып килде. Анасы асрады, угланга Сокыт аты куйдылар. Могул тубылгыны сукай дир, «тубылгылы» димәк мәгънәсендә. Курлавыт илән Бөркүт ыругы һәм могулдандыр. Могул эчендә карендәшлеге Коңгыратка якындыр, кадимге йортлары Коңгырат илән бергә иде.

## Үклән иленең зикере

Үклән иленең асылы һәм могулдыр. Әмма могул кайсы ыругка якын икәне мәгълүм имәс. Җуйрат Җәҗерат һәм дирләр. Бу илнең сөяге могулдыр, дәхи могул эчендә Аланкува нәселеннәндер.

## Бияут иленең зикере

Бу ил күп ыругдыр, әмма яхшысы вә күбрәге ике ыруг булыр. Берсенә Җөдаин-Бияут вә икенчесенә Мекрин-Бияут дирләр. Җөдаин вә Мекрин дигән ага торган ике олуг судыр. Алар шул суларның буйларында утырырлар иде. Шуңа күрә бу су исемнәре аларга ат булып калды, йортлары Ойрат йортына якындыр. Бияут иле могулныңдыр, ләкин ыругыннан аерылыр.

## Җалайыр иленең зикере

Кадимге еллар җөмләсеннән биниһая күп кавем булыр иде. Ривая кылыныр ки, бер кәррә Хытай падишаһы илән яу булганда һәр җирдә утырган җалайырларның яхшы вә яман бер җирдә җыелып җөмләсе җитмеш курен[1] өй булдылар. Ыруглары күп иде, һәркайсы ыруг бер кешене ага кылып бер җирдә утырыр иде, күбрәге Могул йортында Онон дигән җирдә утырырлар иде. Бер тапкыр Хытайдан гаскәр килеп, җалайыр  халкының бер җирдә утырган күп җәмәгатен кырып, өлҗә вә әсир кылып кайтып китте. Чабылган илнең ач вә арыгы җияргә ризыклары юклыгыннан сахра пиязы, ягъни суганының төбен казып җиярләр иде.

Чыңгыз ханның җиденче атасы Дутумнән хан вафат булып сигез углы калды, барча угылларының анасының исеме Мөнулун иде. Олуг углы Кайду ханга кыз алды, ул кызга калым, ягъни мәһәр алып китеп иде. Өенең якынында бер яхшы төзле җир бар иде. Дутумнән хан угланнары анда ат чабып уйнарлар иде. Ул җирнең суганы күп буладыр иде. Шуның өчен чабылган ач вә фәкыйрьләр ул җирне шундый казыдылар ки, хәтта ат йөри алмаслык булды. Аны күреп, угланнар килеп, анасына әйттеләр. Анасы атланып ачуланып барса, күрде ки, берничә кемсәләр янә казып утырырлар иде. Шул заман колларына аларны орырга боерды. Җалайырлар җыелып, ул җирдә олуг орыш булды. Берничә кеше җалайырдан үлде вә Мөнулун башлык тарафыннан дәхи берничә кемсә үлде. Чабылган җалайырлар җыелдылар һәм Мөнулунның өен чаптылар, Дутумнән ханның җиде баш булып йөргән угланнарын һәм колларына төшкән кемсәләрне барын кырдылар. Ачтан йөдәп йөргән фәкыйрьләр бәһанә илән туйдылар. Моны ишеткәч, Кайду хан каенатасы өеннән килде, карендәш вә ыруглары һәм нөкерләре барчалары җыелып, җалайыр халкына кеше җибәрделәр, шундый эшләр булгансыз, ни әйтәсез, дип. Җалайырның яхшылары гауга салып орыш кылганнарны санадылар. Биш йөз кеше чыкты, барчасын ире, хатыны һәм угланнары илән Кайду хан хозурына сөреп китерделәр вә, боларны ничек теләсәгез, шулай кылыгыз, дип тапшырып калдырдылар. Кайду хан иленә вә карендәшләренә киңәшкәч, алар әйттеләр, синең каның илән боларның каны бер-бер килмәс, бәндә кыл, угылдан — угыл, кыздан кыз бәндә булсыннар, диделәр. Барчасы, бу сүзне мәгъкуль күреп, мәслихәт дип, аларны бәндә кылдылар.

Ул җәмәгать үстеләр, күп булдылар, җалайырмын димәделәр, бәлки могул, Кыян угланнарыбыз дип әйтер булдылар. Зирәки[1] азат коллар хуҗаларының ыругыннан хисап кылынмаклары рәсем вә гадәт иде. Чыңгыз хан олуг падишаһ булганнан соң, Җалайыр ыругының барчасы үзләрен бәндә булган җалайыр кеби могул, Кыян ыругыннанбыз диделәр. Ул җалайырлар ун-унбер буын Чыңгыз ханның дүртенче углы, ягъни нәбирәсенең нәбирәсе заманынача бәндә булдылар. Һәр падишаһзадә бүлешә-бүлешә ишекләре алдында ун йә егерме өй җалайырдан булыр иде. Җалайырның аслый сөякләре могулның Дөрләгин ыругыннандыр, ләкин иле Нөкүз әүлядыннандыр.

## Могул падишаһларының зикере

Кыян илән Нөкүзнең әүляды Әркинәкун эчендә күп булгач, һәр җәмәгать бер ыруг исемен күтәрделәр. Кыян нәселеннән Корлас исемле бер кеше бар иде, аның нәселе һәммә ыруглар арасында күп булды. Аларга Корлас иле диделәр, шул Корлас нәселеннән бер затны падишаһ күтәрделәр, аты мәгълүм имәс. Аның бәгъдендә[2] һәмишә шул Корластан түрәләр кылдылар. Халык Әркинәкуннан чыкканда, падишаһлары Корлас ыругыннан бер Тәҗнә исемле иде. Ул үлгәч, аның Куймарал исемле углын падишаһ кылдылар. Ул вафат булгач, аның Бичин Кыян исемле углын падишаһ кылдылар. Ул дарелбакыйга киткәч, аның Тимач исемле углын падишаһ кылдылар. Ул үлгәннән соң, аның Кычый Мәргән исемле углын хан күтәрделәр. Ул үлгәннән соң, аның Бука Бәндүн исемле углын хан иттеләр. Ул вафат тапкач, аның Сам Саучи исемле углын хан куйдылар. Ул дарелбакыйга рихләт иткәннән соң, аның Калмаҗу исемле углын хан күтәрделәр. Ул вафат тапкач, аның Тимерташ исемле углын хан иттеләр. Ул ахирәт сәфәренә юнәлгәннән соң, аның Менгле Хуҗа исемле углын хан куйдылар. Ул үлгәч, аның Йолдыз исемле углын хан күтәрделәр. Йолдыз ханның ике углы бар иде. Икесе һәм үзе терек булганда үлделәр. Бер углыннан бер угыл калды. Дубун Баян исемле вә икенче углыннан бер кыз калды Аланкува исемле. Аланкуваны олуг туй кылып Дубун Баянга алып бирде. Аннан соң Йолдыз хан вафат булды, нәбирәсе Дубун Баян Ата тәхетендә утырып, Могул иленә падишаһ булды. Утыз яшенә җитмәенчә вафат булды. Ике яшь углы калды, берсе — алты вә икенчесе җиде яшендә. Олугының аты Билгедай вә кечегенең аты Бәкҗедай иде вә бәгъзе нөсхәдә Билкенут һәм Бөркенут дип язалар.

## Аланкуваның гаҗәиб вә гараиб[1] хикәяте

Аланкуваның кәдходасы Дубун Баян үлгәннән соң, олуг атасы Йолдыз ханның ага вә энеләренең угланнары бар иде. Замандашларыннан булган илле вә нөкерле падишаһлар һәркаюсы Аланкуваны хатынлыкка теләделәр. «Җаным тәнемдә булып торганда, мин иргә бармам. Угланнарым егет булганчы үзем илгә баш булып торырмын. Аннан соң угланнарыма тапшырырмын», — дип, асла кабул кылмады.

Моннан соң берничә ел үтте. Бер кичә яткан иде, сәхәр вакытында уйганды, төннектән бер ярык нәрсә (нурлы шәй[2]) килеп керде. Көндәге кеби күрде ки, яктының эчендә бер кеше рәвешле ак вә сары төсле күз-

ләре шөгелле булып өйнең эченә керде. Аланкува янында яткан зәгыйфәләрне[3] уятмак өчен кычкырыйм диде, әмма тавышы чыкмады, теле бәйләнде, торыйм дисә, кул-аягының хәрәкәте туктады. Әмма гакылы китмәде. Ул кеше әкертен-әкертен катына килде һәм ир булып якынлык кылды, янә төннектән чыгып китте. Бу сүзне әйтсәм, һичкемсә инанмас дип әйтмәде. Биш-алты көн үткәннән соң, дәхи килде. Берничә көндә бер шул рәвештә һәнүз килә бирде. Ул килгән кичне Аланкува хамилә булды. Дүрт-биш айлык булгач, карендәшләре җыелып килеп, хамилә булганының вакыйгасын сорадылар. Аланкува вакыйганы сөйләп күрсәтте, дәхи әйтте: «Миңа ир кирәк булса, бармасмы идем вә дәхи, хатын булсам да, күп халык мине падишаһ кылып торгач, үземне бу кадәр илне вә халыкны һәм ике углымны шәрмәндә[4] кылып мондый нәмәгъкуль эшне хаша[5] кылыр идемме. Берничә кичә өемнең тышында саклап ятыгыз. Ходай Тәгалә мине оятлы кылырга теләмәсә, сезгә һәм ул гаҗәеп эшне күрсәтер вә дәхи шул ки, минем бу карынымдагы углан туса, әлбәттә, сурәте кешегә охшамас. Аннан һәм белерсез, бу кәйфиятьтә[1] минем хамилә булмагымда Ходай Тәгаләнең гаҗәеп бер хикмәте бардыр», — диде.

Бу сүзне ишеткәч, барысы да ышандылар, зирәки Аланкуваның һәркайсы холкын беләләр иде. Шулай булса да күп халык көндезен һәм кичен өйнең әтрафын саклап яттылар һәм нәүбәт илән уяу тордылар. Берничә көннән соң сәхәр вакытында төннектән өйнең эченә кояш кеби яктылык төшкәндә, югары асманнан түбән җиргә таба сузылган нәрсә пәйда булды, ул күргән кемсә катында ятканнарны уятты. Баягы нур килеп, Аланкува өенең төннегеннән керде, соңра бераз вакыттан соң чыгып китте. Ул нурның иңгәнен саклап яткан халыкның беразы күрде, әмма чыгып киткәнен, бәлки, һәммәсе дә күрделәр, шулай булса да кеше сурәтен күрә алмадылар. Моннан соң Аланкува сүзенең чынлыгы барчаларына мәгълүм булды.

## Аланкува балаларының зикере

Аланкува өч ир угыл тапты. Олугының аты Букун Катыйгыйн. Барча Катыгыйн иле аның нәселедер. Икенче углының аты Бускыйн Җалҗы. Һәммә Җалҗут иле аның нәселеннәндер. Өченче углының аты Буданҗар Мунак. Аны хан күтәрделәр. Чыңгыз хан вә могулның күп олуглары аның нәселеннәндер. Ошбу өч угланнан булган илләргә барчасына Нирун дирләр, «ару токым» мәгънәсендәдер, зирәки могулның зәгымынча нурдан булды дирләр. Буданҗарның ике углы бар иде, олугының аты Бука вә кечесенең аты Тука иде. Тукадан нәсел калганы мәгълүм түгел. Буданҗар үлгәч, Бука ханны хан күтәрделәр. Буканың Дутумнән атлы бер углы бар иде, үзе үлгәч, углы Дутумнәнне хан кылдылар. Дутумнәннең тугыз углы бар иде, сигезен җалайыр халкы үтерде, аның хикәятен югарыда «Җалайыр иленең зикере»ндә әйттек. Олуг углының аты Кайду иде. Ул кыргында сәламәт калды. Дутумнән хан үлгәч, Кайду ханны хан кылдылар. Кайдуның өч углы бар иде. Олугының исеме Байсонкар, икенче углының исеме Чиркаланком, Тайҗут иле аның нәселеннәндер. Чиркаланкомның олуг углының исеме Муркаду Күчнә, аның углы Мимикайкаан, аның углы Кадан Тайшидыр. Кадан исеме булып Тайши хытайча хуш вә яхшы авазлы (көйле) хафизга дирләр. Аны Тайши дирләр. Әгәр хафиз булса, аның углы Арал, аның углы Баргутай вә ләкабе Кырылтыйк. Аның мәгънәсе «көнче-саран» димәктер, үзбәк аш җийгәндә тончыккан кешене кырылди дир. Көнләп күп җийгәнлектән тончыкты дигәне булыр. «Кырылтыйк» «карлыгучы» мәгънәсендәдер. Тайҗут иленә баш Чыңгыз хан илән күп орышкан ошбу Баргутай Кырылтыйк иде. Өченче углының исеме Җаучин. Чиҗүт иле һәм Иртәгин иле аның нәселедер. Кайду хан үлгәннән соң, углы Чиркаланком үги анасын алды. Аннан ике угыл туды. Олугының исеме Кандучина, икенче углының аты Үлкәчинчина. Иркәк бүре вә оргачы бүре[1] мәгънәсендәдер. Аның угланнары күп булгач, аны Ченес диделәр. Ул «ченә»ннең җәмгысыдыр, төркисе чиналар димәктер. Бара-бара ул җәмәгатькә Нөкүз дип һәм әйттеләр. Бу Нөкүз мөкатдәмдә әйтелгән Нөкүзгә башкадыр, борыңгы Нөкүзнең исеме ил эчендә югалып китте. Олуг углы Байсонкарны хан кылдылар. Гакыл вә гадел яхшы падишаһ иде. Күп илләрне үзенә каратып, дусларга — яхшылык, яманга яманлык кылып берничә ел падишаһлык кылганнан соң, углы Төмәнәне үз урынында утыртып, үзе ерак сәфәргә китте.

Төмәнә хан яхшы олуг падишаһ иде. Могулның һәммә Нирун ыругларына күп еллар падишаһлык кылды. Ил аның заманында дәүләтле вә тыныч булдылар. Тугыз углы бар иде. Бәгъзе углыннан бер ыруг вә бәгъзеләреннән ике-өч ыруг булды. Ошбу тугыз угылның эченнән Кабул илән Каҗулы исемле ике углы игез туып иде. Олуг углының аты Нутакыйн, икенчесенең аты Орут, өченчесенең аты Мангыт. Бу өчесенең угланнары өч ыруг ил булдылар. Чаксунның икенче углының исеме Яримшир Буканчу. Аңардан туганнар дәхи бер ыруг ил булдылар. Өченче углының исеме Каҗулы вә аның углының аты Ирүмче Барлас булып, һәммә Барлас иле моның нәселеннәндер. Аксак Тимер ошбу ыругдан иде. Барласның мәгънәсе сипаһи димәктер. Төркичәсе — гаскәрне башлап йөри торган кешедер. Дүртенче углының исеме Симкачун булып, Идуркин ыругы аның нәселеннәндер. Бишенче углының исеме Бат-Кәлкидер, барча Будат ыругы аның нә-

селеннәндер. Алтынчы углының исеме Кабул хандыр. Чыңгыз хан вә аннан гайре күп ил бу Кабул хан угланнарыннан пәйда булмыштыр. Тәңре Тәгалә боерса, анларның һәммәсен үзалдына аерып-аерып әйтәчәкбез. Җиденче углының исеме Удур Баяндыр, Кийком ыругы аның нәселеннәндер. Сигезенче углының исеме Булҗар Дугландыр. Могул аксакны дуглан дир, бер аягы аксак иде, барча Дуглан ыругы аның нәселеннәндер. Тугызынчы углының исеме Чантайдыр, барча Ясут ыругы аның нәселеннәндер, һәммәсенең кинҗәсе ирде, кинҗәне могул утчикин дир, «утчикин» мәгънәсе «ут ясый» яки «ут агасы» димәктер. Аның өчен атасы угланнарын өйләндереп озата-озата (иң кече углы) өйдә ялгыз кинҗә кылыр һәм атасы учагының хуҗасы булыр. Кинҗә угылны могул рәсемендә барча угланнардан артык гыйззәт вә хөрмәт кылырлар. Чантай Утчикиннән туган угланнар баһадир вә булдыклы булдылар. Чыңгыз хан Мавәраәннәһергә килгәндә, Чәпә ноян дигән кемсәгә утыз мең кеше биреп, Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһының артыннан җибәрде. Ул Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһының углан-ушагын вә хәзинәсен алып барча Иран, вә Азәрбайҗан, вә Гөрҗестанны алды, вә Тимер капкадан үтеп, вә Дагстан, вә Чиркәс, вә Кыпчакны кырып, Идел вә Җаек суыннан үтеп, дүрт елда Чыңгыз хан кайтканда Алатауда артыннан җитте. Чәпә ноян Чынтай нәселе Ясут ыругыннан иде. Төмәнә хан үлгәннән соң, углы Кабулны хан кылдылар. Аның алты углы бар иде. Олугының исеме Улкин Баргак, икенчесе — Бартан Баһадир, өченчесе — Котукту Мәнгү, дүртенчесе — Кадан Баһадир, бишенчесе — Кублә Каан, алтынчысы — Будан Кыят, вә Кыятның мәгънәсен югарыда әйттек. Монда һәм әйтәек: таудан төшкән силне могул кыян дир. Кыят аның җәмыгыйндыр. «Кыят»ның асыл мәгънәсе «көчле вә елдам» димәктер. Таудан аккан сил кеби көчле вә елдам булганга күрә аны шул исем илән атадылар. Әркинәкун эчендә Кыян угланнарына Кыят дирләр. Күп еллар үткәч, һәр җәмәгать ил атын күтәрделәр. Аларның берсе Коңгыратмын диде, вә берсе Корласмын диде, вә берсе Дурманмын диде. Кыят исеме ил эчендә асла калмады, юк булып китте. Өч-дүрт мең ел үткәннән соң, шул нәселдән Кабул ханның алты углы булды. Алтысы һәм баһадир, вә пәһлуан, вә елдам иделәр. Шуның өчен аларга кыятлар диделәр. Кыят иле аларның нәселедер. Кабул хан вафат булгач, аның Бартан исемле углын хан күтәрделәр. Аның дүрт углы булды. Олугының исеме Мөнгүдәй, икенчесе — Бүкән Тайши, өченчесе — Исүгәй Баһадир, дүртенчесе — Дөрбәнай. Боларның угланнарын һәм Кыят диделәр. Бартан хан үлгәч, Исүгәй Баһадир ханны хан күтәрделәр. Исүгәйнең биш углы бар иде. Олугы — Чыңгыз, атасы куйган исеме Тимучин иде. Хан итеп күтәргәндә Чыңгыз исемен куйдылар. Икенчесе Җүчи Касар. «Җүчи»нең мәгънәсе «миһман касар» димәктер, гарәпчә — сәбыг, таҗикча — дад дирләр, дүрт аяклы ерткыч җанвардыр ки, иттән башка нәрсә җиймәс, төлке, вә бүре, вә юлбарыс, вә каплан, вә арыслан кеби. Өченчесе — Качун, дүртенчесе — Тимүкә, бишенчесе — Билгүтай Утчикин. Исүгәйнең биш углы Билгә нәселенең күбрәгенең күзләре коңгырт булды. Могул коңгыртны бурчыгыйн дир. Аның өчен Исүгәй Баһадирның нәселенә Бурчыгыйн Кыят диделәр.

### Аланкува әйткән иде ки: миңа килеп җефет була торган кемсәнең күзләре ак-сары

(Ала) Бурчыгыйн дию аның әйткән сүзенең галәмәте тугыз буынга килгәч мәгълүм булды. Бу сүз янә мәгълүм булсын ки, кешенең күз бәбәге кара булып, агы ак булса, бәбәге илән агының арасында каракызыл төс булса, гарәп аны әшһөл дип, могул аны бурчыгыйн дир. Шуңа күрә Бурчыгыйн Кыят диделәр.

# Өченче баб

### Чыңгыз ханның дөньяга килгәненең зикере

Чыңгыз хан биш йөз кырык тугыз тарихында Дуңгыз елында Могул йортында Булун Елдык дигән җирдә дөньяга килде. Бер кулы йомык иде. Әби булган хатын кулын ачып карагач, эчендә бер парә оешкан кан күрде. Моны, килеп, атасына әйттеләр, утырган ил халкыннан моны һичкем белмәде. Бер тәҗрибә иясе кеше әйтте: «Бу углан олуг падишаһ булыр, җир йөзенең һәммәсен алыр, күп илләрне вә вилаятьләрне кател гам кылыр[1]. Бу кан шуның нишанәседер[2]», — диде. Ул кеше әйткәне дөрес килде. Чыңгыз ханның ата-бабаларын югарыда әйттек инде, һәммәсен бер җирдә тәкрар итмәкне мөнәсәб күреп, дәхи әйтәбез. Чыңгыз хан атасының исеме Исүгәй Баһадир (могул атаны ичигә дир). Аның атасы Бартан хан (икенче атаны абуген дир), аның атасы Кабул хан (өченче атаны илинҗик дир), аның атасы Түмнә хан (дүртенче атаны будатур дир), аның атасы Байсонкар хан (бишенче атаны будункур дир), аның атасы Кайду хан (алтынчы атаны мурти дир), аның атасы Дутумнән хан (җиденче атаны дутакун дир). Могул җиде атагача ат куяр, аннан соң куймас. Төрек вә таҗикта барча адәм баласының эчендә җиде атасын да дәлил тотмак рәсемдер. Мәсә-

лән, төрек халкы әйтер: җиде бабадан яки җиде аркадан бирле тимерчемен; вә яки әйтер: минем җиде атам ошбу йортта торгандыр; яисә әйтер ки иде: борыннан бирле ярлылык төсен күргәнем юк дир, таҗик һәм шулай дир. Инде әйтә торган сүзләремнән калмаем ки, Дутумнән ханның атасы Бука хан, аның атасы Буданҗар хан, атасыз Аланкува атлы хатыннан туды. Аланкува Йолдыз ханның нәбирәсе иде, атасы егетлегендә вафат булды, фәкать анадан туып калды. Олуг атасы Йолдызның кулында үсте, ул сәбәптән атасының аты халык эченнән мәшһүр имәс. Йолдыз хан атасы Менгле Хуҗа хан,аның атасы Тимерташ хан, аның атасы Калмажу хан, аның атасы Сам Саучи, аның атасы Бука Бәндүн хан, аның атасы Күчүм Борыл, аның атасы Кычый Мәргән, аның атасы Тимач, аның атасы Бичин Кыян, аның атасы Куймарал, аның атасы Буртачина. Буртачина илән Кыянның арасы дүрт йөз илле елдыр. Бу икесенең арасында үткән кешеләрнең исемнәрен белергә күп сәгый[1] кылган идек, ләкин белмәк мөяссәр[2] булмады. Һичбер тарихта тапмадык. Әркинәкун эчендә бозыклык вакытында һичбер тарих язучы яза алмаган булса кирәк. Кыянның атасы Ил хан, аның атасы Диңгез хан, аның атасы Менгле хан, аның атасы Йолдыз хан, аның атасы Ай хан, аның атасы Угыз хан, аның атасы Кара хан, аның атасы Могул хан, аның атасы Өленҗә хан, аның атасы Киюк хан, аның атасы Диб Бакуй хан, аның атасы Илҗә хан, аның атасы Түтәк хан, аның атасы Төрек, аның атасы Яфәс, аның атасы Нух пәйгамбәр галәйһиссәлам, аның атасы Ләмәк, аның атасы Мәтәвәшләх, аның атасы Идрис пәйгамбәр, аның атасы Бирд, аның атасы Мөһляил, аның атасы Кыйнан, аның атасы Әнүш, аның атасы Шиш пәйгамбәр, аның атасы Адәм Сафиулла.

Исүгәй Баһадир үлгәндә, олуг углы Чыңгыз хан унөч яшендә иде, энеләре аннан яшьләр иде. Буданҗар хан нәселенең барчасы Исүгәй Баһадирның кул астында иде. Могулның рәсеме шул иде ки, елкы вә дөя, сыер вә куй — бу дүрт малдан падишаһ илдән уннан бер өлешен алыр иде. Әгәр бер падишаһның биш йә ун углы булса, атасы үлгәннән соң, берсен хан күтәрерләр вә үзгәсе халыкка кушылыр иде. Аларның малыннан һәр елда бер ат вә йә бер дөя алырлар. Әгәр алар үлеп, угланнары калса, алардан башка халыктан ничек алалар, барча малны шулай алырлар иде. Исүгәй Баһадирга мал бирә торган ил утызкырык мең өйлек бар иде. Барчасы үзенең карендәшләре Чыңгыз ханны яшь белделәр һәм курыкмадылар. Мал — Адәм фәрзәнденең мәгъшукы: бирмәк яман, алмак яхшы. Мал бирмәк өчен, Чыңгыз ханнан йөз чөереп, катыннан күчеп ерак җиргә барып утырдылар. Исүгәй Баһадир иленең эчендә Тайҗут ыругыннан башы вә малы күп юк иде. Ыругы илән илләргә баш булып күчеп аерылды. Ул вакытта Тайҗутның башы Баргутай Кырылтыйк дигән кемсә иде. Аның атасы Арал, аның атасы Кадан Тайши, аның атасы Мимикай Каан, аның атасы Муркаду Көчнә, аның атасы Чиркаланком, аның атасы Кайду хан. Монда Чыңгыз ханга кушылыр. Исүгәй Баһадирның иле икегә бүленде. Өч өлеше Тайҗутка кушылды, бер өлеше Чыңгыз хан катында калды. Ханның олуг атасы Бартан ханнан туганнар. Мангытның ярымы вә үзгә илләрдән ике йөз өйлек, йөз өйлек, илле өйлек, ун өйлек, биш өйлек калды. Араларында Мангыттан күбе юк иде, ул вакытта Мангытның хан катында калганнарының башы Кыелдар дигән кемсә иде. Катыгыйн вә Хөҗүт, вә Җуйрат, вә Кыят башы бөтен Тайҗутка кушылды. Меркит иле Исүгәй Баһадир илән яу иде, ул дәхи Тайҗутка иярде. Атыша, вә чабыша, вә елкы куалаша утырдылар.

## Чыңгыз ханның унөч яшеннән кырык яшенәчә кылган эшләренең зикере

Чыңгыз ханның анасы Олун исемле иде, ике ләкабе бар иде. Берсе — Олунигә вә икенчесе — Олун Кучин. «Игә» могул теледер, «олуг» дигән мәгънәсендә, «кучин» хытай теленчә «өйнең вә малның иясе» димәктер. Моның мокабилендә[1] могул хатын дир, таҗик бану дир, үзбәк байбичә дир. Олун Әлканут ыругыннан гакыллы вә булдыклы вә эшләрнең башына чыгучы хатын иде. Куныкмар ыругыннан бер кеше бар иде, шәехлек кылып барча могул халкының пире хисап кылыныр иде, исеме Менглек, ләкабе Ичигә иде. Могул халкы атасыны ичигә дир, аны сыйлап һәм кадерләп һәммә могул халкы дирләр иде. Төрек халкы газиз кешеләрне ата дир. Мәсәлән, хәким ата вә сәед ата дигән кеби. Чыңгыз хан анасы Менглек Ичигәгә барды, ул сәбәпле барча Куникамар ыругы Чыңгыз ханга кушылдылар. Мин тарихны могулда, үзбәктә үткән яхшы падишаһлар вә гакыллы биләрнең асылын, вә кылган эшләрен, вә әйткән сүзләрен — һәммәсен тәфсиле бәян итеп олуг китап итмәк күңелемдә бар иде, шуларны язып, китап тасниф кылаем дигән идем, ләкин шул арада хаста булдым, хастам озакка тартылды. Күңелемнән әйттем, үлә калсам, китап язылмый калыр, минем кеби ул тәварихларны белгән кеше юк, хосусән безнең халкыбызны Ядгәр ханнан мин фәкыйрьгәчә ят йортның кешесе моны белмәс, үз халкыбызда һич белә торган кеше юк, бәс, мин моны гүргә алып барганымнан ни файда дидем, бәс алдыма дүрт кара савыты утыртып язарга шөруг кылдым[1]. Адәмнән Җүчи ханга килгәнче гяһ иске тарихлардан карадым, гяһ аларга карамый яздым, зирәки барчасын күңелдән ят белер идем. Шибан ханнан үземә килгәнче, әмма хасталыктан куәтем китеп гяһ утырып, гяһ

ятып әйтәдер идем. Шул сәбәпле мохтәсар[2] кыска кылдым, ләфызы мохтәсар булса да, мәгънәсе мохтәсар имәстер.

Тайҗут башлык Нирун иленең күбесе Чыңгыз хан унөч яшендә булганда яу булдылар, күп атышып чабыштылар, бер-берсенең хурлыгын асла күтәрә белмәделәр. Барс елы башында, Чыңгыз хан кырык яшенә җиткәндә, теге яктан бер кеше Чыңгыз тарафына качып килде. Тайҗут башлык барча Нирун иле илән сезнең өстегезгә атланды вә ят илләрдән Бияут, Меркит вә Татар дәхи Тайҗутка кушылып бергә атландылар дип хәбәр бирде. Чыңгыз хан ул вакытта гафил имәс иде, яхшы вә яманны күреп, эссе вә суыкны белеп, ачы вә төчене күп татыган иде, үзенә ияргән илне  өе вә малы илән бер җиргә җыйды, барысы унөч ыруг ил булды, унөч бүлек итте, бер-берсе арасын тигез куеп түгәрәк итеп кундырды, малның яхшыларын куныш-ның ихатасына баглатып, яманнарын тышка таба чыгарып куйды. Шул вакытта яу килде. Чыңгыз хан атланып ихатага арт илән торып яуга каршы торып сугышты. Чыңгыз хан ун, мең яу утыз мең кеше иде, бик каты вә озак сугыш булды, ахры Ходай Тәгалә Чыңгызга нәсыр[3] биреп, кулын өстен кылды, шул көнне биш-алты мең кешене үтерде. Тайҗуттан кулга төшкән яхшыларын баглатып куйды һәм җитмеш җирдә казан астырды, һәркайсысына тулдырып су салдырды, су кайнаган вакытта кулларын вә аякларын баглатып, башлары илән кайнаган суга салдырып, ике аякларыннан югары таба күтәреп тордылар, та мөһере пешеп үләр дәрәҗәгә җиткәнче шулай газапладылар. Аннан соң атланып Тайҗут иленә барды вә чапты, яхшыларының углан, бала-чагасын бәндә кылды, яманнарын сөреп китереп үз иленә кушты, ул ил кушылгач, бик көчле булды, исеме вә авазәсе могул эчендә мәшһүр булды.

## Чыңгыз ханның Кирәет Уң хан илән орышып җиңүче  булганы

Җуйрат иленнән Чамука чичән дигән кемсә бар иде, «чичән»нең мәгънәсе гарәб «гакыл» дир, вә таҗик «ба-хиред» диер, вә могул, вә үзбәк «чичән» диер. «Гакыллы» димәк мәгънәсендә, бу вакытта һәм сүзне яхшы сөйләгән кешене дирләр, гакыллы димәк булыр, гакыллы булмаса сүзне ничек яхшы сөйләшсен. Чамука чичән Уң ханның олуг углы Сәнкүнгә барып әйтте: «Сез ата вә угыл Чыңгызны үзегезгә дус беләсез, ул астыртын кеше җибәреп, Найманның ханнары Тияң хан вә Боерык хан илән сөйләшәдер ки, без өчебез иттифак булаек һәм Уң хан углын һәлак кылаек дип һичкем Чыңгыз ханның серен моннан артык белмәс, бу серне сезгә шуның өчен әйттем ки, сезнең илән бер җирдә туып үсеп карендәш булдым, минем әйткәнем рас икәнен тиз белерсез».

Найман илән сөйләшә дигәннең мәгънәсе шул ки, Кирәет йорты илән Найман йорты тоташ булыр, араларында асла ил булмас иде. Бу сәбәптән бер-берсе илә дошман иделәр, гяһ ярышырлар вә гяһ орышырлар иде. Чамуканың бу сүзенә ата вә угыл икесе дә ышандылар, әмма атасы әйтте, Исүгәй Баһадир вә углы Чыңгыз хан безгә кылган яхшылыкларының хәде[1] вә ниһаяте юк, әүвәл ул яманлык кылмаенча, без ничек кылырбыз, Чамука күп сүзле бозык кешедер, аның сүзенә ышанып дус илән дошман булмак яхшы булмас, диде. Уң ханның Исүгәй Баһадирның безгә яхшылык кылганының күптер дигәненең мәгънәсе будыр: Кирәет иленең Маргуз исемле бер падишаһы бар иде. Вә аның дәхи ике углы булып, олугының исеме Курчакор вә кечегенең исеме Күрмаргуз; хан үлгәннән соң, илне икегә бүлеп, ике углы алып утырдылар. Курчакорның биш углы булды: олугының исеме Уң хан, икенче — Иркә Кара, өченче — Байтимер, дүртенче — Мамишай, бишенче — Җабику. Барчасы да булдыклы вә гайрәтле угланнарын кәдхода кылганнан соң, Курчакор вафат булды, угланнары атадан калган илне вә малны яхшы алышып утыра белмәделәр. Аз ил вә күп түрә булды. Уң хан вә кечек энесе Җабику бер яклы булды. Иркә Кара калган ике энесе илән икенче яклы булдылар, шулай итеп орыштылар. Уң хан галиб килде, Иркә Кара качып Найман эченә барды вә, Найманнан булышлык алып килеп, Уң ханны куалап, йортына ия булды. Уң хан качып Исүгәй Баһадирга сыенды. Исүгәй Баһадир атланып барып, Иркә Караны куалап, Уң ханны атасы урынына утыртып кайтып килде. Иркә Кара агасы Күр хан катына барды. Күр хан энесе Уң ханга күп кеше җибәреп әйтте: «Атадан биш угыл калгансыз, бу чаккача арагызда яхшылык вә яманлык булса, аны урал кылыгыз[1]  һәм илне һәммәсен бүлеп алып тыныч утырыгыз». Уң хан агасының сүзен кабул итмәде; агасы Күр хан, Уң хан сүзен кабул кылмаганына ачуланып, атланып Уң ханның өстенә йөрде. Уң хан сугыша алмый аз кешеләр илән качып Исүгәй Баһадирга килде. Баһадир янә атланып барып, Иркә Кара илән орышып, аны үтереп, Уң ханны хан кылып кайтты.

Аннан соң Уң хан олуг падишаһ булды, дәүләте көннән-көн зиядә[2] булды. Бу яхшылыкларны онытып, Чыңгыз ханга кыз бирәбез, дип чакырып кеше җибәрик һәм, килгәннән соң, башын кисик, дип, Бокадай Кинҗат дигән кемсәне чакырырга җибәрде. Ул кешенең исеме Бокадай иде. Уң ханның Бөкәвели иде. Могул Бөкәвелине кинҗат дир. Ул вакытта өйләре якын иде. Чыңгыз хан, Чамуканың сүзеннән вә Сәнкүннең хәйләсеннән гафил булып, янына ике кеше алып, Уң хан өенә китте. Юлда Менглек Ичигә очрап, Уң ханның хәйләсен тәфсилә бәян кылды. Чыңгыз хан Бокадай Кинҗатка әйтте: «Бу көндә сугым ит арык, Хода

боерса, берничә көн үткәннән соң үзем хәбәр итәрем», — дип, Бокадай Кинҗатны яхшы сыйлап озатты. Бу вакыйгадан биш-алты көн үткәч, Чыңгыз ханның катына ике егет килде, олугының аты Бадай вә кечегенең аты Кыйшлык, алар әйттеләр: «Бер хәбәр илән килдек». Хан сорады: «Ул нинди хәбәр? Сөйләгез», — диде. Бадай әйтте: «Кирәет Бүкәҗирән дигәннең елкычысы мин, төнәгеннән елкыдан сөт алып барып өйнең тышында торган идем, Бүкәҗирән энесе Алакка әйтте, Бокадай Кинҗат Чыңгыз ханның каршыннан кайтып килгәннән соң хан киңәш кылды ки, Чыңгыз хан безнең кылаек дигән  хәйләбезне белде, инде хәйлә вә мәкер илән эшне бетереп булмас, иртәгә кичкә атланып таң атудан мөкатдәм Чыңгыз ханны өендә басаек, диде. Мин, бу сүзне ишеткәннән соң, сөтне биреп, сезне хәбәрдар кылаем дип йөгереп килдем», — диде. Чыңгыз хан, бу хәбәрне ишеткәннән соң, әтрафындагы утырган иленә хәбәр бирде һәм күчүне күчерде һәм, сезләрне Балчуна болагында табарым, дип озатты. Үзе илән ихласлы өлфәт[1] вә баһадир кешеләрен алып калды, барысы ике мең биш йөз кеше булды.

Кичә илән атларының тезгеннәрен тотып, әзерләнеп, йортта көтеп утырдылар. Афтаб[2] ике нәйзә[3] буе күтәрелгәч, яу килде. Барысы унике мең кеше иде. Ике тараф саф тартып орыштылар. Хан катында киңәш иясе Мангыт Куелдар чичән бар иде. Хан аннан мәслихәт сорады, ул әйтте: «Мин үз җәмәгатем илән яуның артына чыгып, әләмне анда кадыйм, сез алдан сугышыгыз», — диде. Куелдар әйткәнчә гамәл кылды. Бер тарафтан Чыңгыз хан сугышты. Кирәет халкы җыелып-җыелып килеп өч мәтрәбә чапты, Чыңгыз хан тарафы орып кайтарды. Дүртенче кәррә һөҗүм кылганда, Уң ханның олуг углы Сәнкүннең йөзенә нәйзә илән чәнчеделәр. Кирәетнең күбесен шул җирдә үтерделәр, берничәсе яралы булып кайтты. Чыңгыз хан әйтте: «Әгәр болай йортыбызда гына торсак, аның безгә зыяны күп булыр, зирәки аның куәте күп килер, инде бу чаклы һөҗүмнәрен кайтаргач, үз көченең артыннан китәек», — дип йөри бирде. Яу шул җирдә калды. Кирәет халкы Чыңгызның кай якка киткәнен асла белмәделәр. Чыңгыз Балчуна болагында күчүнең артыннан җитте, болакның суы аз иде, һәммәсенә җитәрлек булмады, шуңа күрә ул төштә утыра алмады, аннан күчеп Кола суы буена килде. Сунын буе илән күчеп барганда, утырган илгә юлыкты: «Ни ил сез?» — дип сорадылар. Болар: «Коңгыратбыз», — диделәр. Ул вакытта Коңгыратка баш булып йөргән олугның исеме Төрек Әмәл иде. Хан аңа кеше җибәрде: «Һичбер заман сезгә яманлык касд кылырга теләмимен, әгәр ил булсагыз, дәүләтемә шәрик[4] булыгыз, вә әгәр яу булсагыз, менә үзем алдыгызга килеп торамын». Ул кеше, барып, бу сүзләрне әйткәннән соң, Коңгыратның барчасы килеп, ханны күреп чын күңел илән табигъ булдылар. Аннан соң Кола суыннан күчеп, Кунканавар дигән суга килеп тынычлап утырдылар.

Бәгъдә Илдүркин ыругыннан Аркайчун баһадирны илче итеп Кирәет Уң ханга җибәрде. Бу сүзләрне әйтергә боерды: «Ике кәррә йортыңны алдырып атамның ишегенә килдең, икесендә дә атам, барып, йортыңны кайтарып алып биреп, сине атаң тәхетенә утыртып кайтты, үзем биш-алты җирдә сиңа яхшылыклар кылдым, барчасын тәфсилә зикер итеп хатыйга язсак, ничә дәфтәрләр язарга тиешле булыр идем.  — Дәхи әйтте: — Мин синнән мал вә ил теләгәнем юк һәм гайре гөнаһ та кылганым юк, бәс, ни сәбәп өчен үзеңне һәм мине орасың? Арбаның ике көпчәге бөтен булса, төзек күчәр синең дәүләтеңне йөкләп йөргән арбаның бер көпчәге мин идем, ни өчен дәүләтеңне тәләф итәсең?» Аркайчун, барып, бу сүзләрнең барчасын әйтте. Уң хан бу сүзләрне ишеткәч, диде: «Чыңгыз ханның һәммә сүзләре дөрес, моңа һич җавабым юк, бу эшләрне кылып йөргән углым Сәнкүндер, аңа бар, җавабын ул бирсен», — диде. Аркайчун Сәнкүн катына барды. Сәнкүн әйтте: «Икебез орышаек, Тәңре кайсыбызга нәсырат бирсә, аңа булсын, менә сүзнең җавабы», — диде. Чыңгыз хан кабат-кабат татулашыйк дип илче җибәрде, әмма Уң хан татулашмады. Солыхтан өмет өзгәч, Чыңгыз хан Уң хан өстенә атланып йөрде. Уң хан, моны ишетеп, атланып каршы чыкты; икесе сугыштылар, Чыңгыз хан галиб булды, Уң хан һәм углы Сәнкүн һәркаюсы биш-алты кеше илән качып бер якка киттеләр. Кирәет халкы игенче булганга күрә балчык вә хишттән[1] салынган карья вә шәһәрләре күп иде, һәммәсе халкы илән Чыңгыз хан кулына күчте. Уң хан, Найманның Тияң хан катына барыйм дип йөргәндә, Найман вилаятенә кергәч, Тияң ханның Хуры Сумажу вә Таника дигән ике бәгенә  очрады. Кирәет кавеме Найманның яман дошманы иде. Моны ханга терек алып барсак, ихтимал, үтермәс дип шул җирдә Уң ханны барча янындагы юлдашлары илән үтерделәр һәм Уң ханның башын Тияң ханга алып бардылар. Тияң хан, инде мондый олы вә карт булган падишаһны ни өчен үтердегез, тере алып килмәк кирәк иде, дип, бәкләренең эшләрен гаеп күрде һәм, Уң ханның башына көмеш каплап, йөзен ишеккә таба каратып, һәмишә тәхете өстендә куяр иде. Беркөнне Уң ханның башы телен авызыннан чыгарып тибрәтте, шул көнне өч кәррә шулай кылды. Моны Найманның картлары яман ырымга (шомга) нисбәт бирделәр. Сәнкүн Тибет йортына барды, берничә еллар анда торды. Тибет халкы тотып үтерергә киңәшләшкәннәрен ишетеп, качып, Хотан вилаятенә барды. Хотанның хакиме Калач ыругыннан Кылыч Кара исемле иде, Сәнкүнне тотып үтерде һәм хатынын, бала-чагаларын, Сәнкүннең башын Чыңгыз ханга җибәрде.

## Чыңгыз ханның хан булганы

Чыңгыз ханга олуг дәүләт мөяссәр булды. Якын утырган илләрнең көчлесе багылмаса да, көчсезе вә азрагы берсе артыннан берсе килеп табигъ булдылар. Тарихы хиҗри биш йөз дә туксан тугызда, Дуңгыз елында, кырык тугыз яшендә Чыңгызны хан күтәрделәр. Найман Кәһрә дигән җирдә хан олуг туй вә бәйрәм кылып утырыр иде. Кунықмар ыругыннан Менглек Ичигәнең углы Күкчә килде. Күкчәне халык Тәңренең йөзе дирләр иде. Ул әйтте: «Миңа Ходадан ишарә булды, Тимучинга вә илдәге халыкка әйт, бу көннән соң Тимучин димәсеннәр, җир йөзенең падишаһлыгын Чыңгыз ханга, вә аның угланнарына, вә тохымына бирдем», — диде. «Чың»ның мәгънәсе «олуг» вә «каты» димәктер, Чыңгыз аның җәмигыдыр. Күкчә Могулстанның каты суыкларында кыш көннәрендә ялангач вә яланаяк йөрер иде, һәрничә көндә бер кәррә миңа гаибтән бер йөз ат китерәләр, аңа менеп барып, Тәңре илән сөйләшеп кайтам дир иде.

## Чыңгыз ханның Найман илән орышып галиб булганы

Найман кавеменең падишаһы Тияң хан Онгут иленең бәге Алакош дигән кемсәгә кеше җибәрде. Чыңгыз хан ыругының телен алмаган кешеләрне үтертте вә юашларын үзенә каратты. Кирәет йортыбызның бер олуг иле иде, аның ханын, яхшы олуг кешеләре илән кырды вә гавамнарын үзенә тәбгы кылды. Кечек, вак илләр курыкканнарыннан үзләре барып бәйгать[1] бирәләр. Борынгы тәҗрибә ияләре әйтмешләр, ун дәрвиш бер палас өстенә сыяр, әмма ике падишаһ җир өстенә сыймас, дип. Инде нәүбәт икебезнең беребезгәдер, ул өстебезгә атланудан мөкатдәм икебез, бер иттифакта булып, Чыңгыз ханның эшен бетерергә Тәңредән сораек. Алакош, бу сүзләрне ишеткәч, бер игътибарлы кешесен Чыңгыз ханга җибәрде вә Тияң ханнан ишеткән сүзләрне барысын да әйттерде. Чыңгыз хан, бу хәбәрне ишеткәч, һәммә бәкләрен чакырып киңәште, һәммә бәкләр әйттеләр: «Халән[2] атыбыз арыктыр, бераз симергәч, Найман өстенә атланмак кирәк. Чыңгыз хан атасының энесе Даритай Утчикин әйтте: «Ат арыклыгын бәһанә кыласыз, бу көнге эшне иртәгә калдырган кешенең эше һич бетмәс, сезнең атыгыз арык булса, минем илемнең атлары симез, барчагызга мин ат бирим», — диде.

Тарих хиҗри алты йөздә вә Сычкан елында атланып Тияң хан өстенә йөрде, Чәпә ноян дигән кемсәне шымчы итеп Тияң хан тарафына җибәреп иде. Ул бер кеше аркылы ма һүәәлвакыгны[1] бәян кылып җибәрде. Ул кеше әйтте: «Тияң хан Алтай суының буенда Найман гаскәреннән башка Меркит, вә Убрат, һәм Чуйрат гаскәрләренең көлләсе, Тияң хан алдына җыелып, Чыңгыз ханның өстенә йөрмәккә әзерләнмеш», —диде.

Тияң хан, Чыңгыз ханның килгәненнән хәбәр ишетеп, атланып каршы чыкты. Каравыллар, күреп, Чыңгыз ханга хәбәр бирделәр, аны ишетеп, шул хәл гаскәрне тәртип кылырга шөруг кылды. Энесе Җүчи Касарны уң якка баш кылды, олуг углы Җүчи ханны сул якка баш итте, үзе урта вә төпкә баш булды. Шул кәйфиятьтә һөҗүм кылып, иртәдән кич булганчы сугыштылар. Тияң хан каты җәрәхәтләнде. Найман гаскәре качты, Тияң хан үзе атланып йөри алмады. Сугыш тауның итәгендә булды. Тияң ханны тауның өстенә алып менделәр, ханнан кәефен вә хәлен сорадылар, һич җавап бирә алмады. Ханнан өмет өзгәннән соң, Найманның бәкләре әйттеләр, түрәлектән вә йорт-җирдән аерылып һәм ыруг илдән аерылып, ят йортка барып хурлыкта йөргәнче, үлгән яхшы, дип. Тияң ханны шул җирдә куеп, таудан төшеп, Чыңгыз хан илән янә орыштылар. Үзләре аз калгач, Чыңгыз хан әйтте: «Кан вә малыгызны багышладым, бәрәкаллаһ, егетләр, шулай булмак кирәк. Камил гайрәт илән ил вә ыругыгыз өчен кан түктегез, инде калганыгыз юкка тәләф[2] булмагыз, буйсыныгыз», — дип ничә кәррә әйтте, асла кабул итмәделәр, тәмам бер кеше калмый сугыша-орыша үлеп беттеләр. Боларның үлгәннәрен күргәч, Тияң хан катындагы кешеләр ханны атка салып качтылар. Бара-бара Тияң хан ат өстендә җанын тәслим кылды. Тияң ханның Көчлүк исемле углы бар иде, ул, сугыштан сәламәт чыгып, Тияң ханның олуг агасы Боерык хан катына барды.

## Чамука чичәннең үлгәне

Чуйрат (Жуйрат. — *М.Ә.*) Чамука чичәнне әйттек, Уң ханның углы Сәнкүнгә сүз биреп, бозыклык башлаган ул иде. Уң хан үлгәч, өенә барды, Чуйрат халкы утырып киңәш кылдылар. «Чыңгыз хан безем хуҗабыз һәм якын карендәшебездер, Уң хан безем нимебез[1] иде вә Найман Тияң хан дәхи нимебез иде, барып, аңа кушылып, Чыңгыз ханга ук аттык, бу эшләрнең барчасына сәбәп булып йөргән Чамука чичәндер. Аннан аерылмасак, без ил булмабыз», — диделәр һәм, Чамуканы тотып, кулын һәм аягын баглап, Чыңгыз ханга алып бардылар. Хан аны буын-буын кисеп үтерергә боерды. Буынын кискәндә әйтте: «Мин күңелемнән әйтер идем, Чыңгыз хан кулыма төшсә, буын-буын турап үтерер идем, дип. Әмма минем әйткәнем булмады».

## Чыңгыз ханның Меркит иле вә аннан соң, барып, Тангут йортын алганы

Тияң ханны җиңеп кайтканы көз вакыты иде. Ул кышны өендә кышлады. Яз булгач, Меркит иленең өстенә йөрде. Аның түрәсе Туктабики дигән кемсә иде. Тияң хан илән булган орышта ул Тияң хан тарафына кушылып сугышты. Чыңгыз хан илән сугышырга куәте җитмәгәч, качып Найман Боерык хан катына барды. Чыңгыз хан Меркитне алды һәм үзенең иленә аралаштырып кушты. Аннан соң Тангут вилаятенә барды. Тангутның түрәсе кальгага камалды. Аз көн эчендә кальганы алып, җир илән тиң кылды вә, падишаһын үтереп, һәр вилаятенә хакимнәр куеп, өенә кайтты.

## Чыңгыз ханның Найман Боерык хан өстенә йөргәне

Тангуттан кайтып килгән елны өендә кышлап, яз башында Боерык хан өстенә йөрде, илгә якынайды. Боерык хан Чыңгыз ханның атланганын ишетми аз гына кешеләр илән киек ауларга чыккан иде. Шул вакытта аңсыздан Чыңгыз хан аңа очрады һәм шул җирдә тотып башын кисте. Тияң ханның углы Көчлек вә Меркит Туктабики вә угланнары Җылаун вә Мажар илән Боерык ханның урдасында ауга бармый калган иделәр. Боерык хан катыннан кеше качып килеп хәбәр бирде. Көчлек илән Туктабики качып Иртыш буена киттеләр. Боерык ханның өен вә илен алып, Чыңгыз хан үз урдасына кайтты.

## Кыргыз халкының ил булганы

Чыңгыз хан Алтан илән Турамышны илче кылып Кыргызга җибәрде, миңа табигъ булсыннар дип. Ул вакытта Кыргызның падишаһы Ырыс Әйнал дигән кемсә иде. Яхшы кешеләрен күп һәдияләр илән җибәреп бакынды, һәдияләренең иң яхшысы — башы-аягы, вә борыны, вә күзе кызыл ак шоңкар иде.

## Чыңгыз ханның атланып Көчлүк илән Туктабикинең артыннан барганы

Кыш өендә торып, яз илән Көчлүкнең артыннан китте. Иртышка якын җиткәндә, Ойрат иле очрады. Бәгенең исеме Котука дигән кемсә иде вә Карлыкның ханы Арслан исемле иде. Үзләрен аз вә Чыңгыз ханны күп күреп ихтыярсыз итагать кылдылар, ханга башчы булдылар, Иртыш буенда Көчлүк илән Туктабикине табып бирделәр. Алар Чыңгыз ханга каршы орышып, тәкать тота алмый качтылар. Туктабикине тотып үтерделәр, Көчлүк, котылып, Төркестанда Кара-Хытай Күр хан катына барды. Күр хан яхшы гыйззәт кылып, үзенә кияү итеп кызын бирде, аннан соң Чыңгыз хан кайтып, урдасына төште.

## Уйгур халкының ил булганы

Уйгур халкының падишаһы Кот исемле иде, Кара-Хытай Күр ханга табигъ булып мал бирде, Күр хан һәм Шадикүм исемле затны даруга, ягъни зәкятчы итеп җибәрде. Шадикүм ул халыкның арасында карар тапкач күп фасык вә фәсад[1] кыла башлады ки, Уйгур иле аның бозык гамәленә тәкать кыла алмый бик рәнҗеделәр. Ул заманда Чыңгыз ханның Могулстан вә Хытайга барганы вә җәмигъ яхшылыклар кылганы галәм халкы арасында мәшһүр булган иде. Уйгур халкы падишаһы Кот Күр ханның кешесе, Шадикүмне үтереп, Чыңгыз ханга илче җибәреп гарыз кылды ки, ханның авазәсен ишетеп шәфкать вә мәхәббәтле күңеленә төшептер, үзем терек вакытта аларга табигъ булып хезмәтләрендә булсам иде. Илче Чыңгыз ханның урдасына килеп һәдияләрне вә гайре йомышларны әдә кылганнан соң, Чыңгыз хан Дөрбай дигән кемсәне уйгур падишаһы Котка илче кылып җибәрде. Илче Чыңгыз хан исеменнән җибәргән һәдияләрен чын күңелдән вә мәхәббәт итеп табигъ булганына тәхсин вә афәрин укып, күп елларга мәхәббәт илән гомер кичерергә теләде. Аннан соң Кот гарыз кылды: падишаһ Җиһанстанның кәрәменнән[1] өмет итәмен ки, падишаһның бишенче углы булсам иде. Әмма Чыңгыз хан аның сүзләрен, кызымны тели торгандыр дип, аңа бер кызын бирде. «Кот»ның мәгънәсе могул телендә «дәүләтле» димәктер.

## Чыңгыз ханның Хытай, вә Кара-Хытай, вә Чөрчет вилаятьләрен алганы

Хан Кишварстан Могул илләренең мөхаләфәсеннән[2] фаригъ[3] булгач, барча Могул илләрен үзенә караткач, һәммә могул биләрен бер җиргә җәмгъ кылып әйтте ки: «Хытай падишаһы Алтан хан минем аталарым вә агаларыма яман эшләр кылган иде, инде Ходай Тәгалә миңа носрәт[4] биреп, Хытай мәмләкәтен мәсхәр кылып аталарым вә агаларымның үчен Алтан ханнан алырмын дип өмет итәмен». Ханның бу сүзен биләр яхшы күреп, тәхсин итеп сүзне шуңа сөрделәр ки, Алтан ханга әүвәл илче җибәрәсе, әгәр ханның хөкемен кабул итеп табигъ булмаса, ул вакыт аның өстенә атланып бармак кирәк. Чыңгыз хан Чокыр Хуҗа дигән кемсәне илче итеп Алтан ханга җибәрде һәм әйтте: «Ходай Тәгалә җөмлә җир йөзенең падишаһлыгын миңа биреп торыр, минем шөһрәтем бөтен галәмгә җәелеп торыр. Син ки, Алтан хан, минем илчемне күреп, бу сүземне ишеткәч, миңа табигъ булып, олуг падишаһ белеп итагать кыл, әгәр сүземне кабул итмәсәң, күп гаскәр илән атланып, синең илән дуслык вә дошманлыкны сынашырмын. Ходай кадим таҗ вә дәүләтне кемнең башына куяр вә хурлык паласын кемнең өстенә ябар, шуны күрербез».

Чокыр Хуҗа, Алтан ханның урдасына барып, Чыңгыз ханның әйткән сүзләрен берәм-берәм әйткәннән соң, Алтан хан, ачуланып, Чокыр Хуҗага әйтте ки: «Чыңгыз хан мине үзгә төрекләр кеби белмәсен, әгәр орышырга һәвәсе булса, тиз килсен, мин аның илән сугышырга таяр булып торамын», — дип, Чокыр Хуҗага кайтырга рөхсәт бирде. Чокыр Хуҗа Хытайның юлларын вә мәнзилләрен[1] вә тауларын, суларын яхшы белеп вә күреп кайтты, вә килеп Алтан ханның әйткән сүзләрен гарыз кылды. Чыңгыз хан, бу сүзләрне ишеткәч, күп гаскәр илән Алтан хан өстенә йөрде. Алтан хан һәм утырган шәһәреннән сансыз гаскәр илән атланып чыкты вә бер дәрьяның авызына килеп төште. Дәрьяның юлы ниһаятьсез тар иде. Чыңгыз хан, Кишварстанга килеп, Хытайның күп вилаятьләрен алып, күп шәһәрләрен утка якты вә Алтан хан һәм бер бәген күп гаскәр белән Чыңгыз ханга каршы җибәрде. Чыңгыз хан гаскәреннән бер кеше, качып, Алтан ханның элгәре каршы җибәргән бәгенә килде вә әйтте: «Чыңгыз хан хисапсыз гаскәр илән килеп, Хытайның бер олуг шәһәрен алып, халкын кател гам кылып утка якты. Өлҗәләрне алып йөргәндә, мин монда качып килдем». Алтан хан бәге, бу хәбәрне ишеткәч, күп гаскәр илән Чыңгыз ханга таба йөрде. Чыңгыз хан бу гаскәрнең килгәненнән хәбәрдар булып олуг ләшкәр илән атланып, Тәңрегә сыгынып, Алтан ханның бәге илән йөзмә-йөз булып күп орыштылар. Чыңгыз ханга Ходай Тәгалә носрәт биреп, Алтан ханның бәгенә галиб булып, гаскәрен кател гам кылып, Хытайның күп кальгаларын алды. Аннан соң Чыңгыз хан пиядә[2] гаскәр илән дәрья авызында утырган Алтан ханга юнәлде.

Аның илән күп орыштылар. Ниһаять, Алтан хан, утыз мең кешесен кырдырып, Хан-Балык шәһәренә чигенде. Һәркем Хан-Балыкта падишаһ булып тәхетендә утырса, Алтан дирләр иде. Бу орыштан соң Чыңгыз хан Хытайның күп вилаятьләрен алды.

## Чыңгыз ханның Алтан хан иләнярәшеп кыз алып кайтканы

Алтан хан Хан-Балыкка качып барганнан соң ишетте ки, Чыңгыз хан вилаятьләрне вә шәһәрләрне алып, Хан-Балыкка барырга булган, имеш. Алтан хан бәкләре илән киңәш кылды, Чыңгыз хан илән орышкан яхшымы йә ярашкан яхшымы. Чингысан исемле вәзире бар иде. Ул: «Ярашкан яхшы булыр, — диде. — Зирәки солых иткәч, Чыңгыз хан үз йортына кайтып китәр вә без тыныч утырырбыз. Җәмигъ бәкләрне, вә аксакал, вә карасакалларны җыеп, йорт мәслихәте өчен яхшы киңәш итеп гыйлаҗны[1] кылмак кирәк».

Алтан ханга вәзирнең сүзе мәгъкуль булып, Чыңгыз ханга илче җибәрде вә пәрдән гыйсмәттә[2] кызы бар иде, аны ханга һәдия кылды. Чыңгыз хан Кишварстан Алтан ханның илчесенә күп гыйнаятьләр кылып, җибәргән кызын үзе алды һәм, разый булып ярашып, күп мал алып, үз йортына кайтып китте. Аннан соң Алтан хан, мәмләкәтне вәйран күреп, Тимин дигән шәһәргә барып тормакка уйлады.

Бу Тимин шәһәрен Алтанның атасы салган иде. Ул шәһәр гаҗәеп мөхкәм шәһәр иде. Әйләнәсе кырык фәрсәх[3] иде, бер олуг суның якасында вакыг иде. Таң иртә бер ягыннан йөрсәләр, икенче тарафына кич илән намаз ахшамында чыгарлар иде. Ошбу шәһәрне ихата кылган өч мозбут[4] кальгасы бар иде. Алтан хан Хан-Балык шәһәрен углына биреп, үзе Тимин шәһәренә юнәлде. Алтан хан, Хан-Балыкта торганда, Кара-Хытайның бер сәрдарын бер гөнаһ өчен үтергән иде. Шул сәбәп илән Кара-Хытайның берничә баһадиры, Алтан хан углының елкы, вә куе, вә дөя, вә сыерын куеп, Чыңгыз ханның чирүенә кушылдылар. Аннан соң Кара-Хытайдан бер егет хоруҗ[5] кылып, Хытайның бәгъзе вилаятьләрен алып, Чыңгыз ханга илчеләр җибәреп, гакыйбәт үзе халкы илән хан Кишварстанның хезмәтенә барып гыйнаять падишаһына вә мәрхәмәт хосрауанәсенә[6] махсус булды вә мондый күп халык, Алтан ханның бәкләреннән көфране нигъмәт[7] кылып, мәзкүр сәбәптән качып барып, Чыңгыз ханның урдасына кушылдылар. Алтан ханның углы биш айдан соң фәләкнең[8] рәфтарын[9] бикарар күреп, Хан-Балыкның хөкүмәтен бәкләренә тапшырып, үзе атасы катына

барды. Чыңгыз хан Алтан ханның гаҗизлегеннән хәбәрдар булып, Самука баһадир һәм Минкән баһадирны күп гаскәр илән Хан-Балык шәһәрен алырга җибәрде. Юлда Хытайның күбрәк халкы бу ике сәрдарга кушылып Хан Балыкка мөтәвәҗҗиһ[1] булдылар. Бу арада Алтан хан ишетте ки, Хан-Балыкта гаҗәеп ачлык, имеш, дип, шул сәбәптән Алтан хан ике бәгенә гаскәр кушып, берничә мең батман ашлык биреп Хан-Балыкка җибәрде. Ул ике бәк, ашлыкны алып килгәндә, Чыңгыз ханның ике сәр гаскәре илән очраштылар. Ошбу ике гаскәрнең арасында олуг орыш булды. Алтан ханның ике бәге, гаскәре һәм ашлыгы илән Чыңгыз ханның ике бәгенең кулына төштеләр. Алтан хан, бу хәбәрне ишетеп, зәһәр җыеп вафат булды.

Аннан соң Хан-Балык шәһәре Чыңгыз хан сәрдарларына мөсәххәр[2] булды. Могулның әмирләре Чыңгыз ханга илче җибәрделәр, Хан-Балыкны Алтан ханнан күп хәзинә вә дәфинәсе[3] илән алдык дип, Чыңгыз хан Кутуку ноянны ике бәге илән Хан-Балыкка җибәрде, Алтан ханның хәзинәсен йөкләп алып кайтырга дип. Бу өч бәк хәзинә вә дәфинәне йөкләп Чыңгыз ханның хезмәтенә кайттылар. Чыңгыз хан биш елда Хытайның күбрәк вилаятьләрен алды, аларда хакимнәр куйды, бәгъдә кайтып урдасына төште. Аннан соң Акашин вилаятенә йөрде. Ошбу шәһәрне ул чакта Тангут дирләр иде. Андагы вилаятьләрнең барчасын да алды, дәхи берьюлы Хытай вилаятенә барып калган вилаятьләрне мөсәххәр кылырга күңеленә беркетте, ләкин ул максуды мөяссәр булмады. Зирәки Найман Тияң ханның углы Көчлүк, атасы үлгәннән соң, Төркестан вилаятенә качып барган иде. Чыңгыз ханның бәгъзе дошманнары иттифак кылып, Көчлүкне падишаһ күтәреп, Солтан Мөхәммәдкә илче җибәреп, аның киңәше илән Күр ханга яу булды. Ул вакытта Күр хан Төркестанда вәли булып Кара-Хытайга табигъ иде. Көчлүк Күр ханның ярым вилаятен алды. Ул хәбәрне Чыңгыз хан ишетеп әйтте ки: мондый олуг дошман мәмләкәтемнең бер тарафында пәйда булып торганда, озак сәфәргә бармагым лаек имәстер дип, Хытайга бармакны куйды. Ул вакытта хәбәр килде ки, Меркит Туктабикинең энесе Куду өч углы илән качып барып Найман йортына утырып иде. Алар күп фетнә вә фәсад кылалар, имеш, дип, өсләренә Сүбүдәй Баһадир илән Коңгырат Тугачарны күп чирүк илән җибәрде. Алар барып Чөм-Муран дигән суның буенда табып, сугышып вә җиңеп, өлҗә вә әсир алдылар. Тарих алты йөз унөчтә Меркит иленең дәүләте киселде.

## Боргул ноянны Тумат иле өстенә җибәргәне

Тумат иле Чыңгыз хан Хытай йортына киткәч яу булган иде. Хан кайтып җиткәннән соң, Боргул ноянга ләшкәр кушып җибәрде, ул, барып, күп өлҗә вә әсир алып, ханның хезмәтенә кайтты.

## Чыңгыз ханның угланнары, вә хатыннары, вә кәнизәкләре

Чыңгыз ханның хатын вә кәнизәкләре күп иде, хәтта хисабы биш йөздән артык булган. Барча хатыннары ханнарның хатыннары вә кызлары иде. Барчасының олугы биш хатын иде: бере — Бурта Кучин — һәммә угланнарының анасы иде, икенче — Көнҗу — Алтан ханның кызы иде, өченче — Көйсу Тияң ханның хатыны иде, дүртенче — Мисылун, бишенче — Исүгән, ахыргы икесе Татар иленнән бер кешенең кызлары иде; берсе үлгәннән соң, икенчесен алган иде.

Дәхи дүрт углы бар иде: олугы — Җүчи хан, икенче — Чыгтай хан, өченче — Үгедәй хан, дүртенче — Тули хан. «Җүчи»нең мәгънәсе «миһман» димәк, «Үгедәй» мәгънәсе «бәлэнд» димәк, «Тули» мәгънәсе «көзге» димәк. Һәрберсен бер эшкә тәгаен кылып иде. Сохбәт[1], вә туй, вә уенны — Җүчигә, хөкем итмәк вә тоттырмакны — Чыгтайга, мәмләкәт малын саклап забит кылмакны Үгедәйгә вә гаскәр тәртибен Тулигә тапшырган иде.

Ошбу дүрт углыннан башка дәхи үзгә хатыннарыннан биш углы бар иде. Хытай йортын Алматы дигән җиргәчә алып, бу биш углы вә ага энесенең угланнарына биреп кайтып иде. Мәзкүр дүрт углына бүлеп биреп, бер җирдә утыртып әйтте ки: «Бер-берегез илән муаффәкать кылыгыз, мохаләфәт[2] итмәгез. — Шуларның каршында кулына бер укны сындырды, дәхи кулына берничә укны бергә кушып әйтте ки: — Моны сындыра алган кеше булырмы?» Һәркаюсы сындырырга касд иттеләр. Һичберсе сындыра алмады. Чыңгыз хан угланнарына карап әйтте ки: «Бу уклар сезгә охшар, әгәр барчагыз берегеп, берегезне падишаһ кылып, аның мәслихәтеннән чыкмасагыз, һичкем сындыра алмас. Әгәр иттифак итми мохаләфәт кылсагыз, бер укны ничек сындыралар, сезне һәм шулай сындырырлар», — дип, яхшы нәсыйхәтләр вә вәгазьләр сөйләде.

## Көчлүк өстенә Чәпә ноян дигәнне җибәргәне вә аның Көчлүкне үтереп кайткань

Найман Таяң ханның углы Көчлүк, Күр хан катына качып барып, Кара-Хытайга каршы аңа ярдәм итеп, соңра Күр хан илән яу булып күп вилаятьләрен алган иде вә Могул-Татар иленнән Чыңгызга дошманлык

кылып йөргәннәрнең һәммәсен үзенә ияртеп куәт тәхсил[1] кыла башлады. Чыңгыз хан, бу әхвәлдән хәбәрдар булып, Ясут ыругыннан Чәпә ноянга күп гаскәрне кушып Көчлүкнең өстенә җибәрде. Ул барып Көчлүкнең әтбагын[2] орышып җиңде вә басты, үзе аз халык илән качып китте. Көчлүк әтбагының калганын кырып вә бала-чагаларын әсир алып, үзен артыннан эзләп китте. Берничә көннән соң җитеп, янында йөргән һәмраһләрен[3] үтерде, үзе өч кеше илән качып Бадахшанда Сарыкол дигән дөррәгә барды. Чәпәноян дәхи артыннан барып, ничаклы эзләп-сорап йөрсә дә таба алмады. Ахирел әмер беркөн бер диһкан[4], җирне сөреп йөргән кеше әйтте ки: «Сез әйткән галәмәттә өч кемсә фәләнчә тарафка киттеләр», — диде. Чәпә ноян, моны ишетеп, җәһәтләп куып китеп, Көчлүкне тотып башын кисте вә, кайтып, ханның хезмәтенә килеп күп ингам вә сөюгә юлыкты.

## Чыңгыз ханның Мәхмүд Ялавыч дигән кемсәне Хәрәзем шаһы Солтан Мөхәммәдкә илче кылып җибәргәне

Чыңгыз хан Мәхмүд Ялавычны Хәрәзем падишаһы Солтан Мөхәммәдкә илче кылып, бу сүзләрне сөйләргә боерды ки: Ходай Тәгалә мәшрикъвтан синең вилаятеңәчә миңа һәммә җирләрне вә барча халыкларны мөсәххәр итте. Инде тиешлесе шул ки: син минем углым булып яхшылыкка сәгый[5] кыласың, та мөселманнар тыныч вә фәрагать[6] утырсыннар. Мәхмүд Ялавыч барып солтанга бу сүзләрне гарыз кылганнан соң, Солтан Мөхәммәд беркөн Ялавычны аулакка чакырып әйтте ки: «Синнән бер сүз сорыймын, растын әйт: синең ханың Хытай йортын алганы дөресме?» Шул сөаль соңында бер кыйммәт бәһале дөррәне[1] кесәсеннән чыгарып, Мәхмүд Ялавычка бирде. Мәхмүд Ялавыч әйтте: «Хода хакы өчен минем ханым раст әйтәдер, бу сүзнең растлыгы сезгә һәм тиз заман мәгълүм булыр иде». Бу сүздән Солтан Мөхәммәднең гаҗәп ачуы килеп Мәхмүдкә әйтте: «И Мәхмүд, син бераз фәһем итәсеңме ки, минем мәмләкәтемнең киңлеге вә әйләнәсе никадәр җирдер, вә минем дәүләтем ничаклы олуг дәүләттер, вә синең ханың нинди олуг вә шәүкәтле падишаһтыр, үзен миннән олуг күреп, мине «углым» дидер вә аның күпме гаскәре бар, миннән үзен югары тотар». Солтан Мөхәммәднең бу сүзеннән Мәхмүд Ялавыч бик курыкты, дәхи гарыз кылды ки: «Чыңгыз ханның гаскәре синең ләшкәрең янында айның нуры илән Афтабның нурына охшар». Мөхәммәднең бу сүздән ачуы басылып, Мәхмүд Ялавыч газабтан котылды. Аннан соң ике тарафтан гаһед[2] вә пәйман[3] кылдылар ки, бер-берсенең дустына — дус вә дошманына дошман булырга вә бер-берсенә яманлык кылмаска. Моннан соң Чыңгыз ханның илчеләре, солтаннан рөхсәт алып, хан Кишварстанның хезмәтенә кайттылар, вә Чыңгыз хан Солтан Мөхәммәднең гаһед вә пәйманыннан хуш хәл булып, солтан яманлык кылмый, аңа яманлык кылмаска күңеленә беркетте. Багдадтан Насыйр хәлифә солтанга мохаләфәт кылырга өндәп, ханга илче җибәрсә дә, әмма хан аңа илтифат итмәде, ике арадагы гаһедне сындырырга асла күңеленә китермәде, та Гаяр хан Солтан Мөхәммәднең хөкеме илән Чыңгыз ханның сәүдәгәрләрен вә илчесен үтергәнче дуслык җебен кисәргә теләмәде.

## Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһының Гаяр ханның әмере илән Чыңгыз ханның илче вә сәүдәгәрләрен үтергәннәре

Ул вакытта Иран илән Туран арасы шулкадәр имин иде ки, әгәр бер кеше мәгърибтән мәшрикъкача башына бер табак алтын куеп йөрсә, һичкемнең аңа тәгъриз[4] кылырга хәде юк иде. Могулларның утырган җирләрендә шәһәр юк иде, һәрдаим базарчылар вә сәүдәгәрләр комаш вә бүз, вә мәтаг, вә тун, вә чапан, вә буяу кеби малларны алып барып күп файдалар күрерләр иде. Бу һәвәс илән Мавәраәннәһернең базаркяннары иттифак кылып, Могул иленә кул булган малларны йөкләп, Чыңгыз ханның урдасына килделәр. Чыңгыз хан сәүдәгәрләрдән берсен чакырып китергән нәрсәләренә бәһа куйдырды. Ул сәүдәгәр бер алтынлык нәрсәне ун алтынга бәһа куйды. Чыңгыз хан сәүдәгәрнең бу эшен нәмәгъкуль күреп диде ки: «Бу кеше безнең мондый нәрсәләрне күргәнебез юк, ни бәһа куйсам да, белмәсләр, алырлар дип хыял кыладыр». Шул хәл хәзинәчесенә комаш китерергә боерды. Ул, барып, мең сандык әлван-әлван[1] ефәк затлары китерде, барчасын базаркяннарга күрсәтте, аннан соң бәһане ун өлеш артык тәгаен кылган сәүдәгәрнең малын таларга боерды һәм таладылар. Аның бәгъдендә башка сәүдәгәрләрне чакыртты, килделәр, комаш вә башка малларының бәһаләрен сорады. Алар әйттеләр: «Без бер бәһа да тәгаен кылмыйбыз. Әгәр зат шәрифегезгә мөнасиб булса, керем итеп алыгыз, сезгә һәдия вә сыйлаудыр. Без ул малларны сатар өчен китергәнебез юк», — диделәр. Ханга боларның сүзләре хуш килеп, барча китергән малларын алып, бер тәңкәлек нәрсәләренә ун тәңкәлек нәрсәләр биреп, күп гыйнаятьләр кылып кунак итте. Соңра барча бәкләренә хөкем итте ки: ул

сәүдәгәрләрнең катына кешеләр кушарга вә сәүдә өчен барган илләрдә хыянәт вә золым иттермәскә. Бәкләр һәммәсе ханның боерыгын урынына китереп, йөз иллеләп кешеләр кушып җибәрделәр.

Чыңгыз хан өч кешене Солтан Мөхәммәдкә илче кылып җибәрде: бере — Мөхәммәд Хәрәзми, бере — Гали Хуҗа Бохари, бере — Йосыф Отрарый. Аларга бу сүзләрне әйтеп җибәрде: «Сезнең базарчыларыгыз килеп, безнең гыйнаять вә шәфкатебезне күреп киттеләр, без һәм моннан берничә кешеләрне җибәрдек. Аларны мөмкин кадәрле сыйлап җибәрегез, дәхи син минем углым бул, Ходай Тәгалә барча галәмне без икәвебезгә биреп торыр. Без ата вә угыл булып бер-беребез илән яхшы булсак, юллар имин булып мөселманнар фәрагать утырып тыныч йөрерләр», — дип, илче вә базарчыларны җибәрде.

Алар Отрарга бардылар. Отрарның хакиме Солтан Мөхәммәднең агасы иде. Солтан Мөхәммәд аңа Гаяр хан дип ләкаб куйган иде. Базарчылар аны күрергә бардылар. Аларның арасында берсе Иналчыкның әшнә кемсәсе бар иде. Ул аңа Гаяр хан дими, Иналчык дип атады. Аның ул сүзе Гаярга яман тоелып, базарчыларны тотып, җасуслыкка килгәннәр дип мәгълүм итеп, Солтан Мөхәммәдкә гарыз җибәрде. Солтан Мөхәммәд бу эштә күп фикер кылмый үтереп, малларын алмакка хөкем кылды. Базарчы сәүдәгәрләрнең берсе, качып барып, Чыңгыз ханга бу вакыйгадан гарыз кылды. Чыңгыз хан, бу сүзләрне ишеткәч, бик каты ачуланып бәкләрен чакыртты вә алар илән Солтан Мөхәммәд өстенә йөрмәгә мәслихәт итте. Вә һәммә илләрдән гаскәр әзерләмәк илән мәшгуль булды һәм, өстеңә орышка барабыз, дип мәгълүм кылып, Солтан Мөхәммәдкә кеше җибәрде.

## Җүчи ханның Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһы илән сугышканы

Чыңгыз хан олуг углы Җүчине, Көчлүктән аерылып калган Төркестан әтрафында утырган никадәр ыруглар бар исә, шуларны каратып кил, дип җибәрде. Ул чакта Солтан Мөхәммәд Чыңгыз ханның үзенә каршы килгәненнән хәбәрдар булгач, гаскәр җәмгъ кылып Сәмәркандка барды һәм аннан Хаҗәндкә килде, анда барып җиткәч, Җүчи ханның Төркестан вилаятендәге илләрне чапканын ишетте, тиз заман гаскәре илән илләр утырган җиргә китте. Кабли илән Камаҗ дигән ике суның арасында кырылып яткан күп үлекләрне күрде. Шулар арасыннан бер үләргә яткан җәрәхәтле кешене табып, ни вакыйга булганнан хәбәр сорадылар. Ул әйтте: «Җүчи ханның килә торганын ишетеп качып килә идек, төнәге көн шул чакта артыбыздан җитеп, басып кырып, күп өлҗә вә әсир алып китте». Моны ишеткәч, Җүчи ханның икенче көн артыннан куып җитте. Солтан Мөхәммәднең җиткәнен күреп, Җүчи хан бәкләренә киңәште. Бәкләр әйттеләр: «Безне Чыңгыз хан Солтан Мөхәммәд илән орышырга дип җибәрде, чап вә ал дигән илләрне чаптык һәм алдык. Хәерлесе шулдыр ки: без аз, ул күп, чигенеп китәек, артыбыздан җиткән кеше күп булмас, алар илән орышырбыз», — диделәр. Җүчи хан әйтте: «Мин атама вә энеләремә ни йөзем илән күренермен. Яуныерактан күрдем дә качтым диерменме?» — дип, бәкләрнең сүзен кабул кылмады, саф тотып, Солтан Мөхәммәд илән сугышты. Җүчи хан үзе башлап ничә мәртәбә чапты, ахырында тугка[1] җитеп, Солтан Мөхәммәднең калканына ике-өч мәртәбә чапты. Моны күреп, Солтан Мөхәммәднең гаскәре качарга йөз бирә башладылар. Ләкин Солтан Мөхәммәднең углы Җәләлетдин яхшы эшләр вә тәдбирләр[1] йөртеп, гаскәрнең качмасына сәбәп булды. Ул көн кичкәчә сугыштылар. Төн булганнан соң, могуллар шул җирдә куналар икән дип белсеннәр өчен, төрле җирләргә утлар яктылар, әмма үзләре, чигенеп, төннең төн буе йөри бирделәр. Иртә илән Солтан Мөхәммәднең гаскәре барса, могулларның ут яккан урыннардан җилләр исә, аларның артларыннан китми кире кайттылар. Җүчи хан, кайтып, кылган эшләрен атасына бәян кылгач, ул хушхәл булып күп гыйнаятьләр кылды. Солтан Мөхәммәд бәкләре илән киңәшеп, һичберсе сугышмакны мөнасиб күрми гаскәрләрен һәр вилаятьләргә таратып, кальгаларга калырга боерды.

## Солтан Мөхәммәднең дәүләте кайтканының сәбәбе

Солтан бер кичә мәстлектә[2] анасы Төркән хатын илән төһмәт[3] кылып, Шәех Мәҗиделдин Багдадины шәһид кылдырды. Иртәсе көн кылган эшенә пәшиман булып бер табак алтын вә җәүһәрне Шәех Нәҗметдин Көбрага җибәреп әйтте ки: «Минем гөнаһымны Хода җәнабеннән гафу кылмакка дога кылсын». Шәех әйтте: «Аның хун[4] бәһасе алтын вә җәүһәр имәс, бәлки үтергән кешенең башы, вә минем башым, вә ничә мең халыкларның башларыдыр». Аннан соң әмир әл-Мөэминин Насретдин Әбү әл-Габбас хәлифә илән бозылышып, мөфтиләрдән фәтва алып, Термиз сәедләреннән Гали әл-Мөлек дигәнне хәлифә күтәреп, Насретдин хәлифәнең исемнәрен хөтбә вә сиккәдән[5] чыгарды. Дәхи берсе Гаяр ханның сүзенә колак биреп, Чыңгыз ханның илчесен вә базаркянларын үтертте вә болардан башка ничә төрле хилафе шәрыг[6] эшләр кылды, һәммәсен әйтсәк, сүз күп вә озак булыр.

## Чыңгыз ханның Бохара тарафына йөргәне

Тарих алты йөз унбишенче елда Чыңгыз хан биниһая гаскәр илән үз йортыннан атланып Отрар өстенә килде. Юлда Карлык халкының ханы Арслан хан күп гаскәр илән килеп кушылды, вә Әйдикот уйгурның күп иле Бишбалыктан килеп кушылды, вә Алмалыктан Сыгнак дигән кемсә иле илән кушылды. Үгедәй хакан вә Чыгтай ханны үтерергә тәгаен кылды. Җүчи ханны Җәнд тарафына җибәрде. Алак ноян вә Сиктү Боганы биш мең кеше илән Фәнакәнд вә Хаҗәнд тарафына җибәрде вә хан Кишварстан үзе Тули хан илән калган гаскәрен алып, Бохара тарафына йөрде. «Бохара» могул теленчә «гыйлем вә мәгърифәт җәмигъ була торган җир» мәгънәсендәдер. Чыңгыз хан Отрардан атланып Бохарага килгәндә, аңламастан Зарнук кальгасына җитеп килделәр. Шул хәл гаҗәеп сөрән салдылар, моннан Зарнук халкы берьюлы хәбәрдар булып, тизлек илән кальга капкаларын тартып кальгага камалдылар. Бу халык хәтсез курку илән курыктылар.

Чыңгыз ханның янында данишмәнд Хаҗиб дигән бер кешесе бар иде, үзе мөселман иде. Аны Зарнук халкына илчелеккә җибәрде. Данишмәнд Хаҗиб, барып, шәһәрнең халкына күп нәсыйхәтләр кылып куркыткач, шәһәр халкы күп бүләкләр илән чыгып ханны күрделәр, хан һәм аларга шәфкать вә мәрхәмәтләр кылды. Чыңгыз хан Зарнукның исемен Котлык-Балык куйды, ягъни «мөбарәк шәһәр» мәгънәсендә. Ул шәһәрнең егетләрен үзе илән һәмраһ кылып бергә алып йөрде вә картларына урыннарында калырга рөхсәт бирде. Дәхи ул җирдән атланып Турга килде. Тур халкы, моны ишетеп, кальгага камалдылар. Аннан соң күп илчеләр йөртеп, тәмам халык кальгадан чыгып, яхшы һәдияләр илән килеп ханны күрделәр; хан, һәм ул халыкка гыйнаять вә шәфкатьләр кылып, үзләренә кирәк кадәре азык вә тохым[1] кош, үгезне вә нөкүзне алып, кальгадан сахрага чыгарга хөкем кылды вә калган малларын хан гаскәренә таларга рөхсәт бирде. Ул халык ханның хөкеменә гамәл кылып кальгадан чыктылар, калган малларын ханның чирүге талап алды.

Аннан соң Чыңгыз хан атланып гашура аеның әүвәлендә тарих алты йөз уналтыда вә Елан елында Бохарага килеп кальганы камадылар. Ярым кичә булганнан соң, Солтан Мөхәммәднең Бохарада куйган бәкләреннән Күкхан, вә Сөенечхан, вә Көчлекхан егерме мең кеше илән Чыңгыз хан ләшкәренә сугышырга чыгарга табыл[2] сугып игълям[3] кылдылар. Ханның гаскәре һәм моннан хәбәрдәр булып каршы торып күп орыштылар. Ахирел әмер хан Кишварстанның дәүләте куәтле булып, егерме мең кешене басып бер анда[1] набуд[2] вә юк кылдылар. Таң аткач, дәрвазәләрне ачып, Бохараның җәмигъ шәех, мәшаих, вә мулла, вә мөфтие, яхшы вә яманы, шәһәрдән чыгып, ханның хезмәтенә килделәр, хан һәм атланып шәһәрнең эченә кереп, сәйран вә тамаша кылып, мәсҗет җәмигъның ишегенә килде вә мәсҗетнең эченә ат илән керде. Бу мәсҗет гаҗәп олуг гыймарәт[3] иде. Хан сорады: «Бу Солтан Мөхәммәд өеме?» — дип. Халык: «Тәңренең өедер», — диделәр. Аннан соң ат өстеннән төшеп, мөнбәрнең өстенә менде вә могуллар голяма вә мөҗтәһидләргә[4] ат тоттырып, үзләре гыйш вә гошрәт вә ашамак-эчмәк илән мәшгуль булдылар. Мосхәф[5] вә гайре әхкям[6] диния китапларына һич илтифат вә кадер итми, атларының аяк асларында тапталдылар.

Ул заманда Бохара сәедләренең бер олугы бар иде. Мосхәфнең кәгазьләрен атларының аягы астында күреп, бер мөҗтәһидтән сорады: «Бу ни эш вә ни вакыйгадыр?» — дип. Мөҗтәһид әйтте: «И сәед, тик тор, Ходаның газап вә тәкъдире». Чыңгыз хан аннан чыгып гаедкяһка[7] барды һәм җәмигъ халыкны алдына әзер кылды вә, мөнбәргә чыгып, мөселманнарның гаепләрен берсе артыннан берсен әйтә башлады. Солтан Мөхәммәднең вәгъдәгә хилафлык кылып базаркянне вә илчене үтергәнен сөйләде вә аннан соң әйтте ки: «И кавем, сездән олуг гөнаһлар садир[8] булды, Тәңре Тәгаләнең сезгә җибәргән каһәре вә бәласе мин. Мине сезгә мөсәлләть[9] кылып җибәрмештер. — Бу сүзләрне әйтеп бетергәч, әйтте ки: И җәмәгать, күренеп торган малыгызны әйтмәк хаҗәт имәс, әмма җир астында яшергән малыгызны кыенсыз, сугышсыз чыгарып бирегез». Моннан соң халык күренгән һәм яшерелгән малларын китереп-китереп бирделәр.

Ул арада бер кеше, килеп, ханга, бу шәһәрнең эчендә Хәрәзем шаһының күп кешеләре яшеренеп торалар, дип хәбәр бирде. Бу сүзне ишеткәннән соң, ханның хөкеме илән шәһәргә ут төрттеләр, Бохараның каср[10] гыймарәтләре янды. Таштан салынган гыймарәтләре янмады, калды, аның бәгъдендә бер мөхкәм әркнең[1] эчендә Солтан Мөхәммәднең бәкләре калганнар иде, аларны һәм табып үтерделәр вә Бохараның кальгасын җир белән тиң кылдырды. Әлкыйсса: Бохара хакан заманынача вәйран булды вә хаканның фәрманы илән яңабаштан Бохараны абад кылдылар.

## Үгедәй хакан вә Чыгтай ханның, Гаяр хан илән сугышып, Отрарны мөсәххәр кылганнары

Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһы иле мең кеше илән Отрар вилаятен сакламага куеп иде вә, татар гаскәре һәм Отрарга килергә касд кылган имеш дип, янә Солтан-Карача Хаҗиб дигән затны ун мең кешегә баш итеп, Гаяр ханга күмәккә вә ярдәмгә җибәрде. Отрарның эчендә алтмыш мең кеше илән Гаяр хан камалып ятты вә шахзадәләр биш ай камап яттылар. Отрарның эчендәге халык пәришан[2] була башлады. Карача Хаҗиб Гаяр ханга әйтте ки: «Отрарны шахзадәләргә биреп ил булыйк, шаять, бу камалып пәришан вә тәләф булмактан хәляс булырбыз», — диде. Гаяр хан аның сүзен кабул итмәде, зирәки бу фетнәләр аның сәбәпле вөҗүдкә килеп иде. Карача Хаҗиб ханны мәслихәткә күндерә алмагач, үзенең ун мең кешесе илән бер кичә Дәрвазәи-Суфи дигәннән чыгып, шаһзадәләрнең хезмәтенә килде. Шахзадәләр Карача Хаҗибка әйттеләр: «Син үз падишаһыңа вафа кылмагач, безгә ни яхшылык күрсәтерсең?» — дип, аны ун мең кешесе илән шәһид кылдылар. Аннан соң могуллар, Дәрвазәи-Суфидан килеп, Отрарның эченә керделәр. Отрарның җәмигъ халкын сахрага чыгарып шәһид кылдылар. Ул заман Гаяр хан егерме мең кеше илән әркә камалды. Аннан һәр көнне чыгып орышыр иде, яхшы мәрдәнәлекләр күрсәтте вә могул гаскәреннән күп кешеләрне үтерде. Үз катындагы кешеләре тәмам шәһид булып беттеләр. Могуллар дәхи әркнең кальгасын алдылар. Ахирел әмер Гаяр хан ике кеше илән качып бер там[3] өстенә чыкты, ул ике кешесе һәм шәһид булдылар.

Гакыйбәт, сугыша-сугыша Гаяр ханның угы төкәнде, аннан ары диварлардан хиштләрне каерып, ата-ата орышты. Ахирел әмер тирә-ягыннан камап, тере көе тотып, шахзадәләр алдына алып бардылар. Шул вакытта шахзадәләр Чыңгыз ханның Бохараны алып, Сәмәркандка барганын ишеттеләр. Үгедәй хакан вә Чыгтай хан гаскәре биниһая илән Сәмәрканд тарафына юнәлделәр. Гаяр ханны Күк Сарай дигән җирдә шәһид кылдылар.

## Җүчи ханның Җәндкә барганы

Җүчи хан Отрардан атланып Сыгнак килде. Хәсән Хаҗи дигән бер мөселман нөкере бар иде, аны Сыгнакка илче кылып җибәрде вә әйтте: «Халыкка барып нәсыйхәт кыл, килеп, мине күреп, кальганы бирсеннәр вә миңа итагать кылсыннар». Хәсән Хаҗи, Сыгнакка барып, халыкка күп нәсыйхәт кылып торганда, базар халкы моны үтермәк тиеш дип тәкбир әйтеп, Хәсән Хаҗиның өстенә һөҗүм кылып үтерделәр һәм дәрхаль[1] дәрвазәләрне беркетеп камалып тордылар. Бу хәбәрне ишетеп, Җүчи хан каты ачуланды вә могулларга кальганы ябышып менеп алырга хөкем кылды. Могуллар, бер сәгать эчендә ябышып ашасыннан төшеп, кальганы алдылар. Бер Хәсән Хаҗиның каны өчен ун мең мөселманны шәһид кылдылар вә Хәсән Хаҗиның углын Сыгнакка хаким кылдылар.

Аннан соң Җүчи хан атланып Үзкәндкә килде. Үзкәнд халкы, кальгадан чыгып, яхшы һәдияләр илән килеп, Җүчи ханны күрделәр. Хан һәм аларга мәрхәмәт итеп үзләренә һәм малларына тимәде. Аннан ары атланып Әснаш дигән кальгага килделәр. Әснашның халкы чыгып орыштылар. Җүчи хан гаскәре аларны басып, барчасын шәһид иттеләр. Ул хәлдә Җәнд хакиме, Җүчи ханның хәбәрен ишетеп, Җәндтән качып Хәрәземгә китте. Җүчи хан, моны ишетеп, Җантимер дигән нөкерен Җәнд халкына илче кылып җибәрде. Җәнд халкы итагать кылмый Җантимерне үтермәгә касд кылдылар, Җантимер, хәйләләр кылып, аларның кулыннан качып, Җүчи хан хезмәтенә кайтты вә андагы әхвәлләрдән Җүчи ханга бәян кылды. Җүчи хан, ачуланып, Җәндкә барып, Җәндне камады һәм тиз заман кальганы алды, Җантимерне үтерергә касд иткән кемсәләрне шәһид кылдырды вә гайре халыкның канын түкми барчасын кальгадан чыгарып, малларын талатып, Гали Хуҗа Гаҗдуванины Җәндкә хаким итеп тәгаен кылды.

## Алак ноянның Сиктү Бога илән Фәнакәнд вә Хаҗәндкә килгәннәре вә Хаҗәнд хакиме Тимер Мәлик зикере

Югарыда зикер кылып әйттек ки: Чыңгыз хан Алак ноян илән Сиктү Боганы биш мең кеше илән Фәнакәнд вә Хаҗәнд тарафына җибәрде, дип. Алар икесе, килеп, Фәнакәндне камадылар. Фәнакәнд халкы, өч көнгәчә дәрвазәләрне ябып, кальгага камалдылар. Дүртенче көнне халык барчасы, кальгадан чыгып, күп бүләкләр илән Алак ноян вә Сиктү Боганы күрделәр. Аннан соң бу ике сәрдар рәгыйять[1] олугларын — бер якка вә Солтан Мөхәммәд нөкерләрен икенче якка аердылар. Нөкер җәмәгатен үтереп, рәгыйять олуглары илән таҗик халкына атланып үзләре илән сөреп, Хаҗәндкә алып киттеләр. Әмма Хаҗәнднең Тимер Мәлик исемле хакиме бар иде ки, орыш көнендә Рөстәм вә Әсфәндияр аның алдында тәкать тота алмаслар иде. Тимер Мәлик Хаҗәнднең уртасында бер коры җир бар иде, шунда бер кальга салган иде. Ул кальга шулкадәр мөхкәм иде ки, гыйфрит хәтта боза алмаслык иде. Шул кальгада Тимер Мәлик мең егет илән камалды.

Алак ноян илән Сиктү Бога ул кальганы күреп таң-гаҗәпкә калдылар. «Ничек алырбыз?» — дип хәйран калдылар. Тимер Мәлик унике көймә ясатып, өсләрен түбәле әйләмеш иде. Ук вә мылтык атмак өчен һәр ике ягында тәрәзәләр кыйлынмыш иде. Ул көймәләрнең дивары шундый мөхкәм кылынмыш иде, ук вә мылтык аңа үтмәс иде. Ул көймәләргә утырып, шундый сугыш вә мәрдәлекләр кылдылар, могуллар тәхсин кылдылар вә һич тарафтан аларны ала алмадылар. Ахирел әмер могуллар югарыда мәзкүр булган илле мең таҗикны сөреп көймәләр алдына чыгарып кисәк вә ташлар ташлаттылар, әмма көймәдәге кешеләр төшкән кисәк вә ташларны суга ташлар булдылар. Ахирел әмер могул гаскәре галиб булгач, Тимер Мәлик җитмеш көймәгә мал вә әсбабларын йөкләп мәзкүр булган унике көймәгә үзе мең егет илән утырып, кальгадан чыгып, су буе илән йөри бирде. Алак ноян илән Сиктү Бога могул гаскәренә дәрья буенча Тимер Мәликнең артыннан йөрмәккә әмер кылдылар. Могул гаскәре көймәләрдәге халык илән сугыша йөрделәр. Ниһаять, Тимер Мәлик Фәнакәнд шәһәре тугрысына җитте вә күрде ки, суның бер ягыннан икенче ягына көймәләр үтә алмасыннар дип, могуллар бер тимер зынҗыр тартып торалар иде. Тимер Мәлик ул зынҗырны тәбәр[1] илән орып парә-парә кылды вә көймәләре аннан үтеп китте. Аннан соң могуллар һәр мәнзилләрдә[2] барып, Тимер Мәлик илән орышырга тайяр булып тордылар. Тимер Мәлик боларны күреп, дәрьядан чыгып, коры сахра илән яшен кеби Хәрәзем тарафына юнәлеп китте. Могул гаскәре Тимер Мәлик артыннан гөруһ-гөруһ[3] булып киттеләр һәм Тимер Мәлик артыннан җитеп бик каты орыштылар. Тимер Мәлик мең егете илән шундый ирлекләр күрсәтте ки, ахирел әмер егетләре тәмам шәһид булдылар. Аннан соң Тимер Мәликнең артыннан өч мең могул җитте, янында бары өч угы калган иде. Бер угының пикәне юк иде, шул пикәнсез ук илән бу өч могулның берсенең күзенә орды, күзе аннан сукыр булды. Могуллар, моны күргәч, кире кайттылар. Тимер Мәлик Хәрәземгә барды, дәхи Хәрәземнән гаскәр алып Кятькә барды. Кятьтә Чыңгыз ханның хакимен үтереп кайтып, Хәрәзем килде, дәхи Хәрәземнән Солтан Мөхәммәднең катына барды. Солтан Мөхәммәд аңа күп илтифат вә гыйнаятьләр кылды. Аннан китеп, Шамга барды. Анда берничә еллар торып, Хаҗәндкә кайтты. Чыңгыз хан аның углын Хаҗәндкә хаким итеп куймыш иде. Углы илән танышты һәм Үгедәй хакан хозурына китте, юлда Кадыйкан дигән кемсәгә юлыкты. Кадыйкан аны могул илән орышканын белеп, багланып, могуллар илән орышканын сорады. Ул һәм, бәли[4], орышкан идем, дип җавап бирде. Кадыйканның моннан ачуы килеп, аны бер ук илән орды. Тимер Мәлик шул җирдә шәһид булды. Алак ноян вә Сиктү Бога Хаҗәндне алып, Сәмәрканд тарафына мөтәвәҗҗиһ[5] булып Чыңгыз хан хезмәтенә килделәр.

## Чыңгыз ханның Кишварстанның Сәмәркандны алганы

Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһ могул гаскәреннән куркып йөз ун мең кешене утыз хан илән Сәмәркандка куеп иде. Ул гаскәрнең алтмыш меңе төрек вә илле мең таҗик иде. Һәркайсы орыш мәйданында арыслан йөрәк вә фил куәт иделәр, егерме сугышчы фил куеп иделәр. Бу әйтелгән кешеләрдән башка Чиннан халаек бар иде ки, саннан вә хисаптан тыш иде. Кальганың хәндакын[1] казып, су илән тутырмыш иделәр. Чыңгыз хан Отрарга килгәндә, Сәмәркандның мөхкәмлеге вә халаекның күплеген ишетеп, угланнарын Отрарга тәгаен кылып вә нояннарын Сәмәркандның сәрхәдләренә җибәрде, үзе Бохарага килеп, Бохараны алгач, Сәмәркандка килде, вә угланнары Отрарны алып вә нояннары сәрхәдләрне фәтех[2] кылып, Сәмәркандта хан Кишварстанның урдасына кушылдылар. Хәрәзем шаһының Сәмәрканд эчендә куйган ханнары сансыз гаскәр илән дәрвазәдән чыгып, Чыңгыз ханның бер парә гаскәре илән каты орыштылар, ул орышта Хәрәзем шаһ гаскәре могулларның берничәсен үтереп вә бер парәсен әсир кылып кайтып, Сәмәркандка керделәр. Иртәсе көн хан Кишварстан үзе атланып орышка килде. Ул көн шундый орыш булды ки, Хәрәзем шаһ гаскәреннән һичкем дәрвазәдән чыкмага хәдде[3] булмады, әмма кальганың өстеннән каты орыштылар ахшамгача. Аннан соң Сәмәркандның шәйхелислам илән казыйсы килеп, ханны күреп иминлек теләделәр. Хан һәм анларга күп гыйнаять вә илтифатлар кылды. Шәйхелислам илән казый, кайтып, Намазгяһ дәрвазәсен ачтылар. Могул, һөҗүм кылып, дәрвазәдән кереп, башка дәрвазәләрен һәм ачтылар. Җәмигъ могуллар таламак вә кырмак илән мәшгуль булдылар. Солтан Мөхәммәднең ханнарыннан Алып дигән мең кеше илән орыша-орыша котылып китте. Аннан гайре барча ханнар гаскәрләре илән бергә шәһид булдылар. Әһле сәнәгать вә һөнәрдән утыз меңне угланнары нояннарына өләштерде.

Аннан соң шәйхелислам илән казыйга илле мең өйлек халыкны бирде, аннан калганнардан ике йөз мең алтын имана алды. Бу вакыйгат тарих алты йөз уналтыда вакыг булды.

## Чыңгыз хан угланнарын Хәрәземгә җибәргәне

Хан Кишварстан Бохара илән Сәмәркандны алып, астын өстенә китергәннән соң, Җүчи хан, вә Үгедәй хакан вә Чыгтай ханны Хәрәзем өстенә тәгаен кылды. Шаһзадәләр гаскәр бинибһая илән Өргәнеч тарафына мөтәвәҗҗиһ булдылар. Ул вакытта Хәрәземшаһ бәкләреннән Хаммар Тегин, вә Могул Хаҗиб, вә Фәридун Гури дигәннәр бар иде. Хаммар Тегин Хәрәземшаһ анасы Төркән хатынның карендәше иде. Аны Өргәнечтә хаким кылган иде. Өргәнечтә Хәрәзем нөкереннән вә әшрәфеннән вә әкябиреннән[1] шулкадәр күп халаек бар иде ки, хисабын фәкать Ходай Тәгалә белгүчедер.

Ул мөселманнар фәләкнең хәрәкәтеннән вә дулкыныннан шулкадәр гафил иделәр ки, хәтта дошманнар ишегалларына басып кергәнчегәчә гафләт йокысыннан уйганмаганнар иде. Кинәт берничә атлы могул килеп дәрвазәнең алдында торган ат вә ишәкне алып киттеләр, атлы вә җәяүле йөз мең кеше могулларның артыннан куып киттеләр.

Өргәнечнең кальгасыннан бер фәрсәх[2] җирдә баг Хоррам дигән баг бар иде, ул урында могулларның артыннан җиттеләр. Ул җирдә могуллардан күп кеше яшеренеп-посып торырлар иде, ниһаять, ике тарафтан яшеренгән могуллар, атларына менеп, мөселманнарга бердән һөҗүм кылдылар. Шундый сугыш булды ки, йөз мең мөселманнардан торган биш-ун кеше хәляс булып шәһәргә кайттылар. Аларның артларыннан могуллар куа килеп Тинүрә дигән мәхәлләгә керделәр, ул мәхәлләне кичкәчә талап вә утка ягып кайтып киттеләр. Сабах[3] булганда, могулның бер бүлек гаскәре, килеп, шәһәрнең әтрафында саф тартып, кальганың өстеннән күзләрен алмый тордылар. Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһның Фәридун Гури дигән бәге биш йөз егет илән дәрвазәне сакларга тәгаен кылынды. Ул вакытта күрделәр ки, Җүчи хан, вә Үгедәй хакан, һәм Чыгтай хан, гаскәр бинибһая илән атланып килеп, Өргәнечнең әтрафыны камадылар вә Өргәнечкә илче җибәрделәр вә әйттеләр: әгәр безгә табигъ булып ил булсагыз, үзегез әман булып, бала-чагагыз өлҗә вә әсир булмас. Өргәнеч халкы аны кабул итмәделәр вә итагатькә муеннарын имәделәр. Аннан соң Хәрәзем гаскәре җиде ай һәр көнне иртәдән кичкәчә сугышыр булдылар.

Могуллар Өргәнеч әтрафында мөнҗәникъка[4] салмакка таш тапмадылар, тут агачының төп вә тамырларын кисеп, мөнҗәникъка салып атар иделәр. Ул арада могуллар Җәйхун дәрьясын багламакка уйладылар. Тауар-кәнечкә суны җибәрмәс өчен, өч мең могул атланып баглап, торган җиргә килеп эшкә шөруг кылдылар. Өргәнеч халкы моннан хәбәрдар булып килеп, өч мең могулны уртага алып, шундый каты сугыштылар ки, хәтта ул өч мең могулдан бер кеше котылмады. Һичбер вәҗһе[1] илән Өргәнечне ала алмадылар, зирәки шаһзадәләр арасында мөхаләфәт төшеп, куәтләренә зәгыйфьлек килде.

Чыңгыз хан угланнарының җиде айдан бирле Өргәнечне ала алмаганлыкларының сәбәбеннән хәбәрдар булгач, аларга кеше җибәрде. «Җүчи хан илән Чыгтай хан Үгедәй хаканны үзләренә мөкатдәм белсеннәр, вә аңа табигъ булсыннар, вә бер-беренә мохаләфәт кылмасыннар, аннан соң Хәрәзем шаһы илән йөзмә-йөз булып иттифак илә һөҗүм кылсыннар», — дәю фәрман җибәрде. Шаһзадәләр атасының ярлыгын тотып Үгедәйгә табигъ булып мохаләфәтне арадан чыгардылар вә, җөмлә гаскәрне Хәрәзем гаскәренә каршы куеп, бик каты орыштылар. Ахирел әмер Өргәнечне алып, һәммә мәхәлләгә ут куеп, тәмам халыкны сахрага чыгардылар. Аларның арасыннан йөз мең өй әһле һөнәрне алып калдылар вә яшь кыз-хатынны вә яшь угланнарны бәндә итмәк өчен алдылар вә болардан гайре халыкларны гаскәренә кыйсмәт[2] кылдылар. Һәрбер кешегә егерме дүрт кеше тиде, шуннан соң һәр могулга үзенең өлешенә тигән мөселманнарны үтерергә хөкем булды.

Могуллар һәркаюсы үз хиссасына тигәнне үтерделәр.

Риваять кылыныр ки, хәзрәте Шәех Нәҗметдин Көбраның авазәсе галәмгә мәшһүр иде. Ул сәбәптән шаһзадәләр хәзрәте шәехкә кеше җибәрделәр: «Шәех аяк астында калмасын, бала-чагалары вә барча өй җәмәгатьләре илән кальгадан чыгып килсеннәр», — дип. Хәзрәте шәех әйтеп җибәрде ки: «Мин ялгыз гына имәсмен, минем карендәшләрем вә хезмәткәрләрем бардыр. Шаһзадәләр: «Ун кеше илән килсен», — дип җибәрделәр. Шәех әйтте: «Уннан артыктыр», — диде. Шаһзадәләр: «Йөз кеше илән килсен», — диделәр. Шәех әйтте: «Йөздән дә зиядәдер», — диде. Шаһзадәләр: «Мең илән килсен», — диделәр. Моңа җавапта шәех әйтеп җибәрде ки: «Яхшылыкта мин бу халыкның тәмамы илән әшнә вә дус вә яр идем, инде яман көндә ничек боларны ташлап барыйм, юк, бу эшне кыла алмам», — диде.

Шуннан соң могуллар хәзрәте шәехнең мәхәлләсенә коелып килделәр. Хәзрәте шәех берничә могулны үз куллары илән җаннарын җәһәннәмгә җибәреп, үзе һәм шәһид булды. Иннә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигун.

## Чыңгыз ханның Нәхшеб, вә Термиз, вә Бәлхкә барганы

Чыңгыз хан, Мавәраәннәһерне мөсәххәр кылганнан соң, шаһзадәләрне Хәрәземгә җибәрде, үзе Сәмәркандка барды. Ул яз Сәмәркандта торып, Нәхшебкә килде, Нәхшебтән Термизгә килде. Термиз халкы та-

бигъ булмады, саф тартып сугыштылар. Ахирел әмер Чыңгыз хан Термизне алып, халкыны кател гам кылды.

Шөйлә риваять кылынмыштыр ки, ул вакытта могуллар бер хатынны үтермәккә алып килделәр. Ул хатын әйтте: «Мине үтермәгез, мин сезгә энҗе бирәем», — диде. Алар әйттеләр: «Энҗең кайдадыр?» Хатын әйтте: «Энҗене йоттым, эчемдәдер», — диде. Могуллар, ул хатынның карынын ярып, энҗене табып алдылар. Ул сәбәптән һич үлек калмады, барчасының карынын ярдылар.

Хан Кишварстан Термиздан үтеп Бәлхкә барды. Ул вакытта Бәлх шундый төзек шәһәр иде ки, анда мең ике мәчет җәмигъ бар иде вә мең ике йөз хаммамы[1] мәүҗүд иде. Әлхасыйль, Бәлхнең әһеле вә мәүласы килеп, ханны күреп аман теләделәр. Хан кабул кылмады, зирәки солтан Җәләлетдин терек иде, аның тереклегендә бу халык, әлбәттә, мохаләфәт кылыр диде.

Әлкыйсса: хан Бәлхнең халкы илән каты орышлар кылып, Бәлхне алды һәм халыкны кател гам кылып, кальгасын җир илән тигез кылды. Бәлхтән фаригъ[2] булгач, Тули ханны берничә нояннар илән Хорасан өстенә җибәрде. Хан үзе Талканга килде. Талкан гаҗәп бер мөхкәм шәһәр иде. Аның халкы табигъ булмады. Орыш әсбабы таяр кылып хан Кишварстан илән сугыш башладылар.

Әлкыйсса: җиде ай орыштылар, ахирел әмер Тули хан Хорасанны мөсәххәр кылгач, гаскәр биниһая илән Талканга килеп, атасына кушылды. Бу күп гаскәрләр, бер-беренә кушылып, Талкан халкы илән каты орышып, аларны җиңделәр, һич кешене куймай шәһид иттеләр, хәтта имчәк имә торган угланнаргача үтереп, кальгасын вәйран кылдылар. Аннан ары Әндирабны алып, халкын үтереп, кальгасын зир вә зәбер кылып үтеп, Бамиянга килделәр. Бамиян халкы кальгага камалып, күп орыш вә мәрдәнәлекләр кылдылар. Нагях ул сугышта Чыгтайның углына ук тиеп үлде. Ул угланны Чыңгыз хан бик сөяр иде. Хан Кишварстан ул хәлне күреп, авызыннан сөрем чыгып, могулларга кальганы ябышып алырга боерды. Могуллар кальганы ябышып алдылар һәм олуг вә кечек, яхшы вә яманнан, ир вә хатыннан бер кеше куймай үтерделәр вә кальганы җир илән тигез кылдылар. Чыңгыз хан ул кальганы Мау-Балык тәсмия кылды, ягъни Яман Кальга димәктер.

## Чыңгыз ханның Солтан Җәләлетдин илән орышканы вә аның Синд суыннан кичеп качканы

Ул вакытта Чыңгыз хан Солтан Мөхәммәднең артыннан Чәпә ноян вә Сүбүдәй Баһадир, вә Тугачар Коңгыратны җибәргәндә, Ханмәлик кеше җибәреп илмен дип калган иде. Тугачар аның сүзенә инанмай орыш күтәреп, кальгадан аткан ук тиеп үлеп иде, шул сәбәптән Чыңгыз ханнан куркуда иде. Ул арада солтан Җәләлетдин Газнин килгәнен ишетеп, солтанга кеше җибәреп әйтте ки: «Мин һәм бәндәлеккә килдем, гайрәтле булсыннар», — диде. Чыңгыз хан ихтият[1] өчен Газнин, вә Гөрҗестан, вә Забил, вә Кабулның юлларына Шики, Котуку ноян, вә Текәҗәк, вә Молка, вә Укар Калҗауны баш кылып, утыз мең кеше җибәрмеш иде. «Калҗау»ның мәгънәсе «мәзәк кылучы» димәктер.

Котуку ноян ишетте ки, Ханмәлик Солтан Җәләлетдингә кушылмага бара дип. Бәс, елдам артыннан китеп кич булганда басып җитте. Кич илән орыша алмай, иртәсе орышырмын дип, кичне төшеп кунды. Ханмәлик шул кичне йөреп солтанга кушылды. Текәҗәк вә Молка бер булып гаскәр илән Котуку нояннан аерылып Вәлиян кальгасын камап алыйм дигәндә, Солтан Җәләлетдингә күп гаскәр кушылганнан соң, бик тиз Вәлиянга барып могулларның каравылыннан мең кешене алып үтерде. Калганы, качып килеп, Котуку ноянга кушылды. Солтан Ханмәликне — уң якка вә Сәйфетдин мәликне сул тарафка куеп, үзе төптә торып могулларның өстенә килде. Могуллар дәхи саф тартып орыштылар, солтанның ләшкәре күп вә могуллар аз булып кичкәчә сугыштылар. Кич булгач, могул киездән вә шәлдән кеше ясап, атларның вә дөяләрнең өстенә беркетеп, артларында атларны ярдәмче гаскәр кеби күрсәтеп иртә торып орышка бардылар. Солтан Җәләлетдиннең гаскәре боларның кылган эшләрен белми булышлык килде дип качарга мәслихәт иттеләр. Солтан Җәләлетдин кычкырды ки: «Могуллар хәйлә төзегәннәр, курыкмагыз», — диде. Аннан соң гаскәр күңелләрен ныгытып бер мәртәбә хәмлә[1] кылдылар һәм могулларны чолгап алдылар. Ахирел әмер могуллар тәкать кыла алмай качтылар. Могуллардан күп кеше үлде. Шики, Котуку аз гына кеше илән качып, хан каршына килделәр. Чыңгыз хан ачуланып гаскәр җыймакка мәшгуль булды. Солтан Җәләлетдин кайтып, өенә төште.

Могуллардан күп өлҗә төшкән иде, аны бүлешеп йөргәндә, бер ат өчен Ханмәлик илән Сәйфетдин мәлик оршыштылар. Ханмәлик Сәйфетдиннең башына камчы илән орды, солтанга гарыз кылды, әмма солтан хөкем кылмады, ул сәбәпле Сәйфетдин мәлик ачуланып, барча Кангълы халкы илән шул кич иттифактан чыгып, Кирман тауларына китте. Шул заман Солтан Җәләлетдин, Чыңгыз ханның сансыз гаскәр илән кил-

гәнен ишетеп, үз шәһәрендә тормай, Синд суыннан үтеп китмәккә бил баглады. Чыңгыз хан дәхи иртә вә кич йөреп Газнин барды, анда Солтан Җәләлетдиннең киткәненә унбиш көн булды дип хәбәр алды. Газнинга хаким куеп, тизлек илән Синд суы якасына барды. Солтан һәм көймәләрен тәгаен кылып, иртә илән үтәргә әзерләнде. Хан күрде ки: әгәр бу кичне сабыр итсә, иртәсе үтеп, китәреннән шикләнеп, солтанның гаскәрен һәммә тарафтан ихата кылды.

Могул гаскәре таҗик гаскәреннән өч-дүрт өлеш артык иде. Солтан кояш чыкканда күрде ки; ут илән суның арасында калмыш. Чыңгыз хан солтанны терек итеп тота күрегез дип, Укар Калҗау вә Кутур Калҗауны тәгаен кылды. Алар солтанга уңнан-сулдан һөҗүм кылдылар, солтан биш-алты йөз кеше илән ул якка вә бу якка каршы торып иртәдән кичкәчә шул күп гаскәр илән орышып, мәрдәнәлекләр кылды. Ахирел әмер могуллар, уртага алып, кулга тотабыз дигәнгә дәрьяга төшеп үтеп йөри бирде. Чыңгыз хан, солтанның кылган эшләренә күп тәхсиннәр[2] кылып, угланнарына әйтте ки: «Атадан угыл туса, шундый тусын», — дип. Солтанның бала-чагасын вә хәзинәсен алдылар, дәхи Дөрбайноян илән Бала ноянны солтанның артыннан җибәрде, алар Һиндстанның ярымынача эзләп барып, таба алмай кайтып килделәр. Чыңгыз хан шул җирдән кайтып, этраф вә җәнабтагы вилаятьләрне алып, барчасына хакимнәр куйды, үзе Сәмәркандта кышлады.

## Чыңгыз ханның Солтан Мөхәммәднең артыннан гаскәр җибәргәне

Солтан Мөхәммәднең бераз кеше илән Термиздән Аму суын кичеп киткәнен ишетеп, үзе Бәлхне камап калып, Чәпәноян вә Сүбүдәй Баһадир вә Тугачар Коңгыратны һәркаюсына ун мең кеше кушып: «Солтан Мөхәммәдне алмаенча һәр җирдә туктамагыз!» — дип җибәрде. Һәр вилаять сезләргә табигъ булып аманлык теләсә, аман бирегез, әгәр табигъ булмаса, үзләрен үтереп, бала-чагаларын өлҗә вә әсир алып, шәһәрләрен көйдерегез, бу эшне өч ел мөддәтендә тәмам итеп кайткайсыз. Мин һәм монда тормай үз йортыма китәргә телимен. Эшегезне бетергәндин соң, ул юлдан Дәште Кыпчакка барырсыз. Бәкләр ханнан рөхсәт алып, дәрьядан үтеп, Бәлхкә барып, аннан Һерат вилаятенә барганда, Һерат халкы һәдияләр алып чыгып изһар[1] итагать кылдылар. Чәпә ноян аларга тәгъриз кылмай, Солтан Мөхәммәд артыннан йөри бирделәр. Әмма Тугачар Коңгырат соңга калып иде, Һератка килеп боларның сүзен кабул кылмады. Орыш башладылар. Һерат халкы заруридан орыштылар. Тугачарга кальгадан аткан ук тиеп үлде. Гаскәре барып, Чәпә ноянга кушылды. Аннан соң Савага җиттеләр. Сава иле аларга илтифат итмәй, дәрвазәләрен багладылар. Болар һәм юлыбыздан калмыйк дип үтеп йөри бирделәр. Сава иле, гакылсызлыктан мәсхәрә вә мәзәк кылып, могулларны сүгә бирделәр. Болар һәм ачуланып кайтып килеп, өч көн камап, дүртенче көн кальганы алып, бер кешесен терек куймай кырдылар. Аннан соң Нишапурга киттеләр.

Ул вакытта Солтан Мөхәммәд ишетте ки: утыз мең могул судан үтеп, җил вә яшен кеби йөреп килә дип вә солтаннан башка кемсәләр кирәкмәс дип. Бу хәбәрне ишеткәч, солтан бәкләрен чакырып, мәслихәт итте вә бала-чагасын Карындаз кальгасына җибәреп, үзе Гыйрак тарафына китте. Фәхрелмөлек вә Низаметдин Әбелмәгалә Кятиб вә Зыя әл-Мөлек берничә бәкләрен Нишапурны сакларга калдырды да үзе, Рәйдән узып, Казвинга барды. Углы Солтан Рәкыйн эд-Дин утыз мең кеше илән анда иде. Атасының килеп торганын ишетеп, каршы чыгып вә янә бер углы Солтан  Гаязетдинне анасы илән Карындазга җибәрде. Ул вакытта Чәпә ноян илән Сүбүдәй Баһадир, Нишапурга барып, Солтан Мөхәммәднең куйган  бәкләренә кеше җибәрде. Алар күп һәдияләр илән өч кеше җибәреп әйттеләр ки: «Мәмләкәт Солтан Мөхәммәднеңдер, мөһләт[1] бирсәләр, аны алып килер идек», — дәю.

Чәпә ноян уйгур теле илән хат бирде. Чыңгыз ханның биргән нишаны бар иде, мәзмуны[2] бу иде: Ходай Тәгалә галәмне миңа биреп торыр, һәркем миңа табигъ булса, дәүләткә ирешер, әгәр булмаса, үзе юк булып, бала-чагасы бәндә вә өлҗәгә җитешер. Аны һәм бирде, бәгъдә Нишапурдан кыйчырҗи[3] алып, Солтан Мөхәммәднең артыннан китте, аннан Мазандаранга барып, күп кешене үтереп, кальгасын җир илән тиң кылды. Соңра Әсфәраин юлына кереп, ул юлда һәркем очраса, ил булганына тими, ил булмаганын җир илән иксан кылып, Солтан Мөхәммәднең анасы анда булган Гилян кальгасын алып, аннан Рәй бардылар. Рәйне алып вә кешесен кырып, кальгасын зир вә зәбәр кылдылар.

Хәрәзем шаһ бу хәбәрне ишетеп, барып качарга җир тапмай, бәкләре илән киңәшеп, курыкканыннан һич урында тора алмай Карындазга китте; янындагы һәркайсы бер тарафка таралды. Карындазга барганда бер бүлек могулга очрап, орышып, Солтан Мөхәммәднең атына ук тиеп, качып Карындазга барды. Анда һәм тормай Гилянга мөтәвәҗҗир булды. Могуллар артыннан җитеп, олуг орыш булды. Могуллар бер парә гаскәрләрен Карындазга куеп, Солтан Мөхәммәднең артыннан киттеләр. Солтан Мөхәммәд Гилянга барып, җиде көн торып истидарәгә юнәлде. Юлда хәзинәсе тәләф булды. Аннан Каспий дәрьясына барып, аннан дәхи Әбескүн җәзирәсенә[4] барды, анда һәм тора алмады. Солтан чыгып киткән көннән могул шунда

барып җиттеләр. Солтанны таба алмый кайтып, Карындазга килеп, солтанның берничә хатыны вә бала-чагасы анда иде. Анларын алып, өлҗә вә әсир кылып, кечек угланнары Гилян каласында иде, аңа бардылар да камадылар.

Риваять ителмештер ки, Адәм заманыннан бу көнгәчә һич яңгыр ул җиргә яумас иде, шуңа күрә хәвызлар вә кодыклар казып утыралар иде, халык ел утырса да, суга мохтаҗ булмас иде. Чыңгыз ханның дәүләтеннән вә Солтан Мөхәммәднең бәхетсезлегеннән бер катрә яңгыр яумады. Ахры унбиш көндә сулары бетте. Солтан Мөхәммәднең вәзире Насретдин чыгып, Чәпә ноянны барып күргән сәгатьне яңгыр ява башлады. Шулкадәр яуды ки, силләр акты. Хәзинәдә никадәр алтын-көмеш вә җәүһәр бар иде, алдылар, вәзирне вә солтанның анасы вә угланнарын Чыңгыз ханга җибәрделәр. Чыңгыз хан вәзирне вә угланнарын үтертте. Солтан Мөхәммәд, бу хәбәрне ишетеп, гакылы китеп биһуш булды, кайта гакылына килмәде. Иннәә лилләәһи вә иннәә иләйһи рааҗигун. Ул җирдә кәфен тапмадылар һәм кигән киемендә күмделәр. Бу вакыйга Елан елында, тарих алты йөз дә унҗиденче елда вакыг булды. Солтан Мөхәммәднең падишаһлыгы егерме бер ел иде. Аннан соң Нахичеван вә Азәрбайҗан вилаятьләрен алып харап кылып, аннан Ширванга барып, Шәмәхадән ун башчы алып, берсен үтереп, башкасын куркытып әйттеләр ки: «Әгәр безне яхшы юл илән башламасагыз, юлдашыгызга ни кылдык, сезгә дә шуны кылырбыз», — дип, аларга башлатып, Дербенд юлыннан үтеп йөрделәр. Ул вакытта кыпчак вә аланнар аларның юлларын тотып торырлар иде. Сүбүдәй Баһадир Кыпчакка кеше җибәреп әйтте ки: «Сез безем карендәшебезсез, алан бер ят халыктыр, аларга ярдәм бирмәгез вә безем илән муафәкать кылыгыз», — дип, күп һәдияләр җибәрделәр.

Кыпчаклар боларның сүзләрен кабул итеп, алан кавеменнән аерылдылар. Булышлык киткәннән соң, могуллар орышып кырып, өлҗә вә әсир кылдылар. Кыпчак иле урыска барып, аннан булышлык алып килделәр һәм могулларның өстенә юнәлделәр. Могуллар аларны күреп, хәйлә кылып качкан булдылар. Кыпчаклар куркып качкан дип кәмәл кылып, ун көнгәчә артыннан кудылар. Аннан соң могуллар кайтып, җиде көнгәчә орыштылар. Ахирел әмер могуллар галиб килеп, басып кырып, күп өлҗәләр алып, хушхаль вә шатлык илән Чыңгыз ханның хезмәтенә барып, күп һәдияләр вә күренешләр биреп, үзләренең кылган эшләрен гарыз кылдылар. Хан, дәхи боларның кылган эшләренә тәхсин кылып, күп ингамнар вә бүләкләр бирде.

## Чыңгыз ханның Тули ханны Хорасан өстенә җибәргәне

Хан Кишварстан Бәлхне алганнан соң, Тули ханны Хорасан өстенә җибәрде. Тули хан Чыңгыз хан гаскәренең уннан берсе сиксән мең кеше илән Мәрвә өстенә атланды. Ул вакытта Хорасан гаҗәп мәгъмүр[1] иде. Хосусән Мәрвә шундый төзек иде ки, Мәрвәнең диһканнары[2] мал вә нигъмәтнең күплеге горурыннан үзләрен падишаһлар вә бәкләрдән артык тотарлар иде. Ул заманда Солтан Мөхәммәд Мәҗирелмөлек дигәнне Мәрвәдә хаким кылып иде. Мәҗирелмөлек атасы илән бертуган ир кардәшеннән бер гөнаһ садир булган иде. Ул сәбәптән Солтан Мөхәммәд Мәҗирелмөлекне Мәрвәнең хакимлегеннән чыгарып, Бәһаэлмөлек дигән кемсәне Мәрвәгә хаким кылды. Бу Мәҗирелмөлек, Солтан Мөхәммәд Гыйракка киткәннән соң, солтанның хезмәтенә барып йөрер иде. Нагяһ[1] могул гаскәренең Хорасанга килгәне Гыйракта шаигъ[2] булгач та, Солтан Мөхәммәд Мәрвә хакименә ярлык җибәреп әйтте ки: «Һәрвакыт могул гаскәре өстегезгә килсә, аның илән орышмагыз, аңа ил булып, Мәрвәне аңа бирегез», — дәю. Ул ярлык Мәрвә хакименә килгәннән соң, Бәһаэлмөлек Мәрвәдә тормакны мәслихәт күрми Язир кальгасына барып камалды, вә берничә халык башка вилаятьләргә таралды, вә берничә әҗәле җиткән халык Мәрвәнең эчендә калдылар. Ул вакытта Тули ханның гаскәреннән ике сәрдар ләшкәр газыйм[3] илән Мәрвәнең этрафына килеп төштеләр. Бәһаэлмөлекнең наибе[4] шәйхелислам тәмам халык илән кальгадан чыгып, сәрдарларны күреп, ил булып мал бирделәр; нояннар, һәм бу малга разый булып, Мәрвәдән үтеп киттеләр.

Ул вакытта Солтан Мөхәммәднең Бука Төрекмән дигән башчысы бар иде. Ул Мәрвәнең бер тарафында яшеренеп яткан иде. Могул гаскәре киткәннән соң, ул тарафтан чыгып, берничә төрекмәннәр илән муаффәкать кылып Мәрвәнең эченә керделәр. Аннан соң һәр җирдә качкан вә поскан төрекмән, вә таҗик, вә Солтан Мөхәммәднең нөкерләреннән калганы Бука Төрекмәннең катына җыелып, хезмәт кәмәрен[5] билләренә багладылар. Буканың гаскәре хәде ниһаятьтән тыш булды.

Җәзирәи Әбескунда Солтан Мөхәммәд дарфанидан дарелбакыйга рихләт кылганнан соң, Мәрвәнең әүвәлге хакиме Мәҗирелмөлек, бер качырны менеп, Гыйрактан Мәрвәгә килде. Бука Төрекмән хакимлек зәүкыннан Мәҗирелмөлекне Мәрвәгә кертмәде. Берничә көннән соң Мәҗирелмөлек бер хәйлә илән үзен Мәрвәнең эченә салды. Мәрвәнең Бука башлыкның җәмигъ халкы Мәҗирелмөлеккә табигъ булып хаким күтәрделәр. Ул вакытта Сәрхәс халкы могулга табигъ булып иделәр. Могуллар Сәрхәснең шәйхелисламын Сәрхәстә хаким кылып иделәр. Мәрвәнең шәйхелисламы, Мәҗирелмөлектән берничә шикаятьләр кылып,

Сәрхәснең шәйхелисламына кеше җибәрде. Мәҗирелмөлекнең юл каравылчылары шәйхелисламның кешесен тотып, хатны алып, Мәҗирелмөлеккә җибәрделәр. Мәҗирелмөлек, бу хатны күргәч, шәйхелисламны үтереп, аягыннан сөйрәтеп, Чәһар суга ташлатты. Ул хәлдә Мәрвәнең соңгы хакиме Бәһаэлмөлеккә Язир кальгасында камалды дип зикер кылган иде. Ул Язирдән чыгып, Мазандаранга барып, могул әмирләренә Мәрвәнең вакыйгатын гарыз кылды ки. «Миңа гаскәр кушыгыз, мин барып, Мәрвәнең халкын сезгә тәбгы кылып, һәр елда өй башына бер чикмәнлек йон рәгыйятьчелек алып бирәем», — дигәч, могул әмирләре аның сүзен кабул кылып, аңа җиде мең кеше кушып, Мәрвә тарафына җибәрделәр. Бәһаэлмөлек җиде мең могул илән атланып Шәһрестан дигән җиргә килде. Анда ишетте ки, Мәҗирелмөлек Мәрвәдә сиксән мең кеше илән хаким булып тора дип. Бәһаэлмөлек бер могул илән бер каләндәрдән[1] Мәҗирелмөлеккә хат җибәрде вә әйтте ки: «Могул гаскәре илән орышып булмас, яхшы улдыр ки, мин җиде мең могул илән өстеңә бараербыз, сез, әлбәттә, безгә табигъ булыгыз», — дип. Алар, Мәрвәгә килеп, хатны Мәҗирелмөлеккә бирделәр. Мәҗирелмөлек бу хатның мәзмуненә моталәга[2] булгач, ул ике кешене үтертте һәм һәр җиргә каравыллар куйдырды. Бәһаэлмөлек илән килә торган җиде мең могул бу хәбәрне ишеткәч, Бәһаэлмөлекне үтереп, үзләре кайтып киттеләр.

Могуллар кире кайтып киткәннән соң, Мәҗирелмөлек Мәрвәнең атаклы халыклары илән шәраб эчмәккә вә гыйш-гошрәт кылмакка мәшгуль булды. Ул вакытта Әмуя хакиме Ихтыяр-Эддин Төрекмән берничә төрекмәннәр илән Мәрвәгә килеп, Мәҗирелмөлеккә әйтте ки: «Могул гаскәре Мәрвәне камап алырга килә, имеш, ул гаскәрнең бер кыйсеме Әмуяга килде, тиз заман Мәрвәгә һәм килерләр», — дип. Мәҗирелмөлек пәришан булды вә халыкка камалмак мәшгуль булмакка боерды вә Ихтыяр-Эддин Мәрвәдән кайтып, янә берничә төрекмән илә муәффәкать кылып, могул гаскәре илән Мәрвәнең арасында бер олуг суның буена төште. Могул гаскәрендә сигез йөз кеше килеп, төрекмәннәрнең мәхәлләсенә ут салдылар вә мәхәлләнең күбен кыйнап, талап, халкын үтерделәр вә бәгъзеләрен дәхи әсир алдылар.

Ул вакытта Тули хан, Нишапур, вә Абъюрд, вә Сәрхәсне, вә Хорасанның янә берничә вилаятьләрен алып, Мөхәррәм аеның башында тарих алты йөз унсигездә хәтсез гаскәр илән килеп, Мәрвәне камады. Мәрвәнең эченнән гаскәр чыгып орыш салдылар һәм бер сәгать эчендә могулдан мең кешене үтерделәр. Егерме бер көн орыштылар. Ахирел әмер Тули хан ачуланып аттан төшеп, пиядә булып, калканын башына тартып, Мәрвәнең дәрвазәсенә йөгерде, тәмам могул гаскәре аның артыннан йөгерделәр. Ул хәлдә Мәрвәдән чыгып орышып йөргән сиксән мең кеше иде. Һәммәсе качып, кальгага керделәр, могуллар кальганы йөз саф вә ике йөз саф булып камадылар. Мәҗирелмөлек бу кадәр гаскәргә каршы тормак мөмкин булмаганлыгын белгәч, чарасызлыктан Тули ханга илче җибәрде: «Мин ил вә табигъ булдым», — дип. Аннан соң Мәҗирелмөлек күп һәдияләр илән кальгадан чыгып, барып, ханны күрделәр. Хан Мәҗирелмөлектән шәһәрнең малын вә хәзинәсен эстәде һәм ике йөз мең могулны аңа күзәтче кылды, аннан соң шәһәр халкын сахрага чыгармага ярлык вә хөкем кылды. Дүрт көндә халыкны шәһәрдән чыгарып бетерделәр. Һөнәрле кешеләрдән дүрт йөз кешене алып калдылар. Инде башка ир, вә хатын, вә бала-чагаларны — барчасын гаскәргә кыйсмәт кылдылар. Һәрбер могулга дүрт йөз кеше тиде, һәр кемсә үзенә тигән хиссасын үтерде. Сәед Гыйззетдин дигән кемсә берничә диваннар[1] илән Мәрвәнең эченнән чыгарып үтергән кешеләрне язып алдылар. Сахрада үлгәннән башка шәһәр әтрафында үлгәннәрне унөч көндә хатка алдылар. Барчасы бер миллион да өч йөз мең кеше иде.

Әлкыйсса: могуллар хан хөкеме илән Мәрвәнең кальгасын вә гыймарәтләрен шулай вәйран кылдылар ки, хәтта кальганың галәмәтеннән һичнәрсә калмады, Мәрвәнең әкябирләреннән әмир Зыя-Эддин дигән кемсә бар иде, аны Мәрвәдә хаким кылдылар. Качып вә посып калган халыкларга иген игегез дип рөхсәт бирделәр вә Бармас дигән кемсәне аларга даруга кылдылар. Аннан соң атланып Нишапур тарафына киттеләр. Аның бәгъдендә өч мәртәбә Мәрвәдә халык җыелды, кырганда илле-алтмыш мең кеше үлде.

## Тули ханның Нишапурга барганы

Мәрвәне алганнан соң, Тули хан атланып Нишапурга килде. Нишапур халкы казыйларын ханга җибәреп, аман теләделәр. Хан аман бирмәде һәм олуг сугыш илән Нишапурны алды, халкын тәмам кател гам кылды. Хатын вә яшь угланнан башка бер миллион да җиде йөз кырык мең кешене үтерделәр.

## Тули ханның Һератка барганы

Тули хан, Нишапурны харап кылгач, Һерат өстенә йөрде. Һератка якын җиткәннән соң, Зинбур исемле нөкерен илче кылып, Һератның әкябир вә әшрәфләренә әйтеп җибәрде ки: «Безгә ил булыгыз яки үзегез үлеп, бала-чагаларыгыз өлҗә вә әсир булмасын».

Ул вакытта Солтан Җәләлетдин Мәлик Шәмседдин Мөхәммәд дигәнне Һератка хаким кылып, йөз мең кеше аңа тәгаен кылып иде. Мәлик Шәмседдин Мөхәммәд Тули ханның илчесен үтерде, дәхи кальгадарлык вә орыш әсбабын таяр кылмакка мәшгуль булды. Тули хан илчене үтергәнен ишетеп, газыб илән атланып килеп, Һератны камады. Җиде көн орыш булды. Шундый каты орыштылар ки, хәтта каннар су урынына акты. Тули ханның мең дә җиде йөз бәге үлде. Сигезенче көнне могуллар һөҗүм кылдылар, Мәлик Шәмседдиннең гаскәре һәм һөҗүм кылып кальгадан чыгып, олуг орыш кылдылар. Ул орышта Мәлик Шәмседдин Мөхәммәдкә ук тиеп шәһид булды. Тули хан ике йөз кеше илән Һератның дәрвазәсенә чабып килеп, башыннан тулгасын алып, кальгадагы халыкка кычкырып әйтте: «И Һерат халкы! Белегез вә агяһ булыгыз! Мин Чыңгыз ханның углы Тули ханмын, әгәр үзегез үлмәй, бала-чагагыз әсир булмый тыныч булырга теләсәгез, кальгадан чыгып мине күрегез вә миңа ил булып һәр елда Солтан Җәләлетдингә бирә торган малның ярымын Чыңгыз ханга бирегез», — диде. Бу сүзне ишеткәннән соң, Һерат халкы ике яклы булдылар. «Солтан Җәләлетдин яклы ил булмыйбыз вә кальганы бирмибез!» — диделәр. Әмма шәһәр халкы, дәрвазәләрне ачып, үзләре барып Тули ханны күрделәр. Хан һәм, шәһәргә кереп, Солтан Җәләлетдиннең унике мең кешесен үтерде һәм шәһәр халкының гөнаһларын багышлап Мәлик Әбүбәкер дигәнне хаким кылып, үз мөлязимнарыннан[1] Миңтай дигән могулны даруга кылып, үзе атасы тарафына мөтәвәҗҗиһ булды, барып, Талканда атасына кушылды. Тули хан киткәннән соң, Мәлик Әбүбәкер илән Миңтай берләшеп утырдылар.

Ул вакытта Газнин илән Бамиян арасында Солтан Җәләлетдин илән Чыңгыз ханның нояннары арасында олуг сугыш булды. Нояннар тәмам җиңелеп, могуллардан күп кеше үлмеш иде. Ул сугыш Гыйрак, вә Гыйракыйн, вә Хорасан, вә Мавәраэннәһердә шаигъ вә мәшһүр булды. Халык хыял кылды ки, Чыңгыз хан Солтан Җәләлетдин илән орышырга тәкать тота алмыйдыр дәю, шул сәбәптән Һерат халкы, Мәлик Әбүбәкер илән Миңтай даруганы үтереп, Чыңгыз хан илән яу булдылар. Мәлик  Мөбариз дигән кемсәне хаким кылдылар. Бу хәбәрне хан Кишварстан ишеткәч, Тули ханга игътираз кылып әйтте ки: «Әгәр син ул халыкны үтерсәң иде, мондый фетнәләр булмас иде», — дип. Ачуы килеп, Илчиктай дигән ноянны сиксән мең кеше илән Һерат өстенә җибәрде. Һератны алып, бер кешесен терек куйма, диде. Илчиктай ноян  атланып килеп Һератны камады. Һерат халкы алты көнгәчә каты орыштылар, һәр ике тарафтан сансыз кешеләр үлде. Ахирел әмер кальганың дүрт тарафының һәр тарафыннан егерме мең кеше кальгага йөгереп менеп кальганы алдылар һәм барча халкын кател гам кылдылар. Бер миллион да алты йөз мең кешене шәһид иттеләр. Һератның кальгасын харап кылып, җир илән тиң кылдылар. Һератта фәкать унбиш кеше терек калды. Алардан гайре бер кеше калмады.

## Чыңгыз ханның эне вә угланнары  илән Могулстанга кайтмакны киңәш кылганы

Чыңгыз хан Иран илән Туранны тәмам алып, дошманнарының бәгъзесе үлеп вә бәгъзесе качканнан соң, ханның каһәр вә газабы пәст[1] булды. Бу хәлдә Хытай тарафыннан хәбәр килде ки: Хытай халкы Чыңгыз ханның тәхет итагатеннән чыгып яу булган дәю. Хан, бу хәбәрне ишетеп, угланнарын вә әмирләрен чакыртып киңәш кылганнан соң, Чыгтай ханны Кәх вә Мөкран тарафына җибәрде. Солтан Җәләлетдинне табып кулга алмак өчен, вә Үгедәйне Газнин тарафына җибәрде. Солтан Мөхәммәд Сабиктигиннең йортын харап кылмак өчен, Чыңгыз хан үзе Туран йортына кайтмак булды. Үгедәй хакан, атасының хөкеме илән Газнингә барып, Сабиктигин әүлядының йортын мөсәххәр кылып, Туранга кайтты. Чыгтай хан, дәхи Мекринга барып, ул йортларны харап кылып, халкын өлҗә вә әсир итеп, Җәләлетдиннән һич хәбәр тапмады. Бохара, вә Ташкент, вә Сәмәрканд тарафына кайтты.

## Чыңгыз ханның үз йортына кайтканы

Чыңгыз хан бәһар[1] вакытында үз йортына кайтты, вилаятьләргә вә касабәләргә[2] хаким вә даругалар тәгаен кыла-кыла Аму суыннан үтеп, Бохарага килде, вә әтрафка җибәргән шаһзадәләр вә нояннар тәмам килеп кушылдылар. Хан Кишварстан Бохара халкына кеше җибәреп әйтте ки: «Миңа бер данишмәнд кешене җибәрегез, аннан берничә сүзләр сорармын», — диде. Бохара халкы Казый Әшрәф дигән зат илән бер вагыйзне[3] җибәрделәр.

Чыңгыз хан аңардан сорады ки: «Сез ничек мөселмансызлар вә мөселман булмакниләр илә булыр?» Алар әйттеләр: «Мөселманнар — Ходайның бәндәседер. Ходай Тәгалә үзе бер вә ялгыздыр, һичкемнән тумады вә һичкемне тудырмады, аның назыйры вә охшашы юктыр». Чыңгыз хан әйтте: «Бәли, мин һәм Тәң-

рене шулай дип белермен». Вә дәхи әйттеләр: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа гам вә гайре Рәсүлләр Тәңренең илчеләредер. Ходай Тәгалә аларны үзенең әмерен вә нәһиен[4] бәндәләренә әйтмәк өчен җибәрмештер. Чыңгыз хан моны һәм кабул итте. Аннан соң һәр көндә биш вакыт намаз укырбыз, Тәңрегә бәндәлек кылырбыз», — диделәр. Аны һәм яхшы күреп кабул итте. «Аннан соң бер елда унбер ай ашны һәм суны һәрвакыт җиябез, эчәрбез. Әмма бер ай көндез аш җиймәсбез вә су эчмәсбез», — диделәр. Моны һәм хуш күреп кабул итте. «Аннан соң һәр елны бай булган кемсәбез алтыннан, көмештән вә гайре маллардан һәм хайваннардан шәригать буенча тәгаен кылынган микъдарны зәкят чыгарабыз». Моны һәм мәгъкуль күрде. «Аннан соң Ходайның Мәккә исемле өе бар, әгәр куәтебез җитсә, аңа барып зиярәт кылабыз», — диделәр. Чыңгыз хан аны кабул итәсе килми әйтте: «Тәмам галәм — Ходайның йортыдыр, бер җирне тәгаен кылып бармакның мәгънәсе нидер?» — диде. Аннан соң аларга илтифат нәзире илән карап тәгъзыйм вә тәкрим[5] кылып кайтырга рөхсәт бирде. Аннан соң Бохараның әһеле вә мулласы ханнан ярлыкны теләделәр. Хан һәм гыйнаять итеп ул халыкка тархан ярлыгын бирде. Аннан соң Бохарадан Сәмәркандка барды, дәхи Дәште Кыпчакка Җүчи ханга илче җибәрде вә әйтте: «И фәрзәнд газиз, тәмам гаскәрең илән атланып Дәштенең җанварларын безнең тарафыбызга куып китер, аларны шикяр[1] кылырбыз», —диде.

Югарыда әйткән идек ки, шаһзадәләр Хәрәзем өстенә барганда Чыңгыз хан әйтеп җибәреп иде ки, Җүчи илән Чыгтай, Үгедәйне үзләренә мөкатдәм белеп, аның хөкеменнән чыкмасыннар, дип. Ул сәбәптән Җүчи хан Хәрәземне алганнан соң, ханның бу сүзенә намус кылып, Дәште Кыпчакка барып, Дәштенең тәмам илен үзенә мөсәххәр кылды. Аулап вә кошлап йөреп торганда, атасының илчесе килеп, атасының әйткән сүзләрен әйткәннән соң, Җүчи хан тәмам ләшкәре илән атланып, Дәштенең тәмам җанварларын алдына салып килеп атасына кушылды, дәхи атасына күп һәдияләр бирде вә аннан йөз мең ат һәдия кылды; вә аның егерме меңе бүз, вә егерме меңе күк, вә егерме меңе туры, вә егерме меңе кара, вә егерме меңе чуар иде. Чыңгыз хан вә Җүчи ханга күп гыйнаять вә илтифатлар кылды. Җүчи хан энеләренә тәвазыг[2] кылып ширин[3] тел илән сөйләште. Аннан соң Чыңгыз хан, шаһзадәләр илән яхшы шикярләр кылып, үз йортына килеп, бала-чагаларын күреп хушхәл булды, аннан соң Җүчи ханга йорт мәслихәтеннән күп нәсыйхәтләр кылып, яуга вә илгә ничек булырганың киңәшен әйтеп, янә Дәште тарафына озатты.

«Тарихе Рәшиди»дә әйтәдер ки, Өргәнечкә энеләре илән барганда, Чыңгыз хан Җүчи илән Чыгтай, Үгедәйнең теленнән чыкмасыннар дигән өчен Җүчи ханның күңеле калып иде, ул сәбәптән Өргәнечне алганнан соң, Кыпчак, вә Урыс, вә Чиркәс, вә Болгар, вә Маҗар, вә Башкорт йортларын алмак илән мәшгуль булды. Чыңгыз хан үз йортына кайткач, Җүчи ханга ничә мәртәбә кеше җибәрде кайтсын дип. Әмма ул вакытта Җүчи хан хаста булган иде. Авырыймын дип гозер әйтеп җибәрде. Чыңгыз хан гозеренә инанмый каты рәнҗеде. Җүчи хан беркөн, күчеп барганда, бер аулы җиргә кунарга төште, үзе хаста булып, бәкләренә ау ауларга җибәрде. Алар аулап йөргәндә, мангыт таифәсеннән бер кемсә үтеп, Чыңгыз хан катына барганда боларны күреп, Җүчи хан бергәдер дип хыял кылып юлына йөреп китте вә берничә көннән соң Чыңгыз хан катына барды. Чыңгыз хан Җүчи ханның хасталыгыннан сорады, ул мангыт әйтте ки: «Хаста вә сау икәнен белмәдем, әмма фәләнчә җирдә ау аулап йөридер иде», — диде. Хан, бу сүзне ишеткәч, ачуланып, Җүчи ханның өстенә атланмак булды. Ул арада Җүчи ханның вафат хәбәре килде. Хан, мангытның сүзе ялган икәнен белгәч, аны эзләтте, әмма һич таба алмадылар. Хан углының үлгәненә берничә вакыт тәгъзия тотып, аннан соң Чыңгыз хан шаһзадәләр илән яхшы шикярләр аулап, үз йортына кайтып, бала-чагаларын күреп хушхәл булды.

Ул вакытта Тангут хакиме Шидерку яу булды дип хәбәр килде. Хан олуг чирүк илән атланып Шидеркуның өстенә барды. Шидерку һәм ләшкәр биниһая белән ханга каршы торды. Олуг орыш булды. Ахирел әмер Шидерку качты, һәм Чыңгыз хан вилаятен талап, харап кылып, носрәт илән кайтып урдасына төште. Ул вакытта Шидеркуның илчесе килде, аның аркылы әйтеп җибәрмештер ки: «Әгәр гөнаһымны кичерсәләр, мин барып күрер идем, әгәр мине үзләренә угыл итсәләр һәм шуңа ант вә шарт кылсалар», — диде. Чыңгыз хан, бу сүзләрнең барчасын кабул кылып, күп гыйнаятьләр итеп, илчене кайтарып җибәрде. Илче ханның хозурыннан атланып киткәч, ханга бер хасталык гарыз булды, егылды.

## Чыңгыз ханның, хаста булып, угланнарына нәсыйхәт кылып дөньядан үткәне

Чыңгыз хан, Хытай өстенә йөргәндә бер төш күреп, аннан гаҗәеп курыккан иде, үзенең тиз заман вафатын аңлаган иде. Нагяһ хан хаста булды, үзенең хәленнән хәбәрдар булып, угланнарын вә әмирләрен алдына чакырды һәм төрле нәсыйхәтләр кылды вә угланнарына әйтте ки: «Зинһар, бере-берегез илән җөзьи[1] эш өчен хәтерегезне калдырышмагыз, әгәр һәркайсыгызның күңелендә бер зәррә нифак[2] булса, әлбәттә, аны күңелегездән чыгарыгыз, та дошманның мәкереннән имин булырсыз вә, дәхи Үгедәйне минем урыныма

падишаһ кылып, барчагыз аңа табигъ булып, аның мәслихәтенчә эш күрегез». Угланнары вә әмирләре илән Үгедәй хакан арасында гаһеднамә яздырып әйтте ки: «Әгәр мин үлсәм, кешегә белдермәгез Шидерку халкы илән килгәнче. Шидерку килгәч, халкы илән үтерегез, аннан соң минем үлгәнемне заһир кылыгыз», — диде вә рухының кошы тынының кафәсеннән[1] очып китте. Шаһзадәләр атасының васыяте илә гамәл кылып, ханның үлгәнен кешегә белдермәделәр.

Берничә вакыттан соң Шидерку ләшкәре илән килде. Шаһзадәләр дәрхаль гаскәре илән тотып үтерделәр, бәгъдә[2] Чыңгыз ханның вафатын әзһәр кылдылар, җәзагъ вә фәзгъ[3] кылып күп еладылар. Чыңгыз хан беркөн, шикяр кылып йөргәндә, бер олуг дәрәхтнең[4] астына килде, дәхи әйтте ки: «Әгәр үлсәм, мине бу агачның төбенә куегыз», — диде. Хан үлгәннән соң, үлекне бер сандыкка салып, мәзкүр агачның астына куйдылар. Ул җирне Бурхан-Калдун дирләр. Ханны куйганнан соң, ул җирдә күп дәрәхтләр пәйда булды ки, ук атканда үтмәслек иде. Ул җир тәмам падишаһлар вә әмирләрнең мәкъбәрәсе[5] булды. Чыңгыз хан тарих алты йөз егерме дүрттә, Дуңгыз елында дөньядан нәкыль[6] кылды.

Шул Дуңгыз елында дөньяга һәм килеп иде вә Дуңгыз елында хан булып тәхет солтанәткә утырды. Ханның мөддәт[7] гомере җитмеш өч яшендә иде. Егерме биш ел падишаһлык кылды. Өч ай үткәнче әтраф вә җәванибтән[8] халык килеп, шаһзадәләргә тәгъзия җиткерделәр. Тәгъзиядән фаригъ булгач, һәркем үзләренең урыннарына таралдылар, әмма солтанәт мәслихәтеннән һич сүз сөйләшмәделәр.

### Чыңгыз ханның бәгъзе мисаллары, вә белекләре, вә рәсем, вә кагыйдәләре

Чыңгыз хан ун мең кешене бер кешегә тапшырды һәм аңа төмән агасы дип исем кушты вә, мең кешене бер кешегә тапшырып, һәзарә[9] дип исем кушты вә, йөз кешене бер кешегә тапшырып, сәдә[10] дип исем кушты вә, илле кешене бер кешегә тапшырып, пәнчә[11] дип исем кушты вә, ун кешене бер кешегә тапшырып, дәһ дип исем кушты һәм ярлык кылды ки: «Һичкем һәзарә вә сәдә, вә дәһҗәсенә бер унның һәзарә, вә сәдә, вә дәһҗәсенә кушылмасын, әгәр бер кемсәнең эше булса, халык аны әмерән төмәнгә, әмерән төмән әмерән һәзарга, әмерән һәзар  сәдәгә, әмерән сәдә әмерән дәһҗәгә хәвалә кылсын», — диде. Вә дәхи хөкем кылды ки: «Ир вә хатын бездән инәгәчә һәртөрле сугыш көнендә хаҗәт булган коралларын үзләре сакласыннар, һәркем моның хилафынча эш кылса, падишаһның газабына юлыгып, җәзага дучар булыр иде. Вә дәхи һәр угыл атасының сүзен тыңламаса, вә һәр эне агасының телен алмаса, вә һәр хатын иренең иттифакы илән булмаса, вә һәр кияү каенатасын рәнҗетсә, һәр угры угрылыктан гайре эш кылмаса, вә һәр яман кемсә яманлыгыннан гайре эш кылмаса, бу әйтелгән кемсәләргә Чыңгыз ханнан рәхим вә шәфкать булмады, шуңа күрә аның заманында моның кеби эшләргә адәмнәр кадәм[1] куймадылар вә дәхи һәркем гакыйль вә баһадир исә, аны гаскәргә баш кылды, һәркем зәбун[2] вә булмаган исә, аны елкыга җибәрде, көтүче кылды. Шундый тәдбирләре бәрәкәтендә Чыңгыз ханның икъбалы[3] алга китеп, көннән-көн дәүләте артты. Вә дәхи әйтер иде: «Һәркем төмән, вә һәзарә, вә сәдә, вә дәһҗә агаларыннан һәр елның әүвәлендә һәм ахырында мине күреп, минем нәсыйхәтем вә мәслихәтем илән эш кылса, ул кеше олуг гаскәргә баш була белер, — дир иде. — Әгәр минем әйткәнемчә эшне сәрәнҗам[4] кыла алмасалар, алар халыкка баш була алмаслар, андый кешеләр бер ташка охшар ки, аны бер суның уртасына ташларлар, ул батып китеп, һичкемгә күренмәс». Вә дәхи әйтер иде ки: «Һәр кеше үз өен яхшы сакласа, мәмләкәтне һәм саклар вә, һәр кеше ун кешене тәртип кылып башкарса, ул кемсә олуг гаскәрне һәм башкарыр, вә һәркем яманлыктан үзенең күңелен пакь кылса, мәмләкәтне һәм угрыдан пакь кылыр вә, һәркем олуг катына барса, аннан сүз сорамыйча сөйләшмәсен, әгәр сорамый сөйләшсә, аның сүзен ишетсәләр бик хуп, әгәр ишетмәсәләр, суык тимергә чүкеч орган кеби булыр». Чыңгыз ханның мондый сүзләре күп иде, аның һәммәсен язсак, бер олуг китап булыр иде. Инде моның илә мохтәсар кылдык.

# Дүртенче баб

## Чыңгыз ханның өченче углы Үгедәй ханның вә Чыңгыз хан  нәселеннән Могулстанда падишаһлык кылганнарының зикере

Чыңгыз хан вафат булгач, ике елдан соң Дәште Кыпчактан Җүчи ханның угланнары, вә Чыгтай хан, вә Тули хан угланнары илән мәшрикъ тарафыннан Билгедай ноян,  вә Илчедай ноян,  вә барча бәкләре җыелып килеп, Чыңгыз хан язып биргән гаһеднамәсен[1] укып, ханның әйткән васыятьләрен ишетеп, Үгедәйгә: «Ханлык сиңа тиештер», — диделәр. Үгедәй әйтте: «Миннән олуглар бар, атайның энесен, яки агам Чыг-

тайны вә яки энем Тулине хан күтәрегез», — дип. Кырык көнгәчә ханлыкны кабул итми торды. Кырык көннән соң барчалары: «Без Чыңгыз ханның сүзенә хилафлык кылмабыз», — дип, Чыгтай хан — уң кулын вә Тули хан сул кулын алып, Үгедәй хаканны тәхет өстенә утырттылар. Могул рәсеме илән олуг бәйрәм вә туй кылып, мөбарәкбад кылдылар.

Тарих алты йөз егерме җидедә иде. Чыңгыз ханнан соң бәгъзе җирләрдә фетнәләр пәйда булган иде. Барчасын бетерделәр вә Солтан Җәләлетдинне дәфгы[2] кылмак өчен Җирмагун бәкне вә Итмасны өч төмән кеше илән Иранга җибәрде. Солтан Җәләлетдин ул вакытта Һиндтән килеп, Кирман, вә Шираз, вә Азәрбайҗан, вә Тәбризне алып, вә гайре шәһәрләрне мөсәххәр кылып, янына күп кеше җыеп үзенә көч вә куәт пәйда кылган иде. Җирмагун бәк бер парә гаскәр илән Итмасны элгәре җибәргән иде. Солтан Җәләлетдин аларның килә торганнарын белеп качып, Дияр бәк вә Көрдестан җиренә китте. Күрделәр: аны киеме вә аты өчен тотып үтерделәр вә бәгъзеләр мәзкүр тарафта каләндәр киемен киеп каләндәр булып киткән дип. Әйтәләр: «Валлаһи әгъләм, Хәрәзем шаһларыннан дөньяда кеше калмады. Иннәә ләлилә-әһи вә иннәә иләйһи раажигун».

## Үгедәй хаканның Хытайга барганы

Тарих алты йөз егерме җидедә вә рабигыль әүвәлнең аенда Үгедәй хакан, вә Чыгтай хан, вә Тули хан хисапсыз гаскәр илән Хытай тарафына йөрделәр. Кара Муран дигән суның буенда бер шәһәр бар иде. Ул шәһәргә килделәр, аның халкы кырык көн камалып орыштылар. Ахирел әмер шәһәрнең халкы аман теләп, шәһәрне аларга тапшырдылар. Хытай гаскәреннән унике мең кеше көймә илән качып киттеләр. Алардан башка күп халыкны кател гам кылып, бала-чагаларын бәндә кылып, Хытайның янә бер шәһәренә мөтәвәҗҗиһ булды. Үгедәй хакан Тули ханны ун мең кеше илән элгәре җибәрде, үзе аның артыннан әкрен-әкрен йөрде.

Ул вакытта Хытай падишаһы Алтан хан, бу хәбәрне ишетеп, әмирлектән бер-ике кемсәне йөз мең кеше илән каршы җибәрде. Бу йөз мең кеше Тули ханга юлыгып, Тули ханның ләшкәрен аз күреп, һәммә яктан камап алдылар. Ул хәлдә Тули хан, хәбәрдар булып, эш мөшкел булганын аңлады, муллаларына «дога кылыгыз!» дип хөкем кылды. Алар өч кичә вә көндез дога кылдылар. Язның эссе көнендә кар илән яңгыр ява башлады. Аннан соң шундый суык булды ки, күп кешеләр кулларын куеннарыннан чыгармадылар. Тули хан, Хытай гаскәренең суыкка гаҗиз булганнарын белгәч, Хытай гаскәренә ат өстендә һөҗүм кылырга боерды. Татар һәм могул, һәммә тарафтан һөҗүм кылып, Хытай гаскәрен бастылар. Йөз мең кешедән биш мең кеше качып котылды, башкаларны кател гам кылды. Бу хәбәрне Алтан хан ишеткәч, бер якка качып китте, аның әхвәленнән һичкем хәбәр белмәде вә бәгъзе тарихларда әйтмешләр ки: Алтан хан ут яндырды, бала-чагалары илән барчасы утка янып үлделәр.

Әлкыйсса: Тули хан Хытай ханының үлгәнен вә Хытайны мөсәххәр кылганын хаканга мәгълүм кылып кеше җибәрде. Хакан һәм Хытайга килеп, җәмигъ вилаятьләрен мөсәххәр кылып, Мәхмүд Ялавыч даруга кылып кайтты. Ул вакытта Тули хан, хаста булып, шунда вафат булды. Атасыннан соң ундүрт ел падишаһлык кылып, атасының артыннан китте.

## Үгедәй хаканның шаһзадәләрне Урыс, вә Чиркәс, вә Болгар, вә Туран, вә Башкорт, вә гайре вилаятьләрне фәтех кылырга җибәргәне

Үгедәй хакан Хытайны мөсәххәр кылып кайтканнан соң, тарих алты йөз утыз өчтә вә Маймыл елында Җүчи ханның углы Батыйны, вә үзенең углы Киюкне, вә Тули ханның углы Мәнгүне, вә Чыгтай ханның угланнарын Урыс, вә Чиркәс, вә Болгар, вә Туран, вә Башкорт, вә гайре вилаятьләрне фәтех кылмакка җибәрде. Үзе, Кара-Коромда Хытайдан китергән остазлар вә нәкъкашларны алдына китереп, яхшы өйләр вә сарайлар ясатты, вә барча шаһзадәләр вә бәкләр ул сарайларның әтрафында үзләре өчен өйләр вә биналар кылдылар. Аннан соң зәргәрләргә[1] алтыннан вә көмештән фил сырты илән арыслан сырты кылдырып, һәркайсының алдында көмештән хәвызлар ясатты. Фил илән арысланның авызыннан хәвызларның эченә шәраб түгелер иде. Вә дәхи агач илән балчыктан дүрт дивар салдырды ки, һәркайсының озынлыгы ике көнлек җир иде. Аңа дәрвазәләр куйдырды. Һәрвакыт ауга күңеле төшсә, нөкерләре атланып ун көнлек җирдән җанварларны куып китереп, шул диварның эченә салырлар иде. Үгедәй хакан аннан үзе шикяр кылыр иде. Вә дәхи җиде елдан соң барча шаһзадәләр барган вилаятьләрен алып кайтып килделәр. Һерат шәһәре вәйран булган иде. Хаканның хөкеме илән яңадан абад кылдылар, хәтта борынгыдан яхшырак булды.

## Үгедәй хаканның үлгәне

Бар галәмнең падишаһы Үгедәй хакан Хытайны фәтех кылып вә шаһзадәләр һәм үзгә вилаятьләрне фәтех кылып кайтканнан соң, хакан әтраф вә җәванибка кеше җибәреп әйтте ки: «Барча карендәш-ыругларым килсеннәр вә, минем ингам вә ихсанымнан өлеш алып, берничә көн кунак булып гыйш-гошрәткә мәшгуль булсыннар».

Ул вакыт һәр тарафтан халык гөруһ-гөруһ булып килделәр. Үгедәй хаканның урдасында шулкадәр халык җыелды ки, дөньяда моның кеби җәмәгать булганы юк иде. Хакан, бу халык илән күп гыйш вә гошрәтләр кылып, ингамнар бирде вә берничә вакытлардан соң һәркем үз мәнзиленә китсә рөхсәттер дип ихтыяр бирде. Халыклар берсе артыннан берсе үз урыннарына киттеләр. Бу халык киткәннән соң, хаканга нәкаһәт[1] хасталык пәйда булды һәм шул авыруы илән дарелфанидан дарелбакыйга китте.

## Падишаһе Иран вә Туран хаканының бәгъзе холык вә фигыльләре

Бәкләр эченнән бер кеше бар иде, Мөхәммәд пәйгамбәр салаллаһу галәйһиссәламнең диненә мөнкир[2] иде. Беркөн ул хаканга килеп әйтте ки: «Бу кичә бер төш күрдем. Чыңгыз хан миңа әйтте ки, Үгедәйгә әйт, мөселманнарны үтерсен, дип». Хакан әйтте: «Бу сүзне сиңа Чыңгыз ханның үзе әйттеме йә тылмачы әйттеме?» Ул кеше: «Ханның үзе әйтте», — диде. Аннан соң хакан сорады ки: «Син могул телен белермесең?» Ул кеше: «Белмәем», — диде. Хакан әйтте: «Бу кеше ялган сөйләде, Чыңгыз хан могул теленнән гайре телне белмәс иде, үтерегез», — дип хөкем кылды.

Вә дәхи Үгедәй ярлык кылды ки: «Һичкем куйны бугазлап үтермәсен, бәлки күкрәгеннән ярып үтерсен». Бер мөселман базардан бер куй алып китереп, ишекне баглап бугазлады. Ул вакытта бер могул бу мөселманны белеп, там өстеннән өенә төшеп, мөселманның аягын вә кулын баглап, хаканга алып барды. Хакан яхшы тикшереп җавап алды вә, могулны үтерегез, дип хөкем кылды, дәхи әйтте ки: «Бу мөселман хөкемне игътибар кылып ишеген беркетеп торыр, әмма син ярлыкны тотмый берәүнең өенә бирөхсәт керепсең», — диде.

Вә дәхи ярлы тимерче бар иде, беркөн дүрт-биш без ясап, безләрне кулына алып, хаканның үтә торган юлы өстендә торды. Хакан атланып үтеп барганда бу тимерчегә күзе төште, бер есаулга әйтте ки: «Барып, ул кешенең әхвәлен сора», — дип, есаул килеп, аның әхвәлен сорап, һәдия китергән безләрне алып, хакан янына барды. Хакан ул тимерченең һәр безе өчен бер әшрәфи алтын бирде.

Дәхи бер карт кеше бар иде. Аның һич бала-чагасы вә карендәше юк иде. Беркөн хаканның дәргяһына килеп гарыз кылды ки: «Кулымда дәст[3] маям булса, сәүдәгәрлек кылыр идем», — дип. Хакан аңа ике йөз тәңкә алтын бирергә хөкем кылды, сәүдәгәрлек кылсын, диде. Кешеләр әйттеләр: «Бу карт кеше үлем хәлендәдер, моңа ул кадәр күп алтынны бирмәк дәркяр[1] имәс вә дәхи моның фәрзәнде вә карендәше дә юктыр». Хакан әйтте: «Бу кеше миңа бер өмет илән килмеш, аны мәхрүм итмәк безгә лаек имәс, — диде. Дәхи боерды: — Үлеп китмәсен, тизрәк алтынны бирегез!» — диде. Хәзинәчеләр, шул сәгать картка китереп ике йөз тәңкә алтынны санап бирделәр.

Ул алтынны алгач та, ул карт вафат булды. Вә дәхи бер мөфлис[2] кеше килеп, хаканга гарыз кылды ки, дәст маям юк дип. Хакан ул кешегә биш йөз тәңкә алтын бирде, дәст мая кыл, дип. Ул кеше биш йөз тәңкә алтынны алып китеп сарыф кылды, янә, дәст маям юк, бетте, дип, хакан хозурына килде. Хакан дәхи биш йөз тәңкә алтын бирде. Бераз вакытлар үткәннән соң, янә, дәст маям сарыф булды, дип, хакан дәргяһына килде. Халык падишаһка әйттеләр: «Бу кешегә ничаклы алтын бирсәгез дә, хәреж[3] кыладыр, бирмәгәнегез яхшырактыр». Хакан: «Ул ни җирдә сарыф кылыр?» — дип сөаль куйды. Алар әйттеләр: «Алтынчы вилаятьнең халкына сатып, пулын җыймак, эчмәк вә кимәккә хәреж кыладыр», — диделәр. Хакан әйтте: «Әгәр алай булса, ул алтыннар янә минем хәзинәмә килер». Ул кешегә янә биш йөз тәңкә алтын бирде, күп исраф кылма, диде.

Үгедәй хаканның моның кеби эшләре күп иде, һәммәсен язсак, бер китапка сыймас дип мохтәсар кылдык.

## Үгедәй хаканның хатыннары һәм угланнары

Үгедәй хаканның дүрт могтәбәр хатыны вә алтмыш кәнизәге бар иде. Олуг хатынының исеме Туракчин, икенче хатыны Туракинә меркит халкыннан иде, вә бәгъзеләр әйттеләр: Туракинә Ойрат олугы Таяр-

сунның хатыны иде, Таярсунны үтергәндә, өлҗә кылып, Үгедәй хакан алган иде. Туракинә төскә күрекле имәс иде, әмма Үгедәй хаканга күрекле күренер иде. Өченче хатыны — Монга, дүртенче хатыны Хачин иде. Хаканның җиде углы бар иде. Биш могтәбәр углы Туракинә хатыннан туып иде вә ике углы кәнизәктән булып иде. Хаканның олуг углының исеме Киюк, аның йорты Камак дигән җирдә иде. Бәгъзеләр, Мөнграк вә Имал дигән җирләрдә иде, диделәр. Үгедәйнең Ширамун Вәли әл-Гаһди дигән нәбирәсе иде. Әмма Туракинә хатынның угланнары атасының фәрманына мохаләфәт кылып, Киюк ханны хакан кылып, атасының тәхетендә утырттылар, хәлбуки ул паралич авыруына грифтар иде. Аның өч углы бар иде. Олугының исеме Хуҗагыл, анасының исеме Көмеш, икенче углының исеме Багу, ул һәм Көмеш хатыннан иде, аның дәхи Хабат атлы бер углы бар иде, өченче углының исеме Уку иде. Аның ун углы бар иде. Үгедәй хаканның икенче углының исеме Котан иде, аның йорты Тангуттыр. Өченче углының исеме Күҗүдер. Әмма бу зат гаҗәеп бер гакыйль иде. Әмма Үгедәй хаканның терек вакытында вафат булды. Дүртенче углының исеме Карачар иде. Бишенче углының исеме Кашиндыр. Кашин дип шуңа күрә ат куйдылар: әүвәлдә Тангут вилаятенә Кашин дип әйтерләр иде. Чыңгыз хан Кашинны алганда туып иде. Шуның өчен Кашин дип исемен куйдылар. Бик шәрабхур вә фасикъ кеше иде, шул сәбәптән егетлектә вафат булды.

Әлкыйсса: Киюк хан атасы урынында падишаһ булды. Хәзинәнең ишеген ачып, карендәш, вә гайре ят фәкыйрь, вә мескеннәргә, олуг вә кечеккә шулкадәр ингам-ихсан кылды ки, һичкем моның кеби кылган кемсә юк иде, әмма үзе дин исламга рәваҗ[1] бирмәс иде. Падишаһлык мөддәте бер ел булып үткәч, дөньядан рихләт кылды.

## Мәнгү хаканның зикере

Киюк хан үлгәннән соң, Чыңгыз ханның нәселеннән һәр кеше Тули ханның хатыны Сөюркүктай бикәнең халык илән яхшы мәгаш вә мөгамәлә кылдыгыннан Тули ханның угланнарыннан берсен падишаһ кылмакка разый иделәр вә Җүчи ханның углы Батый һәм алардан падишаһ булмакка риза иде. Гәрчә Чыңгыз ханның нәбирәләре арасында Батыйдан солтанәт вә бөеклектә артык кеше булмаса да. Батыйхан шаһзадәләр, вә ноян,  вә әмирләргә кеше җибәреп, Дәште Кыпчакта җыелырга чакырды, иттифак илән берәүне тәхеткә утыртып хан кылмак өчен. Бәгъзеләр килми әйтеп җибәрделәр ки: «Чыңгыз ханның йорты Келурандадыр, без Дәште Кыпчакка бармыйбыз». Ул вакытта Сөюркүктай бикә угланнарына әйтте ки: «Дәште Кыпчакта агагыз Батыйның аяклары авырып ятыр, сәламәтлеген белеп зиярәт кылып кайтыгыз», — диде. Сөюркүктай бикәнең угланнары Мәнгү хакан, вә Һөләкү хан, вә Кубилай хакан, вә Мөңкә угыл Дәште Кыпчакка китеп, Батый хозурына бардылар.  Батый, Мәнгү хаканны күргәч, шаһзадәләр, вә нояннар, вә әмирләргә әйтте: «Ханлыкка Мәнгү хаканны муафикъ күрәмен, сез ни әйтерсез?» — дигәч, һәммә халык кабул итеп, ханлыкка тәгаен кылдылар. Соңра әйтте ки: «Киләчәк елга Келуранда тәмам халыкны җәмгъ кылып, яңадан Мәнгү хаканны күтәрегез», — диде. Бер елдан соң барча халык, Келуранда җыелып, Мәнгү хаканны падишаһ күтәрделәр. Җиде көнгәчә туй кылдылар, һәр көндә ике мең арба шәраб вә буза, өч йөз елкы илән сыер, ике мең куй кәбаб кылыр иделәр. Тарих алты йөз кырык сигездә хан булды.

Ширамун башлык Киюк ханның угланнары Мәнгү хаканны үтерербез дип иттифак кылдылар һәм, берничә арбага кораллар йөкләп, Ширамунны биш йөз кеше илән алдан җибәрделәр, вә башкалары аның артыннан бармак булдылар вә, форсат вакытны күзәтеп, хаканның өстенә һөҗүм кылмак булдылар. Әмма хакан гыйш вә гошрәт илән мәшгуль булып дөньядан хәбәре юк иде. Нагяһ хаканның нөкерләреннән бер кешенең дөясе югалды, ул кеше дөясен эзләп далага чыкты. Дөясен эзләп йөргәндә, нагяһ Ширамунның урдасына туры килеп, арбалардагы сугыш коралларын күрде вә, кайтып, хаканга күргәннәреннән хәбәр бирде. Хакан дәрхаль Мингәсәр ноянны ике мең кеше илән хакыйкать хәлне белмәк өчен Ширамунга каршы җибәрде. Мингәсәр ноян  Ширамунның гаскәре өстенә чыккач, Ширамун ни эшләргә белми каушап китте вә: «Без хаканны күрмәгә киләбез», — диде. Мингәсәр ноян  әйтте: «Әгәр хаканны  күрмәгә бара торган булсагыз торыгыз, минем илән һәмраһ булып бергә барыгыз», — диде.

Зарурияттан Ширамун мөлзәм[1] булып кушылып, бергә хаканның урдасына барып, хаканны күрде. Хакан Ширамун өчен өч көн мәҗлес кылды, дүртенче көнне, тәхет өстенә утырып, Ширамунны барча юлдашлары илән кыстады. Алар иттифак кылган эшләрен һәммәсен баштанаяк икърар кылдылар. Хакан Ширамунның кешеләреннән сиксән кешене үтерде вә Ширамун илән Киюк ханның угланнарын карендәшлек сәбәпле гафу кылды. Аннан соң тәмам шаһзадәләргә, вә нояннарга, вә әмирләргә кат-кат ингам вә ихсаннар биреп, соңра һәркайсына үз вилаятьләренә кайтырга рөхсәт бирде.

### Мәнгү хакан Кубилай хаканны мәшрикъ тарафындагы мәмләкәтләргә вә Һөләкүне мәгъриб тарафындагы мәмләкәтләргә җибәргәне

Мәнгү хакан, Батый ханның иҗтиһады илән тәхеткә утыргач, таркау мәмләкәтне сәрәнҗам кылмага мәшгуль булды. Шәрекъ вә мәгъриб тарафында берничә ил булмаган мәмләкәтләр бар иде. Кубилай хаканны — мәшрикъка, Һөләкүне мәгърибкә җибәреп, үзе сансыз гаскәр илән Чин вә Мачин өстенә йөрде вә Чин йортын һичкемнең ярдәменнән башка алды. Әмма бер олуг вә бәләнд кальгасы бар иде, аны берничә заман камап алырга касд кылса да ала алмады.

Кыш үтеп, яз җитте, һава гаҗәп эссе булды. Әмирләр әйттеләр: «Инде һава бик эссе булды, гаскәрнең күбрәге гофунәт[1] зәхмәтеннән кырылыр, бәс, әлхәл кайтып, кыш булгач килмәк мәслихәттер», — диделәр. Әмма хакан, бу кальганы алмый китмәм, дип кабул кылмады. Аннан соң хаканга бер авыру вә гариз[2] булды. Сигез көн бик авыр хаста булып ятты да тугызынчы көнендә вафат булды.

### Кубилай хаканның хан булганы

Кубилай хакан — Тули ханның дүртенче углыдыр. Мәнгү хакан үлгәндә Хытайда иде. Мәнгү хаканның үлгәнен ишеткәч, газалар[3] тотты, газадан фаригъ булгач, янындагы шаһзадәләренең вә әмирләренең иттифакы илән ханлык тәхетенә утырып дад[4] вә гадел илән мәшгуль булды. Аның бер энесе бар иде Арык Бога исемле. Аны Мәнгү хакан Кара-Коромда урдасына тәгаен кылып калдырган иде. Ул һәм Мәнгү хаканнан соң ханлык мәснәдендә[5] утырып, Кубилай хаканга яу булып, Кубилай хаканның илчеләрен үтерде. Дәште Кыпчакта Батый Саин хан үлгәннән соң, энесе Бәркә угыл ханлык мәснәдендә утырды. Арык Бога олуг гаскәр илән Бәркәнең өстенә йөрде. Икесе арасында олуг сугышлар булды. Ахирел әмер Бәркә җиңде. Арык Бога качып Кара-Коромга килде. Ул вакытта Кубилай хакан, Арык Бога хәбәрен ишетеп, Кара-Коромга килде. Арык Бога, хаканның килә торганыннан хәбәрдар булып, бер тарафка качып китте. Берничә вакыттан соң, атын арыклатып вә тунын туздырып, Кубилай хаканның дәркяһына килде, гозер теләде, хакан һәм гөнаһны гафу кылды. Шул вакытта Һөләкү, вә Бәркәдән, һәм Алгудан, хаканга табигъ булдык вә аның ханлыгына разыйбыз дип, илче килде. Хакан Җәйхун суыннан Мисырга-Шамгача Һөләкүгә бирде. Дәште Кыпчак илән дәхи ничә вилаятьләр Саин ханга тәгаллекъле иде, аны Бәркәгә бирде. Алтай тауларыннан Аму суынача Алгуга бирде. Алгу Чыгтай ханның нәбирәсе иде. Аннан соң Кубилай хакан тәмам Чин вилаятен алды. Утыз биш ел падишаһлык кылып, аннан соң вафат булды. Яше җитмеш өчкә җитте, аның гаҗәиб вә гараиб эшләре күп иде. Аның һәммәсен әйтсәк, китапка сыймас булды, шуңа күрә мохтәсар кылдык.

# Бишенче баб

### Чыңгыз ханның икенче углы Чыгтай ханның вә аның әүлядыннан Мавәраәннәһер вә Кашгарда падишаһлык кылганнары

Чыгтай хан һәйбәтле вә гайрәтле падишаһ иде, үзе гакыл вә дана[1] кеше иде. Чыңгыз хан Мавәраәннәһер вә Хәрәземнең бәгъзесен, вә Уйгур каласын, вә Кашгар, вә Бадахшан, вә Бәлх, вә Газнин та Синд суынача аңа бирмеш иде. Бу әйткән вилаятьләрнең һичкайсына үзе барганы юк иде. Әмма даругалар куеп, үзе Үгедәйнең катында торадыр иде, вә мелла Сикәки дигән зат аның нәдиме[2] вә дусты иде. Беркөн Сикәки дога укып бер гаскәр күрсәтте ки, ул гаскәрнең кораллары уттан иде. Чыгтай хан моны күреп хәйран калды. Чыгтайның бер вәзире бар иде, Сикәкигә дошман иде. Беркөн вакыт табып, Сикәкине ханга гайбәт кылып вә яман күрсәтеп, зинданга салдырды. Ходадан тәкъдир ирешеп, шул зинданда вафат булды. Чыгтай хан бер хастага грифтар булып, табиблар аның гыйлаҗыннан гаҗиз калдылар. Ахирел әмер тарих алты йөз кырыкта дөньядан үтте.

### Чыгтай ханның хатыннары вә угланнары

Чыгтай ханның хатыннары вә кәзинәкләре күп иде. Әмма ике хатыны араларында могтәбәрләр иде. Беренең исеме — Бисылун — Коңгырат падишаһы Кабаноянның кызы иде. Чыгтай ханның могтәбәр угланнары аннан туганнар иде. Икенче хатынының исеме — Теркән хатын — Бисылунның сеңлесе иде, Бисы-

лун үлгәннән соң алган иде. Чыгтай ханның җиде углы бар иде, олугының исеме Мутукан, Бисылун хатыннан туган иде. Икенче углы — Мужи, өченче углы — Бәлдәши, дүртенче углы — Сабин Бәлкә, бишенче углы —Сарман, алтынчы углы — Сөюмөнкә, җиденче углы — Байдар.

## Чыгтай ханның угланнары Мавәраәннәһердә падишаһлык кылганнары

Чыгтай хан үлгәннән соң, Кара Һөләкү бине Мутукан бине Чыгтай падишаһ булды. Аннан соң Мөбарәкшаһ бине Кара Һөләкү бине Мутукан бине Чыгтай хан падишаһ булды. Мөбарәкшаһның балалык вакытында анасы Әрганә хатын мәмләкәттә хакимлек кылды. Аннан соң Алгу бине Байдар бине Чыгтай хан падишаһ булды, аннан соң Барак хан бине Ясунту бине Мутукан бине Чыгтай хан падишаһ булды һәм, ике ел үткәч, мөселман булды. Аңа Солтан Гаязетдин дип ләкаб куйдылар. Чыгтай хан әүлядыннан иман нуры илән мөшәррәф булганнарыннан бу әүвәледер. Аннан соң Бәки бине Сарман бине Чыгтай хан падишаһ булды. Аннан соң Бога Тимер бине Кудагай бине Бузай бине Мутукан бине Чыгтай падишаһ булды. Аннан соң Дуй Чичән бине Барак бине Ясунту бине Мутукан бине Чыгтай падишаһ булды. Аннан соң Күнчек хан бине Дуй Чичән бине Барак хан булды. Аннан соң Күбек бине Дуй Чичән хан булды. Аннан соң Дуй Тимер хан бине Дуй Чичән хан булды. Аннан соң Тарма Ширин бине Дуй Чичән хан булды һәм ислам диненә керде. Моңа ияреп, һәммә халкы Мавәраәннәһердә мөселман булдылар. Югарыда Барак ханның мөселман булганын әйтеп идек. Барак хан үлгәннән соң, мөселман булганнар мөртәд[1] булып, әүвәлге диннәренә кайтканнар иде. Әмма Тарма Ширин илән мөселман булганнар асла кайтмадылар. Аннан соң Тарма Ширинны шәһид кылып, Буран бине Дуй Тимер бине Дуй Чичән падишаһ булды. Аннан соң Җәнекши бине Әбүкән бине Дуй Чичән падишаһ булды. Җәнекши илән Йисен Тимер бер ата вә бер анадан туганнар иде. Йисен Тимер Җәнекшине үтермәгә иттифак кылып иде. Анасы, бу хәбәрне ишеткәч, Җәнекшигә белдерде. Аннан соң Җәнекши илән Йисен Тимер саф тартып сугыштылар. Йисен Тимер Җәнекшине җиңеп, үзен һәм барча гаскәрен үтерде һәм анасының имчәген кисте. Аннан соң Үгедәй хан нәселеннән Гали солтан дигән, Чыгтай хан әүлядына галиб булып, Мавәраәннәһердә падишаһ булды. Аннан соң Казан Солтан хан бине Йисен бине Өрүк Тимер бине Бога Тимер бине Кудагай бине Мутукан бине Чыгтай хан падишаһ булды.

Мәгълүм булынадыр, Мавәраәннәһердә егерме бер кеше падишаһ булды. Аннан соң Чыгтай хан әүлядыннан падишаһ булган кемсәләрне әмирләр ханлык мәснәденә утыртып, исемнәре хан булса да, әмма дәрхакыйкать ханнар хөкүмәт мәслихәтеннән һичнәрсәгә игътибарлары булмады. Бу сүзнең раслыгына дәлил шулдыр ки: Казан Солтан хан гаҗәп гайрәтле падишаһ иде. Әмирләр аңа күренешкә барганда бала-чагалары илән исәнләшеп вә бәхилләшеп барырлар иде. Бу сәбәпле халык аңа гасый булдылар, һәм төзәп халыктан Әмир Козгын дигән кемсә Казан Солтан ханга ук атты. Бу икесе мокатәлә[1] кылдылар. Казан Солтан хан, Әмир Козгынны җиңеп, аңа табигъ халыкны талап вә үтереп барып, Каршы дигән җайда кышлады. Әмма Каршыда ул кышны бик күп кар яуганлыктан, Казан Солтан ханның гаскәре, атлары тәмам кырылды. Әмир Козгын бу хәлдән хәбәрдар булып, ләшкәр биниһая илән килеп, Казан Солтан илән мохарәбә[2] кылды һәм Әмир Козгын мозаффар[3] булып, Казан Солтан  ханны дәрәҗәи шәһадәткә[4] җиткерде. Чыңгыз хан углы Чыгтай хан нәселеннән Мавәраәннәһердә Казан Солтан ханның шәһид булганынча бер йөз дә тугыз ел солтанәт сөрделәр, барысы егерме бер кеше иде.

Әлкыйсса: Әмир Козгын Данишмәндчә хан бине Кайду хан бине Кашыйн бине Үгедәй хакан бине Чыңгыз ханны хан кылды. Ике елдан соң аны үтерде. Аннан соң Баян Колый хан бине Сургу бине Дуй Чичән бине Барак бине Ясунту бине Мутукан бине Чыгтай хан бине Чыңгыз ханны хан кылдылар. Әмир Козгын үлгәннән соң, углы Габдулла Баян Колый ханның хатынына гашыйк булды, шул сәбәптән Баян Колый ханны нахак үтерде дә Тимер Шаһ бине Йисен Тимер бине Әбүкән бине Дуй Чичән бине Барак хан бине Ясунту хан Мутукан бине Чыгтай ханны хан кылды. Әмир Габдулла үлгәннән соң, борадәрзадәсе Әмир Хөсәен бине Бисалай бине Әмир Козгын дигән Гадел Солтан бине Мөхәммәд бине Пулад бине Күнчек бине Дуй Чичән бине Барак хан бине Ясунту бине Мутукан бине Чыгтай ханны хан кылдылар. Әмир Аксак Тимер Әмир Хөсәеннең өстенә касд кылганда, Әмир Хөсәен Гадел Солтанны Аксак Тимер илән бер сүзле икән дип зан[1] кылып, кул-аягын баглап, дәрьяга ташлап үтерде. Аннан соң Кабул Солтан бине Дөрҗи бине Илчиктай бине Дуй Чичәнне хан кылды. Аннан соң Әмир Аксак Тимер бине Әмир Турагай Барлас Бәлх өстендә Әмир Хөсәен илән сугышып, Әмир Аксак Тимер Әмир Хөсәен илән солтанын икесен дә үтерде. Аннан соң Әмир Аксак Тимер Сөюргатмыш хан бине Данишмәндчә хан бине Кайду бине Кашыйн бине Үгедәй хакан бине Чыңгыз ханны хан кылды. Сөюргатмыш хан Хак рәхмәтенә киткәннән соң, аның углы Мөхәммәд Солтанны атасы урынында хан кылдылар. Казан Солтан ханнан соң зикер кылынган ханнарның

фәкать исемнәре хан иде, әмма һич эшкә ихтыярлары юк иде. Әлхасыйль, һәр җирдә һәр олуг кабилә үзалдына хан күтәрделәр. Мәлик таифе (падишалар, солтаннар) күп булды. Әмир Аксак Тимер бине Турагай, Барлас, карендәш-ыругны җыеп, бер сәгать сугышүтерештән бушамады. Ул вакытта Чыгтай хан нәселеннән Туклык Тимер хан дигән Кашгарда Газыйм Әлшан хан булып иде. Мавәраәннәһердәге хәбәрләрне ишетеп, хуш кылып ләшкәр биниһая илән Мавәраәннәһәргә килде. Берничә халык табигъ, вә берничә халык хан кулында булды, вә берничә халык качып китте. Әмир Аксак Тимер илән Әмир Хөсәен качып Никудәри вә Һәзара эченә бардылар. Туклык Тимер хан бер ел Мавәраәннәһердә торды, Ильяс Хуҗа исемле углы бар иде. Мавәраәннәһер хөкүмәтен аңа бирде, үзе Кашгарга кайтып китте. Бер елдан соң вафат булды. Аның үлгән хәбәрен ишетеп, Әмир Аксак Тимер илән Әмир Хөсәен килеп, Ильяс Хуҗа хан илән сугыштылар. Ильяс Хуҗа качып Кашгарга китте. Аннан Мавәраәннәһердә бу ике әмирдән башка олуг кеше калмады. Ахирел әмер бу ике әмир бер-берсе илән Бәлх Өстендә сугыштылар. Әмир Аксак Тимер җиңүче булып, Әмир Хөсәенне үтереп, Мавәраәннәһергә ялгызы хуҗа булды вә Сөюргатмышны заһирда хан кылып, тәхеттә утыртып, исеменә хөтбә укытыр иде. Әмма хакыйкатьтә үзе хан иде. Сөюргатмыш ханның ялганчы солтанәттән егерме ике ел үткәннән соң, хан Хак рәхмәтенә китте. Аннан соң углы Солтан Мөхәммәдне хан кылды. Солтан Мөхәммәд Аксак Тимерне вә аның әүлядын шул дәрәҗә газиз вә олуг тотар иде ки, һич әмирнең хәтеренә тузан кунмас иде. Кичә вә көндез Коръән вә намаз укып, ураза тотып, әмирнең дәүләтен теләп дога кылып утырыр иде. Әмир Аксак Тимер ярлыкларның башында «Гадел Мөхәммәд хан, әмир, Газый сүзебез...» дип яздырыр иде. Туйда вә гаедләрдә Әмир Тимер ханга күренешкә барып, каршында әдәп илән тезләнеп утырыр иде вә, илче килгәндә, Ушандак ханга тәгъзыйм вә тәкрим илән утырыр иде.

Әлхасыйль, Әмир Аксак Тимернең солтанәтеннән утыз өч ел үтеп вә гомереннән алтмыш ел кичкәннән соң, Анатолига Йылдырым Баязид өстенә барды. Аның илән саф тартып сабахтан та кичәнең ярымынача сугышты. Йылдырым Баязид качты, Мөхәммәд хан аның артыннан куды. Иртәсе көн өйлә вакытында артыннан җитеп, Йылдырым Баязидны тотып, Әмир Тимернең алдына алып килде. Әмир Тимер ул сәнә Анатолида торып, Йылдырым Баязид илән Мөхәммәд ханны үтереп, хөтбәне үз исеменә укытып һәм сиккәне үз исеменә сuктырды. Аннан соң кайтып, Сәмәркандка килде. Бераз вакыт үткәч, Хытай мәмләкәтенең өстенә атланды. Отрарга килгәндә юлда дарелфанәдән дарелбакыйга китте, мөддәт гомере җитмеш бер ел вә солтанәте утыз алты ел булып, тарих һиҗри сигез йөз җидедә тәмам булды.

## Туклык Тимер ханның мөселман булганы

Чыгтай хан әүлядыннан Илхуҗа ләкабе Исәнбога хан бине Дуй Чичән бине Барак бине Ясунту бине Мутукан бине Чыгтай хан Мавәраәннәһердә туган иде. Кашгар, вә Яркәнд, вә Алатауда, Уйгурстан мәмләкәтендә Чыгтай хан нәселеннән нафиз[1] фәрман булган һич падишаһ намдар юк иде. Ул сәбәптән әмраи могул җыелып, киңәш кылып, Бохарадан Исәнбоганы китереп, Кашгар, вә Яркәнд, вә Алатау, вә Могулстанда падишаһ кылдылар вә падишаһ газыйм әлшаин булды. Аның Сатылмыш хатын дигән хатыны бар иде. Аның угланы булмас иде, вә падишаһның дәхи бер Миңле исемле кәнизәге бар иде. Аны урдасында тотып илтифатлар кылыр иде. Нагяһ ул кәнизәк хамилә булды. Хан ауга киткәндә, Сатылмыш хатын ул кәнизәкне Ширә угыл дигән могулга бирде вә әйтте: «Син бу вилаятьтә торма, күчеп, Могул йортына барып, анда карар кыл», — диде. Ул могул бу сүз илән гамәл кылып күчеп китте. Әмма ул кәнизәкнең ханнан хамилә булганын тәмам халык белмеш иде. Хан аудан кайткач, ул кәнизәкне сорады, аңа тәмам вакыйганы әйтеп бирделәр. Шулай булса да хан Сатылмыш хатынга һич сүз әйтмәде, аның өчен могул рәсемендә падишаһның ничә хатыны булса, бер хатынны башка хатыннарына хаким кылыр иде. Бу хатын башка хатыннарга ни кылса да, аңа сүз әйтмәс иде. Исәнбога хан Сатылмыш хатынга һич сүз әйтми.

Берничә көннән соң Исәнбога хан үлде. Чыгтай әүлядыннан падишаһлыкка лаек кеше калмады. Һәр кабилә үз алдына бер хан күтәрделәр, мәлик таифе күп булды. Исәнбога ханның Әмир Пуладчи дигән әмире бар иде. Миңле хатынның хамилә киткәненнән хәбәрдар иде. Таштимер дигәнгә азык өчен утыз куй биреп иде. Әгәр Миңле хатыннан вә аның хамиленнән хәбәр алып кайтсаң, хәтсез вә ниһаятьсез мал бирермен дип вәгъдә кылып, Таштимерне озатты. Таштимер галәмне кәшт[1] кылып гизде вә барып Могул йортына төште. Нагяһ бер мәхәлләгә килеп: «Кем мәхәлләсе?» — дип сорады. «Ширә угылның мәхәлләседер», — диделәр. Таштимер Миңле хатынның вә аның хамиленең хәбәрен сорады. Аңа әйттеләр: «Миңле хатынның Исәнбога ханнан бер углы булды, исемне Туклык Тимер куйдылар. Вә Ширә угылдан бер углы булды, исемне Тимер Мәлик куйдылар. Икесе һәм бергә мәхәлләдә уйнап йөрер иделәр». Әлкыйсса: Таштимер, күп хәйләләр кылып, Туклык Тимер ханны Әмир Пуладчига китерде. Аннан соң Әмир Пуладчи Туклык Тимер ханны хан күтәреп, могул рәсеменчә туйлар кылдылар. Туклык Тимер хан аз вакытта Кашгар, вә

Яркәнд, вә Алатау, вә Уйгурстанны алды. Аннан соң Мавәраәннәһер мәмләкәтен тәхет тасрифына күтәреп, Ильяс Хуҗа исемле угылны Сәмәркандка куеп, үзе кайтып, Хак рәхмәтенә китте.

Чыңгыз хан нәселеннән Кашгарда әүвәл мөселман булган бу зат иде. Мөселман булмаганының сәбәбе бу иде ки: беркөн ауга чыгып ау аулап йөргәндә, нагяһ бер җәмәгатькә күзе төште, күчеп килеп утырган иделәр. Хан шул җәмәгатьнең кулларын вә муеннарын баглап хозурына китермәгә боерды. Есаулларга барып баглап алып килделәр. Хан әйтте: «Минем хөкемемне тотмый минем шикяркәмдә ни кылып йөрисез?» Әмма хан ярлык кылып әйтте ки: «Шикяркәгә һичкем бармасын, әгәр барган кеше булса, баглап алып килегез!» — дип. Ошбу баглап китергән халыкның олугы Шәех Җамалетдин дигән зат иде. Шәех Җамалетдин Бохараның әүлядыннан ата-анадан мәртәбәле булып килгәннәр иде. Шәех әйтте: «Без мосафирбыз, падишаһның ярлык кылганын белмәдек, Китек дигән җирдән киләбез». Хан сорады: «Кем буласыз, таҗикмысыз?» Шәех: «Таҗикбыз», — диделәр. Хан: «Таҗиктан эт һәм артыктыр», — диде. Шәех әйтте: «Иман бездә булмаса, эттән һәм кәм булыр идек», — диде. Бу сүз хан күңеленә әсәр килеп, бер есаулга боерды ки, мин кайтып төшкәннән соң, бу таҗикны алып миңа бар, дип әмер кылды. Хан кайткач, есаул шәехне хан алдына алып барды. Хан хәлвәттә[1] утырган иде, хан әйтте: «Син имансыз кеше эттән һәм кәмдер дидең, ул сүзнең мәгънәсе нидер? Вә иман дигән ни булыр?» — диде. Шәех иманны шундый тәгъриф кылды ки, ханның таш кеби каты күңеле балавыз кеби йомшады вә кяферне шул дәрәҗә хурлады ки, ханның кяфердән күңеле кайтып тәмам бизәр булды вә кяференә тәүбә кылып зар-зар елады, дәхи әйтте: «Әлхәл мөселманлыкны әшкярә[2] кылсам, халыкны юлга күндерә алмам, бер вакытка сабыр кыл. Әгәр ата-бабамның мирасы булган фәләнчә вилаятьләрне алсам, әлбәттә, яныма рәхим ит, шул вакытта исламны әзһәр кылырмын», — дип, гыйззәт вә хөрмәт кылып җибәрде. Шәех кайтып, кышына килде. Берничә вакыттан соң шәех хаста булып, углына васыять кылып әйтте ки: «Бу хан олуг падишаһ булачактыр. Әлбәттә, курыкмый ханның хозурына барып, минем сәламемне җиткерерсең, дәхи минем илән гаһед кылганын әйтерсең, зинһар, курыкма», — диде. Шул сүзләрне әйтеп, дарелбакыйга рихләт кылды.

Шәех углының исеме Рәшидетдин. Шәех аны үз урынына вәли әлгаһед кылган иде. Ничә ел үткәннән соң, хан Кашгар, вә Ташкент, вә Яркәнд, вә Уйгурстан, вә Әндиҗан, вә Сәмәрканд, вә Бохара, вә тәмам Мавәраәннәһерне алды. Шәех Рәшидетдин атасының васыятен әйтмәк өчен ханның урдасына барды. Никадәр иҗтиһад кылса да, ханны күрә алмады. Беркөн сабах садыйк булганда урданың якынына килеп бәләнд аваз илән азан әйтте. Хан, бу авазны ишетеп, барып, шул кычкырган кешене алып кил, дип, кеше җибәрде. Ул кеше шәехне алып килде. Хан аңа әйтте: «Ни өчен безне син йокыбыздан тавышың илән куркытып уйгаттың?» — диде. Шәех Рәшидетдин атасының барча васыятьләрен ханга бәян кылды. Хан, үзе кәлимән шәһадәтне әйтеп, мөселманлыгын әзһәр кылды, дәхи әмирләрен берәм-берәм чакырып, аларны һәм мөселман кылды. Әмма бер бәге бар иде, Чурас исемле, ул әйтте: «Монда бер пәһлеван бар, бу таҗик шуның илән көрәшсен, әгәр аны екса, мин мөселман булырмын», — диде. Хан, моны мәнгы кылса да, әмма бәк кабул кылмады. Шәех Рәшидетдин әйтте: «Әмир Чурас яхшы шарт кылды, пәһлеванны алып килегез, көрәшик», — диде. Могулның пәһлеванын алып килделәр. Шәех аның илән тотышып вә көрәшеп йөргәндә пәһлеванның күкрәгенә бер кәррә орды ки, шул хәл биһуш булып егылды. Берзаманнан соң пәһлеван, гакылына килеп, кәлимәи шәһадәтне әйтә-әйтә урыныннан торып, шәехнең аягына егылды. Ул хәлне күреп, Чурас мөселман булды.

Болар илән бәрабәр җәмигъ халык мөселман булдылар, ул көнне ислам кабул иткәннең хисабы йөз алтмыш мең кеше иде. Чыгтай иленең эчендә ислам заһир булды. Берничә көннән соң Әмир Пуладчи вафат булды, Туклык Тимер ханны ханлык мәсабында[1] утыртып, үзе әмирел-өмәра[2] иде. Аннан җиде яшәр бер угыл калды, Ходайдад исемле. Атасының ләземен аңа бирде. Әмма Әмир Пуладчи биш ага-эне иделәр. Өченче энесенең исеме Камәретдин иде. Ул гаҗәп бипакь иде, әмма үзе бик көчле пәһлеван кеше иде.

Әлкыйсса: беркөн хан күренешханәдә утырып торганда, Камәретдин гарыз кылды ки: «Әмир Ходайдад яшьтер, мондый олуг илгә сәрдарлык кылып башкара белмәс. Үсеп башкарырдай булганчы, мәнсабын миңа бир, аңанчы минем катымда торсын», — диде. Әмма хан аны кабул кылмады, ул сәбәптән Камәретдин ханнан күңеле калып эченә салды. Туклык Тимер хан тарих җиде йөз утызда дөньяга килде. Әмир Пуладчи Дуглатиның тырышлыгы илән унсигез яшендә хан булды. Егерме дүрт яшендә нур иманга мөшәррәф булып мөселман булды, утыз дүрт яшендә Тәңре хөкемен тәмам кылып дарелбакыйга күчте.

Ханның вафатыннан соң Камәретдин Дуглати, ачуы чыгып, Ильяс Хуҗа бине Туклык Тимер ханны үтерде. Ул көн Туклык Тимер ханның нәселеннән олуг-кечек унсигез кешене шәһид иттерде вә үзенең игътибарлы кешеләренә әйтеп куйды ки, һәркайда Туклык Тимер хан нәселеннән мәүҗид булса, үтерегез, дәю. Аннан соң Камәретдин, үзенә хан аты куеп, хөтбә вә сиккәне үз исеменә кылды. Әмма Туклык Тимер ханнан бер сөт имә торган углан бар иде. Анасының исеме Әмирага иде. Әмирага хатын бу угланны алып, Әмир Ходайдад каршына барды, вә Әмир Ходайдад бу угланны яшерде, ничә мәртәбә Камәретдин кеше җибәреп сораса да, бирмәде. Ул вакытта Әмир Аксак Тимер гаскәр биниһая илән Камәретдиннең өстенә

килде. Болар мокатәлә вә мөхарәбәгә мәшгуль булганда, Әмир Ходайдад Туклык Тимер хан углына даялар[1] тәгаен кылып, берничә игътибарлы кешеләр илән Таг-Бадахшанга ханзадәне тәрбия кылырга җибәрде.

Әлкыйсса: Әмир Аксак Тимер Камәретдиннең өстенә биш мәртәбә килде, һәр килгәндә саф тартып сугышып, ике яктан да күп гаскәр тәләф булды. Әлхасыйль, соңгы килгәндә Камәретдин гыйлләт[2] истискага[3] дучар булган иде. Әмир Аксак Тимернең килә торганын ишетеп, берничә халык илән бер тарафка качтылар. Зирәки Камәретдиннең нәфестән гайре хәрәкәте юк иде. Берничә көнлек азык илән Камәретдинне бер кәнизәккә тапшырып, бер олуг урман бар иде, аңа җибәрделәр. Билзарури, берничә көннән соң ишеттеләр ки, Әмир Аксак Тимернең килмәк хәбәре ялган, имеш, дип. Халык кайтып, җирле җиренә утырдылар һәм Камәретдин өчен урманга кеше җибәрделәр. Ул кеше урманга барып ничаклы эзләсәләр дә, Камәретдинне тапмый кайтып киттеләр. Ахирел әмер мәгълүм булды ки, Камәретдин Мәлик Гаҗимның хезмәтенә бармыш.

Әлкыйсса: Бадахшанга җибәргән ханзадәнең исеме Хозыр Хуҗа иде. Аны кайтарып, атасының урынына хан кылдылар. Ул вакыттан бу вакыткача Кашгар вә Яркәндтә булган падишаһлар ошбу Хозыр Хуҗа бине Туклык Тимер хан бине Исәнбога хан бине Дуй Чичән Барак хан бине Ясунту бине Мутукан бине Чыгтай хан бине Чыңгыз ханның нәселеннәндер. Ак Мангыт кабиләсеннән Котлык Коба дигән бер кеше бар иде вә аның дәхи бер углы илән бер кызы мәүҗүд иде. Кызын Тимер бәк углан алды. Тимер Котлык хан аннан вөҗүдкә килде, углының исеме Идегәйдер. Ул Туктамыш ханга барып нөкер булды. Туктамыш, Ырыс ханыннан качып, Аксак Тимер бинең янына Сәмәркандка килде. Артыннан Идегәй Мангыт килеп әйтте ки, Ырыс хан гаскәр җәмгъ кылып, бу тарафка мөтәвәҗҗиһ булды дип, Аксак Тимер бинең ярдәме илән Ырыс ханны җиңеп, Җүчи ханның халкына әкә булып, Шәһре Сарайда ханлык тәхетенә утырды. Тимер Котлык хан хәде балигъка җитеп егет булганнан соң, Идегәй Мангыт, Туктамыш ханнан аерылып, Тимер Котлык ханга кушылды. Зирәки Тимер Котлык ханның күңелендә падишаһ булмак морады бар иде. Шул сәбәптән Туктамыш ханга хилафлык кылыр иде. Туктамыш аны тотып үтермәгә касд кылды. Тимер Котлык хан, аннан качып, Аксак Тимер бинең янына килде. Идегәй Мангыт Тимер Котлыктан аерылып калган иде. Алты айдан соң Тимер Котлыкка килеп кушылды. Берничә вакыттан соң Әмир Аксак Тимер Иран мәмләкәте өстенә атланды. Туктамыш хан, Мавәраәннәһерне әкәсез табып, Сәмәркандка килеп, берничә мөселманнарны шәһид кылып, талап, үтереп кайтты. Әмир Аксак Тимер, бу хәбәрне ишетеп, кайтып, Сәмәркандтә тормый, Туктамыш ханның өстенә атланды. Барып, Идел суының буенда Туктамыш хан илән орыштылар. Ахыр Аксак Тимер җиңеп, Туктамыш хан качып китте. Аксак Тимер би күп халыкны кател гам кылды.

Югарыда әйтелеп иде ки, Тимер Котлык хан, Туктамыш ханнан качып, Әмир Аксак Тимернең катына килде, шул Тимер Котлык Әмир Тимернең Туктамыш хан өстенә барган гаскәрендә аның илән юлдаш иде. Килеп, Әмир Тимергә гарыз кылды ки: «Туктамыш хан минем ата вә бабаларымнан мирас булып калган халкымны көчлүк илән алган иде, инде аларның барчасын сәламәт дип ишетәмен, әгәр рөхсәт бирсәгез, аларның һәммәсен хезмәтегезгә алып килер идем», — диде. Әмир Аксак Тимер Котлык Тимергә рөхсәт бирде. Тимер Котлык илне Идел суының буенда табып, күчереп, Әмир Тимер тарафына юнәлде. Берничә мәсафәт[1] килгәннән соң, Идегәй Мангыт Тимер Котлыкка әйтте ки: «Бу халыкны Тимер бигә илткәннән ни файда бар? Тимер би бу халыкны Сәмәркандка алып барып, һәркайсын бер җиргә җибәрер, син халкыңның олугыдай Тимер бигә нөкер булып йөрерсең», — диде. Тимер Котлык Углан Идегәй Мангытның сүзенә колак салып, кабиләсенең аксакалларын җыеп әйтте ки: «Сезләрне Тимер би үтереп, балачагаларыгызны әсир кылыр», — диде. Ул вакыт халык әйттеләр: «Без синең өчен барабыз, югыйсә без Тимер бине танымыйбыз», — диделәр. Аннан соң Тимер Котлык Углан, илне алып кайтып, Туктамышка һәм Аксак Тимергә кушылмый Дәште Кыпчакның бер җирендә карарланды.

# Алтынчы баб

## Чыңгыз ханның кече углы Тули ханның нәселеннән Иран йортында падишаһлык кылганнары

Киюк хан бине Үгедәй хакан үлгәннән соң, Мәнгү хакан бине Тули хан булды. Мәгълүм булсын ки, һәркемнең гыйззәте вә дәүләте ханлык мәртәбәсеннән артык булса, халаеклар вә әмирләр аны хакан диерләр. Тули хан Ойрат халкыннан Аргын ага дигәнне Хорасанга хаким кылып җибәрде. Аргын ага ун ел хөкүмәт кылганнан соң вафат булды. Аннан соң Мәнгү хакан үзенең энесе Һөләкү ханга гаскәрнең биштән

берен биреп, Иран мәмләкәтенең хөкүмәтен бирде. Ул Иранга килеп, җәмәгаи мөляхәзәне вә хәлифәи мөхтәсимне үтереп, аларның мөлкәтен тәхет тасрифына кертте. Аннан барып, Шам мәмләкәтен алды. Тугыз ел падишаһлык кылып дөньядан үтте. Аннан соң Абака хан бине Һөләкү хан агасы Кубилай хаканның хөкеме илән атасының урынына утырды, унҗиде ел ханлык кылып, атасының артыннан китте. Аннан соң Әхмәд хан бине Һөләкү хан падишаһ булды. Аның падишаһлыгыннан ике ел үткәч, Аргын бине Абак хан бине Һөләкү хан, аны үтереп, аның урынына утырды, ул һәм җиде ел падишаһлык кылып дөньядан үтте. Аннан соң Кинҗайту бине Абак хан бине Һөләкү хан хан булды. Падишаһлыктан дүрт ел үткәч, Байду бине Торагай бине Һөләкү хан, аны үтереп, урынына хан булды. Падишаһлыктан сигез ай үткәч, Газан хан бине Аргын хан бине Абак хан бине Һөләкү хан, аны үтереп, аның урынына падишаһ булды. Тули хан нәселеннән Иранда ислам нуры илән мөшәррәф булып, исламны кабул иткәннәрнең әүвәле иде. Аның заманыннан ул тарафта ислам шөһрәт табып, кяфер яшертен булды вә кяфер ханәләрен утка яктырды. Аның сәбәпләре Иран-заминның җәмигъ могулы вә татары ислам илән мөшәррәф булдылар. Падишаһлыктан тугыз ел үткәч, тарих җиде йөз бердә дарелбакыйга күчте, гомере утыз ел булды. Аннан соң Өлҗәйтү хан бине Аргын хан бине Абак хан бине Һөләкү хан падишаһ булды. Унөч ел падишаһлык кылып вафат булды. Аннан соң Әбүсәгыйд хан бине Өлҗәйтү хан падишаһ булды. Әбүсәгыйд хан атасы үлгәндә унике яшендә иде, ул сәбәптән берничә вакыт зимам[1] хөкүмәтне Әмир Чупан Сөлдуска бирде. Падишаһлыктан унтугыз ел үткәннән соң, Хак рәхмәтенә китте.

## Һөләкү хан нәселеннән Иран мәмләкәтендә Әбүсәгыйд ханнан соң әмирләр хан кылганы

Мәгълүм булынадыр, ошбу Әбүсәгыйд ханнан соң булган ханнарның, фәкать исемнәре хан булып, мәмләкәт эшләрендә һич ихтыярлары калмады, дәхи Сөлдус Чупаны әмралары Әбүсәгыйд ханнан соң әмралар Тули хан нәселеннән Арык Бога углы Арпа ханны хан күтәрделәр. Багдад хакиме Ойрат ыругыннан Гали дигән кемсә Муса бине Гали бине Байду бине Һөләкүне хан кылды. Кайсы кем Арпа хан илән сугышып җиңүче булды, Арпа ханны үтереп, мәмләкәтне тәхет тасрыйфына алды. Ул вакытта Рум хакиме Бөзрек ләкабе илә мәшһүр Шәех Хәсән Җалайыр дигән зат, Муса ханның хан булып Арпа ханга галиб булганын ишетеп, Мөхәммәд бине Юл Котлык бине Тимер бине Анбарчи бине Мәнгү Тимер бине Һөләкү ханны хан кылып, Румнан вә Гөрҗидән гаскәр газыйм җәмгъ кылып, Иран тарафына юл тотты вә, килеп, Тәбриз өстендә Муса хан илән орышып галиб булды. Гали Ойрат — Ойрат халкының олуг кешесе иде, ул үлде, Муса хан качып Ойрат иленең эченә китте. Ул арада Хорасан хакиме Гали бине Әмир Гали Кошчы дигән зат, бу хәбәрне ишетеп, Хорасанда утырган тәмам татар вә могулны җәмгъ кылып, Бистамга бардылар. Чыңгыз хан энесе Җүчи Касар нәселеннән Тугай Тимер дигән Мазандаранда хаким иде. Китереп, хан кылдылар һәм Шәех Хәсән Җалайырның ханы Мөхәммәд хан өстенә йөрделәр. Азәрбайҗанда Ойрат халкы илән Муса хан килеп, Тугай Тимергә кушылды. Шәех Хәсән Җалайыр, бу хәбәрне ишетеп, каршы килде. Бу ике гаскәр сахраи Герм-Рудта мөхарәбә кылдылар. Шәех Хәсән Җалайыр мозаффар булды вә Муса хан орышта үлде. Тугай Тимер хан илән Шәех Гали бине Әмир Гали качып Хорасанга киттеләр. Шәех Хәсән бине Тимерташ бине Әмир Чупан Сөлдуска, аңа Шәех Хәсән Күчүк дирләр. Әбүсәгыйд ханның әмире илән Румның бер тарафына хаким иде, ул һәм бу хәбәрне ишетеп, гаскәр бинипаяя илән Шәех Хәсән Җалайырның өстенә йөрде. Бу ике гаскәр Нахичеван өстендә сугыштылар. Шәех Хәсән Күчүк мозаффар булды, Мөхәммәд хан орышта үлде. Шәех Хәсән Җалайыр качып Солтаниягә китте. Шәех Хәсән Күчүк Сатыйбикә хатын бинте Солтан Мөхәммәд Хор Бәндәне Тәбриздә тәхеткә утыртты һәм Шәех Хәсән Җалайырның артыннан барды. Шәех Хәсән Җалайырга каршы чыгып, Шәех Хәсән Күчүккә табигъ булып солых кылдылар. Дәхи бер елдан соң Шәех Хәсән Күчүк Сатыйбикә хатынны урыныннан төшереп, Сөләйман бине Мөхәммәд бине Сөнкә бине Яшмүт бине Һөләкү ханны хан кылды һәм Сатыйбикә хатынны аңа никахландырды. Берничә вакыттан соң Шәех Хәсән Җалайыр, Әмир Шәех Хәсән Күчүктән йөз чөереп, Багдадка барды һәм Җиһан Тимер бине Алафирәң бине Кинҗайту хан бине Абак хан бине Һөләкү ханны хан кылды. Бәгъдә ләшкәр газыйм җәмгъ кылып килеп, Шәех Хәсән Күчүк Сөлдус илән мокатәлә кылды. Шәех Хәсән Күчүк галиб булды. Шәех Хәсән Җалайыр качып Багдадка килде вә, ханны урыныннан төшереп, үзе хан булды. Аннан соң Шәех Хәсән Сөлдусның эше куәт тапты.

Ошбу Шәех Хәсән Күчүкнең бер гарәб хатыны бар иде, ул хатынга Якуб Шах дигән кемсә гашыйк иде. Хатын һәм аңа гашыйк иде. Беркөн Якуб Шах бер гөнаһ эш кылды, шуның өчен Шәех Хәсән аны зинданга салды, бу хатын, минем илән эш булганны аңлап аны зинданга салды, дип хыял кылды. Шул сәбәптән Әмир Шәех Хәсән бер кичә мәст[1] булып килеп ятканда, бу гарәб хатын Шәех Хәсәннең үзегеннән өстерәп

йөреп үтерде. Аннан соң Шәех Хәсән Күчүкнең Мәлик Әшрәф дигән энесе бар иде, ул агасының урынына утырды һәм Һөләкү хан нәселеннән Әнүширван дигәнне хан кылды. Берничә вакыттан соң аны урыннан төшереп, үзе хан булды, хөтбә вә сиккәне үз исеменә кылдырды. Бу Мәлик Әшрәф гаҗәп бипакь залим иде. Мөселманнар аның җәбереннән һәр тарафка качар булдылар. Казый Мөхетдин качып Дәште Кыпчакка Җанибәк хан каршына барды, дәхи Җанибәк ханның алдында Мәлик Әшрәфнең җәберен шулай бәян кылды ки, Җанибәк хан вә җәмигъ халаек зар-зар еладылар. Ахирел әмер Җанибәк хан ләшкәр биниһая илән Мәлик Әшрәфнең өстенә атланды. Азәрбайҗанга килеп, Хой дигән җирнең өстендә Мәлик Әшрәф Сөлдус илән мөхарәбә[1] кылды һәм, мозаффар булып, Мәлик Әшрәфне үтереп, хәзинә вә дәфинәсенә ия булды. Бу вакытта тарих җиде йөз илле тугызда иде.

# Җиденче баб

## Җүчи хан әүлядыннан Дәште Кыпчакта падишаһлык кылган ханнар

Әүвәл Җүчи ханны бәян кылаем. Җүчи хан анасының исемен Бурта Кучин диерләр. Бурта Кучин хамилә вакытында, Чыңгыз хан өйдә юк вакытта, меркит халкының ханы Чыңгыз хан хатыны Бурта Кучинның җиңгәсе иде, Уң хан илән меркит ханы арасында дуслык бар иде. Ул сәбәптән Уң хан Бурта Кучинны теләп алды, Чыңгыз ханга җибәрде. Аның өчен Уң хан илән Чыңгыз ханның атасы Исүгәй Баһадир хан дус иде. Әлкыйсса: Бурта Кучин юлда Җүчи ханны тудырды. Ул җирдә салырга бишек юк иде, бәс, тәне авыртмасын өчен, камырдан тагарак вә колаша кеби нәрсә ясап, аның эченә салып кайттылар. Чыңгыз хан, бу угылны күреп, хушхәл булып, безгә Җүчи килде, диде. Могул телендә «җәүчи» дип яңа килгән миһманны әйтерләр, шул сәбәптән исемне Җүчи куйдылар.

Вә мәгълүм булсын, Җүчи хан атасыннан әүвәл үлде. Аның хосусында әҗмәлә[1] Чыңгыз хан дастанында зирек кылынган иде, шуңа күрә мохтәсар кылдык.

### Батый хан бине Җүчи хан

Чыңгыз хан, Җүчи ханның үлгәнен ишеткәч, бик кайгырып газа тотты. Ул вакытта мәмләкәт мәслихәте өчен угланнары вә әмирләренә һәммәсенә үгет вә нәсыйхәтләр әйтә башлады вә васыять охшашлы сүзләр сөйли башлады. Газадан фаригъ булгач, Утчикингә Дәште Кыпчакка барырга боерып, Җүчи ханның икенче углы Саин хан ләкабендә Батыйны атасы тәхетендә утыртып, энеләре вә әмирләрен аңа тәбгы кыл, диде. «Әгәр энеләре сүзеңне тотмасалар, үзең анда калып, безгә ул хосустан мәгълүм кылып хәбәр күндер. Ул вакытта без аның мәслихәтен күрербез», — дип хөкем кылды.

Утчикин Батый ханның урдасына якынайганда, Батый хан, хәбәр алып, угланнары вә энеләрен каршы алырга җибәрде, үзе һәм аларның артыннан истикъбальга[1] чыгып, Утчикин илән күрешеп, газаны яңарттылар. Өч көннән соң Утчикин, Батый ханны атасы тәхетендә утыртып, Батыйның эне вә әмирләренә Чыңгыз ханның әйткән сүзләрен әйтте. Халыкның барчасы кабул кылдылар. Аннан соң олуг бәйрәм кылып, татар вә могул рәсеменчә Батыйга аяк[2] бирделәр. Батый һәм аларга аяк биреп күп ингам вә ихсаннар кылды. Ул вакытта Чыңгыз ханның урдасыннан бер кеше, килеп, Чыңгыз ханның үлгәненнән хәбәр бирде. Аны ишетеп, барчасы ах вә фиган[3] итеп вә газаны яңартып, күзләреннән яшь урынына кан түгеп елаштылар.

Әлкыйсса: газадан фаригъ булгач, Батый хан мәмләкәтне кече энесе Тукай Тимергә тапшырып, биш энесе — Арду, Шибан, Бәркә, Җомбай, Бәркиҗарны алып вә Утчикин илән кушылып, Чыңгыз ханның тәхет-башкаласы Кара-Кором тарафына мөтәвәҗҗиһ булдылар, җитеп, Кара-Коромда җәмигъ әмирләр вә шаһзадәләргә кушылып, дәхи олуг газа тоттылар. Газадан фаригъ булгач, Батый хан вә җәмигъ шаһзадәләр, Чыңгыз ханның васыяте илән Үгедәй хаканны тәхеттә утыртып, олуг туй кылып, хаканга аяк бирделәр. Хакан һәм шаһзадәләргә вә әмирләргә аяк биреп, хәзинәнең ишеген ачып, шундый ингам вә ихсаннар бирде ки, илдә һич ярлы кеше калмады, һәммәсе дә баедылар. Хытай мәмләкәтендә берничә мәликнең падишаһлары яу булган иде. Хакан ул тарафка атланмак булып Батый ханга бу сәфәрдә минем илән һәмраһ бул дип хөкем кылды. Батый хан һәм биш энесе илән атланды. Ул орышта хакан ул вилаятьләрнең барчасын кател вә гайрәт кылып, Кара-Коромга килде. Аннан соң Батый ханны Болгар, Урыс вә Чиркәс вә гайре вилаятьләрне алырга тәгаен кылды. Үзенең углы Киюк хан, вә Тули ханның углы Мәнгү хакан, вә Чыгтайның углы Байдарны бу сәфәрдә Батый ханга хезмәт кылыгыз вә ярдәм бирегез дип кушып җибәрде. Батый хан боларны алып, атланып үзенең тәхтегяһына[1] кайтты.

Батый ханның энесе Тукай Тимер хан бу җәмәгатьне миһман кылды. Өч кичә вә көндез үзеннән җибәрмәде. Аннан соң Батый хан аларны кырык кичә вә көндез миһман кылды. Ошбу мөдәттә бер сәгать гыйш вә гошрәттән бушамадылар. Аннан соң ләшкәр җәмгъ кылмак өчен, әтрафка өндәүләр җибәрде. Кыска гына вакытта шулчаклы күп гаскәр җыелды ки, хәд вә ниһаяте юк иде. Мәгълүм булсын ки, Җүчи ханның тәхтегяһы Дәште Кыпчакта Күк Урда дигән җир иде. Батый ханның Маҗар, вә Башкорт, вә Болгар, вә Урыс, вә Карел, вә Немец йортларын алганы вә үзенең вафаты моннан түбәнрәктә бәян кылыныр.

## Бәркә хан бине Җүчи ханның Дәште Кыпчакта хан булганы

Батый хан үлгәч, Мәнгү хакан Батый ханның углы Сартак угланны хан кылды. Ул ханлык мәснәденә утырмастан вафат булды. Аннан соң аның энесе Улакчыны хан кылдылар. Улакчы һәм аз вакыт эчендә вафат булды. Аннан соң Мәнгү хакан Бәркә хан бине Җүчи ханны хан кылды. Бәркә хан, хан булгач, олуг бәйрәмнәр кылып, күп ингамнар бирде вә барча энеләренә Батый хан биргән өлешләрен бирде дә хаканга күп һәдияләр җибәрде. Аннан соң Ходай Тәгалә беркөн Бәркә ханның күңеленә мөселманлыкның мәхәббәтен салып, үзенең ялгыш диндә йөргәнен белде.

Әлкыйсса: беркөн атланып агасы Батый ханның салган шәһәре Сарайчыкка барганда күрде ки, юлда Бохарадан күп кәрван килеп торыр. Ул кәрванның эчендә ике яхшы галим кешеләрне бер аулак җиргә чакырып, мөселманлыкның тарикъ[2] вә әдәбен сорады. Бу кешеләр мөселманлыкны тиешле булганча бәян кылдылар. Бәркә хан шул кыска вакыт эчендә чын ихлас күңеле илән мөселман булды. Аннан соң кече энесе Тукай Тимерне чакырып, бу серне аңа әйтте. Ул һәм агасы артыннан мөселман булды. Аның бәгъдендә иле эчендә дин-исламны әшкярә кылып, һәр җирдә, кяфер булса, аңа дошман булып хилаф торды. Ахирел әмер аның зате шәрифендә чәнчү зәхмәте пәйда булып, тарих алты йөз алтмыш дүрттә Хак рәхмәтенә китте. Егерме биш ел падишаһлык сөрде.

## Мәнгү Тимер хан бине Тукай бине Җүчи хан, аннан соң Туда Мөнгү бине Тукай бине Җүчи хан, аннан соң Туктагу хан бине Мәнгү Тимер ханнарның бәяны

Бәркә хан вафат булгач, Мәнгү Тимер хан үз өлешенә тигән илне үзенә каратмак илән мәшгуль булып ага-энеләренә Батый хан дәстүре[1] илән гамәл кылды. Ак Урда дигән вилаятьне Баһадир хан бине Шибан ханга бирде. Кафа вә Кырым вилаятьләрен Уран Тимер бине Тукай Тимергә бирде, үзе Болгар мәмләкәтенә атланды. Ике елдан соң Болгарга галиб булып кайтты. Аннан сансыз чирүк илән Гыйрак-зәминга Абак хан өстенә барды. Абак хан илән солых кылып кайтты, шуннан соң бер-берсенә бүләкләр җибәрешеп, йөрешеп тордылар. Тарих алты йөз сиксәндә 1281/1282 миладида, Абак хан дөньядан үтте. Аның урынына Әхмәд хан мөселман иде, хан булды. Берничә вакыттан соң Аргын хан бине Абак ханның кулыннан шәһид булды. Аннан соң Аргын хан бине Абак хан падишаһ булды. Дәште Кыпчакта Мәнгү Тимер хан, Аргын ханның падишаһ булганын ишетеп, Тукай вә Төректай дигән ике бәкне баш кылып, сиксән мең кеше илән Аргын ханның өстенә җибәрде. Аргын хан, һәм бу хәбәрне ишетеп, Әмир Тугаҗар дигәнне ләшкәр биниһая илән каршы чыгарды, үзе аның артыннан атланды. Бу гаскәр Карабах өстендә орыштылар. Мәнгү Тимер ханның халкы мәгълүб[2] булып качып киттеләр. Мәнгү Тимер хан моннан кайгырып, авырып вафат булды. Аннан соң Туда Мөнгү бине Тукай Тимер бине Батый хан падишаһ булды. Бу Туда Мөнгү хан бик залим кеше иде. Туктагу хан бине Мәнгү Тимер хан аның золымыннан качып китте. Берничә вакыттан соң күп гаскәр җәмгъ кылып, Туда Мөнгү илән орышып, гаскәрен җиңеп, Туда Мөнгүне үтереп, үзе падишаһ булды вә, күп йортларны алып ата вә агасының дәстүре илән гамәл кылып, ахирел әмер дарелфанәдән дарелбакыйга рихләт кылды. Алты ел падишаһлык кылып, Сарайчык шәһәрендә мәдфүн[3] булды.

## Үзбәк хан бине Тугрул хан бине Мәнгү Тимер хан бине Батый хан бине Җүчи хан бине Чыңгыз ханның хан булганы

Туктагу хан үлгәч, Үзбәк хан хан булды. Барча илне унөч яшендә ата-бабасының дәстүре илән үзенә каратты вә, һәркемнең мәртәбәсенә лаек хөрмәт кылып, ингамнар бирде. Үзенә табигъ булган һәммә илне исламга кергезде. Барча халык ул сахиб[1] дәүләт сәбәбеннән ислам илән мөшәррәф булдылар. Аннан соң җөмлә Җүчи илен Үзбәк иле диделәр, кыяматкәчә шулай әйтеләчәктер. Дад вә гадел хөкем кылды вә, ике

мәртәбә Иран йортына — Әбүсәгыйд хан өстенә барып, ала алмаенча кайтып килде. Ахирел әмер дарелбакыйга рихләт әйләде.

### Җанибәк хан бине Үзбәк ханның хан булганы

Үзбәк хан үлгәннән соң, Җанибәк ханны хан кылдылар. Бу Җанибәк хан гаҗәеп изге мөселман падишаһ иде. Галимнәрне һәм аерылып торучы суфиларны яхшы хөрмәт итеп вә бәндә булып төшкән әсирләргә шәфкать кылыр иде. Шәһри Сарайчыкта тәхеттә утырып дин-мөбин[2] вә шәригать нуры илән хөкемне иҗра[3] кылды. Мәлик Әшрәф бине Тимер Таш дигән Азәрбайҗанда иде. Гаҗәп фасикъ вә залим кемсә иде. Аның җиреннән Азәрбайҗанның әһелесе вә түрәләре һәр тарафка таралдылар. Казый Мөхетдин дигән кемсә качып Сарайчыкка килеп, анда торды, һәр көнне пәнд[4] вә нәсыйхәтләр кылып, вәгазьләр әйтер иде.

Беркөнне, казыйның вәгазен ишетмәк өчен, хан вәгазь мәҗлесенә барды. Казый вәгазь әйтеп бетергәч, Мәлик Әшрәфнең золымыннан вә җәбереннән шундый хикәят кылды ки, хан вә бәкләр һәм барча халыклар зар-зар еладылар. Аннан соң казый ханга әйтте: «Әгәр барып, Мәлик Әшрәфтән безем дадыбызны алып бирмәсәң, кыямәт көнендә синең итәгеңдә безем кулыбыз булыр», — диде. Ханга бу сүз тәэсир кылып, чирүк җыеп, Мәлик Әшрәфнең өстенә атланды. Барып, Мәлик Әшрәф илән мөхарәбә кылып галиб булды һәм Мәлик Әшрәфне үтерде. Вә Мәлик Әшрәфнең дүрт йөз дөя ләгыль[1], вә мәрҗән, вә җәүһәре бар иде — барчасын гаскәренә кыйсмәт[2] кылдырды вә углы Бирдебәкне анда хаким итеп фәтех вә носрәт илән үз йортына кайтты. Йортына кайтканнан соң, зате шәрифенә бер хаста пәйда булып, озак авырды. Ахирел әмер шул хастадан сихәт таба алмагач, углы Бирдебәккә, кайтсын, дип, Азәрбайҗанга кеше җибәрде. Бирдебәк кайтып җиткәнче, Җанибәк ханның хәле зәгыйфьләнде һәм, халыкны җыеп, Бирдебәкне галибанә вәли әлгаһед[3] кылды вә күп пәнд вә нәсыйхәтләр әйтте. Тарих җиде йөз илле сигездә Хак рәхмәтенә китте, унҗиде ел падишаһлык кылып, Сарайчык шәһәрендә дәфен кылынды.

### Бирдебәк хан бине Җанибәк ханның хан булганы

Җанибәк хан үлгәннән соң, Тәбриздән Бирдебәк хан Сарайчыкка кайтты. Өч көн газа тоттылар. Газадан соң барча шаһзадәләр вә өмәрәләр Бирдебәк ханны хан кылдылар. Бирдебәк хан гаҗәп залим вә фасикъ, эче кара, яман ниятле кеше иде. Мәмләкәт ялгызыма калсын дип, ага-энедән вә карендәш ыругыннан һич кешене куймады, үтерде, бу дөнья фани, ата-бабаларыннан үткән, миннән дә үтәр дип уйламады. Ахирел әмер падишаһлыгы ике елга җитмәде, тарих җиде йөз алтмыш икедә вафат булды. Саин хан әүляды Бирдебәктә киселде. Әлхәл үзбәк эчендә мисал бар ки: нар[4] муены Бирдебәктә киселде, дәю. Аннан соң Җүчи ханның башка угланнарының әүляды падишаһлык кылдылар.

# Сигезенче баб

## Җүчи хан бине Чыңгыз ханның бишенче углы Шибан ханның әүлядыннан Туранда, вә Казакъта, вә Кырымда, вә Мавәраәннәһердә падишаһлык кылганнары

Чыңгыз ханның углы Җүчи хан, аның углы Шибан хан, аның углы Баһадир хан, аның углы Җүчи Бога, аның углы Байдакол, аның углы Мөнкә Тимер, аның углы Биккунды Углан, аның углы Гали Углан, аның углы Хаҗи Мөхәммәд хан, аның углы Мәхмүдәк хан, аның углы Абак хан, аның углы Тулук хан, аның углы Шәмәй солтан, аның углы Ураз солтан, аның углы Баһадир солтан, Мәхмүдәк хан мәзкүрнең углы Мортаза хан, аның углы Күчем хан. Бу җәмәгатьнең нәселе Күчем ханда өзелде. Ошбу Күчем хан Туран вилаятендә кырык ел падишаһлык кылды, гомере озын булды, бәгъдә ике күзе сукырайды. Тарих мең дә өч елда кулыннан Туранны урыс алды вә Күчем хан, үзе качып мангыт халкы эченә барып, Хак рәхмәтенә китте.

### Тукай Тимер нәселеннән Кырымда падишаһлык кылганнары

Чыңгыз ханның углы Җүчи, аның углы Тукай Тимер, аның углы Үз Тимер, аның углы Сарыйча, аның углы Күнчек Углан, аның углы Тукколхуҗа, аның углы Туйхуҗа Углан, аның углы Туктамыш хан, аның сигез углы бар иде, бу тәртип иде: Җәләлетдин, Җаббарбирде, Күпәк, Кәримбирде, Искәндәр, Әбүсәгыйд, Кучүк, Кадыйрбирде, Тукколхуҗа мәзкүрнең энесенең исеме Түләк Тимер, аның углы Хөбинә, аның углы Хәсән углан, аны Эчкеле Хәсән дирләр, аның углы Мөхәммәд хан, аның углы Таштимер, аның углы Гаязетдин хан, аның углы Хаҗи Гәрәй; аның сигез углы бар иде, бу тәртип илән: Дәүләтъяр, Нур Дәүләт хан, Хәйдәр хан, Котлыкзаман, Килдиш, Миңлегәрәй хан, Ямгырчы, Үз Тимер. Кырымның падишаһы Хаҗи Гәрәй ханның нәселеннәндер. Әлхәл җирнең ераклыгыннан Хаҗи Гәрәй ханның Кырымда кайсы углының нәселеннән падишаһлык кыла торгандыр, һич белеп булмады.

## Тукай Тимер нәселеннән Казакъта падишаһ булганнары

Чыңгыз хан углы Җүчи хан, аның углы Тукай Тимер, аның углы Үз Тимер, аның углы Хуҗа, аның углы Байдакол, аның углы Ырыс хан, аның углы Коерчык хан, аның углы Барак хан, аның углы Әбүсәгыйд, ләкабе Җанибәк хан, аның тугыз углы бар иде, бу тәртип илән: Иранчи, Мәхмүд, Касыйм, кайсы кем Мөхәммәд хан Шибани илән орышып, Мөхәммәд ханның шәһид булмагына сәбәп булды; аннан соң Итик, Җаниш, Канбар, Тениш, Үсүк, Җавык.

## Җүчи ханның өченче углы Тукай Тимернең нәселеннән Мавәраәннәһердә падишаһ булганнары

Чыңгыз хан углы Җүчи хан, аның углы Тукай Тимер, аның углы Үз Тимер, аның углы Абай, аның углы Томган, аның углы Котлык хан, аның углы Тимер солтан, аның углы Мөхәммәд хан, аның углы Җуак солтан, аның углы Мангышлак солтан, аның углы Ярмөхәммәд солтан, аның углы Җани солтан, аның углы Динмөхәммәд солтан, аның углы Нурмөхәммәд хан, аның углы Габделгазиз хан. Үзбәк нәсәбләре әйтәләр ки, Габделгазиз ханның, вә казакъ падишаһларының, вә Кырым, вә Казан ханнарының аталары Җүчи хан бине Чыңгыз ханның өченче углы Тукай Тимер хан нәселеннәндер. Вә дәхи Хаҗим ханның, вә Габдулла ханның, вә Күчем ханның аталары Җүчи хан бине Чыңгыз ханның бишенче углы Шибан хан нәселеннәндер. Мәгълүм булынадыр: мәзкүр өч хан бер гасырда булдылар, бере-беренең артыннан дөньядан нәкыль кылдылар. Җүчи хан угланнарының башкалары вә йортлары югарыда зикер кылынды.

## Җүчи ханның бишенче углы Шибан хан әүлядының зикере

Бу ике бабның ханнары бер-берсеннән соңыннан аерылганга күрә, аерылмастан борын булган ханнарны әйтмәк зарур булдыгыннан ике бабны бергә кушып бәян кылмак дәхи тиеш булды. Югарыда әйтелде ки, Җүчи хан Маҗар, вә Башкорт, вә Урыс, вә Карел, вә Болгар, вә Немец йортларына атланырга дип илгә яр салдырды, җиде еллык сәфәр ерагының авырлыгын танысыннар дип фәрман кылды, әмма үзе гаскәр җыелганчы хаста булып вафат булды. Дәхи әйтелмеш иде ки, Чыңгыз хан терек вакытында нәбирәсе Батый ханга: «Атаң ни җиргә баруга ният кылган булса, син шул җиргә атаң урынына баш булып бар!» — дип хөкем кылган иде. Батый хан гаскәрен җәмгъ кылып йөргәндә, Чыңгыз хан һәм вафат булды, ике елдан соң Үгедәй хакан хан булды, ул һәм Батый ханга сугыш сәфәренә чыгарга әмер кылды.

Батый хан атланып, урысның вилаятьләрен ала-ала, Мәскәүгә барды. Анда карел, вә немец, вә урысның хакимдарлары мәслихәтләшеп үр казыдылар. Өч айгача олуг орышлар булды. Ахирел әмер Шибан хан агасы Батый ханга әйтте: «Үз нөкеремнән башка миңа биш-алты мең кеше бир. Бер кичә дошманның артыннан төшәем, иртә илән сез яуның алдыннан орыш башлап, мин артыннан төшәрмен», — диде. Иртәсе көн сабах булгач, Шибан хан мәслихәтенчә эш кылдылар. Орыш кызган вакытта Шибан хан, урысларны чабачаба, үрнең якасына килде, шул хәл гайрәт илән үзе, аттан төшеп, үрдән үтте. Үрнең эчендә һәммә җиргә арбаларны бер-берсенә тимер зынҗыр илән теркәп куйганнар иде. Зынҗырларны кисеп, арбаларны ватып бозды, вә барча гаскәр аның артыннан пиядә һөҗүм кылып, сөңге һәм кылыч илән дошманга чаптылар. Алдан — Батый хан, арттан Шибан хан сугышып, шул көнне җитмеш мең дошманны үтереп, малларны талап, Мәскәүне утка яктылар. Аннан соң Урыс йорты һәммәсе Батый ханга табигъ булды.

Ул сәфәрдән кайтып төшкәч, Җүчи ханның олуг углы ләкабе Ичин исеме Урдага, эшебезне бетергән син булдың, дип, ун мең өйлек ил бирде вә энесе Шибан ханга, рәең[1] илән эшебезне алга җибәреп баһадир-

лык кылдың, дип, унбиш мең өйлек ил бирде, янә ул сәфәрдә алган өлҗә вә вилаятьләрдән аңа Карел йортын бирде вә дәхи нәсел-ыруг иленнән Кошчы, вә Найман, вә Карлык, вә Бөйрек — бу дүрт ыруг илне бирде. Соңра әйтте ки: «Утырган йортың булсын, язлыкта Оргыз, вә Ор, вә Илек та Урал тауларынча Җаек суының көнчыгыш тарафында җәйләрсең, — диде, — вә кышлыкта Араком-Караком вә Сыр суының буенда вә Аму суының аягында кышларсың», — диде. Шибан хан Карел йортына бер углын, яхшы бәкләрен илләре илән күчереп җибәрде. Ул йорт угылдан угылга Шибан хан угланнары кулында калды. Хәзерге вакытта һәм Карелның ханнары Шибан хан нәселеннән дип риваять кылалар. Вәләкин җире ерак булганга күрә, растын вә ялганын Тәңре үзе яхшы белер. Шибан хан ошбу әйтелгән йортларда җәйләп вә кышлап утырды. Ничә елдан соң вафат булды. Аның унике углы бар иде. Исемнәре болардыр: Байнал, Баһадир, Кодак, Балка, Чирик, Нәркән, Кортга, Илчи, Саелган, Баянҗар, Мажар, Кунҗи.

### Икенче углы Баһадир хан атасы урынында утырды; аның ике углы бар иде: олугының исеме Җүчи Бога, кечегенең исеме Котлык Бога

Җүчи Бога атасы урынында утырды; аның дүрт углы бар иде, исемнәре болардыр: Байдакол, Биктимер, Никочар, Ис Бога. Җүчи Бога бу дөньядан ахирәт йортына киткәннән соң, олуг улы Байдакол падишаһ булды. Вә аның Миңтимер исемле бер углы бар иде, гаҗәеп баһадир, вә булдыклы, вә гакыллы иде, шул сәбәптән аны Күлүк Миңтимер хан дирләр иде. Күлүк дигәнебез кадимге төрек теленчә «нәзер» мәгънәсендәдер. Миңтимер ханның алты углы бар иде, исемнәре болардыр: Илбәк, Җантә, Фулад, Сөенеч, Тимер Төнкә, Бәккунды. Миңтимер хан үлгәннән соң, углы Фулад атасы урынына торды. Аның Ибраһим вә Гарәбшаһ исемле ике углы бар иде. Үзбәк ул икесен Әсәгарәб дип әйтер иде.

### Шибан хан нәселеннән Мавәраәннәһердә падишаһ булганнары

Чыңгыз хан углы Җүчи ханның углы Шибан ханның углы Баһадир, аның углы Җүчи Бога, аның углы Байдакол, аның углы Миңтимер, аның углы Фулад Тимер, аның углы Ибраһим Углан, аның углы Дәүләтшәех Углан, аның углы Әбелхәер хан. Аның унбер углы бар иде, олугының исеме Шаһбадак солтан. Аның дәхи ике углы бар иде, олугының исеме Мөхәммәд, ләкабе Шаһ-Бәхет Гали-әр-Рәхмәти, шагыйрь кемсә иде. Шибан хан нәселеннән булганга күрә, үзенә Шибани Гали-әр-рәхмә дип тәхәллүс куеп иде. Кечек углының исеме Мәхмүд солтан, аның углы Габдулла хан. Мәзкүр Әбелхәер ханның икенче углының исеме Хуҗа Мөхәммәд. Әмма үзбәк аны Хуҗагым Тинтәк дирләр иде. Аның углы Җанибәк, ул һәм бигакыйль кеше иде. Аның углы Искәндәр хан, ул һәм гакылы ким кеше иде. Әмма аның ике һөнәре бар иде: берсе — фарыз вә нәфел намазын асла куймый вакытында укыр иде вә икенче — карчыганы салып, ау ауламак артыннан йөрмәктә дөньяда бер булдыклы иде. Аның мәшһүр Габдулла хан углы бар иде вә аның углы Габделмөэмин хан исемендәдер. Ошбу җәмәгатьнең нәселе Габделмөэмин ханда мөнкатыйг[1] булды. Мәгълүм булынадыр ки: Габдулла ханның хикәяте галәмдә мәшһүр иде, шул сәбәптән тәфсилә бәян кылмадым.

## Тугызынчы баб

### Җүчи хан бине Чыңгыз ханның бишенче углы Шибан хан әүлядыннан Хәрәземдә падишаһ булган кемсәләр

Фулад үлгәннән соң, атасыннан калган илләрне Ибраһим илән Гарәбшаһ ага-эне икесе бүлешеп, бер җирдә күчеп вә кунып, Җаек суының башында җәйләп вә Сыр суының аягында кышлап, татулык илән гомер кичерделәр. Гарәб үлгәннән соң, углы Хаҗи Тули атасы урынында падишаһ булды. Аның Тимершәех исемле бер углы бар иде. Хаҗи Тули вафат булыр алдыннан, Тимершәехне урынына утыртып, дарелбакыйга китте. Тимершәех егет вакытында калмыктан ике мең кеше килеп, илен чабып киттеләр. Тимершәехнең моңа ачуы килеп, калмыкның артыннан куа китеп, гаскәре җыелып җитүдән мөкатдәм барып, орыш салды. Шунда калмыктан мәгълүб булып, ахры шунда шәһид булды. Илен яу чапты вә түрәсеннән аерылды, бала-чага да вә агай-эне дә калмады, берсе өстенә берсе өметсезлек булды, бу сәбәптән утырган халык башка түрәләргә китте. Шул вакыт уйгур халкының аксакаллары җыелып урда ишегенә килделәр вә

мәрхүм Тимершәехнең олуг хатынына кеше җибәреп әйттеләр ки: «Ил барчасы китте, без һәм китәргә торабыз, икмәк-тозлары өчен безгә разый булсыннар, янә бер сүзебез шулдыр: ханның хатыннары вә кәнизәкләре күп иде, аларны яхшы карасыннар, әгәр берсенең буенда булса, ул туганчы китми утырырбыз». Бу сүзне ишеткәннән соң, хатын әйтте: «Башкаларының буенда юк, әмма минем буемда өч айлык балам бар, зан галибем углан булса кирәк», — диде. Бу сүзне ишеткәннән соң, уйгур халкы урдада утырдылар, найман халкы күчеп киткән иде, бу хәбәрне ишеткәч, түрәләргә нөкер булмый һәм урдага да кайтмый үз алларына утырдылар. Әмма гайре илләр башка түрәләргә нөкер булдылар.

Байбичә ханым алты айдан соң бер угыл бала тудырды, исемен Ядгәр куйдылар. Уйгур халкы барча күчеп киткән илләргә сөенче алмакка бер кеше җибәрделәр. Ул кеше әүвәл найман халкына барды, алар бер кара кашка ат сөенче бирделәр. Найман халкы кайтып, Урда катына төшкәч, анасы яшь углан ханзадәне атасының күренешханә (миһманханәсенә) илтеп, күтәреп түргә утыртты. Сул тараф могул рәсемендә уңнан хөрмәтлерәк булыр, зирәки бәдән мәлигенең падишаһы йөрәктер, Ходай Тәгалә йөрәкне сул якта яратмыштыр. Уйгур найманга, михмансән дип, сул якта үзеннән югары урын бирде. Бу вакыткача найманның югары утырмагы шуннан калды. Аннан соң атасыннан калган нөкерләрдән күңел тартканнары килеп, урдага кушылдылар. Әмма башы бөтен җиңле вә якалы ил татар ыругыннан уйгур илән найман булды. Ул икесенең Ядгәр хан угланнарына карачимыз дигәннәренең лөгатендә мәгънәсе шул ки, карачи яхшы вә яманны килерен вә китерен, имгәклесен вә имгәксезен һич кешегә тарафдарлык кылмый эш кылучы димәктер.

Ядгәр егет булды. Аннан дүрт угыл булды. Әүвәле — Бәркә, икенче — Әбүләк, өченче — Амәнәк, дүртенче — Әбәк. Амиңның мәгънәсе улдыр ки, ул вакытта могул теле ил арасында бөтенләй онытылып бетмәгән иде. Хан ләфызы гарәби лисаныдыр, аны таҗик һуш дир вә үзбәк тин дир вә могул аман дир. Ул Амәнәкнең кафен гарәп кәф тасфир дир, кечкенә мәгънәсендәдер, үзбәк аны гына вә кәһ урында гына дир, мисле кечек атны ат кына вә кечек кешене кеше генә дир. Бәс, Амәнәкнең мәгънәсе җан гына димәк булыр, инде әйтә торган сүзебездән калмаек.

## Ядгәр ханның олуг углы Бәркә солтан гаҗәеп булдыклы ир-егет иде

Мәрвидер[1] ки, аның күкрәген Ходай Тәгалә бөтен яраткан, имеш. Түшенең сөякләре арасында кимерчәге булыр, әмма аның түшенең һич кимерчәге юк, беркөе тоташ сөяктән яратылмыш иде. Бәркә солтанның егетлеге илән Әбелхәер ханның картлыгы икесе бер вакытта булмыштыр. Аксак Тимер би әүлядыннан Мавәраәннәһердә Әбүсәгыйд мирза, үз карендәшләреннән Габделлатыйф мирзаны үтереп, йортына ия булды. Габделлатыйф мирзаның углы Мирза Мөхәммәд Җүки качып Әбелхәер ханга барды. Әбелхәер ханның хатыны Габделлатыйф мирзаның сеңлесе вә Мөхәммәд Җүкинең гаммәсе[1] иде.

Берничә вакыт хан хозурында торганнан соң, Мавәраәннәһердән бер кеше килде вә әйтте: «Солтан Әбүсәгыйд мирза Сәмәркандтан атланып Хорасанга китте, аннан ары Мазандаранга һәм барырмын», — диде. Бу сүзне ишеткәннән соң, мирза Мөхәммәд Җүки ханнан күмәк[2] сорады. Хан Бәркә солтанны чакырып әйтте: «Мирза Мөхәммәд Җүки бездән күмәк теләптер. Минем угланнарым да, вә якын энеләрем дә, бу эшне башкарырдай кеше юк, син һәм минем углымсың, үз гаскәрең илән атлан, мин һәм үз тарафымнан гаскәр кушаем», — диде. Бәркә солтан, ханның сүзен кабул кылып, Мөхәммәд Җүки мирзаны алып, утыз мең кеше илән атланып Ташкентка килде. Атасыннан вә үзеннән калган вә Әбүсәгыйд мирзадан хәтере калган Чыгтай иле, бозылып, Мөхәммәд Җүки мирзага килделәр. Аннан соң Ташкентка барып керде, бәгъдә Рухияне алып вә Сыр суын үтеп, Сәмәркандка барды.

Әбүсәгыйд мирза, Хорасанга киткәндә, Сәмәркандта үз урынына Аргын ыругыннан Мәзият әмир дигән кемсәне куеп киткән иде. Ул үзенә тәгаллекъле кешеләр илән Сәмәркандтан чыгып орышты. Бәркә солтан Мөхәммәд Җүки мирзаны Чыгтай гаскәре илән төпкә уртага куйды, үзе, сул якта торып, Әбелхәер ханның кушкан гаскәренә Бәшкәнд Углан дигән кемсәне баш кылып, уң якка куйды. Шул рәвешчә сугышып, Ходай Тәгалә Бәркә солтанның кулын өстен кылып, Мөхәммәд Мәзият Аргынның тугын[3] түбән салды. Орыш шәһәр якынында иде, шәһәрнең дәрвазәсенә тигәнче Бәркә солтан Чыгтай гаскәрен кылычтан үткәреп кире чигенде. Әмир Мәзият кулга төшми шәһәргә керде вә дәрвазәләргә сакчы кешеләр тәгаен кылып камалмак әсбабының гамен күрде, Хорасанда Әбүсәгыйд мирзага, маһүә[4] әлвакыгны язып, гарыз җибәрде. Солтан Әбүсәгыйд мирза, гарызны күргәч, Хорасан гаскәренә тезелеп җыелмакка хөкем кылды. Гаскәр җыелып беткәннән соң, олуг ләшкәр илән үзе Сәмәркандка йөрде. Мөхәммәд Җүки мирза Куфин вә Кәрминәгә килде. Бохара вә Сәмәркәнд шәһәрләреннән башка һәммә Мавәраәннәһер вилаятьләре Мөхәммәд Җүкигә

мөяссәр булды вә барчасына даругалар тәгаен кылды. Ул арада хәбәр килде ки, Әбүсәгыйд мирза олуг гаскәр илән Бәлхкә килде, дип.

Моны ишеткәннән соң, барча олуг-кечек утырып киңәш кылдылар. Бәркә солтан әйтте: «Әлхәмделилла шөкер, Ташкент, вә Төркестан, вә Мавәраәннәһер кулыбызда, үзбәк вә чыгтайның күп гаскәре дәхи үзебездә, хәзер һичбер турыда кимчелегебез юктыр. Бәс, Аму дәрьясының якасына барып, яуны үткәзмәек, әгәр үтсә, орышаек», — диде. Чыгтай биләре әйттеләр: «Моннан кайтып, Сыр-Дәрьяны кичеп, Шаһ-Рухиядә тораек, барча Мавәраәннәһерне саклап кулыбызда тота алмабыз, Төркестан илән Ташкентны кулыбыздан чыгармасак, безгә җитәр», — диделәр. Мөхәммәд Җүки мирза Бәркә солтан сүзе мәгъкуль икәнне аңласа да, әмма үз иленең сүзен кайтарырга кыймый Кәрминәдән күчеп, Шаһ-Рухиягә таба йөз тотты. Чыгтай гаскәренең яманнары Әбүсәгыйд мирзаның куәтенә тәкать тота алмаганлыктан качты дип хыял кылдылар, шул сәбәптән алар Мөхәммәд Җүки мирзадан аерылып, Әбүсәгыйд мирзаның гаскәренә кушылырга бил багладылар. Бәркә солтан биргән мәслихәтне кабул итмәгәнгә ачуланды, бәгъдә күрде ки: чыгтайдан һичкем калмады, вә чигенеп кайткан вакытта үз гаскәренә, Сәгыйднең илләрен чабыгыз, дип хөкем кылды. Өч көн чабып, терек малны һәйдәп вә гайре малларны йөкли алган кадәре йөкләп үз йортына кайтып китте.

Мөхәммәд Җүки мирза Шаһ-Рухиягә барды. Әбүсәгыйд мирза, бу хәбәрләрне ишетеп, Җүкинең артыннан китте. Мөхәммәд Җүки мирза Шаһ-Рухиянең кальгасына камалды. Әбүсәгыйд мирза дүрт ай камап утырды, әмма һич ала алмады. Ахирел әмер Хуҗа Габид Сәмәркандка килеп, ике арада йөреп, Мөхәммәд Җүки мирзаны үтермәскә дип Әбүсәгыйдтән ант алып, Җүкине Әбүсәгыйд хозурына күрештерергә алып барды. Ул, сүзенә вафа кылып, Мөхәммәд Җүкине үтермәде, әмма Хорасанның Ихтыяр-Эддин дигән кальгасына ябып саклады. Бу вакыйга тарих сигез йөз алтмышта иде.

## Мангыт Муса бәкнең Бәркә солтан ишегенә килеп булышлык теләгәне

Муса би илән Куҗаш мирза икесе яу булып орыштылар. Куҗаш мирза галиб булды. Муса би качып, кемнең ярдәме илән бу үчемне алырмын икән, дип, әтбагы илән киңәште. Әгәр бу эш килсә, Бәркәнең кулыннан килер, башка кешенең кулыннан килмәс, дип, Бәркә солтанның урдасына килде һәм әхвәлне гарыз кылды. Бәркә солтан әйтте: «Яхшы вә хуш килдең, кулымнан килгәнне аямам. Атабыз хан булсын, син аның олуг бие бул», — дип, әтрафтагы халкын чакырып, олуг бәйрәм кылды. Атасы Ядгәр ханны ак киезгә салып, хан күтәрделәр. Аннан соң Бәркә солтан сәфәрнең кирәк-ярагын хәзерләп, Муса бине алга куеп, башчы булып атланды. Кыш көне иде, кар ул елны калын төшкән иде. Бара-бара атлары арыкланды вә азыклары төкәнде. Халык кайтмакны мәгъкуль күрделәр, әмма солтан кайтмакка разый булмады. Берничә көннән соң гаскәр әүвәлгедән яман йөдәде. Ахирел әмер Муса би башлык барча бәкләр илән килеп, солтанга гарыз кылдылар ки: «Үзебезгә һәм атларыбызга яман кахтлык[1] (йөд) булды, атсыз җәяү ни җиргә барырбыз, бу ел булмаса, киләчәк елга булыр, бу сәфәрдән кайтмак лязим», — диделәр. Солтан әйтте: «Бу көн вә иртәсе көн алга таба йөрик, әгәр Куҗаш мирза иленнән хәбәр белсәк, уйлаганча уй кылырбыз, әгәр хәбәр тапмасак, кайтырбыз», — диде һәм иртә илән иртүк торып атланды да алга таба йөри бирде.

Йөри торгач, бер калку вә түгәрәк кырга җитте. Кырның өстенә чыккач, аргы тарафта бер чокыр өй сыман җирдә бик күп ил күренде. Кырдан бераз чигенеп, ял итәргә төшеп, түбәнге илнең нинди ил икәнлегеннән хәбәр алып кайтырга ике кеше җибәрде. Алар барып, хәйлә илән: «Могавәзә[2] кылмакка нәрсәләребез бар», — дип, бер сәүдәгәрне алып килделәр. Аннан: «Кем иле вә кем кышлавы?» — дип тәфсилә сорадылар. Ул Куҗаш мирзаның иле икәнлектән вә гайре әхвәлләреннән хәбәр бирде. Моны ишетеп, бер сәгать кичекми атланып гафил торганда, барып, мирзаның өенә һөҗүм кылдылар. Куҗаш мирза кулга төште, һәм солтан аны үтерде, илне чапты, күп өлҗәләр алды, калган иле табигъ булды. Мөлай ханзадә дигән Куҗаш мирзаның бер кызы бар иде, аны Бәркә солтан үзенә алды, ул кыш анда үткәреп, яз булгач, йортына кайтты.

## Ядгәр ханның вафаты һәм Бәркә солтанның шәһид булганы

Бу вакыйгаттан берничә ел үткәннән соң, Ядгәр хан вафат булды. Аннан соң Әбелхәер хан булдыклы дусларын көлдереп вә дошманнарын егълатып йөргән кемсә иде. Дүрт тарафындагы утырган карендәшләренең һәркайсысына тияре үтмәгән вә кулы җитмәгәне юк иде. Ул вәҗәдән барчасы баш күтәрделәр һәм Әбелхәер ханны үтерделәр. Аның гәрчә үзеннән угыллары вә нәбирәләре күп калса да, аларның берничәсен дошманнар үтерделәр вә берничәсе дәхи төрле якка качтылар вә илнең барчасы төрле якка таралдылар.

«Атаның өен яу чапса, бергә чап» дигән мәкаль буенча гамәл кылып, Бәркә солтан һәм мәзкүр илне берничә кәррә чапты.

Бу маҗарадан соң берничә еллар үткәч, Әбелхәер ханның нәбирәсе Шаһ Бәхет хан гайрәтле егет булды вә, ата-бабасының йортына килеп, азган-тузган илен җәмгъ кылды вә, Бәркә солтан илә ата-бабасы ничек мөгамәлә кылган булса, шул кәефенчә эш кылды, әмма дошманлыгын асла изһар кылмады. Бер ел Сыр-Дәрьяның аягында кышлаганда, Шаһ Бәхет хан Бәркә солтаннан бер тугай югары кышлыйдыр иде. Беркөн Шаһ Бәхет хан халкына яр салдырды ки: «Бу көн барчалары килеп, өем катына ятсыннар, иртә илән сабахауга барырмын!» — диде. Нөкерләре җыелганнан соң, төн ярымы булды дигәндә, атланып Бәркәнең урдасы тарафына юнәлде һәм нөкерләренә әйтте: «Таң сабах илән барып, Бәркәне өендә басарбыз, һич берегез өлҗәгә карамагыз, өйне түгәрәкләп камап алып, Бәркәне кулга ала күрегез!» — дип хөкем кылды.

Таң аткач та килеп, урданы камап, солтанны эзләделәр, әмма һич таба алмадылар. Кол вә кәнизәкләреннән тәфтиш кылып сорап карагач, алар әйттеләр: «Сез килгәнче бар иде, сез килгәч, һәркайсыбыз бер якка качтык, солтан кай тарафка качканын белмәдек», — диделәр. Әмма солтан дәрвакыйг[1] урдада ялангач яткан иде. Ат аякларының дөпелдәгән тавышы килгәч, яланаяк тунын аркасына салып, йөгереп тышкары чыкты.

Яуның килгәнен белгәч, өе тугайның эчендә иде, ишеге алдында камышлы олуг күл бар иде, шул дәкыйга камышның эченә йөгерә бирде. Камыш арасында бозның өстеннән йөгереп качканда, бер камышның камылы аягын ярып җибәрде, каны асла туктамады вә, куе камышның эченә кереп, аягын туны итәгенә чолгап утырды. Шаһ Бәхет Шибани хан качканнарны берәм-берәм тотып һәркайсысыннан Бәркәне сорап эзләп йөрде. Бәркә солтанның уйгур ыругыннан Мөнәкә исемле бер нөкере бар иде, ул һәм качмыш иде. Бәркә солтанны эзләп йөргән кемсәләрнең берсенә очрады. Мөнәкәдән: «Син кем буласың?» — дип сөаль кылгач, «Мин шул эзләп йөргән кешегезмен», — диде. Мөнәкә — җәяү, ул атлы иде, аттан төшеп тотмакка куркып, ат өстендә һай-һай салып юлдашларын чакырды, бу авазны ишеткәннәр бер-берсен чакырыштылар. Бәркә солтанны эзләп йөргән кешеләрнең һәммәсе җыелып Мөнәкә нөкерне тотып, Бәркәне таптык, дип, Шаһ Бәхетне Шибани хан алдына алып бардылар. Хан һәм гайреләре барчасы Бәркәне танырлар иде. Хан: «Бу Бәркә имәс, Бәркәнең Мөнәкә нөкередер, — диде, дәхи Мөнәкәгә әйтте: — Ни өчен син Бәркәмен дип ялганладың?» Мөнәкә диде: «Бәркәнең күп ашын ашап вә суын эчтем вә кече яшьтән бирле бергә үсеп күп яхшылыклар күрдем. Аны эзләп йөргән кешеләр мине Бәркә солтан дип белеп, аңа качарга форсат булсын дидем, аннан калганын үзең яхшы белерсең», — диде. Шаһ Бәхетне хан аның кылган эшен яхшы күреп, канын багышлап ингам кылды. Аннан соң барчасы Бәркәне эзләмәк илән мәшгуль булдылар. Ул кичне ярым карыш кадәр кар яуган иде. Бер кеше авылның читендә бер яланаякның эзен күрде. Шул эз илән бара торгач, күлгә кергән ул кешенең аягыннан бозның өстенә кызыл кан ага биргән. Шул канлы аяк эзе илән бара торгач, куе камыш эчендә утырып торган бер адәмне күрде. Шул хәл юлдашларына кычкырды, биш-ун кеше килеп, аны тотып, Шаһ Бәхетне Шибанга алып бардылар. Шибан хан шул ан[1] Бәркә солтанны шәһид кылып, өен чабып вә талап кайтып, өенә китте.

Кунаш мирзаның кызы Бәркә солтанның хатыны иде. Аның солтаннан буенда ике айлык угланы бар иде. Аны Әбелхәер хан углы Хуҗа Мөхәммәд солтан өлҗә кылып алды, ул җиде айдан соң бер иркәк углан тудырды, исемен Җанибәк куйды. Җанибәк углы Искәндәр хан аның углы мәшһүр Габдулла хан, аның углы Габделмөэмин хан. Хуҗа Мөхәммәд солтан гакылсыз кеше иде, аны Хуҗагым Тинтәк дирләр иде. Гакылсызлыгы шул дәрәҗә иде ки, авылдагы хатыннарга, утка май салып: «Синең углың яки кызың булыр, яисә башыңа фәләнчә вә төгәнчә эш вакыг булыр», — дип фал ачып йөрер иде. Җанибәк угланның үзеннән булганын вә яки гайредән булганын белердәй гакылы юк иде. Әмма халыкның барчасы Хуҗагым Тинтәк Бәркәнең углын үземнеке дип угыл кылып йөрер диерләр иде. Малай ханзадә үзенең файдасы өчен дөресен әйтмәде. Безнең картларыбыз әйтерләр иде: Габдулла хан олуг атасы Бәркәнең канын Әбелхәер хан угланнарыннан бер урынына унны вә егермене алды, безнең халык үзенең якыны идек аңламыйча аны һәм кырды, үзе вафат булып, углы һәм аның артыннан китте, нәселеннән һичкем калмады, йортын ятларга бирде. Инде Бәркә солтанның әүвәл угланнарын әйтеп, соңра, Ходаа теләсә, энеләрен әйтермен.

## Бәркә солтанның угланнары Илбарыс илән Билбарыс

Бәркә солтаннан ике угыл калды. Олугсының аты Илбарыс вә кечесенең исеме Билбарыс, халык эчендә мәшһүр исеме Бәликәч иде. Сөт имә торган вакытта хаста булып, ике аягы кибеп, тездән түбәненең җаны юк иде. Бу ике угыл үсеп буйга җиттеләр, икесе һәм булдыклы егет булдылар. Атасы йортында йөрделәр. Шаһ Бәхет хан Мавәраәннәһерне алды. Ул йортта Ядгәр хан угланнарыннан башка кеше калмады.

## Инде Илбарыс ханның Өргәнечне ничек алганын бәян кылаем

Шаһ Бәхет хан Мавәраәннәһерне алып булгач, Һератта Солтан Хөсәен мирза үз әҗәленнән үлде. Шаһ Бәхет хан барып, Хөсәен мирза угланнарының кулыннан Хорасанны алды. Хөсәен мирзаның угланнары вә нәбирәләре күп иде. Ике-өче качып хәляс[1] таптылар, башкаларын һәммәсен үтерде. Ул вакытта Өргәнеч вилаяте Солтан Хөсәен мирзага табигъ иде. Шаһ Бәхет хан Өргәнечкә даруга җибәрде. Бу вакыйгаттан биш-алты ел үткәннән соң, Шаһ Исмәгыйль, Мәрвәгә килеп, Шаһ Бәхет хан илән сугышып шәһид итте. Бу хәбәрне ишеткәч, Шаһ Бәхет ханның Өргәнечтә куйган даругасы Өргәнечне ташлап китте. Шаһ Исмәгыйль Хорасанның барча вилаятьләренә даруга җибәрде вә Хәрәземнең үзенә өч даруга тәгаен кылды. Берсе Хива илән Һәзарасыбта, вә икенчесе Өргәнечтә, вә өченчесе Вәзирдә торды. Өргәнеч, Вәзиргә җибәргәненең икесе бертуган гарәб нәселеннән иделәр. Өргәнечтә торганының исеме Собханколый, Вәзирдә торганының исеме Рахманколый иде. Рахманколый гарәб Вәзиргә килгәннән соң, Вәзирнең олугларын җәмгъ кылып, олуг аш мәҗлесе кылып, хилгатьләр[2] кидерде.

Ул вакытта Вәзирнең казыйсы Гомәр исемле гакыллы вә мәгърифәтле карт кеше иде. Бу зат хакимне барып күрмәде. Ашка чакырганда бармады, сәламәтлегем юк, дип калды. Хаким аш биргән көннең иртәсендә казый Гомәр, кеше җибәреп, өч-дүрт атаклы әкябирләрне яшерен үзенә чакырды вә аларга әйтте: «Янки хакимнең биргән сәрапае[1] һәм янки мәзһәбегез куәтле булсын», — диде. Бу әкябирләр, гаҗәпләнеп: «Янки мәзһәб дигәнегез нидер?» — дип, казыйдан сорадылар. Казый әйтте: «Шул көнгәчә падишаһыгыз Исмәгыйльнең һәм бу хакимегезнең ни юлда вә ни мәзһәбтә икәнлекләрен ишеткәнегез юкмы?» Алар ант эчеп әйттеләр: «Безгә берничә елда һәркем Хорасан падишаһы булса, аннан даруга килер, без моны һәм шулай дип хыял кылабыз». Казый әйтте: «Шаһ Исмәгыйльнең бу мәзһәбен ихтыяр кылганына унөч-ундүрт ел булды, бу бер батыйль[2] мәзһәбтер», — дип тәфсыйлә бәян кылды. Әлхәл бу хаким үз кешесе аз вә без күп булганга күрә куркып, мәзһәбен заһир кылмыйдыр, берничә вакыт торып ихтыярыгызны алганнан соң, әүвәл сезнең кеби олугларга әсхабны сүгәргә тәклидә кылыр, сезне үз юлына күндергәч, мәзкүр мәзһәбен гавамәлнаска тәклиф кылыр, тыңламаганнарын үтерер, тизлек илән моның гамен җыймасагыз, әһле әлсәптә вә җәмәгатә мәзһәбеннән аерылып, шыйга мәзһәбенә керерсез, диде. Бу сүзне ишеткәннән соң, Вәзир шәһәренең олуглары ошбу сүзләрне фикерләреннән асла чыгармадылар. Бер-ике ел үтте, һич эш кыла алмадылар.

Ул вакытта Бакырганда Ата нәселеннән Хисаметдин Китал дигән бер яхшы кеше бар иде. Аңа барып әйттеләр: «Сезне падишаһ кылаек, кызылбашны кыраек», — диделәр. Ул әйтте: «Минем падишаһ булганымны халык, бу көнге көн кабул кылсалар да, әмма соңыннан асла кабул итмәсләр. Әгәр бу эшне ихлас күңелегез илән кылыр булсагыз, мин бер яхшы нәселле падишаһ табып бирәем», — дигәч, Вәзир шәһәре халкы: «Ул кемдер?» — дип сорадылар. Хуҗа берничә елда бер кәррә Аркага үзбәк эченә барып, халыкның нәзер-ниязларын алып килер иде. Шундагы Илбарыс ханның нәсел-нәсәбе вә яхшылыгын вә яманлыгын тәфсилә бәян кылды. Аннан соң Вәзир шәһәре халкыннан ике инабәт[3] иясе кеше вә хуҗаның дәхи үз кешесе, хуҗаның мәктүбен һәм шәһәр әкябирләренең гаризасын алып, Илбарыс ханга бардылар. Илбарыс хан энесе Билбарыс илән атланып юлга чыктылар, теге өч нәфир[1] кемсәне үзләреннән элгәре җибәрделәр. Алар, килеп, алдан Вәзир халкына хәбәр бирделәр. Шәһәрнең олуглары, барчасы җыелып иттифак кылып, ханга каршы бер кеше чыгардылар. Ул кеше ханга килеп әйтте: «Сезгә бәндәлектән соң халыкның гаризасы будыр ки, шәһәргә җитәрәк кичәсен йөреп кальгадан күренмәстәй бер якынрак җиргә төшеп, шәһәргә бер кеше җибәрсеннәр, дип үтенделәр», — диде. Илбарыс хан аларның дигәненчә эш кылды. Илбарыс ханга барган әкябирләр кешесе Илбарыс ханның килеп төшкәненнән кайтып әйтте. Аннан соң олуг вә кечек һәммәсе җыелдылар вә дәрвазәләргә кешеләр тәгаен кылып, кальга эчендәге торган кызылбаш халкын һәрберсен куймады, кырдылар, иртә сабах Илбарыс хан торып кальгага таба йөрде. Барча халык ханның алдына каршы истикъбальга чыктылар һәм, ханны алып барып, хаким утыра торган өйгә төшерделәр. Илнең барчасына сөенеч хәбәр җибәрделәр вә, олуг туй кылып, үзбәк вә сарт халкы һәммәсе иттифак илән җыелып тарих тугыз йөз унбердә, Куй елында Илбарыс ханны хан күтәрделәр.

Вәзир шәһәренә караган вилаятьләр Күп иде, һәммәсе берсе артыннан берсе Илбарыс ханга табигъ булдылар. Илбарыс хан килгән чакта өч хаким утырган шәһәр бар иде, берсе Вәзир шәһәре, икенче Яңа Шәһәр, өченче Тәрсәк шәһәре. Илбарыс хан үзе Вәзир шәһәрендә утырды, Яңа Шәһәрне энесе Бәликәч солтанга бирде, Тәрсәк шәһәренә хаким куйды.

## Илбарыс ханның Өргәнечне алганы

Вәзир шәһәре халкы кызылбашны кырганда, беркемсә вәйран[2] ханәдә яшеренеп ятты. Кич булгач, дәрвазәдән чыгып, Өргәнечкә килде. Югарыда әйтеп киткән идек ки, Өргәнеч хакименең исеме Собханколый гарәб вә Вәзир хакименең исеме Рахманколый гарәб, дип.

Мәзкүр качып килгән кеше, Собханколыйның алдына килеп, мавакыгны баштанаяк сөйләп бирде. Собханколый Өргәнечнең олугларын чакырып әйтте: «Вәзир шәһәрендә мондый вакыйга булган, имеш, ничә елдан бирле сезнең икмәк-тозыгызны җыеп торамын, инде әгәр сезнең ризалыгыгыз минем китмәгемдә булса, китәем, әгәр тормагымда булса, тораем», — диде. Өргәнеч халкы әйттеләр: «Әлхәмделилла, Шаһ Исмәгыйль падишаһыбыз тәхет өстендә утырып торганда, җөмлә Гыйрак вә Хорасан аның кулындадыр. Синең килгәнеңә дүрт-биш ел булды, синнән һич җәбер вә җәфа күргәнебез юк. Арка тарафыннан биш-ун кеше үзбәк Вәзиргә килде димәк, илән ни дип падишаһ алдына барырсың, вә без сине ни дип җибәрербез, үзбәкнең өе вә иле юк, бер җирдә карар кылып тормас, биш-ун көннән соң Вәзирне талап вә чабып кайтып китәр. Аның өчен ник тынычсыз буласың?» — дигәч, Собханколый әйтте: «Әгәр бу сүзләрне дөрес күңелегез илән әйтсәгез, минем алдымда барчагыз миңа яманлык кылмаска касәм[1] бирегез», — диде. Олуг-кечек барысы, утырып, Собханколыйның алдында: «Сиңа яманлык салмабыз, әгәр үзбәк килсә, алдыңда торып сугышырбыз», — дип ант эчтеләр. Аннан соң Собханколый хадименә бер янчык акча китерергә боерды. Ул, алып килеп, алларына акчаны куйды. Собханколый олугларга карап әйтте ки: «Миңа бер булдыклы егет табып бирегез, тиз барып, Вәзир шәһәрендәге вакыйгатны яхшы белеп кайтсын», — диде. Шәһәр олуглары тәгаен кылмактан мөкатдәм, каравыл халкының диваннар дигән җәмәгатеннән без яшь вакытта Гыйваз Кызыл Үгез дигән бер кеше бар иде. Шуның атасы бик булдыклы кеше иде, шул кемсә, урыныннан торып: «Бу хезмәтне мин кылырмын»,— диде. Ул вакыт Собханколый әйтептер ки: «Мин синең барып алып кайткан хәбәреңә ышанырмын, әгәр бу тәңкәләрне алып сәб сәхәбә[1] кылсаң», — диде. Теге кеше, тәңкәләрне алып вә сәб сәхәбә кылып, Вәзир шәһәренә барып, һәрни булган вакыйгатны тәфсилә кайтып, Собханколыйга мәгълүм кылды. Илбарыс хан, Вәзирдә өч ай торганнан соң, атланып Өргәнеч өстенә килеп вә Собханколый дәхи аңа ярым фәрсәх Өргәнеч гаскәре илән каршы чыгып, икесе сугыштылар. Илбарыс хан җиңеп, үтерә-үтерә, шәһәргә кергән. Собханколый барча нөкерләр илән шунда улмыш.

Аннан соң Илбарыс, хан өенә вә иленә кеше җибәреп, барчасын күчереп китерергә уйлап диде: Хивада вә Һәзарасыбта торган кызылбаш һәм Өргәнеч хакиме Собханколый сартка киңәш кылмыш, сартлар Собханколыйның китмәгенә разый булмый җибәрми торырлар, имеш. Өргәнечтән үзбәкнең күмәге килеп, Хиваны чабар, имеш, шул кәйфиятьчә утырып торырлар. Илбарыс ханның нөкере азлык кылып, Ядгәр хан иленең күбесе Әбүләк вә Амәнәк угланнарының катына торыр. Шул сәбәптән беркөн бәкләрен чакырып әйтте: «Без аз гына ил илән монда килдек, илебезнең күбе карендәшләребез катында калды, инде сезгә мәгъкуль булса, карендәшләребезне чакырыр идем», — диде. Анда һәммә бәкләр әйттеләр: «Без моннан мөкатдәм үк ни өчен кеше җибәрми дип фикердә торадыр идек. Бик мәгъкуль, бәли, шулай итмәк кирәк», — диделәр. Уйгур ыругыннан бер карт кеше бар иде, аңа өй эчендә урын тими тышка утырган иде, ул, җирдән торып, хан алдына барды вә кул кушырып торып гарыз кылды ки. Борынгы үткән үзбәкнең тәҗрибә әһелләреннән мәнкульдер, түрә дәүләтенең алга китмәге нишанәсе шулдыр ки, нөкергә миһербанлы булыр вә дәүләтенең артка калмагы нишанәсе карендәшкә миһербанлы булыр, димешләр. Илбарыс ханга ул сүз хилаф төшеп утырган бәкләренең барчасы ул кешене сүгеп шелтәләделәр. Ике карендәшне берберсе илә бозыштырмак шундый ирләр булыр, карендәшләрегез килгәч, шундый бозык сүзли торган яманнардан бер-ике кешене үтермәсәгез мәгъкуль булмас, диделәр.

## Әбүләк хан вә Амәнәк хан угланнарының,Өргәнечкә килеп, Хива, вә Һәзарасыб, вә Хорасан итәген алганнары вә Әбү-Әлхан, вә Мангышлак, вә Дабистанда утырган төрекмәннәрне тәбгы кылганнары

Ул вакытта Ядгәр ханның дүрт углы дүртесе дә үлгән иде. Илбарыс хан аларның угланнарына кеше җибәреп әйтте ки: «Без килеп, Вәзир илән Өргәнечне алдык, Хива вә Һәзарасыбтан кызылбаш китми торыр. Әгәр Ходадан вилаятьләр теләсәләр, Хорасан тигезлегендә вилаять күп, әгәр ил теләсәләр, Мангышлак вә Төрекмәндә биниһая ил бар». Барган кеше бу сүзләрне әйткәч, Әбүләк ханның бер углы вә Амәнәк ханның алты углы өй вә илләре илән күчеп Өргәнечкә килделәр. Аннан соң Амәнәк хан угланнары Хива вә Һәзарасыбны тәкрар чабып харап кылганнан кызылбашлар куркып качып киттеләр. Хива вә Һәзарасыб һәм Кятьне алганнан соң, Хорасан тарафына атландылар. Ул вакытта Шаһ Исмәгыйль, үзбәктән куркып, Хорасан тавының шималь тарафындагы сәрхәдләрнең көн тугыш Мөһинәгәчә вә көнбатышы Дарунгача — һәммәсенең хакимнәрен ташлап качты. Үзбәкнең җире киң булгач, һәр түрә, барып, әтбагы илән берничә вила-

ятьләргә ия булып утырдылар. Аннан соң Җөнүби Хорасанны вә көнбатышы Әбү-Әлхан илән Мангышлакны тәкрар барып чаптылар. Илбарыс хан энесе Бәликәч солтанны югарыда әйткән идек ки, имчәк имә торган вакытта аяклары зәгыйфь булып, ике тезләреннән түбән җаны юк, ботларына ябышып йөридер иде. Шул сәбәптән атка менә алмый арбага утырып йөрер иде. Бер кеше утырып ятарлык арбада урын калдырып, әйләнәсеннән тимер илән каплатып, яхшы аргамак атларны җигеп, дүрт-биш баһадир егетләрне янына алып, аларга баш булып берничә кәррә Әбү-Әлхан илән Мангышлакны чапты. Арбаның эчендә утырып, уңга вә сулга һәм артка вә алга ук атканына һич күз иярмәс иде. Олуг сугыш булганда, үзе егетләренә баш булып сәргаскәрлек кылыр икән. Арбасын алып йөргән егетләргә, болай йөрегез, алай йөрегез, элгәре йөрегез, кире кайтыгыз, дип әйтер икән. Атлы кешеләр илән тиң булып орышыр икән, арбага җиккән аргамак атлары менелгән атлардан асла калышмас икән. Төрекмән халкының берничәсе рәгыйять[1] булып, аңа мал бирер булганнар, никадәр мал бирмәген тәгаен кылмадыгыннан гяһ вакытта күп вә гяһ вакытта аз итеп бирер булганнар. Хода теләсә, Суфиян ханның хикәятендә төрекмәннең малына бер мөгайян[2] бирү тәгаен кылынганын әйтсәк кирәк. Берничә ел шул рәвешчә утырдылар. Бәликәч солтан вафат булды. Аннан соң озак тормый Илбарыс хан һәм дарелбакыйга китте.

Илбарыс ханнан җиде-сигез угыл калды, олугының исеме Солтангазый, икенчесенең Мөхәммәдгазый, башкаларының исемнәре мәгълүм имәс. Илбарыс хан, Вәзирне алгач, йортны кызылбаш кулыннан алганлыктан, угланнарының барчасына Газый дип ләкаб-ат куйды: Фәлән «газый» вә Баһман «газый» дигән кеби. Энесе Бәликәч солтаннан булган угланнарның барчасына Хаҗи дип ләкаб бирде. Фәлән «хаҗи» вә Баһман «хаҗи» димәк кеби. Ул вакытта Ядгәр хан нәбирәләренең эчендә Бәликәч углы Солтанхаҗидан башка олуг юк иде. Аны Яңа Шәһәрдән Вәзиргә китерделәр һәм хан күтәрделәр. Солтанхаҗиның иле вә нөкере аз иде. Ил, мал вә йортының ихтыяры Илбарыс ханның кулында иде. Ул үлгәннән соң олуг углы Солтангазыйның кулына күчте. Солтангазый вә булдыклы, гайрәтле егет иде. Ул заманда ил эчендә ошбу сүз мәшһүр иде ки, Солтангазый теләсә яхшы вә теләсә яман хөкем кылсын, Солтангазый ярлыгыдыр, һич чара юк, диярләр иде. Әмма яман гаебе шул иде ки, бик саран иде. Солтан-хаҗи ханга ике өлеш биргән иде: берсе — ханлык исемен, икенче — шиләп ашының алдын. Ул дәхи, бер ел торып, дарелбакыйга күчте.

Аннан соң Әбүләк хан углы Хәсәнколыйны хан күтәреп, Өргәнечне аңа бирделәр. Барчасы бер Ядгәр ханның өч углының угланнары иде. Өч бүлек булып, башка-башка атланып йөрерләр иде. Берсе — Илбарыс хан угланнары, болардан мәшһүрләре Солтангазый иде вә икенче — Бәликәч солтан угланнары, болардан мәшһүре Хәсәнколый иде. Өченче Амәнәк хан угланнары, аларның алты угыл: олугы Суфиян хан, вә икенче Буҗага, вә өченче Әвәниш, вә дүртенче Кал, вә бишенче Акатай, вә алтынчы Аганай. Ошбу алтысының угланнары дәхи күп иде. Хәсәнколый заманында мәзкүр алтыдан башка янә исем тоткан алты кемсә бар иде. Хәсәнколый хан атадан ялгыз булып, угланнары күп иде. Әмма араларында исем тотканы Билал дигән углы иде. Ата-угыл һәр икесе гайрәтсезрәк булдылар. Бер якта Илбарыс ханның булдыклы вә гайрәтле угланнары вә икенче якта Әмин ханның булдыклы вә гайрәтле угланнары Хәсәнколый ханның ялгызы Өргәнечнең хасыйлен алып ятканына хөсет кылып, һәр ике тараф иттифак илән Хәсәнколый ханга яу булдылар. Алар күп вә Хәсәнколый аз вә куәтсезлегеннән бигыйлаҗ булып Өргәнеч шәһәренә камалды. Өргәнечнең ул вакытта Ирек кальгасы юк иде. Аннан соң Иш солтан Ирекне салдырды һәм барчасы, килеп, Өргәнечне камадылар, дәхи һәммә түрәләр егетләре илән Хорасан дәрвазәсенә килделәр. Хәсәнколый хан, дәрвазәдән пиядә чыгып, хәндакка арты илән торып орышты. Тышкарылары атлы вә эчкәреләре җәяү иртәдән ярты көнгәчә бик каты сугыштылар. Амәнәк ханның кече углы Аганай солтан егермедән узган гайрәтле егет иде. Иртәдән ярым көнгәчә орышып ала алмаганнарына намус кылып чабучы егетләргә баш булып чапты вә яу җиткән җирдән һич кайтмады. Күп җәяүле сугышчылар эченә кереп, хәндак якасында сөңге илән кешеләрне чәнчеп чыкты. Аннан соң күп пиядә халык ук илән әүвәл атын орып ектылар, бәгъдә үзен егып башын кистеләр. Җәяү халыкның алды сөңге илән ук вә арты кальга качып китәр җире булмадыгыннан ничаклы алырга тырышсалар да булмады. Ахирел әмер куышларына кайттылар, вә Өргәнечнең кешеләрен яхшы санадылар, вә түрәләр нөкерләренә лаек кешеләрен алышып, күңелләрен Өргәнечне алмый кайтмаска бәян багладылар. Хәсәнколый ханның вә берничәләрнең әҗәленә вә имгәгенә каршы Аганай солтан үлеп китте. Ул үлмәсә, Хәсәнколый ханда каннары вә үчләре булмас иде, бәлки берничә көн үткәннән соң, сәрхәдтән бер вилаять җир биреп, татулашып, Өргәнечтән кайтырлар иде. Әмма Аганай солтанның үлмәге түзә алмас яра вә авыр имгәк булды.

Өргәнеч олуг шәһәр булганга күрә, бик тиз кахтлык булды, бер ишәкнең кәлләсе[1] кырык-илле тиенгә җитте, әмма ул да табылмады. Чикрыйк дисәң, Өргәнеч сартларының ачуы килер. Аның мәгънәсе будыр ки: Өргәнечнең Салурлар дигән җәмәгате булыр, аларның бер дәүләтле яхшы кешесе бар иде. Гавам халкыннан бер кеше аларга кереп-чыгып йөрер иде. Беркөн ул аның өенә барып керсә, Салурларның биш-алты аксакалы утырып, өй иясе ишәгенең җенес әгъзасын табакка салып, елкының казысын тураган кеби чикрыйк-чикрыйк итеп турап утырырлар. Ике ай мөддәсендә халыкның әхвәле шул дәрәҗәгә җитте, аннан

соңгысын моннан кыяс кылып фәһемлә. Бәгъдә халык, ачлыкка тәкать тота алмый, чарасызлыктан кальгадан тышка чыга башладылар, ахыр кальгада бик аз кеше калды, аз кеше андый олуг шәһәрне саклый алмады. Дүрт ай булды дигәндә Өргәнечне алдылар. Хәсәнколый хан илән олуг углы Билал солтанны үтерделәр вә яшь угланнарын анасы илән Бохарага җибәрделәр. Ул җәмәгатьтән сәгыдтә[2] әлхәл унбишләп кеше бар. Аннан соң Суфиян ханны хан күтәрделәр, Өргәнечне аңа бирделәр. Вәзир вә Яңа Шәһәр вә Тәрсәкне һәм Хорасанда Дарун илән Мангышлак төрекмәнен Бәркә солтан нәбирәләре Газый башлык алды. Су буенда Хива, вә Һәзарасыб, вә Кять, вә Булдумсаз, Никчигә шәһәрләрен вә тау буенда Баг-Абад, вә Нисай, вә Абъюрд, вә Чәһәрдә, вә Мөнһә, вә Чәчә бәлдәләрен[3], ушандак[4] Аму дәрьясы буенда һәм Әбү-Әлхан илән Дабистанда утырган төрекмәннәрне барчасын Амәнәк ханның дүрт углы алып, һәркайсы мәртәбәсенә мөнасиб өлеш алып, тыныч вә рәхәт утырдылар.

Суфиян хан бервакыт Төрекмәнгә кеше җибәрде. Ул вакытта Ирсары халкы Әбү-Әлханда утырырлар иде. Ходаның боерыгында зәкят бирмәк фарыздыр. Һәр елны малларыннан зәкят бирсеннәр, әгәр Ходаның әмеренә итагать кылсалар, мин илләрен чаптырмам, диде. Бу сүзне кабул кылып, һәр елда малларының зәкятләрен биреп табигъ булдылар. Бер елны Суфиян хан аларга кешеләр җибәрде, һәр елны олуг ыругларга бер кеше вә кечек ыругларының икесенә вә өчесенә бер кеше җибәрер иде. Бу елны һәм шул кәйфиятьчә җибәрде. Юлга чыкканнан соң санадылар, барча чыккан кеше кырык кемсә булды. Илгә барып, һәр кеше бер ыругның малын җыеп йөрер иде. Шул елны төрекмән егетләре мәслихәт кылып, һәркайсы үз ыругына килгән зәкятчене үтерделәр.

Берничә заманнан соң бу хәбәрне ханга җиткерделәр. Хан, төрекмәннәрнең бу кылган эшләренә ачуланып, дүрт энесе илән атланып, Әбү-Әлхан өстенә барды. Ул вакытта Өргәнечтән Әбү-Әлханга бармак бу авылдан ул авылга бармак кеби иде. Аның өчен Аму дәрьясы Өргәнеч кальгасының төбеннән үтеп, Әбү-Әлхан тавының мәшрикъ тарафына барып, тауның төбенә җитеп, кыйбла тарафыннан әйләнеп, мәгъриб тарафына барып, аннан үтеп, Угырҗәгә барып, Мазандаран диңгезенә кояр иде вә дәхи Аму-Дәрьяның ике тарафы Угырҗәгә барганчы йөзем багы вә агачлык вә игенчелек иде. Язның эссе көннәрендә маллы кешеләрнең бәгъзесе черки вә чебеннән тынычламак өчен бер-ике мәнзил сахра тарафында кодык[1] башларында утырып вә кайберсе дәхи малларын тау өсләренә бәлнд җирләргә һәйдәп китәрләр иде. Черки-чебен беткәннән соң, янә дәрья буена төшәрләр иде. Андагы җирләрнең абадлыгына вә шәһәр илән карьяләренең мәгъмүриятенә[2] хәйран калмаган кеше юк иде. Дәрьяның ике тарафында Кара-Кичеткәчә кара урман кеби тау вә бостак арасында мәдәниятле атаклы Хозыр дигән ил утырыр иде. Кара-Кичеттән Әбү-Әлхан тавының мәгъриб тарафынача ике тарафта Гали иле утырыр иде. Аннан диңгезгә койган төшкәчә Дөяче халкы утырыр иде. Инде әйтә торган сүздән калмаек: Суфиян хан, энеләре илән ил читенә килгәч, түрәләрен бүлек-бүлек итеп илләрне чабарга вә таларга боерды. Ирсары халкы илән Хорасан Салуры халкы бергә аралаш утырганнар иде. Аларны шундый чабып таладылар ки, хәтта малларны сөреп йөрергә кешеләре җитмәде вә бала-чагаларын барчасын әсир кылдылар, ерактагылар качып котылды. Ат җиткән җирдә чабылмый калган фәкать бер мөхкәм кыр калды. Әбү-Әлханның шималь тарафында Әбү-Әлхан илән аның арасы атлыга өч көнлек юл иде, ул урынны Җутак дирерләр, ягъни кахтлык димәктер, вә җә тәсмия шул ки, җиренең суы юк иде, юкса, яу килеп, йөз ел камаса да ала алмас иде. Дөя асрап көн иткән фәкыйрь халыклар, ул урынны ерак күреп, шунда барып камалдылар. Чабучы гаскәр җыелгач, хан, барып, Җутакны камады. Төрекмәннәр, бер-ике көн утырып, сусызлыктан кырылырга җитеште. Аксакаллар, таудан төшеп, Акатай солтанның утырган җиренә килеп, хозурына керделәр вә ханга күренеш кылып гарыз кылдылар ки: «Без ишетәбез, үзбәк рәсемендә өй вә йорт кинҗә[1] угылның булыр, имеш. Ата баш булып, барча агалар кинҗә угылны сыйлап, аның сүзеннән чыкмаслар, имеш. Амәнәк хан угылларының кинҗәсе син буласың дип ишетәбез, инде безем кулыбыз синең итәгеңдәдер. Әгәр син безем гөнаһыбызны агаларыңнан үтенеп алсаң, барчабыз ант эчәрбез: угыл — угылга вә кыз кызыбызгача, Акатай ханның токымыннан һәркем булса, аңа баш тартып каршы килмәскә. Акатай хан, ул аксакалларын кайтарып җибәреп, барча эшкә ярарлык кешеләрен чакыртып алдырды. Алар, Акатай солтанның каршында ошбу әйтелгән сүзләрне әйтеп, Коръәннән кыйсем бирделәр. Акатай солтан, төрекмәннәрне йортында калдырып, агасы Суфиян солтан катына барып, төрекмәннәрнең гөнаһын үтенде. Агасы гафу кылды. Аннан соң Буҗага хан, аннан Әвәниш хан, аннан Кал хан хозурына барды, барчасы сиңа багышладык, гафу кылдык, ничек кылсаң, шуңа разыйбыз», — диделәр.

Акатай хан йортына кайтты, күргән вә ишеткәнен җөмләсен төрекмәннәргә әйтте. Алар, сөенгәннәреннән кайсы егълап, кайсы көлеп, ни кылырларын белмәделәр. Аннан соң Акатай хан төрекмәннәргә әйтте: «Агаларым гөнаһларыгызны кичерделәр, инде сезне йолып алганым өчен миңа ни бирерсез?» — диде. Алар әйттеләр: «Сез нәрсә дисәгез, шуны бирербез», — диделәр. Акатай солтан: «Ханның ничә нөкерләрен үтердегез?» — дип сорады. Төрекмәннәр, хисап кылып: «Кырык кешене үтердек», — дип җавап бирделәр. Акатай солтан әйтте: «Инде бу ел чабылып, бик чыгымлы булдыгыз, Хода теләсә, киләчәк елда һәр кеше-

нең каны өчен агам Суфиян ханга меңәр куй бирерсез. Аларны ни рәвешле тапшырмакны агамның үзе илән сөйләшерсез», — диде. Төрекмәннәр моны җан вә тәннәре илән кабул иттеләр. Ирсары таифәсе уналты мең куйны, Хорасан Салуры таифәсе янә уналты мең куйны вә Тәкә вә Сарык һәм Ямут таифәселәре сигез мең куйны бирмәк булдылар. Бу әйтелгән илләрнең барчасы бер ыруг халыктыр, барчасына Тышкы Салур дип әйтерләр.

Суфиян хан кайтып Өргәнечкә төште. Киләчәк елны хан бер зәкятчене җибәрде. Төрекмәннәр кырык мең куйны тизлек илән җыеп, унике атаклы бәкләре зәкятченең алдыннан куйларны һәйдәп күп һәдияләр алып килеп ханны күрделәр. Икенче елны зәкятче җибәреп сорагач, янә бирделәр. Шул кырык мең куйны һәр елда бирмәк ничә буынгача аларга лязим булды.

Инде башка төрекмәннәрнең бирә торган малларын калдырмый ошбу җирдә әйтәек: бу вакыйгаттан берничә ел үткәннән соң, мал бирә торган төрекмәннәрнең башын вә малын һәм йортын хисап кылып, Эчке Салур таифәсенә һәр елны зәкят турысына уналты мең куй вә падишаһның сугымлыгында суймак өчен мең алты йөз данә куйны бирергә илтизам[1] иттеләр. Мәзкүр уналты мең куй бирәт[2] куе вә мең алты йөз куйны казан куе дип тәсмия кылдылар. Бирәт тугрысына алынган куйлар падишаһның нөкерләренә бирелде. Бирәт тугрысына алына торган куйлар илән бергә падишаһ казанына һәм куйлар алындылар. Хәсән иленә уналты мең бирәт куе вә мең алты йөз казан куе калдылар. Аның унике меңен Икдәр-Чавылдыр таифәсе күтәрде вә дүрт меңен башка вак илләр күтәрде. Әрәпче таифәсенә дүрт мең бирәт куе вә дүрт йөз казан куе салдылар, вә Күклән таифәсенә унике мең бирәт куе вә мең йөз казан куе салдылар, вә Әдаклый таифәсенә унике мең бирәт куе вә мең ике йөз казан куе салдылар. Аму дәрьясының якасында иген игеп утырган өч ыруг төрекмән бар иде, аларны Өч дирерләр иде; берсе Хазар таифәсенең Әдаклый иле, вә икенче Гали иле, вә өченче Тәвәче иле. Боларның игеннәреннән дә гошер алдылар вә моннан гайре Тәвәче иле илән Гали иленә дәхи малларыннан зәкят алып, Әдаклый иленнән нөкер алдылар. Берничә ел үткәннән соң, Суфиян хан Хак рәхмәтенә китте.

Суфиян хан үлгәннән соң, Буҗага ханны, Өргәнечкә китереп, хан күтәрделәр. Суфиян ханның биш углы бар иде. Әүвәле Йосыф, икенче Юныс, өченче Гали, дүртенче Агиш, бишенче Пәхлеванколый. Ошбу бишесенә Хиваны бирделәр. Буҗага хан заманында Бохарада Габид хан бар иде. Ул ничә кәррә Хорасан өстенә барып, ничә вилаятьләрен мөсәххәр кылды, вә Хорасанның гайре вилаятьләрен үзбәкләр чабып, өлҗә вә әсир алып тордылар. Абъюрд, вә Нисай, вә Дарун, Өргәнеч үзбәкнең кулында иде. Болар һәм атланып Фил күперенәчә чабарлар иде. Чабучыларның бер гөруһы кайтса, аның урынына дәхи икенче гөруһ китәр иде. Хуҗәнд илән Әсфәраин Нисайдан арада бер кич кунып бара торган җирдер. Ул икесенең хакимнәре иген игә белми вә малны асрый белми кышны вә язны корган (кальгача)ның эчендә камалып утырырлар иде. Бу сәбәптән Хорасан падишаһы Шаһ Таһмасыб аларның тынычсызлыгыннан гаҗиз калды вә үзбәкләр илән дуслыкта вә рәхәттә утырмак өчен Шаһ Таһмасыб Буҗага ханга илче җибәрде. Әйткән сүзләре будыр: «Мин ханга угыл булыр идем, Тимер би Чыңгыз әүлядына кияү булмак илән бу заманча исемне Тимер күргән дирләр. Мин һәм Чыңгыз әүлядына кияү булмакны күңлем эзлидер. Хункар кеби олуг дошманым әйтсен иде ки, Шаһ Таһмасыб үзбәк падишаһының кызын алды һәм солых кылды», — дип.

Буҗага ханның кызы юк иде, агасы Суфиян ханның буй җиткән кызы бар иде, Гайшәбикә исемле, шуны бирмәк булды. Кызның туган агаларын биш икәнен мөкатдәмдә әйттек, аларның эчендә Агиш солтанның адәми фәкыйрь әлхәл вә дәрвиш ниһаять бер диһкани егет иде. Аны баш кылып, тугыз кеше илән мал алмакка Таһмасыб шаһка Казвин шәһәренә җибәрделәр. Таһмасыб шаһ бәкләрен аларны каршы алырга чыгарып, олуг җыен җыеп, хәдсез кадер вә хөрмәт итте. Агиш солтанга Хаҗәнд шәһәрен бирде. Анда утыз ел хөкүмәт кылып вафат булды. Үлгәнче Хаҗәндтән атланып һичбер җиргә сәфәр чыкмады. Буҗага ханга тугыз алтын хишт вә сиксән бер көмеш хишт, вә тугыз чатыр, башы алтын, аягы чуптардан нушакы[1] илән бер мәҗлеснең әсбаб вә җиһазы — барчасы алтын вә көмештән, вә тугыз ат җегәре вә йөгәне илән, вә мең ефәк комаш җибәрде. Буҗага хан һәм кызны падишаһларга лаек әсбаб вә кием-салым илән Казвинга озатты. Фәләк[2] берничә вакыт өркелгәннән соң, ягъни берничә заман әйләнеп үткәннән соң, Буҗага хан вафат булды.

## Әвәниш ханның падишаһ булганы

Әвәниш ханны Буҗага ханның вафатыннан соң хан күтәрделәр. Буҗага ханның өч углы бар иде. Олугының исеме Дусмөхәммәд, икенчесе Ишмөхәммәд, өченчесе Бурум, аны Иш-Дус дип әйтерләр иде. Әүвәлге икесенә Кять вилаятен бирделәр. Әвәниш ханның өч углы бар иде. Олугы Динмөхәммәд хан, уртанчысы Мәхмүд, кечесе Гали солтан. Динмөхәммәд ханның анасын Мангыттан килгән сәүдәгәрдән сатып алган иде, чәһрәсе[3] кара иде, үзе әйтер иде, фәләнчә мангыт мирзаның кәнизәгеннән туган кызы идем, мангыт халкы бозылып таралгач, мине бер кеше өлҗә кылып сәүдәгәргә сатты; калган ике кечек углының ана-

сы Мангыт мирзаларының кызы иде. Динмөхәммәд ханны, имчәктән аерылганнан соң, Гали солтанның анасы биемгә тапшырды.

Һәр падишаһ Мангыт мирзаларының кызын алса, ул хатынны бием диярләр иде. Бием Динмөхәммәд ханны яхшы карап тәрбия кылмас иде. Динмөхәммәд хан алты яшәр углан вакытында үз тиңе угланнар илән уйнап, кальга ясап, берничәсен кальганың эчендә куеп, калганнарын тышта калдырып, кальгага йөгерегез, дир иде. Кайсыгыз кальгага әүвәл чыкса, ингам вә ихсан кылырмын, әмма әгәр берегез куркып кальгага һөҗүм кылмаса, үтерермен, диде. Бервакыт бием, боларның кальга-кальга уйнаганнарын күреп, Динмөхәммәдкә карап әйтте: «Бакыгыз, бу ниләр кылынып йөри, сиңа шәһәр вә кальга урынына таш вә туфрак булыр», — диде. Динмөхәммәд хан, урыныннан торып, кул кушырып тәгъзыйм кылып, биемнең алдына килде. Биемнең ачуы килеп: «Мин моны сүгәмен, ул миңа тәгъзыйм кылып алдымда тора», — диде. Динмөхәммәд хан әйтте: «Сез миңа таш вә туфрак булыр дигән сүзегезне Хода Тәгалә телегездә сөйләтте, шәһәр вә вилаять, әлбәттә, таш вә туфрактан булыр», — диде.

Шундый ниятенә муафикъ Ходай Тәгалә аңа күп вилаятьләр бирде. Динмөхәммәд хан атасы кулында унтугыз яшь яшәде, атасы аңа үз гомерендә һичнәрсә бирмәде, ул вакытта Хорасан итәге Астрабадкача Өргәнеч падишаһларына караган иде. Аны тау буе вә Өргәнеч су буе дирләр иде. Икесе бер падишаһның йорты иде. Өргәнечнең булдыклы егетләре, Хорасанга барып, кызылбашны чабып, мал табып кайтырлар иде. Динмөхәммәд солтан, берничә егетләрне ияртеп Астрабадка барып, Мазандаранны чабармын, дип, атасыннан рөхсәтсез кырык кеше илән атланып китте. Су якасы илән чиктә агачлары үскән тугайга төшеп, аннан Динар дигән кодыкка барды. Ул урыннан торып йөреп барганда, бер кеше очрады. Алты төясе вә утыз куе бар иде. Аннан: «Кая барасың?» — дип сорады. Ул кеше әйтте: «Мөхәммәдгазый солтанның фәләнчә дигән кешесенең нөкере булам, төрекмәнгә зәкят алырга килгән идем, шул эшемне бетереп кайтып Дарунга барамын», — диде.

Ул вакытта Дарун хакиме Илбарыс ханның углы Мөхәммәдгазый солтан иде. Мәзкүр куйларның эчендә бер сары сәркә[1] бар иде. Динмөхәммәд солтан әйтте: «Ошбу сәркәне миңа сайлап бирегез, шаять, ырымга яхшы булып, сәфәребез мөбарәк булыр. Хода теләсә, кайтканыбызда аның урынына куй бирербез», — диде. Ул кеше кабул итмәде, солтанның аңа ачуы килде һәм аны баглатып ордырды, төясен вә куен алып, юлына йөрә бирде. Без кечкенә вакытта карт кешеләр әйтерләр иде: яман эшне, бу аз гына нәрсә, аны кылганнан ни булыр, дип, асла кылма, безем йортыбыз бер сары кәҗә баласыннан бозылгандыр, дигәннәре шул кәҗә баласыдыр. Инде йортның ничек бозылганын әйтәем.

Динмөхәммәд солтан Астрабадка барды, дәхи өч-дүрт кәррә кызылбашны чабып, күп өлҗә илән атасы катына кайтты. Теге куен, төясен алдырган кеше барып, бәгенә мәвакыйгны сөйләп күрсәтте, бәге, барып, Мөхәммәдгазый солтанга әйтте. Солтан, Динмөхәммәд солтанның бу кылган эшенә бик ачуы килеп, кайта торган колларына күп кешеләр тәгаен кылды. Ул кешеләр саклап тордылар, Динмөхәммәд солтанның бу эштән хәбәре булмый кайтканында барча нөкерләре илән сакчылар кулына төште. Нөкерләрнең өлҗәләрен алып вә күп әдәләр кылып җибәрделәр. Динмөхәммәд солтанны тотып, Мөхәммәдгазый солтан алдына алып бардылар. Солтан, аны бер өйгә яптырып, ишеген бикләтеп, берничә кешене, качырмый саклагыз, дип, каравыл куйды. Нөкерләренең күбесе, җәяү арып-талып кайтып, өйләренә киттеләр вә берничә ихласлы вә төплеләре солтанны тоткын куеп йортка барып ни әйтербез, дип, олуг юл өстендә утырган илләрдә гидайлык[1] кылып йөрделәр.

Өйләренә кайткан нөкерләр башларыннан үткән вакыйгатны сөйләделәр һәм бу хәбәрне Әвәниш ханга ишеттерделәр. Хан бу хосустан һичнәрсә әйтмәде, аның өчен Динмөхәммәдкә ата күзе илән карамас иде вә бере дәхи шул ки, Әвәниш хан ул вакытта илле яшенә җитмеш иде. Гали солтан анасы илән бер яшьтә иде. Мөхәммәдгазый солтанның бер сылу сеңлесе бар иде, аңа яңарак өйләнгән иде. Мөхәммәдгазый солтан Динмөхәммәдне берничә көн тотканнан соң, уйгур халкыннан Ришау Ходайбирде дигән нөкере бар иде, шаһзадәне аңа тапшырды һәм аның янына биш-алты кеше кушты. Ходайбирдегә әйтте: «Аягын атның карыныннан багла. Кичә вә көндез туктама, тизләп атасы ханга алып бар вә ханга минем догамнан соң әйт ки, углыгыз сездән рөхсәтсез киткән, имеш, вә, монда килеп, фәләнчә эшләр кылды, шуны тәнбия кылып, сезгә аны кайтарып җибәрдем», — дип. Аннан соң Ришау Ходайбирде биш-алты кеше илән солтанны алып киттеләр. Кичләрне йөргәндә, Динмөхәммәд солтан ил якыныннан үтәбез дип гөман кылганда, бәләнд аваз илән кычкырып үтәр иде. Моннан максуды бу иде ки: нөкерләремнән бу ил эчендә мине саклап яткан булса, авазымны ишетеп танып килсен. Һәркайчан солтан кычкырса, Ходайбирде Ришау әйтер иде, аның бу сүзе солтанга ук-кылычтан яманрак күренер иде. Ходайбирденең бу сүзне әйтмәк гадәте иде, шуның өчен күзен Хорасан юлыннан алмады. Динмөхәммәд солтанның кешесе хатларны алып барды вә Мөхәммәдгазый солтанның хатларының мәзмунын[1] аңлагач, атланып Өргәнечкә сары тизләп йөрде. Өргәнечнең дәрвазәсеннән кереп, ханның хәүләсенә[2] кереп, аттан төшеп, сеңлесенең катына йөгереп керде. Мөхәммәдгазыйның ул көн каны түгелмәк көне икән, Әвәниш хан шул көнне иртә илән, карчыга алып, ау ауларга

чыкмыш иде. Динмөхәммәд солтан Мөхәммәдгазый солтанның килгәненнән хәбәрдар булып, нөкерләрен башлап дәрхаль атасының йортына йөгерде. Яз көне чашт[3] вакыты иде. Мөхәммәдгазый сеңлесе торган сарайның ишеген ачып кергәч вә сеңлесе аның килереннән хәбәрдар булмый агасын күргәч, урыннан тора килеп, «мәрхаба» дип күреште. Солтан әйтте: «Инде Ходайга шөкер, яхшы сәламәтләнгәнсең, руз кыяметкәчә күрешеп калырга телимен, дип язган хатыңны юлыгып алдым. Шул хатны алгач, көндез туктамый вә төнне ятмый килеп җиттем», — диде. Сеңлесе әйтте: «Гаҗәп, мин авырганым һәм хат язганым юк», — диде. Бу сүзне ишеткәннән соң, куркып, утырмый йөгереп кайтмакка чыкты. Шул хәл дөп-дөп итеп йөргән Динмөхәммәд солтанның аяк тавышын ишетте. Аннан соң бер бәла булачагын гайнелякыйн[4] белде вә хәүлә ишегенә бармый куркып, башка тарафка йөгереп барганда, бер олуг ишек очрады вә, йөгереп керсә, атханә, һичкем юк, чыгарга җир карады, һич тапмады. Диварга колак салып караса, йөгереп йөргән пиядәнең аяк авазларын ишетте вә, моннан зиядә куркып, яшеренергә урын эзләде, әмма тапмады. Һич әмәл кылырга белмәгәннән нагыйлаҗ атның өеп куйган тиресе эчен казып, шунда кереп ятты вә зәнбилне[1] өстенә тартып каплап куйды. Динмөхәммәд солтан кырык-илле нөкерләре илән йөгереп анасының өенә керде, һәммәләре таралышып эзләделәр, һич таба алмадылар. Кәнизәкләрдән сорадылар, һичкайсы белмәде. Аларның берсе әйтте: «Шул тарафка киткәнен күрдем», — диде. Динмөхәммәд солтан ул тарафка таба йөгерде, һәр нөкере һәр өйгә кереп эзләделәр, берсе ханның атханәсенә керде, араннарны карап йөргәндә, тиреслек өстендә бер кызыл иске кисәге ятканын күрде. «Бу ни шәй икән?» — дип, якынрак килеп күрсә, кием итәге икәнен белде, дәхи йөгереп килеп, Динмөхәммәд солтанга хәбәр бирде. Ул шул хәл, зәнбил астыннан чыгарып, башын кисте. Шул сәгать Солтан Мөхәммәдгазый, аны Ришау Ходайбирде дирләр иде, Динмөхәммәд солтанның моннан хәбәре булмый, мине мәсхәрә кыла дип күңеленә килер иде.

Шулай йөри торгач, Күрдишкә килделәр. Сәхәр вакыты иде. Солтанның казакъларыннан биш-алты кеше ошбу илнең эчендә иде. Ат аягының авазы килгәнгә казакълар тордылар. Ул вакытта солтан кычкырды, барчасы авазыннан танып йөгереп килделәр. Ходайбирде әйтте: «Илгә төшәр вакыт җитте, төшәек», — диде. Солтан әйтте: «Мин илгә төшәргә намус кыламын, бераз йөреп төшәек», — диде. Ходайбирде, солтанның сүзен кабул кылып, таң атканда барып, бер җиргә төште, янындагы кешеләре барчасы йокыга яттылар. Солтанның казакълары артыннан килделәр. Берсе, килеп, солтанның аерысын сындырып бушатты. Солтан Ходайбирденең кылычын алып, аның муенына чапты. Солтанның һәр казагы Ходайбирденең берәр кешесен үтерделәр. Каннарына ком салып, үлекләрне йөкләп, юлдан эчкәрәк илтеп күмделәр. Солтан барча нөкерләренә бу эшне һичкемгә әйтмәскә кыйсем бирдерде. Аннан соң Өргәнечкә кайтып, атасы илән күреште. Атасы хәл-әхвәл сорашкач, әйтте: «Мөхәммәдгазый солтан әүвәл миңа ачуланган кеше кеби эш кылган иде, ләкин соңыннан ат-тун биреп, яхшы сыйлап, гозер итеп озатып җибәрде». Бу сүзгә атасы ышанды.

Шул көнне солтан, базардан бер мөһер язучыны китереп, атасының исеменә бер мөһер яздырды вә атасының яшь хатыны — Мөхәммәдгазый солтанның сеңлесенең исеменә янә бер мөһер яздырды. Әвәниш ханның теленнән бер хат язды: «Мөхәммәдгазый солтанга күп догадан соң мәгълүм булынадыр, сеңлең хаста ятар, булырын-булмасын Хода үзе яхшы белер, синең дидарыңны күрмәктән гайре теләгән нәрсәсе юктыр». Вә сеңлесенең теленнән дәхи икенче хат язды. «Агама күптин-күп бәндәлектән соң мәгълүм булынадыр, ничә көннән бирле авырумын, бу хастадан сәламәтләнермен дип белмимен. Инде морадым вә арзуым[1] шулдыр ки, сине бер күреп үлсәм иде. Мөмкин булса, тизлек илән килә күр. Кыяметкәчә бер күрешеп калаем», — диде.

Бу ике хатны мөһерләп, бер игътибарлы нөкеренең кулына биреп, башка сүзләрне дәхи өйрәтеп, куш ат илән Мөхәммәдгазый солтанга җибәрде. Солтан үзе мөкатдәмдә чабарга барган егетләрне янына җыеп вә алардан гайре дәхи егермеләп егетне үзенә яр кылып, ашап, Газыйның үтерелмәге бу шәһәр эчендә фаш булды.

Өргәнеч илән Вәзирнең арасы алты фәрсәх җир иде. Солтангазый солтанның Өргәнечтә йөргәннәренең берсе, шул көнне барып, Солтангазый солтанга хәбәр бирде. Солтанның кечек хатыны Суфиян ханның кызы иде. Суфиян ханның Гали исемле углы сеңлесен күрергә барган иде. Солтангазый солтан энесенең мокател[2] булганын ишеткәч, һич кешегә киңәш итми, карендәш ачуына чыдый алмый, шул сәгатендә яткан каенагасы Гали солтанны тотып үтерде. Әвәниш хан, аудан кайтып, Мөхәммәдгазый солтанның үлеген күрде. «Динмөхәммәд кайда?» — дип сорады. «Мөхәммәдгазый солтанны үтергән сәгатьне сездән куркып нөкерләре илән атланып качып китте. Кай җиргә киткәнен һич әйтеп белә алмыйбыз», — диделәр.

Әвәниш хан энеләрем вә бәкләремә киңәшеп, йорт мәслихәтенә кайсы эш яхшы булса, аны кылаем дип торганда, Вәзирдән: «Солтангазый солтан Галине үтерде», — дип, бер кеше хәбәр китерде. Бу хәбәрне ишеткәч, ни кылырын белми хәйран булып торганда, энеләре Кал хан вә Акатай хан вә агасы Суфиян хан вә Буҗага ханның угланнары һәм Әвәниш ханның үз иле, бу хәбәрләрне ишетеп, Солтангазый солтанның иле Әвәниш ханны чабар дип, Өргәнеч тарафына куаладылар вә Амәнәк хан угланнары нөкерләре илән Өргәнечкә җыелдылар, вә Илбарыс хан угланнарының иле Вәзиргә җыелды. Әвәниш хан ничаклы солых

итәек, дип әйтсә дә, энеләре вә агасының угланнары вә нөкер халкы асла кабул итмәделәр, иттифак илә Вәзир өстенә йөрделәр. Солтангазый солтан Яңа Шәһәрдә Бәликәч солтанның угланнарына, тизрәк килә күрсеннәр, дип, һәр көнне кеше җибәрде. Алар «бүген барабыз», «иртәгә барабыз» дирләр иде. Әмма үзләре шәһәрләреннән чыкмаслар иде. Алар килмәстән мөкатдәм Амәнәк хан угланнары Вәзиргә бардылар. Вәзирнең мәшрикъ тарафында кырның итәгендә бер фәрсәх җирдә Комкәнд исемле бер кәнде бар иде, ул вакытта гаҗәеп абад иде. Солтангазый солтан Вәзирдән атланып Комкәндкә килде. Бәхетсезлеккә каршы, солтанның илгә шәфкате аз вә золымы күп, вә нөкерләргә бирмәге аз, хезмәте күп иде. Бу сәбәптән илнең һәммәсе аны бик яман күрерләр иде. Шуңа күрә солтан гаскәрләренең сафларын тәртип кылып йөргәндә: «Бу төшкә кеше аз куелган, күбрәк кирәк иде», — диде. Ул гаскәр эчендә торган үзбәкнең берсе кычкырып әйтте: «Ул төшнең кешесе аз булса, елкың илән сыгырыңны китереп куй!» — диде. Күп халык эчендә кем әйткәне мәгълүм булмады, солтан һәм ишетмәмешкә салынып һичнәрсә әйтмәде, үтеп китте. Ике гаскәр саф тартып орыштылар. Әвәниш хан җиңде. Шул көнне, яуны куалый-куалый килеп, Вәзиргә керделәр. Олуг вә кечек Илбарыс хан угланнарыннан башлыклары Солтангазый солтан илән уналты җанны үтерделәр.

Солтангазый солтанның куәте күп иде, Хорасанның Бөрмә дигән җирендә төрекмәнне чапканда, Олуг Түбә Зәнбил бәк дигәннең кызын алган иде. Аңардан ике углы вә ике кызы бар иде. Олугының исеме Гомәргазый солтан вә кечегенең исеме Ширгазый солтан. Олуг кызының исеме Зөһрә ханым вә кечегенең исеме Нунаш ханым. Мәзкүр Бөрмәдәге Әрдүсин Акатай солтан нөкерләре өлҗә кылдылар. Гомәргазый солтан унбиш яшендә вә Ширгазый солтан унике яшендә иде. Амәнәк ханның башка угланнары һәркайсы үзләре өлҗә кылган солтаннарының өйләрен таладылар, угланнарын үтерделәр, кызларын вә хатыннарын өлҗә кылдылар. Әмма Акатай солтан үзе һичнәрсәләрен алмады вә угланнарын үтермәде. Дүрт-биш кешегә ат вә дөяләр биреп, Олуг Түбә Зәнбил бәк кызы Солтангазый солтанның хатынын ике углы, ике кызы илән Бохарага озатты. Бәликәч солтанның угланнары, Яңа Шәһәрдән атланып Вәзир якынына килеп җиткәч, Солтангазый солтанның яуга каршы Комкәндкә киткәнен ишеттеләр. Шул хәл Комкәндкә юнәлделәр. Анда барып җиткәч, орышта үлгән үлекләрне күргәч, ни вакыйгат булганны аңладылар; кайтып, өйләренә бармый, Өргәнеч өсте илән Бохарага киттеләр.

Ул җәмәгатьнең нәселе Мавәраәннәһердә күп иде. Шул вакыйгаттан соң бу җирдә аларның нәселеннән, орышта һәлак булып, һич кеше калмады, мөнкатыйг булды. Ошбу маҗаралар тарих һиҗри илән бер мең җитмеш дүрт елда вакыйг булды. Моннан соң тау буе вә су буе Амәнәк (Әмин) хан угланнарына калды. Әвәниш хан Өргәнечтә утырды, гайре вилаятьләрне вә төрекмәннәрне истихкакларына[1] лаек бүлешеп алдылар һәм тынычлык илән утырдылар. Дарун җире Солтангазый солтанның вилаятедер, синең өлешең будыр, дип, аны аңа бирделәр.

## Габид ханның Өргәнечне алганы

Солтангазый солтанның углы Гомәргазый гайрәтле яхшы егет иде. Бохарага барганнан соң, Габид хан хезмәтендә булды, аннан һәмишә ярдәм теләде. Габид хан Өргәнечнең бозылганын ишетеп, әгәр барсам ярыймы, Амәнәк угланнарыныкы булса ярыймы, минеке булыр, диде. Дәхи гайре тарафлардан барча Әбелхәер хан угланнары атланмакка иттифак кылдылар. Ташкенттан Барак хан, Сәмәркандтан Җәвәнмәрд хан, Хисардан Хәмзә вә Мәһди солтан нәбирәләре вә Бохарадан Габид хан һәммәсе атландылар да Өргәнечкә килделәр. Амәнәк хан угланнарының Хива вә Һәзарасыбта утырганнары, тора алмый качып, Әвәниш хан катына бардылар. Әвәниш хан дәхи Өргәнечтә тора алмый, барчасы берегеп, кыр тарафына качтылар. Габид хан, Өргәнечкә килеп, Әвәниш хан артыннан кешеләр җибәрде. Вәзирнең шималь тарафында Бият кыры дигән җирдә Әвәниш ханның артыннан җиттеләр. Барчаларын кулга төшереп, Әвәниш ханны, катилең, дип, Гомәргазый солтанга бирделәр. Гомәргазый Әвәниш ханны үтерде. Акатай ханны Габид хан үз химаясенә алды, Кал ханны Хәмзә вә Мәһдинең нәбирәләре вә Хисар түрәләре сакладылар. Өргәнечне Габид хан Габделгазиз исемле углына бирде, ул Өргәнечтә утырды. Андагы сарт вә төрекмән, вә барча рәгайәне урыныннан тибрәтмәде, шулкадәр тынычлык булды ки, хәтта бер кеше икенче кеше тавыгының аягын сындырмады. Үзбәкнең ыругларын, хисап кылып, дүрт өлешкә бүлде. Бер өлешен Габид хан, вә берен Хисар түрәләре, вә берен Сәмәрканд түрәләре, вә берен Ташкент түрәләре алдылар. Һәркайсы, үз иленә кеше куеп, үзләре үз өйләренә кайтып киттеләр. Әвәниш ханның угланнары Мөхәммәд солтан вә Гали солтан, яу кулына төшми, качып, Динмөхәммәд солтан катына — Дарун вилаятенә бардылар. Гали солтан җиде яшендә иде. Суфиян хан угланнары Йосыф илән Юныс, болар һәм яу кулына төшми, Динмөхәммәд солтан катына бардылар вә болардан гайре түрә-караның яу кулына төшмәгәннәре Дарун вилаятендә Динмөхәммәд солтан янына җыелдылар. Акатай хан угланнарының Хаҗим ханнан башкасы һәммәсе яшь иделәр.

Алар ата вә аналары илән Бохарага киттеләр. Хаҗим хан унсигез яшендә иде. Яу килеп, илгә аралашкач, качып чыга алмады.

Һәрнәрсәнең мәгънәсен беләә торган атасының бер гакыйльле нөкере бар иде. Дурман халкыннан. Җан Сәед исемле. Аның өенә барды, бер иске бүрек илән тузган чикмән киде вә, кулына корык алып, Җан Сәеднең елкысын багып йөргән булды. Дурман халкын Сәмәрканд түрәләре өлҗәгә алмыш иделәр. Аларны, һәйдәп Кызыл Рабат дигән җиргә алып барып, анда утырттылар. Өч ай үткәч, таный торган Өргәнечләр бер-берсенә әйтә башладылар: «Акатайның углы Хаҗи Мөхәммәд солтанны күрдем. Җан Сәеднең елкысын багып йөрептер». Бу сүз Өргәнечләр арасында көннән-көн күбәйде. Аннан соң Җан Сәед солтанга әйтте: «Өргәнечләрнең бу җирдә утырганнары сине белделәр, инде бу көн йә иртәгә бу сүз Габид ханга җитәр, ни әйтерсең?» — диде. Хаҗим солтан әйтте: «Әгәр кулыңнан килсә, үзең юлдашлык кыл, әгәр килмәсә, миңа ат бир, Динмөхәммәд солтан катына китәм», — дигәч, Җан Сәед дүрт ат алды, ике атны икесе менде. Җан Сәед алдан йөрде вә ике атны, ризыклар салып, уртага куеп, артыннан Хаҗим хан йөрде. Шул рәвешчә олуг юл илән Өргәнечкә килделәр. Кимә ул вакытта Өргәнеч илән Вәзирнең арасында йөрер иде. Кимәдән үтеп, Дарун вилаятендә Динмөхәммәд солтан катына барды.

## Динмөхәммәд солтанның Габид хан илән орышканы

Хаҗим солтан килгәннән соң, барчалары, утырып киңәшеп, Өргәнеч өстенә йөрделәр. Күрдишкә килеп җиткәч, Хозыр иленең Әдаклысының яхшыларын чакырып: «Без йорт эзләп барабыз, — диделәр. — Әгәр безгә ярдәм бирсәңез, Тәңре Тәгалә йортны безгә мөсәххәр кылса, сезне тархан кылып, сул якта урын бирербез, яхшыларыгызны нөкер кылырбыз. Ни булса да, үзбәкнең яхшы ыругларының берсе сез буласыз», — диде. Хозыр халкы бу сүзне җан-тән илән кабул итеп, ике арада гаһеднамә языштылар.

Хозыр халкының Әдаклысы бер мең кеше вә ике мең кеше үз нөкерләре ике тарафтан җөмләсе өч мең кеше илән Пишкяһ килделәр. Анда утырып, үзара мәслихәт кылдылар. Әгәр Өргәнечкә барсак, Габид хан углы Габделгазиз солтан бар, вә моннан гайре анда барганда, судан үтеп кичмәк кирәк. Судан кичмәк яудан да яманрактыр. Хивада яу да юк, су да юк, дип, Хивага килделәр. Хивада бер даруга бар иде биш-ун кешесе илән. Аны тотып үтерделәр. Һәзарасыбның даругасы качып китте. Бу вакыйгатны ишеткәннән соң, Габделгазиз солтан, Өргәнечне ташлап, Бохарага атасы катына качты. Габид хан бу эшкә каты намусланды. Шул вөҗүдтән күп гаскәр җыеп, Өргәнеч өстенә сәфәр кылып, Төя-Муен дигән җиргә җитте. Үзе шул җирдә торып, Углан ыругыннан булган бер бәкне, барча гаскәргә баш итеп, Динмөхәммәд солтан өстенә җибәрде. Ошбу хәбәрне ишетеп, Динмөхәммәд солтан Хивадан атланып каршы чыкты. Барча нөкерләре әйттеләр: «Без өч мең кеше, яу кырык мең кеше, орышмак мәслихәт имәс, кайтып Дарунга китәек, — диделәр. — Габид хан үзе Өргәнечтә тормас, кайтып китәр, без дәхи килербез. Өргәнечкә килмәк Габид ханга мөшкел булса да, безгә асаттыр».

Динмөхәммәд солтан аларның әйткән сүзләренә колак салмады, яуга таба атланып йөри бирде. Барча биләре чабып Динмөхәммәд солтанның алдына чыгып, аттан төшеп, ике-өч йөз кеше: «Кайтаек, харап булырбыз», — дип үтенделәр. Динмөхәммәд солтан моңа һич җавап бирми алга таба китә бирде. Бераз баргач, баягыча янә солтанның алдына чыгып кайтырга үтенделәр. Бу кәррә һәм җавап бирми юлына китә бирде вә өченче кәррә шулай кылдылар. Бу кәррә атыннан төште вә җирдән кулы илән бер уч туфракны йомарлап диде: «Йә Раббым Кәрим! Җанымны сиңа тапшырдым вә тәнемне туфракка тапшырдым! — дип, туфракны күлмәгенең якасыннан куенына салып, урыныннан торып, бәкләренә карап әйтте: — Мин үлдем, әгәр сезләрнең җаныгыз миннән артык булса, орышка бармагыз. Әгәр минем илән тиң бәрабәр булса, минем илән йөрегез, калмагыз», — диде дә янә алга таба атланып йөри бирде. Халкының йөрәкләре кубып вә котлары очып егълаган тавышларына җир-күк тетрәде. Барчалары, ах орып, Динмөхәммәд солтанның артыннан киттеләр.

Бераз баргач, яу бүген Һәзарасыбтан үтеп кунды. Кичне йөреп вә көндезен ятып йөрерләр дип хәбәр булды. Динмөхәммәд солтан ахшам вакытында Кәрден-Хаст дигән җайга барды. Анда бер чокыр күлнең урыны бардыр. Шул орыштан бирле Әшкәст күле дирләр. Анда барып, күлнең көнбатышында аттан төшеп утырды һәм тирә-якка каравыллар куйды. Кич булгач, каравыллар: «Менә яу килде», — дип кайтып хәбәр бирделәр. Шул хәл Динмөхәммәд солтан атланып, гаскәрен икегә бүлеп, бер бүлегенә Суфиян хан углы Йосыф солтан баш булды вә икенче бүлегенә Динмөхәммәд солтан үзе баш булды. Акатай хан углы Хаҗи Мөхәммәд солтан Динмөхәммәд солтан катында йөрде. Әвәниш хан углы Гали солтан сигез яшендә иде. Аны биш-алты яхшы кешегә кушып, бер чит җирдә калдырып әйттеләр: «Әгәр безнең эшебез яман булса, бу угланны алып качарсыз, чырагыбыз сынмасын», — диделәр. Аннан соң Ходага тәвәккәл кылып, юлның ике ягында яшеренеп тордылар. Яу гаскәре килеп үтә башлады. Бирем Углан вә Хафиз Коңгырат башлык-

лар, барча бәкләр бер җирдә килә иделәр. Моны шуннан белделәр ки: утыз-кырык мәшгалә (фанус)[1] ның шәгъләсе бер җирдән чыгар иде. Шулар якын килеп җиткәндә, Динмөхәммәд солтан ике тарафтан ат салып һөҗүм кылдылар. Яу гаскәренең арты хәбәрдар булганчы Бирем Углан вә Хафиз Коңгырат барча бәкләрнең әҗәле җиткәнен үтереп, җитмәгәненең муенын вә кулларын бәйләделәр. Бу вакыйгатны күргәч, Габид хан гаскәре кача башлап, баһадир егетләр шунда йөзәр кешене кулга төшерделәр. Коңгырат ыругыннан Көнтугар баһадир, алтмыш кешене чәнчеп ектым, дир икән. Хаҗим хан әйтер икән: «Орыш көне әүвәленнән ахырынача Динмөхәммәд ханнан һич аерылмадым. Динмөхәммәд хан илән күп гаскәрнең эченә кереп атышып йөргәндә, Динмөхәммәд ханның кулыннан җәясе чәчрәп төште, сугышның гаугасыннан җәянең төшкәнен тоймады. Мин, аттан төшеп, җәяне алып, ханның кулына бирдем. Шунда йөземә карап әйтте, и үкәм[2], синең илән минем арада бу бер сер булсын, диде. Динмөхәммәд хан миннән ике яшь олы иде, шул орышта ул егерме яшендә иде, мин унсигездә идем».

Яу илән сугышып бушаганнан соң, терек төшкән бәкләрне Динмөхәммәд солтан катына алып килделәр. Бу фәлән бәк вә төгән бәк дип, солтанның алдыннан берәм-берәм үткәзә бирделәр. Солтан ат өстеннән карап торганда, бер бәкне алып килделәр. «Бу кем?» — дип сорады. Алып килгән кемсә: «Бу Хафиз Коңгырат», — диде. Аннан соң солтан әйтте: «Син, Хафиз, һәмишә Габид хан алдында Өргәнечне мөселман имәс, кяфердер дир, имеш, син ни сәбәптән безне кяфер дирерсең?» Хафиз җавап биреп диде: «Хәзерге заман мөселманлык илән кяферлек мәгълүм булыр». Моңа солтан һичнәрсә димәде. Хафиз Коңгыратның бу сүзе шул көннән соң үзбәк арасында мисал булып калды. Динмөхәммәд солтан әсир төшкән бәкләрнең барчасын бер җиргә җыеп, Кал хан вә Акатай хан башлыклар илән Мавәраәннәһергә алып киткән илнең мәслихәтен кылдылар. Бәкләр барчасы Өргәнечтән алып барган илләрне вә түрәләрне һәммәсен кайтарып җибәрмәккә ант эчтеләр. Әгәр Габид хан бу сүзебезне кабул итмәсә, җөмлә өебез илән сиңа борылып килербез, диделәр. Бәкләргә ат, тун биреп, гыйззәт вә хөрмәт кылдылар. Хаҗим ханны, син гакыйль егетсең, барып атаңны вә илеңне алып кайтырлык кеше син, булыш, синнән башка кешенең кулыннан килмәс дип, аны тәклиф[1] кылдылар. Ул дәхи кабул кылып, бәкләрне алып, Габид ханның артыннан барып, Бохарада күрде. Габид хан, аны гыйззәт вә хөрмәт кылып, атасын вә илен бирде. Аннан ары Сәмәркандка барып, Җәвәнмәрд ханны күрде, ул һәм шулай кылды. Аннан соң Хисарга барды. Андагы түрәләр Кал хан җөмлә иле илән бирде. Шулай итеп, Хаҗим хан, Кал ханны атасы Акатай хан илән Өргәнечтән Мавәраәннәһердә бер өйлек кешене куймый барчасын күчереп, Өргәнечкә китерде. Бәгъдә барча үзбәк халкы Өргәнечтә иттифак илән Кал ханны хан күтәрделәр.

Кал хан заманында Өргәнеч җире абад вә халык арасында тынычлык булып, биниһая арзанлык булды. Кал хан хан булгач, бер пулга нан булды, диделәр. Берничә ел үткәннән соң, Хак рәхмәтенә китте.

Кал ханның вафатыннан соң Акатай ханны Вәзирдә хан күтәрделәр. Кал ханның ике углы бар иде. Беренең исеме Шәех Мөхәммәд вә беренең аты Шахназар. Ул икесенә Кять вилаятен бирделәр. Фәләк берничә өркелгәннән соң, ягъни берничә заманнар әйләнеп үткәннән соң, Амәнәк ханның нәбирәләре барчасы балигъ булып, егет булдылар. Вилаять, вә ил, вә мал күп булды. Олуг агалары Суфиян ханның биш углы бар иде. Гали исемле углын Солтангазый солтан үтерде. Агиш исемле углы, Хорасанның Хаҗәнд дигән шәһәрен хатынының калынына алып, анда гомер үткәрде. Йосыф исемле углы, кулыннан кан алдырып, каны туктамый вафат булды. Калган ике углының берсе Юныс вә икенчесе Пәхлеванколый исемле иделәр. Буҗага ханның, вә Әвәниш ханның, вә Акатай ханның угланнары барчалары, берегеп, Суфиян ханның бу ике углын Бохарага куаладылар. Аннан соң Кятьта утырган Кал ханның ушандак ике углын Бохарага куаладылар. Аннан соң Акатай хан Вәзирдә торды. Өргәнечне Гали солтан алды, дәхи Мөхәммәд исемле бер яман агасы бар иде. Аны Өргәнечтә куеп, үзе Дарунны алды, Баг-Абадны Хаҗим ханга бирделәр, Нисай вә Абъюрдны Динмөхәммәд ханга бирделәр. Хива вә Һәзарасыбны Буҗага ханның Иш вә Дуст исемле ике углына бирделәр. Шул кәйфиятьчә бүлешеп, үзара тыныч вә фәрагать[1] утырдылар.

Берничә ел үткәннән соң, Суфиян ханның углы Юныйсның алган хатыны Исмәгыйль би дигәннең кызы иде, ул вакытта Мангытның бәге ул иде. Юныс Бохарадан кырык кеше илән атланды. «Мангытта каенатам катына барып, Өргәнечне чабармын», — дип, Кятьнең шималь тарафыннан үтеп, Түк кальгасына барды. Ул вакытта ил Өргәнечнең этрафында Вәзир өстендә утырырлар иде. Түктә ил булмас иде. Ул кичне Түктә кунды. Иртә илән Түк кальгасының өстенә чыгып карап, Өргәнечнең кальгасын күрде һәм казакъларына: «Ул күренә торган ни кальгадыр?» — диде. Алар: «Өргәнечнең кальгасыдыр», — диделәр. Юныс әйтте: «Моның кеби намәрдлек[2] булырмы?! Атам йорты күренә торып, аңа бармый, Мангытка китмәк», — диде. Казакълары: «Син ни кылсаң, без шуңа разыйбыз», — диделәр. Аннан соң Өргәнечкә бармакны ихтыяр кылып, ул көн Түктә торып, кояш батканнан соң, җыелып, ярым ахшам вакытында Өргәнечнең кыйбла тарафыннан килделәр һәм, аттан төшеп, җәяү хәндак читенә килделәр.

Ул вакытта Өргәнечнең кальгасын һәр кичне мәшгалә илән өркелеп саклар иделәр. Эчләреннән чыккан казакъларның куркынычларыннан Юныс солтан хәндак читенә килгәндә, мәшгалә илән берничә кеше:

«Кем анда?» —дип килеп җиттеләр. Юныс солтан күкрәгеn җиргә куеп ятты, алар үткәннән соң, кальга төбенә килде. Берсе, агач ташлап, кальгага менде, ул янә берен кальгага тартып алып, ахирел әмер барчасы кальгага менделәр, дәхи Сары Мөхәммәд солтанның йортына килеп, акрынлык илән өенә кереп тоттылар. Ул бер мәшһүр тинтәк кеше иде. Гали солтан кеби яхшы энесе аркасында Өргәнечне җыеп утырыр иде. Юныс солтан илән Мөхәммәд солтан арасында кыйсас[1] кан юк иде, шуңа күрә Юныс солтан, бер-ике кешесен кушып, аны Вәзирдәге Акатай хан катына җибәрде. Аннан соң Өргәнечнең сарты һәм үзбәге Юныс ханны килеп күрделәр, ул көнне үзен хан күтәртте. Армия һәм халык моның килгәнен яхшы күрделәр. Ул Мөхәммәд Тинтәкнең кылган эшләреннән вә сөйләгән сүзләреннән, вә әхлагыннан Өргәнеч халкының һәммәсе туеп вә бизәр булганнар иде. Юныс хан гакыллы вә юмарт, вә гайрәтле, вә хөкеме каты кеше иде. Мөхәммәд Тинтәк, Акатай хан катына баргач әйтте: «Йә ага, ни өчен бикяр[2] ятасың? Торып атлан, Юнысның катында кырык кешесе бар. Өргәнечнең үзбәге минем нөкерем вә рәгаятемдер. Юнысны аннан асатлык илән чыгарырбыз», — диде. Хан халкына киңәште, барчалары атланмакка мәслихәт кылдылар.

Хан мөлаем кеше иде, атланмакка күңеле тартмады, шулай булса да, халыкның сүзен җиргә салмас өчен, атланып Өргәнечкә килде. Юныс хан аңа каршы чыкты. Шәех Нәҗметдин Көбраи Галия әл-Рәхмәти зыярәтенең мәгъриб тарафында орыштылар. Яз көне төш вакыты иде. Юныс хан галиб булды. Акатай хан качып китте. Юныс ханның Касыйм атлы бер углы бар иде, Акатай ханның кызыннан туган иде. Нөкерләре илән качып барган ханны куып, артыннан җитеп, бабасына сәлам биреп әйтте: «Бу эссе вакытта ни җиргә барасыз? Дәрәхт[3] күләгәсенә төшегез. Бу көн монда торыгыз, сабах булгач китәрсез», — диде. Хан әйтте: «Атаңның эче казан күтеннән карарактыр. Миңа яхшы кылыр булсаң, тимәгез», — диде. Касыйм солтан әйткән сүзен өч-дүрт мәртәбә кайтарып әйтте. Акатай хан һәр сүзенә ошбу җавапны бирде. Касыйм солтан ханның кайтмасын белгәч, килеп, бабасының аты башыннан тотып, ихтыярына куймый шәһәргә алып кайтып, әрбабның[4] өенә төшерде. Моннан гарыз бу иде ки: ханны әрбабның өендә үтерде дигән аваз чыкса, Өргәнеч сартының барчасы Акатай хан угланнары илән канлы булсын, моннан аерылмасын дип, бу хыялга китте.

Әрбабның исеме Сөләйман иде. Юныс хан Акатай ханны Сөләйман әрбабның өендә тотты, дәхи Вәзирдәге угланнарына кеше җибәрде. «Атагыз карт кеше, эссе көндә ат өстендә чапканда эче авыртып ятар, җибәрәм дисәм, мине авыру хәлемдә юл мәшәкатенә салма, углым катында булмасам да, нәбирәм катында ятармын, дидер. Сезгә мәгълүм булсын дип, ошбу кешене сезгә җибәрдем», — диде. Ун-унбиш көнгәчә, ханның эче авыртадыр дип, катына һичкемне кертмәде. Бер кичә Юныс хан өч-дүрт кешегә өйрәтте Акатайның кулын вә аягын бәйләп, таякны артыннан җибәреп болгагыз, үлгәнче шулай кылсагыз, тәненең һич җирендә күгәргән вә каралган җире булмас, фәкать артыннан кан килер, эче авыртып үлгәне раст икәндер, дирерләр. Теге кешеләр боерылганча эш кылдылар.

Иртә таң илән Юныс солтан, Акатайның үлеген арбага салып, Вәзиргә угланнарына җибәрде. Акатай ханның алты углы бар иде. Олугы — Хаҗи Мөхәммәд, икенчесе —Мәхмүд, өченче — Пулад, дүртенче — Тимер, бишенче —Аллаколы, алтынчы — Сөләйман. Акатай хан шәһид булганда, Хаҗи Мөхәммәд илән Мәхмүд Хорасанда Баг-Абадта иделәр. Дүрт углы үзенең катында иде. Ике углына ханның шәһид булганын әйтеп кеше җибәрделәр. Бу хәбәрне ишеткәннән соң, икесе атланып Вәзирдәге энеләренә атлансыннар, фәлән көнне Өргәнечтә күрешермез, дип, кеше җибәрделәр. Хаҗим хан Өргәнечнең көн тугышында Фатыйма хатын тугаеннан Аму дәрьясын үтеп йөрде, Вәзирдәге угланнары һәм атландылар. Юныс хан, моны ишеткәч, кичә илән Өргәнечтән чыгып, Бохарага качты. Янында нөкере калмады, һәркайсы теләгән тарафка киттеләр.

Юлда барганда, углы Касыйм солтан атасыннан адашты, атасы тугры Бохарага китте; углы кич йөреп иртә илән бер куе камышның эченнән бара иде, сулы вә чоңгыллы җиргә чыкты. Шул вакыттан бирле ул җирне Хан чоңгылы дирләр. Бурлу кыры илән Кулгыйның арасындадыр. Ул көн анда ятты, янында бер кешесе бар иде, аңа әйтте: «Бер җирдән азык алаек, юкса моннан Бохарага азыксыз ничек барырбыз», — диде. Нөкере әйтте: «Син монда утыр, мине һич кеше танымас, илгә барып, азык алып киләем», — дип атланып китте. Дәхи Өргәнечкә Хаҗим хан алдына килеп, Касыйм солтанның чоңгыл эчендә калганыннан хәбәр бирде. Хаҗим хан, шул сәгать кеше җибәреп, тотып китереп үтертте. Суфиян ханның угланнары барчасы үлде, һич нәселе калмады. Әвәниш хан угланнары Хорасанда булдылар. Акатай хан угланнары Өргәнеч илән Вәзирдә булдылар.

Буҗага ханның угланнары Иш вә Дуст Бурум исемлеләр Хива, вә Һәзарасыб, вә Кятьтә булдылар. Дустны хан күтәрделәр. Фәкыйрь вә дәрвиш мәшрәб[1] кемсә иде. Энесе Иш яуга баһадир нөкердән малын аямас, гакылы урта, мөселманлыгы аз, гайрәте Ходадан вә ниһаятьтән тыш иде, һәмишә кылган эше кешенең хатынына вә кызына карамак иде. Үзе тирәсендә якын булып йөргән яхшы кешеләренең хатынына вә кызына күңелен мәел кылдырыр иде. Иш солтанның хәтере өчен агасы Дустны хан кылдырдылар. Хива — агамныкы, миңа Өргәнечне бирегез, дип теләде, әмма бирмәделәр. Иш солтан, Хивадан ләшкәр тартып,

Өргәнеч өстенә атланды. Комкальга якынында Җүнүк дигән җирдә Хаҗим хан илән орышты. Хаҗим ханның гаскәре күп, Иш солтанның аз иде. Иш солтан аркасын дәрьяга биреп, бер ягына арба тезде. Сигез көн орыштылар, һичкайсы галиб булмады. Иш солтан әсир төшкән уйгур илән найманны газап кылып үтертте, гайре әсирләргә ат, тун биреп, сыйлап җибәрде.

Ахирел әмер солых кылдылар. Хаҗим хан Өргәнечкә кайтты вә, Иш солтан Хивага кайтып, уйгур илән найман халкын куалады, аларның урынына дурман халкын тәгаен кылды. Берничә вакыт үткәч, дәхи атланып Өргәнечкә барды. Хаҗим хан энеләре илән каршы чыгып, Түк кальгасы илән Өргәнеч арасында орыштылар. Иш солтан янә әүвәлге кеби арба алып барып күрән тартып орышты. Бер һәфтә орыштылар, һичкайсы галиб килмәде. Иш солтан бер кичне атланып Хаҗим ханга белдерми Өргәнечкә барып керде. Шәһәрдә сарттан башка кеше юк иде. Акатай хан угланнары Вәзиргә бардылар. Иш солтан Өргәнечтә утырган уйгур илән найманның малын талап, бала-чагаларын Вәзиргә куалады вә алардан гайре халыкка тимәде, ихтыярларына куя бирде. Ике солтан ике җирдә бер-берсе илән яу булып тордылар. Аннан соң һәр икесе Гали солтанга кеше җибәреп чакырттылар. Солтан Нисайдан иде, кеше баргач, атланып Хаҗим хан катына барды. Акатай ханның Гали солтан углы илән Динмөхәммәд хан угыллары вафат иде. Калган углы Әбел солтан Хаҗим ханга кушылып, барчалары килеп Өргәнечне камадылар. Дүрт ай булганда сәхәр вакытында кальгага йөгереп менделәр. Иш солтан атлы вә нөкерләре пиядә иделәр. Яуга каршы йөреп барганда дурман халкыннан Тингали дигән күптәнге нөкере бар иде. Аның бер кыз сеңлесе булып, Иш солтан ул кызны көчләмеш иде. Шуның кинәсе Тингалинең күңеленнән чыкмаган иде. Яу кальга өстенә менде. Иш солтан, кальгага якын килгәндә, Тингали солтанны ук илән атты. Угы атның сагырына тиде. Ат дулап, ахры егылды. Атның дулаганында, диварларга вә тамларга орып аягын сындырды. Солтанның нөкерләре моны күреп, һәркайсы бер якка качтылар. Хива халкыннан Хакколый Пәһлеван дигән бер көчле баһадир — яхшы егет бар иде. Иш солтан аны тәрбия кылып, һаман үзе илән бергә алып йөрер иде. Янында Хакколый Пәһлеваннан гайре кеше калмады. Ул солтанны егылып яткан җирдән күтәреп утыртты, сынган аягын суздырып ипләп куйды. Ул вакытта яу килде. Хакколый баһадир солтанның янындан китми үлгәнче сугышты. Ахирел әмер Хакколыйны һәм Иш солтанны шунда үтерделәр. Агасы Дуст хан Хивада иде, кеше җибәреп аны һәм үterттеләр. Иш солтанның ике углы бар иде. Олугының исеме Шахколый вә кечегенең исеме Таһир. Аларны Бохарага җибәрделәр. Анда баргач, икесе һәм вафат булдылар. Буҗага ханның өч углы бар иде, өчесеннән һәм нәсел калмады. Бу вакыйгалар тарих һиҗри илә тугыз йөз алтмыш биштә вә Елкы елының ахырында булды.

Шуннан соң Хаҗим ханны хан күтәрделәр. Ул вакытта утыз тугыз яшендә иде. Вәзирне һәм аңа бирделәр. Өргәнеч, вә Һәзарасыб, вә Кятьне Гали солтанга бирделәр. Ул вакытта Акатай ханның Аллаколый вә Сөләйман исемле ике углы вафат булып, дүрт углы терек иде. Исемнәре Хаҗи Мөхәммәд вә Мәхмүд, бу икесе бер анадан туып, Пулад илән Тимер дигән дәхи икесе бер анадан туганнар иде. Мәхмүд солтан Хаҗим хан янында Вәзирдә торды. Пуладка Хиваның ярымын вә төрекмәннән Олуг Түбә вә Күниш вилаятьләрен бирделәр вә Тимергә Хиваның ярымын вә Төрекмәннән Карабүкәвел дигән җирне бирделәр. Шул рәвешчә бүлешеп, үзара тыныч утырдылар.

## Динмөхәммәд солтан бәяны

Кал ханны хан күтәргәннән соң, Динмөхәммәд солтанга Нисай илән Абъюрдны бирделәр. Динмөхәммәд хан бер җирдә тыныч утыргандай кеше имәс иде, һәмишә кызылбашны чабар иде. Ул сәбәптән Шаһ Таһмасыб аның өстенә гаскәр җибәрде. Динмөхәммәд хан Нисайда иде. Килгән гаскәр Абъюрдны алып, хаким куеп кайтып китте. Динмөхәммәд хан бу эштән хафаланып, үзе Казвинга Шаһ Таһмасыб хозурына барып, мәзкүр вилаятьне кайтармакка теләде. Әмма Шаһ Таһмасыб кайтармады. Анда алты ай калып, морады хасыйл булмагач, бер мөһер язучыдан Шаһ Таһмасыб исеменә мөһер яздырды һәм Абъюрд хакименең исеменә фәрман яздырды. Ошбу намәне алгач та Абъюрдны Динмөхәммәд солтанга тапшыр, аны аңа ингам кылдык, дәю. Шаһ Таһмасыб ауга киткәндә, Динмөхәммәд солтан бер кичә атланып йортына кайтып китте. Шаһ Таһмасыбка аның киткәненнән хәбәр биргәч, үзе килгән иде һәм үзе китте, диде, гайре сүз әйтмәде.

Динмөхәммәд хан Абъюрдка килде. Намәне хакимнең кулына бирде. Хаким дәрвазәне ачтырды, ул барып өенә төште. Кич ятып, сабах дәрвазәгә кешеләр тәгаен кылды һәм кызылбаштан бер кеше куймый барчасын үтерде. Абъюрдта төбәп утырды. Шаһ Таһмасыб, бу вакыйгатны ишеткәч, олуг ләшкәр илән атланып Динмөхәммәд хан өстенә йөрде. Динмөхәммәд хан шаһның килгәненнән хәбәрдар булып, якын киләрәк кырык-илле кеше илән атланып шаһка каршы китте. Шаһ ул вакытта, Мәшһәднең шималь тарафында бер Кара Су булыр иде, анда килгән иде. Каравыллар, Динмөхәммәд ханны күреп, шаһка хәбәр бирделәр.

Шаһ ышанмады, бер каравыл барды, аңа һәм инанмады, янә бер кеше килде: «Менә Динмөхәммәд солтан ишек алдына килеп җитте», — дигәч, шаһ чатырының бусагасы төбендә каршы очрады. Динмөхәммәд юлын тотты, җибәрмәде. Шаһ бер кулы илән муенын тотып вә икенче кулы илән күлмәгенең якасын тотты, йөрәге һич типмәде. Ханның йөзенә карап: «Йөрәгең таштан һәм карадыр», — диде. Шаһ, сәламәт калганына шатланып, ул көнне олуг бәйрәм итеп, иртәсе көн күп ингамнар кылды вә, Абъюрдны сиңа кайтарып бирдем вә кылган эшләреңне барчасын кичтем, дип озатып җибәрде, үзе Казвинга кайтты.

Динмөхәммәд ханның дәхи бер кылган эше будыр: Мәрвә илән Шаһ-Җиһан вилаятьләрен Габид хан Найман ыруглык Юлым би дигән кемсәгә биреп иде. Габид ханга Юлым би турысыннан гайбәт кылдылар. Ханның моннан хәтере калып, аны ничә мәртәбә хозурына чакыртып, кеше җибәрде. Юлым би куркып бармады. Хан аның килмәсен белгәч, тотып алып килегез, дип, аның өстенә утыз мең кеше җибәрде. Гаскәр Мәрвә өстенә килгәннән соң, Абъюрдка Динмөхәммәд ханга Юлым би кеше җибәрде. «Әгәр моны бу бәладән коткарса, Мәрвә аныкы булыр», — диде. Динмөхәммәд хан, бу сүзне ишеткәч, Абъюрдтан атланды һәм Мөргаб суының аягына килде, дәхи хөкем кылды ки: «Һәр кеше дәрәхтләрдән өч шах[1] киссен, икесен ике якка баглап, берсен атның койрыгына багласын һәм һәр кеше йөргәндә чәчелеп берәм-берәм йөрсен», — диде. Мәрвәнең җире йомшак иде, каравылларга әйтте: «Бу көн яуның каравылларын, ерак булса да, барып күрегез», — диде. Ул көнне аз гына йөреп кунды. Каравыллар яуның каравылын күреп килде.

Иртәсе көн күчеп дәхи аз гына йөреп кунды, яуның каравыллары барып әйттеләр: «Динмөхәммәд хан олуг гаскәр илән акрын-акрын күчеп киләдер». Моны ишеткәннән соң, яу тарафы Динмөхәммәд ханның гаскәр куәтен белергә кешеләр җибәрделәр. Ул кешеләр төнлә илән бик күп урыннарда Динмөхәммәд ханның каравыллары вә гаскәрләренең төрле җиргә куйган утларын күргәч, бик күп ләшкәр илән киләдер дәю яу гаскәренә кайтып әйттеләр. Бу сүзне ишеткәннән соң: «Эчебездә — Юлым би яу вә тышыбызда Динмөхәммәд хан, ике яуның уртасында ничек утырырбыз?» — дип күчеп, Бохарага качтылар. Динмөхәммәд хан Мәрвәгә барып падишаһлык кылып утырды; үзенең табигате яуга баһадир, юмарт, һич мал саклый белмәс иде. Нөкергә миһербанлы вә һәркемгә тәвазыглы иде. Бәгъзе вакытта холкы диваналарга охшар иде. Аның кылган эшләрен күзе илән күрми ишеткән кеше инанырлык түгел иде. Тарих һиҗри тугыз йөз алтмыш вә Сыгыр елында Мәрвә шәһәрендә кырык яшендә вафат булды.

Аның ике углы бар иде. Олугының исеме Баинда Мөхәммәд вә кечегенең исеме Әбү Әлмөхәммәдтер. Атасы аны үзеннән соң хан булырга тәгаен кылып, ул сәбәптән атасы терек вакытында вә Әбү Әлхан дирләр иде. Баинда Мөхәммәд солтан гакылсызрак кеше иде. Беркөн атасы күренешханәдә утырган вакыт килеп әйтте: «Минем яшем Әбү Әлмөхәммәдтән олуг, аны хан дирләр, мине солтан дирләр, бу ләкабләрне сезнең хөкемегез илән әйтәләрме яки үзләре әйтәләрме?» Хан бу соальгә һич әйтеп җавап бирә белмәде. Ханның янында бер яхшы бәк бар иде, Торумчы исемле, төрекмәннең Лайна ыругыннан, бинииһая гакыллы кеше иде. Аның әйткән яхшы сүзләре бик күптер. Ул әйтте: «Моның турысын, падишаһым, мин бирәем», — дигәч, хан: «Яхшы, мәгъкуль, шулай ит», — диде. Торумчы Баинда солтанга карап әйтте: «Сезне Ходай Тәгалә дөньяга җибәргәндә, атагыз солтан иде, энегез дөньяга килгәндә, атагыз хан иде. Кешенең атасы ни дәрәҗәдә булса, углы шул дәрәҗәдә булыр. Солтаннан туганны солтан дирләр вә ханнан туганны хан дирләр». Бу җавап ахмакка мәгълүм булып, урыныннан торып китте. Ул һәм атасыннан соң тиз заманда вафат булды. Баинда Мөхәммәд солтанның бер углы бар иде. Торсун Мөхәммәд исемле, Мәрвәдә падишаһ иде. Хәтсез булдыклы егет иде, егерме өч яшенә җиткәндә, үз нөкерләреннән берничә кеше кич ятканда урынына кереп, пычак илән чәнчеп үтерделәр, бала-чагасы юк иде.

Әбү Әлмөхәммәд хан, атасы вафатыннан соң, Мәрвәдә хан булды. Җәлал исемле бер углы бар иде. Ул, Хорасан өстенә гаскәр илә барып, дүрт тарафны чабарга җибәреп, үзе Мәшһәд өстендә егерме көн торды. Барча Хорасанның кызылбаш гаскәре Мәшһәдкә җыелды. Шәһәрнең шималь тарафында Кара Суның ягасында ике ләшкәр орышты. Кызылбаш галиб булды. Җәлал солтанның ун мең үзбәге илән башын кистеләр. Әбү Әлмөхәммәд ялгыз, улыннан аерылгач хаста булды, ни хаста икәнен һичкем белмәде. Мәшһәдтән бер табиб китерделәр, ул әйтте: «Хан бер углыннан аерылганы кайгысыннан хаста булып торыр, әгәр яңадан бер углы булса — сәламәтләнер, углы булмаса — сәламәтләнмәс», — диде. Халык әйтте: «Фәрзәнд көч илән йә мал илән була торган нәрсә имәс». Шулай булса да бер кылдылар.

Мәрвәдә бер хатын бар иде, Бибичә исемле. Хатыннар арасында дәф[1] кагып вә нәкыш итеп йөрер иде, һич иргә барганы юк иде, дүрт яшәр углы бар иде. Углын бәкләрнең алдына алып килде дә әйтте: «Бер кичә хан миңа нәкыш иттергәндә мәел кылды, аннан хамилә булып, бу угланны тудырдым. Бу вакыткача ханның харәмнәрендәге хатыннарыннан куркып әйтергә кыймый идем», — диде. Бәкләр угланны табибка тапшырдылар, табиб аны хан катына алып барды. Хан ул вакытта кешене яхшы танымый иде. Табиб угланны һәм ханны икесен дә ялангач кылып, угланны ханның куенына салып, өсләренә юрган ябып яткырды, дәхи ханга кычкырып әйтте: «Бу синең углыңдыр!» Һәр көнне өч мәртәбә шул кыяфәтчә ханның янына салып

кычкырыр булды. Хан моңа ышанып, күңеле шат булып, сәламәтлеге артты, аны үзенә угыл кылып, Нурмөхәммәд дип исем куйды.

Ул егет булгач, Әбү Әлмөхәммәд вафат булды. Әбү Әлмөхәммәднең вафатыннан соң Нурмөхәммәдне хан кылдылар. Ул берничә ел падишаһлык кылды. Аның заманында Хаҗим ханның энеләре вә угланнары Өргәнечтән барып, Мәрвәне чабып: «Син лүли[2] бәтчәсе, ничек син безем карендәшебез буласың?» — дип, күп битәрләр булдылар. Нурмөхәммәд хан, бу иһанәткә[3] чыдый алмый, Бохарага Габдулла ханга барып, Мәрвәне тапшырды. Габдулла хан, Нурмөхәммәдне алып, олуг гаскәр илән атланып Мәрвәгә килде. Нурмөхәммәднең максуды бу иде ки: Габдулла хан, Мәрвәне алып биреп, мине яңадан утыртып, Габдулла хан исеменә хотбә укып торсам, Хаҗим ханның энеләре вә угланнары миңа тимәс дип уйлады. Әмма ул дигәнчә эш булмады. Габдулла хан Мәрвәне алганнан соң, Нурмөхәммәд, үз җаныннан куркып, бер кичә качып, Өргәнечкә Хаҗим хан катына барды. Аның бәгъдендә Хаҗим хан илән кызылбаш өстенә барып, биш ел кызылбашта торганнан соң, Габдулла хан вафат булды. Нурмөхәммәд хан, килеп, Мәрвәне алды, үзен мөкатдәмдә хан күтәргән үзбәк халкын кырып, сарт илән төрекмәнне үзенә якын рәгаять итте. Моны ишеткәннән соң, кызылбаш падишаһы Шаһ Габбас Мазый, килеп, Мәрвәне камады. Нурмөхәммәд хан кырык көннән соң чарасыз, чыгып, Шаһ Габбасны күреп, аман теләде. Шаһ Габбас Мәрвә, вә Абъюрд, вә Нисай, вә Дарун — барчасы Нурмөхәммәдкә тәгаллекъле иде. Һәммәсенә хакимнәр тәгаен кылып, үзе кайтып китте. Нурмөхәммәдне һәм үзе илән алып китеп, Ширазда бер мөхкәм җирдә тотты. Шунда вафат булып, аннан һич нәсел калмады.

Әвәниш ханның ике углы бар иде. Олугының исеме Динмөхәммәд вә кечесенең исеме Мәхмүд иде. Аны һәм Сары Мәхмүд солтан дирләр иде. Бинигһая тинтәк, вә гайрәтсез, вә намуссыз, куркак кеше иде. Яхшылыктан аңа Ходай Тәгалә дөррә кадәрле нәрсә бирмәгән иде. Шуңа күрә Сары Мәхмүд дирләр иде. Амәнәк хан әүлядыннан бу вакыткача ирдән вә кыздан аның кеби мәгънәсез кеше булганы юк иде. Ул нәпакь беркөн күп халык илән буза эчеп утырганда, бер кеше, килеп: «Менә яу килде», — дип хәбәр бирде. Барча халык атка вә коралга йөгереп киттеләр. Ул, йөгереп килеп, хәмнәрдә торган бузага пычак илән билгe сала, имеш, бу хәмнең бузасы бу билгедә вә теге хәмнең нишанәсе ул нишанәдә, дип, өй иясенә тапшыра, имеш. Ул вафат булды, нәселе калмады.

Әвәниш ханның кече углы Гали солтан тау буенда, Нисай, вә Абъюрд, вә су буенда Өргәнеч, вә Һәзарасыб, вә Кять аның кулында иде. Ошбу су буе илән тау буенда булган түрә-караның ихтыяры һәм солтанның кулында иде. Һәр елны хутның[1] башында Өргәнечтән атланып, Хорасанны чабып, җәйләкләрдә җәйләр иде. Чаба торган җирләренең чите Бил-Күпри, Тәршиз, Тирит, вә Җам, вә Хәркерд иде. Алган вилаятьләре Җөрҗан, аның пайтәхете Көбүд-Җама дирләр, Җачарам, Керәйлү, Астрабад, гаскәре кырык меңгә җитәр иде. Көз гакрәб[2] булганда, кайтып, Өргәнечтә кышлар иде. Атланып чыга торган күп үзбәкнең барчасының исемен дәфтәргә язып, галәф[1] бирер иде. Җәяүле нөкеренә уналты куй бирер иде. Төрекмәннең куен аларга өләштерер иде. Җитмәгәненә, Хорасанны чабып, егерме биш куйдан берне бирер иде. Бер елны аз гына кеше илән Уклы-Күкләннән бер ат алырмын, дип, Астрабад барып вә нөкерләрен җибәреп, бер ат алмак илән мәшгуль булды.

Инде кызылбашны әйтәек. Шаһ Таһмасыб «һәр елда Гали солтан фәләнчә вилаятьне килеп чапты» дигән сүзне ишетер иде, ләкин илтифатына алмас иде. Ошбу ел кыш Бәдерхан дигән бәгенә унике мең нөкер алып, Хорасанга барырга әмер кылды. Әгәр Гали солтан килсә, аның илән йөзмә-йөз булып сугыш, әмма бу сүзне ат өстенә менгәнче һичкемгә әйтмә. Гали солтан ишетмәсен, диде. Бәдерхан атланып Бистамга килде вә ишетте ки: Гали солтан аз гына гаскәр илән килеп, Астрабадта төрекмәннән бер ат алып торыр, һәр нөкере төрекмән иле эчендә таралып, солтан катында һич кеше юк, имеш, дип, тизләп Астрабадка килде, кызылбашның гаскәрен күреп, солтанга хәбәр бирделәр. Кызылбаш унике мең кеше булып, солтанда өч мең кеше иде. Хәбәрне ишетмәге илән атланып Күргән суының якасына килде. Мин, фәкыйрь, ул суны үзем күрдем, ике ягы яр булыр, бәгъзе җирләре йөз кыры булыр, фәлән кадәр вә төгән кадәр дигән кадимдә чабып ясалган кичүләре булыр. Гали солтан бәләнд ярның читенә гаскәрен төшерде, яр тарафына һич кеше төшерми, анда дүрт-биш хилкага бүлеп, куышын төшерде. Яр читеннән бер олуг юл калдырды, дәхи куышның тышкы ягыннан ат йөгерә алмастай дүрт үр казытты. Атларны вә төяләрне мөхкәм бәйләтте, шул эшләрне тәмам иткәч, кызылбаш һәм килеп җитеп орыша башлады. Һәр тарафтан биш йөзләп вә бер меңләп төп-төп булып чапты. Үзбәк пиядә йөгереп укны ата бирде, әмма кызылбаш һич дүрт үрдән үтә алмады, һәркайчан кызылбаш чапса, үзбәк каршы йөгереп орып кайтарыр иде. Кызылбаш тарафы мылтык атканда, куышка кереп, төянең ышыгында утырды. Кызылбаш моннан гаҗиз булды.

Уклы халкының Ababәк исемле бер бәге бар иде. Ул зат ун бәге вә иленең атаклылары илән бары өч йөз кеше булып, солтанны күрмәккә килеп иде. Гаскәрнең урта җирендә тигез җирдә атларын тотып утырыр иде. Абабәк солтанга барып гарыз кылды ки: «Орыш һәр ике тарафта бәрабәр булды, вәләкин сездә атлы кеше булмадыктан, кызылбашны качканда куалап булмыйдыр, шуңа күрә кызылбаш һич каушамый

үзенең урынына кайтып утырадыр. Әгәр миңа рөхсәт бирсәң, бер тарафтан атланып орышаем», — диде. Солтан рөхсәт бирде. Абабәк атын менеп, дәрвазә куйган җирдән чыкты. Абабәк солтаннан рөхсәт алып кайткач, һәр кеше солтанга әйттеләр: «Аңа нә өчен рөхсәт бирәсез? Безне аз күреп, кызылбашка кушылырга бара», — диделәр. Солтан әйтте: «Кызылбаш унике мең кешедер, хуш, өч йөзе артык булсын, үзе килгән кешегә яманлык кылмак — намәрд[1] кешеләрнең эшедер. Мин үземне Ходайга тапшырдым». Абабәк атланды һәм кызылбашның бер тарафы илә сугыш башлады. Кызылбаш өстенә каты һөҗүм кылганда, үзбәккә таба чигенде, әмма кызылбаш чигенгән вакытта артларыннан куып атып чаба бирде. Биш-алты мәртәбә шулай кылгач, орыш кызып китте. Үзбәкнең барчасы төрле җирдән сугыша башладылар. Абабәк кызылбашның артына әйләнде, үзбәк йөреп орыша-орыша Исауга — гаскәрнең мәркәзенә җитте. Абабәк арттан, үзбәк алдан «Алла! Алла!» дип, кызылбашка аралашып китте. Кызылбаш тәкать кыла алмый качты, төяләрен үзбәкнең пиядә гаскәрләрен алып, аларның артларыннан атланып көн батканчы кудылар. Кызылбаштан Бәдерхан башлык илән качып бик аз кеше хәляс[2] тапты. Солтанның атлар караучысы әйтер икән: «Солтанга ганаимнан[3] тигән атның тугыздан берен алыр идем. Шул сәфәрдә мин җиде йөз ат алдым. Башка өлҗәне шуннан кыяс[4] кылыныр».

Бу вакыйгаттан унбиш-уналты ел үткәч, Гали солтан Өргәнечтән көзнең башында атланып Хорасанның Хаҗәнд җилкәсенә барып кышлады. Моннан нияте — язны барып, Гыйракны чапмак иде; Таһмасыб килсә, орышмак булды. Олуг челләнең эчендә гаурәт җиренә көйдергеч чыкты, моны кешегә әйтмәде. Вакыты үткәннән соң, аяктан егылды. Халык, авырткан җирне күрик, дисәләр, күрсәтмәде, зирәки шулкадәр оялчан иде ки, гомере эчендә тәһарәт кылганын һичкемгә күрсәтмәде. Аннан соң халык, киемегезне кисеп күрәек, дип әйттеләр. Аңа һәм разый булмады, бәгъдә ихтыярына куймый, тәнен ачып күрделәр, ут кутыры, имеш, дару кылып карасалар да, файда бирмәде. Аның өчен вакыты үтеп киткән иде. Шул мәризы[5] илән Хак рәхмәтенә китте. Тарих тугыз йөз җитмеш алтыда, Сыгыр елында кырык яшендә иде. Солтанның тарихын бер шагыйрь бу нәзым[1] илән әйтмештер. Кыйтга[2]:

> Бар дөнья беләдер ки Гали солтанның бөеклеген,
> Кылычы аның кояш нурыннан иңгән,
> Ә Шаһ Таһмасыб өчен ул иң куркыныч әйбер.
> Падишаһыбыз дөньяга килгәч тә
> Бик күп бәлаларгә тарган.
> Кызылбашларны җиңү юлында ул
> Ун хан эшли алмаганны башкарган.

Гали солтан яхшы кеше иде. Хаҗим хан әйтер икән: «Ядгәр хан заманыннан бу вакыткача Гали кеби кеше туганы юк иде», — дип. Күркәм холыклы, мөлаем сүзле вә яуга баһадир вә юмарт, эшнең башына чыгучы, нөкернең әхвәленә яхшы карый торган гадел вә сәясәтле, вә бәдәнле һәм тыйнак иде. Тыйнаклыгы шулкадәр иде ки, үлгән вакытта атасы урынында торган Атабай дигән, җаны бар микән, юк микән дип караганда, кулын юрганның өстенә салып, аягын тотты. Үләр вакытта күзен ачып әйтте, үлмәстән мөкатдәм абруемны вә хәямне китәрмә, диде. Вә гадәләте мондый иде ки: Хорасанга атланып барганда, тугчының[3] гаскәр күчкәндә аты югалмыш. Энесе атны эзләмәккә йортка кайтып барганда, бер куышта, кучкарның яткан башын күреп, аны алып янына бағламыш, гаскәр кайтып килгәндә, бер кеше, аны танып дәгъва кылып, солтанга гарыз кылыптыр. Теге кеше йорттан таптым димеш, кучкар иясе аның куышыннан алдым башны солтанга алып килмеш. Солтан аны шуның өчен асып үтермәккә әмер кылмыш. Бер кәррә солтан фализ, ягъни багның янынннан үтеп барганда, бер нөкер, аттан төшеп, бакчадан ике кавын алмыш. Кавынның иясе, йөгереп барып, солтанга гарыз кылмыш. Солтан шул җирдә торып, нөкерне китертеп, бер олуг агачны утыртып, аны шуңа астырып, җаны чыкканнан соң китмештер.

Гали солтанның ике углы бар иде: олугсының исеме Искәндәр вә кечегенең исеме Сәнҗәр. Искәндәр атасыннан соң алты айдан соң вафат булды. Сәнҗәр диванарак иде, шулай һәм булса Найман ыругының Колмөхәммәд би хезмәт иткән солтанның углыдыр дип, Нисайда падишаһ кылды. Солтанны сигез көндә бер халык әхвәлен белмәсен өчен күренешханәгә чакырыр иде яки үзе солтан катына кереп чыгып, солтан мондый сүз вә тегенди сүз әйтте, дип әйтер иде вә гяһ солтанның ышанычлыларының берсенә өйрәтер иде. Шуннан соң Колмөхәммәд би үзенең миһманханәсендә утырганда, солтан теге өйрәткән фәрманнарны болай дип әйтер иде: «Ата-бәк, мин сезгә берничә хезмәт боердым, шуны тәмам иткәйсең, мәсәлән, фәләнгә мең тәңкә ингам кылдым, вә Ходай колына биш мең тәңкә, вә Алла колын шаһка илчелеккә тәгаен кылдым, вә фәләнчә кешеләрне би әйтсен, һәр нәрсә хәзинәдә булса — алып бирсен, булмаганын башка җирдән алып биреп, кыйммәтен диваннан хәвалә кылсын, фәлән гамәлне Ходаи назыйрга бирсен».

Колмөхәммәд бинең Сәнҗәр солтанга кылган эшләрен кайсы берсен әйтеп бирдем, башка эшләрен һәм моңа кыяс кылыныр. Егерме биш ел ошбу рәвеш илән Сәнҗәрне падишаһ кылып утырды, аннан соң Сәнҗәр вафат булып, нәселе калмады.

## Хаҗи Мөхәммәд хан башлык Акатай ханның угланнары

Акатай ханның алты углы бар иде. Олугы — Хаҗи Мөхәммәд хан, икенчесе — Мәхмүд солтан, өченче — Пулад солтан, дүртенче — Тимер солтан, бишенче — Аллаколый солтан, алтынчы — Сөләйман солтан. Аллаколый — егерме ике яшендә, Сөләйман унсигез яшендә үлделәр. Мәхмүд солтан кырык яшендә үлде. Мәхмүднең алты углы калды. Әүвәл — Мөхәммәд, икенче — Амәнәк, өченче — Гали, дүртенче — Мөхәммәд Әмин, бишенче — Гарәб, алтынчы — Акбаба. Амәнәк илән Мөхәммәд Әмин атасыннан соң вафат булдылар вә Мөхәммәд солтанның ике углы бар иде. Кәдехода кылган олугысының исеме Шаһ Гали вә кечегенең исеме Шаһ Бәхет. Бу икене һәм Мәхмүд солтанның калган дүрт углын бер яшьлек, ике яшьлек яшь угланнары илән бергә барчасын Габдулла хан шәһид кылды. Гали солтан вә Гарәб солтанның хатыннары хамилә иде. Ул ике хатынга, кешеләр тәгаен кылып, сакларга боерды. Берсе кыз тудырды, аңа тимәде. Вә берсе угыл туды, шул көнне аны үтертте. Тимер солтан кырык яшендә вафат булды. Өч углы бар иде. Олугысы — Мөхәммәд солтан, икенче — Кадербирде солтан, өченче — Әбелхәер солтан, өчесен һәм Габдулла хан үтертте. Пулад солтанның дүрт углы бар иде. Әүвәл — Баба солтан, икенче — Хәмзә солтан, өченче — Курайҗы солтан, дүртенче — Пәхлеванколый солтан. Пулад солтанның өч углы бар иде. Үзен угланнары илән Габдулла хан шәһид итте. Пәхлеванколый солтан атасыннан биш елдан соң әҗәле җитеп вафат булды.

## Пулад (Булад) солтанның сыйфаты

Пулад солтан гакылсыз вә гайрәтсез тинтәк кеше иде. Бер кечек булганда, аннан күп нәрсәләр нәкыль кылырлар иде. Кылган эшләре халык эчендә тәмам онытылып китмәсен өчен, өч-дүртне нәкыль кылаем. Аның ике гадәте бар иде: берсе — сөйләшкәндә бер сүзне әйтеп, артыннан «шылык-ру» дигән сүзне әйтер иде вә дәхи бере — ике кечек бармагын йомып, урта бармакны баш бармагы өстенә куеп, ике кечек бармагына өреп, шырык-шырык авазын чыгарыр иде. Мәсхәрәчеләр вә талашучылар кылган кеби, ике кулын шулай итеп, «шылык-ру» дир иде, һәр кылган саен бер «шылык-ру» дир иде. Бер кәррә, Хорасанга китә торган кәрван бармы, дип сорады. Төнәгеен китте, диделәр. Бер кеше, хөкем итеп, ул кәрванны барчасын кайтарып алып килергә боерды. Ул кеше Сагча кодыгында кәрванны, артыннан җитеп кайтарып, Хивага алып кайтты. Ул мөселманнарның күңеленә бу килде ки: әлбәттә, солтан Хорасан илән яу булырга телидер, юкса үзгә эш өчен булганда беребезне кайтарса да җитәр иде. Кәрван халкының барчасын солтан алдына алып килделәр, солтан, йөзләренә багып, кулларын шырык-шырык итеп: «Миңа бер үткен пәке шылык-ру», — дип, дүрт-биш кәррә шуны тәкрар итте. Кәрван халкы моны аңламадылар. Солтанның нөкерләре әйтте: «Бер үткен пәке китер, үзгә нәрсә кирәкмәс, дидер, бар, китегез», — диде.

Вә дәхи Габдулла хан Өргәнеч йортына өч мәртәбә килде. Әүвәл килгәндә, ала алмый, Яңа Арыктан кайтып китте. Габдулла хан Яңа Арыкта торганда, яшь егетләрдән биш йөз кеше каравылга тәгаен кылынып, ул көнне Габдулла ханның каравылы илән сугышмак булып атланып китеп торганда, Пулад солтан: «Мин һәм барырмын», — дип атланмыш. Энесе Тимер солтан: «Егетләргә кушылып кайда барасың, кайт!» — дип мәнгы кылмыш. Барча бәкләр һәм: «Барма», — дигәннәр. Аларның сүзен кабул итми, бергә китмеш. Каравыллар илән орышканда галиб килмешләр. Орыш кызганнан соң, аерыла алмый, яуның ярдәме күп килгәч, качмышлар. Пулад солтан, һәммәдән элгәре качып килеп, аттан төшеп, Хиваның дәрвазәсендә бусаганың өстенә менеп, ике ботын җәеп: «И, яу! Килер булсаң кил, шәһәргә ничек керерсең икән!» — дип фөрьяд кылыр, имеш.

Өч хатыны бар иде. Олугсының исеме Газизә ханым, Илбарыс хан нәбирәседер. Ул көнне аның өенә килеп, хатыннарына үзенең кылган эшләрен тәгъриф[1] кылмыш. Бу көн яу илән болай орыштым вә тегеләй орыштым, инде иртәгә болай итәрмен вә болай итәрмен, диде. Газизә ханым, бу сүзләренә ят хатыннардан оялып, җитәр, куй, сөйләмә, димеш. Солтанның моңа ачуы килеп сүкмеш. Ханым аңа каршы сүз кайтарган. Солтан, пух җыйма, кыргый дуңгыз, димеш. Ханым, дуңгызның ире кабан булыр, димеш һәм, бер чыбык илән кизәнеп сугыйм дигәндә, солтан урыннан торып качып китәем дигәндә, егылып үчиге[2] парә-парә булмыш. Бу кадәр әйттем, җитәр.

## Энесе Тимер солтанның сыйфаты

Тимер солтанның гакылы аз, сүзе тозсыз, әмма кылган эшләренең һәммәсе яхшы, яуга баһадир һәм гадел кеше иде. Үлгәнгәчә кеше өенә миһман булып аш җимәде. Бер кәррә Һәзарасыбтан агасын күрмәгә Хивадан килмеш. Пулад солтанның ата урынында торган уйгур ыругыннан Индибай дигән кемсә иде. Пулад солтан хөкүмәте һәммә ихтыяры аның кулында иде. Беркөн аш-су хәзерләп, бер зур мәҗлескә кешеләр чакырып, Тимер солтан агасы Пулад солтан илән күрешеп кайтканда, Индибай, аның алдына чыгып, бер тар күчәдә каршы чыгып, өенә чакырмыш. Солтан ат өстендә һич җавап бирмәмеш. Индибай әйткән: «Бер карт колың мин, бу вакыткача кеше өенә төшмәгәнеңне белермен, мине башка халыктан артык күреп, бәлки, рәхим итәр дип өметем бар иде. Һәммә ерактагы вә якындагы кешеләр әйтсеннәр иде, солтан һич кешенең өенә төшмәс иде, Индибайның өенә төшеп ашын җийгән, имеш», — дип. Ул вакыт кыш көннәре иде. Солтанның өстендә зөбәрҗәт ташлы алтын төймәле кеш туны бар икән, шуны чакырып, ат башчысына биреп, Индибайга тапшырырга боерган. Ул шул сәгать алып, тунны мәзкүр Индибайның аркасына салып, атын камчылап йөреп киткән.

Тимер солтан әйтер икән: «Унбиш яшемә җиткәндә, беркөн биш-ун егет илән атланып, Вәзирнең Оры дәрвазәсеннән чыгып, сәйяр кылып йөрер идем. Бер авылга килдем. Өй иясе берзаман, атыннан төшеп, атланыгыз, дип, өенә алып барырга тәкәллем кылды. Ул кешенең хәтерен калдырмас өчен, барып, өенә төштем. Бер куйны зәбехләп китерде, ул куйның үчәсен[1] атама алып килдем. Атам: «Бу нинди ит?» — дип сорады. Бергә катымда барган кешеләр әйттеләр: «Солтан сәйяргә чыккан иде, бер бай кеше өенә тәкәллем кылып, бер куен суеп кунак итте. Бу шул куйның үчәседер», — диделәр. Шуны ишеткәч, атам, камчы алып, мине «кил бире» дип чакырды вә әйтте: «Минем яшем иллегә җитеп, һич кеше өенә төшкәнем юк. Син исә унбиш яшьтә кеше өенә төшеп куйны җийәсең, егермегә җиткәч, елкыны җийәрсең, синнән ни күрсәләр, нөкерләрең шуны кылырлар», — дип, кешедән тоттырып, үз кулы илән йөз камчы орды. Тәнемнән кан акты. Ак туным бар иде, һәммә җире кызыл кан булды. Аннан соң кайтып, миһманханәдән чыгып бара идем, олуг агам Хаҗи Мөхәммәд хан очрап: «Аманмы син, Тимер, ни хәлең бар?» — диде. Аңа мавакыйгны бәян кылдым. Ул әйтте: «Атаң яхшы эш кылган. Бәрәкаллаһ, инде тәнеңдәге каның юма вә бу ак туныңны чыгарып ташлама. Иртә сабах атаңны күреп гарыз ит», — диде. Мин шулай кылдым. Атам әүвәл нәсыйхәт кылды, бәгъдә биргән җәзасына үкенеп, гөнаһны кичеп, күргән җәзасы өчен төрекмәннең Төяче ыругын бирде. Ул вакытта Төяче биш-алты мең өйлек бар иде. Шул көнне Ходай Тәгаләне гуаһ кылып, мин үлгәнче кеше өенә төшмәм, әгәр белсәм, нөкерләремне һәм төшермәм, дип касәм[2] иттем».

## Мөхәммәд солтанның сыйфаты

Хаҗим хан илән аның анасы бер иде. Гакыллы вә күркәм холыклы, вә юмарт, вә эшләрнең башына чыгучы, гавамга каты хөкемле вә мулла, вә дәрвишләр, вә шәехләрнең сохбәтенә[3] мәел кылып, һәмишә алардан төрле дин мәсьәләләрен сорар иде вә мәшаихләрнең сүзенә колак салыр иде, бинәзыйр[4] хисап белүче иде вә рәгаятьтән бирүне алып нөкеренә биргән малларны һәммәсен күңелдән белер иде. Укыган булмаса да, көн, вә ай, вә елның хисапларын, вә унике йолдызлык, планеталар, гаскәр эше хисабы вә тылсымны һәм белер, имеш.

## Хаҗим ханның зикере

Амәнәк (Әмин) ханның угланнары Арык тарафыннан Өргәнечкә килгәндә, Акатай хан дәреслеген бәйләп килгән егет иде. Килгәннән соң, төрекмәннең рәгыйятьчелекне кылганына тими, кабул кылмаганын чабар иде. Акатай хан барып, Күкләң илен чабып, анда Чакырлар дигән ыругның уң бәгенең кызы кулга төшеп, аны алып кайтканнан соң, Акатай хан аны никахлап алган. Ханның ул хатыныннан угланнары күп булган. Анча гомер иткәннәре Хаҗи Мөхәммәд хан илән Мәхмүд солтан булып өч кызын озаткан. Тарих тугыз йөз утызда, Ләү елында, Хаҗим хан дөньяга килеп, югарыда өч төрле кылган эшләрен әйттек, монда һәм әйтәем. Габид хан Өргәнечне алып, Мавәраәннәһерне һәммәсен үзенә каратканда, үзен кешегә белдерми Сәгъдедтин илә качып, Дарун шәһәрендә Динмөхәммәд хан катына барып, атланып, йорт вә ил эстәмәк кирәк, дип киңәш биреп, Динмөхәммәд ханны атландырып китереп, Хива илән Һәзарасыб арасында Габид хан илән орыштырып, галиб килергә сәбәп булган Хаҗим хан иде. Икенче — Габид ханның бәкләрен үтерми, Габид хан алдына алып барып, атасының агасы Кал хан вә атасы Акатай ханны Өргәнеч үзбәгеннән һичкемне куймый, һәммәсен күчереп китереп, бозылган Өргәнечне төзәтеп йорт кылган Хаҗим хан иде. Өченче — атасының үлгәнен ишетеп, Хорасанның Тагабад дигән вилаятьтән тизлек илән Өргәнечкә килеп, атасын үтергән Юныс ханның углы Касыйм солтанны үтергән, атасының канын өч айга тартмаган Хаҗим хан иде. Өргәнечтә Иш солтанны үтереп вә Хивада Дуст ханны үтереп, Ак киезнең бер читен Гали солтан

вә өч читен өч энесе тотып, Хаҗим ханны уртада утыртып, утыз тугыз яшендә Елкы елында, тарих тугыз йөз алтмыш биштә Өргәнеч вилаятендә хан күтәрделәр.

## Хаҗи Мөхәммәд ханның хан булганыннан вафат булганынача булган әхвәле

Хаҗи Мөхәммәд ханны хан күтәргәннән соң тугыз ел үткәч, Гали солтан вафат булды. Хаҗи Мөхәммәд хан Өргәнечне алды. Мөхәммәд солтанга Вәзирне бирде. Бу вакыйгаттан берничә ел үткәннән соң, Габдулла хан гаскәр тартып Өргәнеч өстенә килде. Ул вакытта Хаҗи Мөхәммәд хан Хорасанга барган иде. Пулад солтан Хивада вә Тимер солтан Һәзарасыбта иде. Габдулла хан атланды дип хәбәр килгәннән соң, Тимер солтан күчеп Хивага килде, вә Һәзарасыбның үзбәген вә сартын, вә Кабанактан югары утырган үзбәк, сарт рәгаятьне барчасын Хивага китерде, вә дәрвазәнең алдында олуг үр казытты. Өргәнеч халкы Өргәнечтә вә Вәзир халкы Вәзирдә камалды. Сахрада утырган үзбәкнең мең өйлесе вә ике мең өйлесе һәркайсысы бер мөхкәм җиргә җыелдылар. Һәр көндә Хаҗи Мөхәммәд ханга бер кеше җибәреп, хәл-әхвәл белешеп утырдылар. Габдулла хан Каланҗага килде. Каравыллары Яңа Арык дигән җирдә торыр иде. Ун көн булганнан соң, Хаҗи Мөхәммәд киләдер дип, Хорасаннан кеше килде. Моны ишетеп, чынын вә ялганын белмәделәр. Шуны белер өчен кешеләр җибәрде. Ул: «Нухвастка барыгыз, аннан соң Комкальгага барыгыз, аның бәгъдендә Исем-Мәхмүд Атага барып туктап торыгыз. Әгәр Хаҗи Мөхәммәд ханның килә торган хәбәре раст булса, гаскәрдән кайткан кешеләр булса, алып килегез», — диде.

Ул кешеләр Исем-Мәхмүд Атага бардылар. Кятьнең чыгтайларыннан алты кешегә юлыктылар. Ул, алты кешене Габдулла хан алдына алдырып, хәбәрләр сорамыш. Кятьлеләр әйтмешләр: Хаҗи Мөхәммәд хан Нисайда иде, сезнең килгән хәбәрегез иреште. Шул көнне елдам атланып әлхәл юлда килә торыр, ханнан без өйләдән соң аерылдык. Төнәге көн хан Өргәнечкә барып төште. Бу хәбәрне ишеткәннән соң, Габдулла хан Пулад солтан илән Тимер солтанга солых кылаек, дип, кеше җибәрде. Болар һәм кабул кылдылар. Бу көннән соң бер-беребезгә яманлык кылмаек дип, Бохарага кайтып китте.

## Габдулла ханның килгәненең сәбәбе

Ошбу килмәгенә өч нәрсә сәбәп булды. Берсе ул ки: Габдулла ханның авазәсен[1] ишетеп, Рум падишаһы Салә шаһ дигәнне илче кылып җибәрде. Мин бу тарафтан булаем, Габдулла хан ул тарафтан булсын, шулай итеп Шәех угылны уртадан чыгараек, диде. Габдулла хан Салә шаһны яхшы сыйлап кайтарды, килгәндә Һиндстан юлы илән килеп, өч елда җитте. Салә шаһ әйтте: «Инде моннан Өргәнечкә бараем, аннан Төрекмәнгә барып, көймәгә утырып, Ширванга барсам, Истанбул ул юлдан дүрт айлык җирдер», — дип, Өргәнечкә килде. Хаҗи Мөхәммәд ханның углы Мөхәммәд Ибраһим солтан Саләнең барча малын алып калып, фәкать Румга кайтып җитәрлек юл хәреҗе бирде вә, Мангышлакка озатып, Ширван көймәсенә салып җибәрде. Габдулла хан моны ишетеп кәефе кырылды, вә дәхи ул вакытта Ширван румлы кулында иде. Мавәраәннәһернең хаҗилары вә сәүдәгәрләре, кызылбашның йөзен күрмик дип, Өргәнеч аркылы Мангышлакка барып, көймәгә утырып, Ширванга бара торган булдылар.

Габдулла хан Өргәнечкә килмәстән бер ел мөкатдәм күп хаҗиларга вә кәрванга Хаҗи Котас дигән баш булып Хивага килде. Пулад солтанның олуг углы Баба солтан, барча малларын алып, һәммәсен Бохарага пиядә кайтарып җибәрде. Хаҗи Котас, Габдулла хан атланганда, барып гарыз кылды. Аңа Габдулла хан әйтте: «Хаҗи Мөхәммәд хан минем кеби Өргәнечтә падишаһтыр. Ят йорт минем нөкерем имәс», — диде. Шуннан Хаҗи Котас әйтте: «Яүме мәхшәрдә Тәңре Тәгалә казый булып, пәйгамбәр шәфәгатьче булганда, сине тотып барып әйтермен: и Ходаем, Хаҗи Мөхәммәд ханның көче Габдулла ханның бер нөкереннән артык имәс иде. Габдулла ханның аңа көче җитәрлек иде, ялкаулык кылып, барып, минем хакымны алып бирмәде, дирермен», — диде. Хан әйтте: «Хәер, бик олуг җирдән тоттың. Хуп, хуп, кулыбыздан килгән кадәр иҗтиһатында булаек», — диде.

Өченче сәбәп ул ки: Әвәниш ханның нәбирәләренең барчасы үлде, Әбү Әлмөхәммәднең лүлидән туган бер нәмәгълүм углы калды. Мәрвә илән Абъюрд вилаятьләре аңа караган иде. Хаҗи Мөхәммәд ханның энеләренең угланнары һәр елда Мәрвәне чабып, ни хурлыктыр бу лүли бәтчә алдында торыр, дип, күп җәфалар бирерләр иде. Нурым хан, бу золымнарга чыдый алмый, Габдулла ханга китте. Хыялы бу иде ки, хотбәне Хаҗи Мөхәммәд хан исеменә укымасам, Габдулла хан исеменә укырмын, Мәрвәне янә миңа кайтарып бирер, диде. Габдулла ханның углы Габделмөэмин хан Динмөхәммәд ханның кызыннан туган иде, бу нисбәте дә бар иде. Нурым хан барып, Габдулла ханны күргәннән соң, Габдулла хан атланып Мәрвәгә килде. Мәрвәнең үзбәген Бохарага сөрмәккә кешеләр тәгаен кылды, Мәрвәгә ия булды. Нурым хан эчкән

шәрабыннан махмур булды, хыялы ялгыш юлга киткәнен аңлады. Бер кичә егерме-утыз кеше илән качып, Өргәнечкә Хаҗи Мөхәммәд катына барды. Габдулла хан, ул килгәндә, Мәрвә вә Абъюрд, вә Нисай, вә Баг-Абадны алган иде. Дарунда Хаҗи Мөхәммәд ханның углы Гарәб Мөхәммәд ханга мин кәминәнең атасыдыр, ул калды Даруннан башка Хаҗи Мөхәммәд хан кулында, Хорасанда һич вилаять калмады. Габдулла хан, кайтып, Бохарада кышлады. Өргәнеч үзбәге икегә аерылды. Ярымы, Габдулла хан килсә орышаек, диде вә ярымы, орышмабыз, Габдулла хан килсә, тезелеп барып, яхшыбыз вә бик яманбыз, нөкер булырбыз, диде.

Мәхмүд хан, илнең орышмасын белгәннән соң, Мөхәммәд Ибраһим исемле угылны Өргәнечтә калдырды вә Сөенеч Мөхәммәд исемле угылны, вә аның дәхи ике углын, вә алардан гайре Мөхәммәд Ибраһимның бер углын, вә үзенә итагать кылган нөкерләрен алып, Дарунга Гарәб Мөхәммәд солтан катына барып, язда Нисайны чабармын дип, олуг чилләнең эчендә Өргәнечтән чыгып китте. Ул вакытта Һәзарасыбта Тимер солтанның өч углы бар иде вә Хивада дәхи дүрт углы илән Пулад солтан утырыр иде. Өргәнечтә Хаҗи Мөхәммәд хан углы Ибраһим солтан торыр иде, Вәзирдә Мөхәммәд солтанның дүрт углы вә ике сәдак баглаган нәбирәсе бар иде. Кечек чиллә булганнан соң, «Габдулла хан килде» дигән хәбәр чыкты. Хивадан ун вә Һәзарасыбтан ун кешене Даруган-Атага хутның әүвәл көнне каравыллыкка җибәрделәр. Башкалары кулга төшеп, өч каравыл качып кайтты. Бу хәбәрне ишеткәннән соң, Мөхәммәд солтан әйтте, Габдулла хан моннан мөкатдәм килгәнендә атам, Һәзарасыбны ташлап, Хивага өе-иле күчеп барган иде, дәхи Хивада күп халык җәмгъ кылгач, Габдулла хан тора алмый кайтып китте. Хәзер булса һәм шулай кылмак кирәк дип, Хивага күчте вә тәмам үзбәк солтаны илән күчеп Хивага килделәр. Ике көн торганнан соң, бер-беренә инана алмый, хәзрәте Пәһлеванның мазарына барып, Коръәннән ант эчтеләр. Моның илән һәм бер-берсенә ышанмагач, Хивадан халык җыеп берегеп торып булмас, бәлки, Вәзиргә барып, көчебез бер җиргә җәмгъ кылаек, җәмгыять бер урында булсын дип, иртә илән торып, Тимер солтанның углы вә Пулад солтанның дүрт углы илән барча нөкер халкы арба илән туйга барган кеби намаз вакытыннан күчтеләр. Төш кайтканда, дәрвазәдән арбаның соңга калганнары чыгып тәмам булды, төеннәрне йөкләп вә тавыкларны арбаның артына бәйләп киттеләр. Ике мең өйлек күченнек алды, өйлә вакытында соңгы, ил ятканда, Зәһ дигән арыкның аягына килеп кундылар. Габдулла ханның сипаһисы Хуҗамколый исемле өч мең кеше илән күчеп киткән соңгы арбаларның карасы гаиб булган иде, Хивага килеп керде һәм дәрвазәгә килеп яр салдырды: «Калган үзбәк — яхшы вә яман — барчасы килсен, ингам бирәем. Атаклы кешеләренә ханнан җиремлек алып биреп, гайреләрен нөкер кылаем!» — дигәч, һәммә иелеп бардылар. Барчасының исемнәрен дәфтәргә язып алып әйтте: «Инде сәхәр атланырмын, ханнан инде бар кеше вә җаннан, вә малыннан өмет кылган кеше, хаһ[1] — үзбәк вә хаһ — рәгаять, миннән калмасын», — диде. Ул, кич кунып, сәхәр илән атланып, Пулад солтанның артыннан китте.

Инде Пулад солтанны әйтәем. Кич төштән соң Хивадан кеше барды: Хаҗиколый Кош-бәги килеп, шәһәргә керде дип, күңелләренә яман тоелмады, йөкләрне арбаларга мөхкәм бәйләп, тавыкларга җим вә су бирмәк илән мәшгуль булдылар. Шул заман «яу җитте» дип каравыл килде, арбаларны бер җиргә җыйдылар, дәхи алгы якка гаскәр тезделәр, яу килеп, ләшкәре илән орыш башлады. Ничаклы орышсалар да, кешеләрне кулга күп төшерә алмады, хәер малны күп төшерде. Пулад солтан углы Кулҗи солтанны терек кулга төшерде, аннан башка солтаннар барчасы качып Вәзиргә бардылар. Ике көннән соң Вәзир солтаннары әйттеләр, Габдулла ханга без һичбер яманлык кылганыбыз юк, хаҗиларның вә кәрванның малын алып яманлык кылган кеше Баба солтандыр, аны эчебездә тотмаек, дип куаладылар. Баба солтан атасы Пулад солтан һәм ике энесе Хәмзә вә Пәһлеванколый илән — дүртесе Хаҗи Мөхәммәд ханның артыннан Дарунга киттеләр.

Мәхмүд солтанның дүрт углы вә ике нәбирәсе, вә Тимер солтанның өч углы Өргәнечтән, вә Хаҗи Мөхәммәд хан углы Мөхәммәд Ибраһим солтан өе илән күчеп Вәзиргә килде. Аның илән ун түрә кечекләрен әйтмимен. Боларның барчасына баш булып торган Мәхмүд солтанның Гали исемле углы бар иде, аның биле авырганлык сәбәпле, ат өстенә менеп йөри белмәс иде, барчаларының телендә шул иде. Габдулла хан, килеп, Вәзирне камады, дәхи бер айдан кеше җибәрде. «Баба солтанның кылган эшенә ачуланып килгән идем, ул монда юк, имеш. Мин сезләргә карендәш булам, сезләрнең кылган гөнаһыгыз юк, миңа килеп күренегез», — диде. Һәммә солтаннар үзара киңәштеләр һәм бер-берсенә әйттеләр: «Габдулла хан илән безем арабызда кан вә кинә юк, вә аннан гайре дәхи бу бар, Хаҗи Мөхәммәд хан угланнары илән терек булып торганда, безгә яманлык кылмас, барып күрмәк яхшы булыр», — диделәр һәм, илчегә кеше кушып, болай әйтеп җибәрделәр: «Бәкләр килеп, безгә тимәскә ант эчсәләр, барып күрербез», — диделәр.

Габдулла хан Хәсән Хуҗа нәкыйб[2], вә ата иткәне Сархин би, вә диван бәге Мөхәммәд Бакый би, вә Сәмәрканд хакиме Хаҗи би, вә пәрвәнчесе Дустым би Аргынны җибәрде. Ошбу биш олуг кешеләре, килеп, Тәхтепыл өстендә утырдылар. Ун солтан вә утыз-кырык атаклы кешеләр болар илән бергә утырдылар. Теге биш кешеләр ант эчтеләр. Бәкләр дәрвазәгә килгән вакытта халык әйтте: «Бу килгән биш кешеләр илнең

башы вә йортның мәдарыдыр[1]. Габдулла хан бу килгәннәрнең берсенең тырнагын тәмам Өргәнеч йортына бирмәс, боларны тотып кайтарып җибәрми озата килгән кешеләренә болай язып хат бирәек, мисле без биш бәгегезне сезгә дошманлыктан тотмыйбыз, бәлки аларны гыйззәт вә хөрмәт илән саклыйбыз. Әгәр Габдулла хан җәнаблары Бохарага кайтып китсәләр, без мәзкүр бәкләрне кадерләп Бохарага озатып илтеп куябыз», — дип. Моңа каршы Гали солтан диде: «Бу ниндәен намәгъкуль сүзләр сөйлисез? Габдулла хан илән һичвакыт җәбер кылышканыбыз юк. Аның илән без кардәшбез. Өргәнечне безгә биреп китәр, әгәр бирмәсә, Өргәнечнең һәм Вәзирнең артык җирләреннән һәркайсыбызга җир бирер. Хаҗи Мөхәммәд хан угланнары илән терек булганда безгә яманлык кылаем дисә, һәм кыла алмас». Халык никадәр әйтсә дә, түрәләр вә солтаннар аларның сүзләрен игътибарга алмадылар. Габдулла хан кешеләре ант эчеп утырганда, барча егетләр һөҗүм кылаек дип тайяр[2] булып торсалар да, әмма аксакаллар аларны ул эштән кире дүндереп мәнгы кылдылар, бәкләрнең антларына инандылар. Моннан соң түрә-кара һәммәсе Габдулла ханны барып күрделәр. Габдулла хан түрәләрне есауллар дад хаһысы һәм Сагырыҗ хакиме Ишим би дигәнгә тапшырды. Үзбәкләрне сипаһилар башы Хуҗамколый калмыкка тапшырды. Хуҗамколый ыруг-ыругны, өй-өйне дәфтәргә язып алды. Ун өйлек вә егерме өйлек үзбәккә бер дәүләтмәндне[3] кәфил[4] кылып, аларны аңа тапшырды һәм зәкят вә гошерләрен ул кәфил булган кеше аркылы алмакка хөкем кылды. Өргәнеч илән Вәзирне Сары Углан дигәнгә бирде вә Хиваны Дурман Меңлиш бигә бирде, Кятьне, Өргәнечне, төрекмәннең Бият ыругыннан үзенең галим имамы бар иде, аңа бирде. Шулай итеп, Габдулла хан тарих һиҗри илән мең дә икенче елда, Елан елында, Өргәнеч йортын алып, кайтып Бохарага китте.

Пулад солтан угланнары илән Дарунда Хаҗи Мөхәммәд хан катына барды. Аларга, бер айдан соң кеше барып, Габдулла ханның Өргәнечне алганыннан хәбәр бирде. Хаҗи Мөхәммәд ханның олуг углы Сөенеч Мөхәммәд солтан, аның углы Гыйбадулла, дәхи бер углы Гарәб Мөхәммәд ханга (фәкыйрьнең атасыдыр), аның углы Әсфәндияр солтан Хаҗи Мөхәммәд ханның янә бер нәбирәсе, Мөхәммәд Ибраһим солтанның углы вә Хаҗи Мөхәммәднең дәхи бер углы, Мөхәммәдколый солтан — барчасы өч угыл вә дүрт нәбирәсе — Габдулла хан илән Бохарага киттеләр. Пулад солтанның углы Динмөхәммәд ханның нәбирәсе Габдулла ханга Мәрвәне биргән лүли бичә — боларның барчасы ун түрә Гыйракка килделәр. Пулад солтан кяфер эченә Шаһ Габбас Мазый катына ничек бараем, яшем җитмешкә килгәндә, мин бер тинтәк кеше, мине Габдулла хан ни өчен үтерер, дип кайтып, Габдулла хан катына китте. Хаҗи Мөхәммәд хан катында өч мең кеше иде. Барчалары өйләренә кайттылар. Яхшы вә яман Хаҗи Мөхәммәд хан илән йөз илле кеше китте. Габдулла хан Бохарага кайтканнан соң, Пулад солтанны Кулҗи исемле углы илән вә Хаҗи Мөхәммәд ханның углы Мөхәммәд Ибраһим солтанны, вә Тимер солтанның өч углы — Мөхәммәд солтан, Кадербирде солтан, Әбелхәер солтанны, вә Мәхмүд солтанның дүрт углы — Мөхәммәд солтан, Гали солтан, Гарәб солтан, Акбаба солтанны, вә Мөхәммәд солтанның ике углын — Шаһ Гали солтан илән Шаһ Бәхет солтанны — ошбу әйткәнебез уникe затны янә унга якын кечекләрне барчасын бер көндә Сагырыҗ вилаятендә Ак Суның якасында шәһид кылды. Өргәнеч үзбәгенең мәшһүр дәүләтмәнд кешеләренә мөхәссаллар куеп, мал алдырды, һәр рәгыйятьнең башына утыз тәңкәи салым салды. Ул вакытта Габдулла ханның бер тәңкәсе бер әшрәфи алтыннан артык йөрер иде. Шул акча таба алмый качкан кемсәнең акчасын кәфил булган кешедән алды. Арада акчасы булмаганнар углын-кызын сатып биргәннәре күп булды. Бер казаннан аш җыя торган ун-унбиш кеше барчасыннан башка-башка алды, ун яшәр угланны бер өйлек язды, шуңа биргү салды. Хаҗи Мөхәммәд, хан эне вә угланнары илән барып, кызуында шаһны күрде. Шаһ Хаҗи Мөхәммәд ханга каршы килде, куышына җиткәндә аттан төшертте, кулыннан тотып алып барып, үз урынына утыртты. Кул кушырып торып, яхшы килдең, хуш килдең, хан Баба, диде. Күп ингамнар бирде. Сөенеч Мөхәммәд солтан, ике углы илән кызылбаш эчендә тора алмам дип, Румга китте. Башкалар Хаҗи Мөхәммәд хан илән өч ел тордылар, Елан елында барган иделәр, ул елны торып, Куй елы Ялтыравык йолдызы туган чакта Габдулла хан углы Габделмөэмин хан Хорасанның тәмам вилаятьләрен алган иде. Әсфәраин дигән вилаятьтә кызылбаш камалып калган иде. Аны һәм килеп камады. Әсфәраин хакиме кеше җибәрде. Шаһ Габбас олуг гаскәр илән Казвиннан атланып Бистамга килде.

## Хаҗи Мөхәммәд ханның Гыйрактан килеп Өргәнечне алганы вә Габдулла ханның өченче кәррә Өргәнечкә килгәне

Ул вакытта Астрабад төрекмәненең Имри дигән ыругы Галияр бәк дигәннең кулында иде. Бистам илән Астрабад кәндләре бер-берсенә якын иде. Солтаннар Хаҗи Мөхәммәд хан катына килеп әйттеләр: «Астрабадтагы төрекмән үз илегез, ишетәбез ки, Хивада сипаһтан алтмыш кеше, Өргәнечтә кырык кеше бар, имеш, барсак, төрекмәннең ярымы илән йортын алып, аннан соң фәләк ничек хәрәкәт кылса, аңа лаек эш кылыр идек, әгәр шаһка әйтсәк, рөхсәт бирмәс, әйтми, шул кичә китмәк булабыз», — диделәр.

Хан мәгъкуль күрмәде, ләкин ханның сүзенә карамадылар. Хаҗи Мөхәммәд ханның ике углы — Гарәб Мөхәммәд солтан вә Мөхәммәдколый солтан, вә Пулад солтанның өч углы — Баба солтан, вә Хәмзә солтан, вә Пәхлеванколый солтан илнең алды яткада киттеләр, сәхәр вакытында төрекмәннең каравылы торган җиргә килделәр. Көн төш булганда, Астрабадка килделәр.

Хаҗи Мөхәммәд хан иртә илән шаһ катына барды, дәхи вакыйгатны әйтте. Шаһ әйтте: «Габдулла хан терек булган заманда йортны таләп кылмак ошамас. Әгәр алсалар да, соңыннан башларын бирерләр. Инде алар моннан рөхсәтсез киткәннәреннән кайтып, минем катыма (килергә. — *М.Ә.*) оялырлар, башка җиргә китәрләр һәм заегъ[1] булырлар. Син хан Баба аларның артыннан барып әйт, оялмасыннар һәм курыкмасыннар, янә кайтып, минем катыма килсеннәр», — диде. Хаҗи Мөхәммәд хан, бу сүзне ишеткәннән соң, ике нәбирәсен вә куышын куеп, бер яхшы атка менеп елгып китте һәм, Астрабадка барып, артларыннан җитте. Аннан соң Күрән тавына килделәр, Тәкә вә Ямут ыругларыннан илле-алтмыш кеше кушылды. Ул вакытта Мангышлак төрлесе төрле якка таралып бозылган иде. Ирсары, Мангытның талап чапканы сәбәпле, Күрдиш вә Уртак-Кодык дигән җиргә килеп утырган иде, Ирсары эченә килделәр. Аннан биш-алты йөз кеше кушылды. Тәкә илән Ямут Мәхмүд солтан угланнарының рәгаяте иде. Мәхмүд солтан илән Хаҗи Мөхәммәд ханның угланнарына иярделәр. Пишкяһка килгәннән соң, Хаҗи Мөхәммәд хан ике углы илән Өргәнечкә китте. Баба солтан ике энесе илән Хивага барды. Сары Углан Өргәнечнең әркяненә[1] камалды, янында илле кешесе бар иде, төн булганнан соң, кальганың бер җирен тишеп керделәр дә Сары Углан башлыкны барча нөкерләре илән үтерделәр. Тәкә вә Ямуттан биш-алты кеше калды, башкасы өлҗәне алды вә, төясенә ашлыкны йөкләп, өенә кайтты.

Баба солтан Хивага барды. Ул вакытта Хиваның әркяне юк иде, кальганы камады. Сарт кальганы бозды һәм бирде. Меңглиш бине йөз кешесе илән үтерде. Һәзарасыб хакиме илән Кять хакиме Бохарага качтылар. Баба солтан илән килгән Ирсары ыругыннан унбиш кеше калды, башкасы өлҗәне алды һәм, ашлыкны төясенә йөкләп, өенә кайтты. Баба солтан Хивада ун көн торды да Ханкяһка барды, энесе Хәмзә солтан Ханкяһта берничә көн шәраб эчәрмен дип торды. Баба солтан, Һәзарасыбка барып, халыкны башкарып кайтыйм дип, Җиһаннамәсендә җиренә төшкән иде, шул хәл бер егет, кыйбла тарафына карап: «Бу килә торган кешеләрне карагыз, кемнәр икән?» Баба солтан караса күрде ки: улҗүм[2] кигән кәттә чуар атлы, кулында кылычы алдан ялгыз килер, аның артыннан бер чаптар атлы дәхи килер, аларның артларында бер бүлек утыз кеше бар иде. Баба солтан дәрвазәгә йөгерде, дәрвазәнең бер ягын ябып, икенче ягын япканчы кәттә атлысы җитеп, дәрвазәне өч кәррә чапты. Аның артыннан чаптар атлысы дәхи өч кәррә чапты. Аннан соң икесе һәм кире чигенделәр. Кальганың өстеннән мылтык илән аттылар, дәрвазәнең алдына мылтык җитмәс җиргә иелеп тордылар. Барысы йөз илле кеше булды. Бер сарттан хәбәр сорадылар, сарт әйтте: «Кальганың эчендә Баба солтан бар, аннан гайре кальганың эчендә һәм тышында сипаһтан һичкем юктыр, энесе Хәмзә солтан Ханкяһтадыр». Бу сүзләрне ишеткәннән соң, артка кеше чаптырдылар. Бу торган йөз илле кеше Ханкяһка китте. Төш вакытында Хәмзә солтан өстенә барды. Ул базар эчендә йөрер иде. Пиядә хәлдә орышты. Янына илле-алтмыш кеше җыелып та кичкәчә орышты. Ил ятыр алдында яу бүлек-бүлек пиядә булып һаман орышны куймады вә яуның бәгъзе бүлеге, белдерми сарайны тишеп, эчкә керделәр, барчасын шунда үтерделәр.

Инде бу яуның ничек тиз килгәнен әйтим. Габдулла хан тарих һиҗри илән мең дүртенче, Куй елында гаскәрен китереп, Ялтыравык йолдызы туган чакта Бохарадан атланды. Моннан әүвәл әйткән идем, ул вакытларда углы Габделмөэмин хан Әсфәраиндә иде. Бу кыш углым илән Хорасанда кышлармын, әгәр мәгъкуль булса, бәлки, Гыйрак өстенә йөрермен дип, Хуҗамколыйга, син, Иравылга барып, Чәһар-Җуйдан үтә тор, мин Күрдиштә үрдәккә куыш салып, ау аулармын дип, Хуҗамколыйга тәгаллекъле гаскәр судан үткән вакытта Һәзарасыб хакиме качып килеп, бу көн дүрт көн булды. Баба солтан, Гыйрактан килеп, Хивада Меңглиш бине үтерде, дип әйтте, шул заман качып кайткан Хуҗаны Габдулла хан алдына җибәрде. Хан, хәбәрне сораганнан соң, Хуҗамколыйга Өргәнеч өстенә бармакка хөкем кылды, үзем һәм артыңнан барам, дип, мәгълүм кылды. Баба солтан Хиваны алганнан соң, унөч көндә Һәзарасыбның дәрвазәсенә яу килде. Хәмзә солтанны Ханкяһта тотып алганнан соң, Хуҗамколый килеп җитте. Шул кичне Хаҗи Мөхәммәд ханның кечек углы яуга Мөхәммәдколый солтан, баһадир, мылтык атарга оста, булдыклы яхшы егет иде. Ул атасына әйтте: «Сез агам илән Өргәнечтә калыгыз, мин, берничә кешене алып, Баба солтан катына бараем», — дип. Өргәнечнең чыгтай вә төрекмәненнән берничә кешене алып, Мангытка сәүдәгә барамын, дип иярлтте. Юл өстендәге илләрнең күбесе гафил булып ышандылар. Йөри торгач, үзенә бер-ике йөз кеше табып иярлтте һәм, Баба солтан катына бараем дип, дәрья буе илән Һәзарасыбка китте. Гафил Чилпук дигән кальганың турысына килгәндә, алдына яу чыкты, бер җиргә җыелып торды. Яу мең кешедән артык иде, башы Хуҗамколый Калмык килеп орыш башлады. Һәммә тарафтан чолгап алды һәм: «Солтанны качырмагыз, тотып алыгыз!» — дип хөкем кылды. Күп орыштылар. Мөхәммәдколый солтанның кешесе аз калды. Солтан әйтте: «Болай орышсак, бездән бер кеше калмас. Инде мәгъкуле шул ки, бер тарафны йөреп чыга-

ек, гомере беткәнебез үләр, бетмәгәнебез котылыр», — диде. Солтанның бу сүзен кабул итеп, барчасы иттифак илән бер җирдән ярып чаптылар. Яу икегә аерылды. Исән-сау яудан чыгып киттеләр.

Шул качканнан соң, атасы катына бармый, Мангыт йортына барды. Мангытның бер баш мирзасы бар иде, Күчүк исемле. Аның сеңлесен Хаҗи Мөхәммәд хан Мөхәммәдколый солтанга алып биргән иде. Каенагасы Күчүк мирзаның өенә барды, ул тотып урыска җибәрде. Мөхәммәдколый солтан урыста күп еллар торгач вафат булды. Мөхәммәдколый солтан илән яудан качкан кешеләрдән бер кеше качып Өргәнечтә Хаҗи Мөхәммәд катына барды. Шул заман Хаҗи Мөхәммәд хан илән углы Гарәб Мөхәммәд солтан качтылар. Ике көн йөреп, өченче кичәсе бер җиргә төшеп яткан иделәр, ат аягының тавышы килде, коралларын баглап атландылар. Яу килеп, боларның өстенә һөҗүм кылдылар. Куышның һәм нөкеренең ярымын алдылар, үзләре аз гына кеше илән качып котылдылар. Сабах чашт вакытында янә артларыннан яу җитте. Орыша-орыша киттеләр, янә калган кешеләрнең ярымын алдырып, ярымы илән орыша-орыша Астрабадка барды. Аннан соң Казвинда шаһ катына килделәр.

Һәзарасыбта Габдулла хан үзе килеп, Баба солтанны дүрт ай мөхасарә[1] кылып, соңра кальганы алып, Баба солтанны үтерде. Баба солтан янында үз нөкереннән унбиш кеше вә Ирсары төрекмән өч кеше бар иде. Алардан гайреләрнең барчасы Һәзарасыбның сарты иде. Һәзарасыбның атаклы вә яхшы халкы кальгага керми калды, аның өчен кальгада кәсәбә бар иде.

## Хаҗи Мөхәммәд хан углы Гарәб Мөхәммәд хан илән Сөенеч Мөхәммәд солтанның, килеп, йортка ия булганнары

Тарих һиҗри бер мең алтыда, Тавык елында Габдулла хан вафат булды. Эт елының әүвәлендә Казвинда Шаһ Габбаска Габдулла ханның үлгәненнән хәбәр барды. Бу хәбәрне ишеткәннән соң, Шаһ Габбас гаскәргә яр салдырып, атланып Бистам килде. Хаҗи Мөхәммәд хан Шаһ Габбастан рөхсәт теләп әйтте: «Инде Габдулла хан үлгәннән соң, үзбәк халкы Габделмөэмин ханны үтерер, ул вакытта без йортыбызга якын булмасак, безем җәмәгатебездән Мавәраәннәһердә казак булып йөргән күп кешеләр бар, анларның берсенә халык китереп падишаһ куярлар, аннан соң падишаһлык безгә тимәс», — диде.

Шаһ Габбас Хаҗи Мөхәммәд ханның углы Мөхәммәд Ибраһим солтанның Борындык исемле егерме яшәр егет углы бар иде, аны алып калды. Хаҗи Мөхәммәд хан углы Гарәб Мөхәммәд солтанның углы Әсфәндияр солтанга бергә китәргә рөхсәт бирде. Әсфәндияр солтан ул вакытта унөч яшендә иде. Болар киткәннән соң, Нурым ханга һәм китәргә рөхсәт бирде. Хаҗи Мөхәммәд хан, Астрабадка килеп вә аннан үтеп, Тәкә халкының эченә Күрән тавына килде.

Инде ни җиргә китәрен белми хәйран булып торды. Ул вакытта ата илә угылның катына яхшы вә яманнан унбиш кешеләре бар иде. Июльнең урталарында көннәр бик эссе иде. Иртә илән таң намазын укып, тауның күләгәсендә утырганнар иде. Шул хәл Дарун тарафыннан ике атлының карасы күренде. Якын килгәннән соң таныдылар: икесе һәм Найман ыругыннан Гарәб солтанның Бохарага төшеп киткән нөкерләреннән иде. Икесе һәм ханның хозурына күренешкә килделәр, дәхи гарыз кылдылар ки: «Габделмөэмин хан вафат булды, Ходай Тәгалә сезгә озын гомер биргәй иде», — дигәч, хан: «Бу вакыйгатны тәфсилә бәян кыл», — диде. Алар әйттеләр: «Без Мәрвәдән киләбез, Габделмөэмин ханны, кичә күчеп барганда, Замин кальгасының алдында атасының бәкләре ук илән атып үтерделәр. Шул кичәне мин бу тарафка килдем, дип, Мәрвә хакименең кешесе килде. Без сезне Гыйракта табарбыз дип барадыр идек. Нисайда Шаһ Габбас Бистамга килде дип хәбәр алдык, аннан Дарунга килеп, сезнең төрекмән эченә килгәнегезне ишеттек, шул рәвешчә сезгә бәндәлеккә килеп торганбыздыр, диделәр». Хан, шул сәгать атланып, сигез көн булганда Өргәнечкә килделәр.

Өргәнеч илән Вәзирне Хаҗи Мөхәммәд хан алды. Хива илән Кятьне Гарәб Мөхәммәд хан алды, Һәзарасыбны Әсфәндияр солтанга бирделәр. Габдулла хан Өргәнечтән күчереп алып киткән үзбәктән кеше калмады. Һәммәсе кире кайттылар. Хаҗи Мөхәммәд ханның олуг углы Румга китте, дип, югарыда әйткән идек. Ул Румда, Габдулла ханның вафатын ишетеп, йортына кайтырга чыгып Ширванга килде. Йортта ни вакыйгатлар булганын ишетеп белде. Аннан соң көймәгә утырып, Сычкан елының башында Мангышлакка чыкты. Хаҗи Мөхәммәд хан Эт елында кайтты, әмма углы ике ел аннан соң кайтты. Хаҗи Мөхәммәд хан аңа Өргәнеч илән Вәзирне бирде, үзе, Хивага килеп, кечек углы Гарәб Мөхәммәд солтан катында утырды. Бер елдан соң Сөенеч Мөхәммәд солтан Хак рәхмәтенә китте. Гыйбадулла исемле бер углы калды. Бер елдан соң ул һәм атасы артыннан китте. Хаҗи Мөхәммәд хан тарих һиҗри мең унбердә вә Барс елының ахырында сиксән өч яшендә Хак рәхмәтенә китте.

## Гарәб Мөхәммәд ханның падишаһ булганы

Атасы үлгәннән соң, Гарәб Мөхәммәд солтанны хан күтәрделәр. Һәзарасыб вилаяте өстенә Кять вилаятен Әсфәндияр солтанга бирделәр. Хан булып алты ай үткәннән соң, Куш-Җаек дигән җирдә йөргән урысның атлы казагыннан мең кеше, июльнең әүвәл көнендә кинәт килеп, Өргәнечнең кальгасына керде. Шәһәрдә рәгыйятьтән башка кеше юк иде. Ханның урдасы вә сипаһ халкы АмуДәрья якасында иде. Хивадан ханга кеше чаптырдылар. Җиде көн булганда хан килеп җитте. Урыс Өргәнечтә рәгыйятьтән мең кеше үтерде, вә мең кыз илән яшь егетләрне алды, вә мең арбага яхшы малларны йөкләде. Бүз вә палас, вә тун, вә түшәк-ястык, вә моның кеби нәрсәләрне барчасын утка якты. Боларны сәрәнҗам[1] кылып алып киткәнче җиде көн үтте. Аннан соң, Өргәнечтән чыгып, дәрья якасына китте. Гарәб Мөхәммәд хан, урысның алдына барып, үр казыды вә чиб[2] кылды. Ике көн орыштылар, өченче көн урыс чибны алды һәм алга таба йөрде. Урыс пиядә вә безем халык атлы. Бик тиз артка ике фәрсәх чигенеп, янә үр казыдылар. Безем халкыбызның максуды бу иде ки: эссе көндә урысны чүлдә сусызлыктан гаҗиз итеп, һәнүз сугышны туктатмаек, юкса урыс суга җиткәннән соң, тугайда беркөнне кальга салып, бәгъдә йортына кеше җибәреп, аннан янә булышлык килер. Ошбу вакытны ганимәт белеп, барчасын кыраек, дип, урыска һөҗүм кылдылар. Урыс йөкләп киткән суын эчеп бетерде. Суы беткәч, канны эчә башлады. Бишенче көнне каны түкәнде. Үзбәк һәр тарафтан гөрух-гөрух булып чапты, урысның күбесен үтереп кайтты. Урыс әүвәл арбадан чыгып орыша иде. Ахирел әмер арбаның эченнән чыга алмады, гаҗиз булды. Җиденче көнне барча үзбәк иттифак илән урыска һөҗүм кылды. Урыс коралны ташлагач, һәммә үзбәк аттан төшеп, сугышны куеп өлҗә алмак илән мәшгуль булды. Шул хәлдә йөзләп урыс дәрья якасына качып, Түк кальгасының турысында агачтан кальга салып, балык аулап җийеп утырды. Аннан соң Гарәб Мөхәммәд хан, барып камап, унбиш көннән соң алып, урысны тәмам кырып бетерде.

Бу вакыйгаттан алты айдан соң калмык килде. Моннан мөкатдәм үзбәк мөселман булганнан бирле һич калмык килгәне юк иде. Хуҗа күле илән Шәех Җәлил тавының арасыннан үтеп, суның ике ягында утырган илне Түк кальгасынача чабып, Борылчидан чыгып китте. Гарәб Мөхәммәд хан артыннан куып барып, малны вә әсирне алып калса да, әмма калмыкның үзен тота алмады.

## Казакъның әүвәл килгәне

Мавәраәннәһердә йөргән Илбарыс хан угланнарыннан Хөсрәү солтан дигән кемсәне Найман халкы бер кичә Хиваның эченә кергезделәр, Гарәб Мөхәммәд ханны үтереп, Хөсрәү солтанны падишаһ кылаек дип. Киңәш эчендәге кешеләрдән ике кеше — берсе кыргыз Бәк Баклы баһадир вә икенчесе Уйшун Баклы мирза килеп Гарәб ханга хәбәр бирделәр. Шуннан соң Хөсрәү солтанны тотып үтерделәр. Аны алып китергән кешеләрнең башы Найман Суфый мирза дигән кемсә иде, аны үтерделәр, башкаларына тимәделәр.

## Казакъның икенче килгәне

Бу вакыйгаттан соң ике ел үткәннән соң, уйгур халкыннан егерме кеше, Саш мирза дигән аксакал илән барчасы, Өргәнечтән Сәмәркандка барып, Хәсәнколый хан әүлядыннан Салих солтан дигәнне, суның буеннан килми, бераз югарырактан йөреп, Өргәнечтә утырган үзбәк эченә алып килделәр. Аны ишетеп, Гарәб Мөхәммәд хан Хивадан барды. Һәммә халык хан тарафына чыгып, казакъ тарафында кеше калмады. Берике йөз найманнан азган-тузганнар барганнар иде, алар һәм кайтып качып киттеләр. Ахирел әмер Салих солтанны тотып китереп үтерделәр. Егерме уйгурның һичкайсын үтермәделәр. Хан әйтте: «Мин рәгыйять халкым илән яман атлы булырга теләмимен. Һәркем яманлык кылса, аны Ходайга тапшырдым; төнәгеһ Суфый мирза Хөсрәү солтанны китерде дә, аны һәм мин үтермәдем; энесе Баба мирза, падишаһым, синең дошманың җир йөзендә булмасын, дип, үзенең туган энесе Баба мирза үтерде. Әлхаль һәм булса, әгәр уйгур халкы, үтерербез, дисәләр, үзләре белер, мин үз кулым илән тотып үтермәм», — диде. Уйгур халкы һәм үтермәккә кыймады.

Инде Әбелгазый әйтәдер: «Кадимге заманда халык бу заманның халкыннан яхшы иде. Әгәр ил халкы җыелып кешене үтерергә куәте булса, вә йә гөнаһкяргә җәзасын бирмәккә көче җитсә, вә яки бер эш башкармак кулыннан килер булса, ни өчен бер мәрдкәр падишаһ исемен бирде, аны өенең түрендә утыртып, барча халык ихтыярларын аның кулына бирерләр. Ахры атабыз ханның башына вә барча йорт халкының башына ханның киңлеге һәм гөнаһларын гафу кылмагы артыктыр».

## Моннан ун ел үткәч, калмыкның икенче кәррә килгәне

Бакырган өстендә янә бер мең калмык килеп, илне чабып, әсир вә мал алып китте. Аның артыннан һич җитә алмадылар. Гарәб Мөхәммәд ханның җиде углы бар иде: әүвәл Әсфәндияр хан, икенче Хәбеш солтан, өченче Илбарыс солтан, дүртенче Әбелгазый хан, бишенче Шәриф Мөхәммәд солтан, алтынчы Хәрәземшаһ солтан, җиденче Әфган солтан. Әсфәндияр ханның анасы үз җәмәгатебездән иде. Хәбеш солтан илән Илбарыс солтанның анасы найман ыругыннан икесе бер анадан иде. Үз анабызның кайсы нәселдән икәнен югарыда әйткән идем, шулай булса һәм яңадан әйтим. Анамның исеме Маһирәбану ханым, атасы Хангазый солтан, аның атасы Ширгазый солтан, аның атасы Солтангазый солтан, аның атасы Илбарыс хан, аның атасы Бәркә солтан, аның атасы Ядгәр хан; атам илән анамның һәр икесенең атасы Ядгәр хандыр. Шәриф Мөхәммәд солтан илән Хәрәземшаһ солтанның анасы Хуҗа Мәүдүд Чиштий әүлядыннан иде, Чишт-Һератның бер кәндедер. Әфган солтанның анасы Әбелхәер солтан әүлядыннан иде.

## Атабыз Гарәб Мөхәммәд хан тәхеткә утырганнан соң ундүрт ел булганда Хәбеш вә Илбарысның яу булганнары

Хәбеш солтан уналты вә Илбарыс солтан ундүрт яшенә җиттеләр. Икесе һәм Хивада үстеләр. Гарәб Мөхәммәд хан Өргәнечкә барганда, Хивада дәүләт шәрабына мәст[1] булган үзбәк егетләре, Хәбеш солтан илән Илбарысны атландырып, Өргәнеч илән Вәзиргә яр кылмага кеше җибәреп, гаскәрнең алды-арты җыелганчы, Пишкяһ дигән кодыкка җыелдылар. Өргәнечтән елдам атлыга бер көнлек җир булыр, шунда барып ун көн тордылар. Гарәб Мөхәммәд хан аларга кеше җибәрде: «Килсеннәр, шәһәр Вәзирне бирермен», — диде. Угыллары әйттеләр: «Әлхәл барып күрмәккә атабыздан куркабыз, гаскәр килгәннән соң, барып күрербез», — дип, барган кешене кайтардылар. Һәр җирдә булдыклы егетләр шаһзадәләр катына туп-туп булып киттеләр. Гарәб Мөхәммәд ханның аталарының угланнары һәм вәкилләренең угланнары барчасы киттеләр. Ул вакытларда халык ханнан шулкадәр куркыр иде ки, барча үзбәк бер елгача өенә кереп хатыны илән ятмасын дисә, һич кешенең хилафлык кылырга хәле юк иде вә һичкем өе тарафына аяк басарга кыючылык итә алмас иде. Хан, күренешкә чыгып, халыкка әйтсә: «Эне вә углыгызны Хәбеш катына җибәрмәгез, әгәр җибәрсәгез, миннән яхшылык өмет кылмасын вә минем бу сүземне бер-берегезгә әйтегез», — дип хөкем кылса вә, кешеләр җибәреп, шәһәрләрдә вә базарларда ошбу сүзне әйтеп яр салдырса, өеннән тышка чыгылмакка һичкем җөрьәт итә алмас иде. Хан халыкның киткәнен яман күрде, шулай булса да тышыннан һичнәрсә әйтмәде, халык углының янына барганны хан яхшы күрәдер, әгәр яман күрсә мәнгы кылыр иде, дип китмәк илән булдылар. Шаһзадәләр янына барча халык җыелып беткәч, барып, Хорасанны чабып кайттылар вә гаскәр эчендәге һәркемнең углы атасына исәнлегеннән мәгълүм итеп бүләк җибәрде. Соңра Өргәнечкә бер мәнзил җир калды дигән җирдә шаһзадәләр туктадылар. Гаскәргә барган кешеләрнең күбесе өйләренә кайтып киттеләр, шаһзадәләр катында намуслы вә гарьле егетләрдән җитмеш-сиксән кадәр кеше калды.

Ул вакытта ханның уйгур ыругыннан Корбан Хаҗи дигән бер олуг бәге бар иде. Аны угланнарына җибәреп, мине килеп күрсеннәр, диде. Корбан Хаҗи иртә китеп, төш вакытында кайтып килде. Мин фәкыйрь атамны күрәем дип ишегенә барган идем, шул вакытта Корбан Хаҗи һәм ишеккә килеп, хан катына бергә кердек, хан Хаҗига, күргән эшеңне сөйлә, диде. Хаҗи әйтте: «Ни итәем, ханым, барганыма пәшиман[1] булдым, Даруган-Ата коесыннан башлап Бакырган Атагача утырган үзбәк угланнары шаһзадәләргә иярмешләр. Эт аяклы, сыгыр башларыннан башкалары һәммәсе шаһзадәләргә табигъ улмышлар. Мине сезгә, атаңыз чакырта җибәрде, дип әйткән идем, мең төштән һәркайсы бер сүз әйтеп җикеренеп кычкырдылар. Йә, ханым, эш яман булды. Үзең белерсең, минем синең өчен җаным көйгәндә, башкаларның тунының итәге дә көймәс. Инде Хивага китә күр, ул залимнәрнең сүзләре ямандыр, алардан ерак була күрегез. Хивага баргач, илебез вә халкыбыз илән үзара бу хосуста бер мәслихәт кылырбыз», — диде. Хан бу сүзне ишеткәннән соң, аягы багланды вә теле тотылды. Атны ияртеп, дөяне йөкләмәккә боерды. Ханнан гайре халык, Илбарыс илән Хәбешнең янында җитмештән артык кеше юк икәнне яхшы беләбез, диделәр. Шулай булса да Ходай Тәгаләнең әмеренә һич чара юк, Корбан Хаҗиның сүзе растмы йә ялганмы, һичкемнән сорамады, хан илән Хәбеш вә Илбарыс угланнарының арасы иртә илә чыккан кеше төштән элгәре барып килер иде. Гаҗәп, һич булмаса, бер кешене барып, ни микъдар кешеләр бар икән, белеп кил, дип әйтмәде. Хорасанны чапканнан кайткан гаскәрнең күбесе өйләренә таралдылар, гайре җирдән гаскәр җыелмакка форсат булганы юктыр. Хәбешнең Өргәнеч якынына килгәненә бары ике көн иде. Ул: «Күп гаскәр асманнан төштеме йә

җирдән чыктымы, кайдан килде», — дип күңеленә китермәде. Хан киткәннән соң, Хәбеш илән Илбарыс Кыран кырына барып төштеләр.

Ул вакытта Мәздаһкян кальгасыннан та Бакырганның бире ягы Койгын дигән җиргәчә бодай игелер иде. Безнең хан Түк кальгасының югары тарафыннан бер арык казырлар иде. Мин фәкыйрь дөньяга килмәстән, бер ел мөкатдәм Мизан йолдызы булганда сәкасын[1] күмеп, бодайны урган вакытта аны ачарлар иде. Берничә елдан соң арыкның киңлегенә аткан ук җитмәс булды. Суның аягы, Койгынга барып, аннан Ачы диңгезгә төште. Шул арыкның буенда фәкать бодай игелер иде. Атлы кеше ун көндә бодай кырының бер башыннан икенче башына барып әйләнеп кайтып килә алмас иде. Ул вакытта пучык ярым көмеш акча бер тәңкә урынына йөрер иде. Бер тәңкәгә ярты төя йөге бодай бирерләр иде вә бер мыскал көмешкә бер хәрвар[2] бодай бирерләр иде. Инде әйтә торган сүзебездән калмаек. Хәбеш илән Илбарыс һәр җирдә ханның амбар кылып куйган ашлыгын һәм нөкеренең ашлыгын алып үз нөкерләренә өләштерер булдылар. Моны ишеткәннән соң, ашлык алмак өчен яхшы-яман кара халыкның барчасы һәм бәкләрнең бәгъзеләре шаһзадәләр катына җыелды, вә ханнан Вәзир шәһәрен барча төрекмән тәбәгалары илән Хәбеш илән Илбарыска алып бирделәр. Аннан соң шаһзадәләр, дүрт мең кеше илән Хивага барып, атасын күрделәр, бәгъдә кайтып, Вәзиргә килделәр, биш ел ата вә угыл булып утырдылар. Алтынчы елны Илбарыс солтан Абъюрдны чапмак булып Хивага барып, ул елны атасын күрмәде, гаскәренең алдын вә артын җыймак өчен барып, Сагча кодыгына төште. Ул вакытта хан атланып Өргәнечкә китте. Илбарыс солтанның куйган кешесе ханның Хивадан чыгып киткәненнән хәбәр китергәч, Илбарыс солтан атланып Хивага килеп керде. Хан ул вакытта Риш-Табан Атада икән, хан катында шул көнне яуга каршы торып орышырлык утыз кешесе бар икән. Ханга Хивадан сәхәр вакытында кеше килеп, Илбарыс солтанның Хивага барып кергәненнән хәбәр бирде. Хан катындагы гакыйль хуҗалар ханга Хиваның дәрвазәсенә барып төшмәккә мәслихәт иттеләр. Илбарыс хан сезнең барганыгызны ишетеп, тора алмый Хивадан үзе чыгып китәр, диделәр.

Хан, хуҗаларның мәслихәтенчә тизлек илән барып, Хиваның Хәстәкян дигән касәбәсенә төште. Илбарыс солтан ханның Хәстәкянга килгәнен ишеткәч, биш кешене, барып, атамны тотып китерегез, дип җибәрде. Бу кешеләр барып җиткәч, хан өйгә кереп бикләнде. Илбарыс солтанның кешеләре аттан төшеп, дүрт тарафтан орыш башладылар. Ул арада кояш һәм батып китте. Караңгы булганнан соң, диварны һәр җирдән тишеп өйгә керделәр һәм, ханны тотып, атка мендереп, тезгенен үз кулларына алып, ярым кичәдә Хивада Илбарыс солтанның алдына алып килделәр. Илбарыс солтан, атасын бер өйгә ябып, ишегенә каравылчы куйды. Утыз елдан бирле җыелган хәзинәне алып эткә вә кошка өләштеләр. Атасының бәкләрен үтерми, барчасының малларын алды һәм анасын терек куеп Хивадан чыгып өенә китте. Илбарыс солтан атасын тотып малын алып йөргәндә, Әсфәндияр солтан Һәзарасыбта вә Хәбеш вә мин фәкыйрь һәм Шәриф Мөхәммәд солтан Өргәнечтә халыкны җыеп тордык. Илбарыс солтан өстенә бармакны аксакаллар мәгъкуль күрмәделәр. Аның өчен, безгә ачудан ханны үтерер бармасак, малын алыр да ташлап китәр, диделәр. Илбарыс солтанның өе безнең өебезгә якын килгәч, Әсфәндияр солтан илән атабыз Гарәб Мөхәммәд безем гаскәрне җыеп яткан җиребезгә килделәр. Без Илбарыс солтанның өстенә бардык, ул орыша алмый качып биш-алты кеше илән кырга чыгып китте, өйне вә илне чабып, барча солтаннар катына кайттык. Атамны күрәем дип килдем, урдада ялгызы ахшам намазын укып утыра иде. Намазны тәмам иткәч, янына килеп утырып дидем: «Илбарыс солтан биш-алты кеше илән кырга чыгып китте, инде ни мәслихәт бирәсез, атам?» — «Синең үзеңә ничек мәслихәт булыр?» — дигәч, мин әйттем: «Бу арбаның олуг юлы кеби күренеп торган эшне атасыз кылмассыз». — «Нәрсә ул? Сөйлә», — дигәч, әйттем: «Әсфәндияр солтан илән мин фәкыйрьгә рөхсәт кыл, әүвәл барып, Хәбеш солтанны, аннан соң Илбарыс солтанны барып үтерәек, бәгъдә калган биш угылның һичкайсы синең хөкемеңнән чыкмас». Хан: «Яхшы әйтәсең, мәгъкуль, — диде. — Хөсәен Хаҗи исемле аталык аталган бер зат бар иде, аның илән бу хосуста барып мәслихәт кылаем, син бар, дәхи фәлән вә фәлән дип, биш кешенең исемен тотып, аларга киңәш, аннан соң барып, Әсфәндияргә киңәшеп, ошбу кичәнең эчендә килеп, миңа җавапны бир», — диде. Мин барып сөйләшеп килдем дә әйттем: «Әсфәндияр солтан һәм аннан гайреләре әйттеләр, без бу вакыткача ханга бу мәслихәт эшне әйтмәккә кыймый идек, бу эш моннан элек күптән кыла торган эш иде. Әлхәл һәм булса вакыты үтмәгән, тизләп эш кылырга тиештер, синең рәинең бик мәгъкуль әйттеләр», — дидем. Хан әйтте: «Мин Хөсәен Хаҗига киңәштем, ул әйтәдер, әгәр угланнарыгызның берсен үтерсәгез, аннан соң калганының һичберсе сезгә инанмас. Инде бу эшне кыла алмаем», — диде. Әбелгазый мин әйттем: моннан биш-алты ел мөкатдәм Хөсәен Хаҗиның агасы Корбан Хаҗи аркылы Хәбеш солтан илән Илбарыс солтанны чакырта җибәрдең, икесенең катында җитмештән артык кеше юк иде. Сиңа ул килеп әйтте, эт аяклы, сыгыр башлыларыннан башкаларның һәммәсе шаһзадәләренә йыйылыптыр, дип, сезгә ялган сүз сөйләп, сине Хивага качырды. Хөсәен Хаҗиның гарызы Хәбеш солтан илән Илбарыс солтанга уйгур илән найманны якын күрсәтмәк иде вә аннан гайре дәхи Илбарыс солтанның катында хезмәт итеп йөргән Дустым илән Ишем бар, ул икесе Хөсәен Хаҗиның якын энеләре иде. Илбарыс солтан үлсә, алар һәм үлмәк кирәк. Инде сезне тотып, өйгә ябып, малы-

гызны алганнан соң ни эш калды? Иртә моннан яман эшләр булыр, үкенерсең, файда бирмәс, диде. Ата, бер сәгать фикер кылып торганнан соң, мин бу эшне кылмакка җөрьәт итә алмам, углым, Әбелгазый, бу эшне куй, диде. Атам ханнан өмет өзгәннән соң, атланып ярым кичәдә Әсфәндияр солтан катына бардым, мәвакыйгны бәян кылдым. Хан атам бу эшкә разый булмый, син разый булсаң, бу эшнең башына чыгармын, дидем. Әсфәндияр солтан әйтте, алай димә, Әбелгазый, атабыз мөнасиб күрмәгән эшне мин «кыл» дип әйтә алмам. Инде моннан ары бу сүзне әйтмә, диде. Аннан соң кайтып өемә килдем.

Әсфәндияр солтанның нөкерләреннән бер найман егете, минем мәзкүр хосуста кичә барып сөйләшеп кайтканымны белеп барып, Хәбеш солтанга хәбәр биргән. Аннан соң Хәбеш солтан минем илән дошман булды. Атам Хивага китте. Әсфәндияр солтан Һәзарасыбка китте. Хәбеш солтан Илбарыс солтанга кеше чаптырды, ата кайтып китте, тиз килсен, дип. Минем серем заһир булды. Ике дошманның арасында тора алмадым, күчеп, атамның артыннан киттем. Атам миңа Кять вилаятен ингам кылды. Бу вакыттан соң биш ай үткәч, мин фәкыйрьнең мәслихәтен тотмаганга үкенде. Әсфәндияр солтан илән мин фәкыйрьгә атлансыннар дип, кеше җибәрде. Шәриф Мөхәммәд солтанның анасы Өргәнечтә иде, Хивага атасын күрмәккә килгән иде. Аны һәм кайтарып җибәрде. Хан атланды. Угланнарым катында ун нәфәр[1] фетнәче кеше бар, әгәр аларны миңа тотып бирсәләр, алар минем угланнарымдыр вә җанымдыр, авызларыннан очармын да кайтырмын. Әгәр ул яманнарны бирмәсәләр, мин ул угланнарымнан бизәрмен. Тәңре Тәгалә кемгә ярдәм бирсә, шул булыр, дип, юлга йөрде. Бу сүзне әйтеп, угланнарына кеше җибәрде. Мин — Әбелгазый — атам ханнан кеше барган сәгатьне гаскәрне җыеп сөрмәккә кеше тәгаен кылдым. Куышыма кеше куеп әйттем: «Сезләр суны үтә торыгыз», — дип, үзем атам катына бардым. Ул, Хивадан чыгып, Кәндемкәнд дигән кәндкә төшкән икән, халык һаман ятмаган иде, хан катына килеп яттым. Атам: «Кайдан киләсең?» — диде. «Кятьтән киләм», — дидем. «Кайчан чыктың?» — диде. «Ошбу көн төш вакытында чыктым», — дидем. «Ни өчен куышыңны калдырып, үзең алдан килдең?» — диде. Мин әйттем: «Күңелемә бер нәрсә килде, аны гарыз кылаем дип килдем», — дидем. «Гарызың ни? Сөйлә», — диде. Мин әйттем: «Хәбеш илән Илбарыс, сезнең моннан барганыгызны бүген йә иртән ишетеп, илгә гаскәр җыярга быргычыларын җибәрерләр. Сез Әсфәндияр солтан илән суның бире ягыннан йөреп, миңа хәзер китәргә рөхсәт бирсәгез, намаз вакытында Кятькә барып, аннан арада бер кунып ил эченә ятармын. Үземнең катымда сигез йөз нөкерем бар, сахрада утырган үзбәкнең ярымыннан күбесе синең илән минем илебездер, алар бер сүз илән минем артымнан барырлар. Хәбеш солтан илән Илбарыс солтанның иле курыкканлыктан табигъ булырлар. Әгәр берсе ялгызы Хәбеш солтан катына китсә, казанынача алдырырмын, сахрада утырган үзбәктән башка Хәбеш илән Илбарыс солтан катында ике йөз-өч йөз кешедән артык кеше юктыр. Мин барганнан соң ул икесенең хозурына кеше җибәрермен. Сез, хан атам, тизлек илән йөрегез. Шуннан соң алар бер ук атмый качып китәрләр, әгәр болай кылмасагыз, сез барганчы, илнең гаскәрен җыеп, каршы килеп орышырлар, Ходай носрәтне[1] кемгә бирере мәгълүм түгел». Моны сөйләп бетергәннән соң: «Бу сүзләрне кайдан өйрәнеп килдең?»— дип миңа әйтте. «Һичкемнән өйрәнмәдем, фәкать үз белгәнемне әйтәм», — дидем. «Бу сүзләрне өйрәткән кемсә ни мәгъкуль сүз әйтептер. Бар, куышың илән минем катыма кил», — диде.

Мин, кайтып барып, куышымны күчереп, Хост манарасында ханның хезмәтенә барып җиттем. Аннан күчеп, Икенче Ком дигән җиргә төштеләр. Ул көнне янә гарыз кылдым: «Фәкыйрьне җибәрегез, мине җибәрмәсәгез, Шәриф Мөхәммәд солтанны җибәрик. Кеше яуны атмый, чапмый ала алса, атышып-чабышып йөрмәк нигә зарур? Ошбу эшне кылсагыз, Хәбеш солтан илән Илбарыс солтан бер ук атмый качып китәр, алай итмәсәгез, эш яман булыр», — дидем. Хан атам кабул кылмады. Ханның бәкләренә әйттем, алар һәм кабул кылмадылар. Күрә торып бәлагә очрадык, күчеп Гали солтан казыттырган Ташлы Ярмышның сәкасына барып җиттек. Каравыллар яуның карасын күреп кайттылар. Бераз йөргәч, яуның үзе килде һәм орыш башланды. Без мәгълүб булдык. Гарәб Мөхәммәд ханны, тотып, Хәбеш солтан катына алып киттеләр. Шул сәгать Хәбеш солтан атасының күзен чыгартып, кешегә тапшырып, Хивага өй җәмәгатьләренә җибәрде. Үзе Әсфәндияр солтанны куалап Һәзарасыбка китте. Мин фәкыйрь Кятькә бардым, аннан Бохарага киттем. Әсфәндияр солтан вә Шәриф Мөхәммәд солтан вә Хәрәземшаһ солтан Һәзарасыбның кальгасына камалдылар. Хәбеш солтан илән Илбарыс солтан, кырык көн камап торганнан соң, кеше җибәреп яраштылар. Әсфәндияр солтан Мәккәгә дип сәфәр чыкты. Шәриф Мөхәммәд солтанны алып калып, аңа Кятьне бирделәр. Хәрәземшаһ солтан унике яшендә вә Әфган солтан ун яшендә иде. Хивада аналарының катында иделәр. Шәриф Мөхәммәд солтан, Кятьтә дүрт ай торганнан соң, качып Бохарага мин фәкыйрьнең катына килде. Әсфәндияр солтан борынгы Шаһ Габбасны күрде. Хәбеш солтан атасының күзен чыгартканы тарих һиҗри мең утызда вә Тавык елында иде. Хәбеш солтан Өргәнеч илән Вәзир шәһәрендә торды. Илбарыс Хива илән Һәзарасыбта торды. Гарәб Мөхәммәд ханны, өч хатынын, вә ике кечек угланнарын Ком кальгасында үтерделәр.

## Гарәб Мөхәммәд ханның шәһид булганы вә Әсфәндиярнең хан булганы

Бер ел үткәннән соң, Илбарыс солтан, агасы Хәбеш солтанга әйтми, атасын вә ике кечек энесен Хивага китертте. Әсфәндияр солтанның ике углы бар иде: олугы өч яшендә вә кечеге бер ярым яшендә; Хивада Илбарыс солтан катында иделәр. Кечек энесе Әфган солтанны агасы Хәбеш солтанга җибәрде, аны агам үтерсен, дип. Атасын вә Хәрәземшаһ атлы энесен вә Әсфәндияр солтанның ике углын — дүртесен бер җирдә үтертте. Хәбеш солтан, ул яшь угланның ни гөнаһы бар, дип үтерми, урыс падишаһына җибәрде. Әфган солтан, урыс кулында утыз ел торганнан соң, Хак рәхмәтенә китте, аннан нәсел калмады.

Шаһ Габбас Мазый Әсфәндияр солтанга, Хорасан итәгенә барып, йортыңны дәгъва кыл, дип рөхсәт бирде. Аннан соң Әсфәндияр хан Дарунга килде. Бәгъдә Әбү-Әлхан тавына барды. Тәкә вә Сарыйктан җитмеш кеше вә Ямуттан ун кеше кушылды, үзенең өч йөз нөкере бар иде. Ул вакытта Хәбеш солтан Аму суының кыйбла тарафында — Түк кальгасының каршысында утырган иде. Ярым кичәдә килеп, Хәбеш солтанның өен басты, үзе өендә юк иде. Бер нөкеренең өенә барып, миһман булып яткан иде, яуның сугыш трубалары уйнаганын ишетте дә, атланып качып, энесе Илбарыс солтан катына барды. Илбарыс солтан Хәбеш солтан илән икесе Әсфәндияр солтан өстенә йөрделәр.

Өргәнечтә Гарәб Мөхәммәд ханнан калган нөкер вә мин фәкыйрьдән калган вә Шәриф Мөхәммәд солтаннан калганның җөмләсе Әсфәндияр солтан ишегенә иелде. Бакырган астанәсендә Сәед Ата әүлядыннан бер кеше бар иде, аңа Назыйр Хуҗа дирләр иде. Илбарыс солтан аның кызын алды, ул ялганчы мәккярнең[1] сипаһи кыюлыктан бераз хәбәре бар иде. Бакырганнан атланып Әсфәндияр солтанга кеше җибәргән, мин кәминә[2] сиңа бәндәлеккә килдем, әмма синнән ике көн соң барырмын, зирәки якын утырган бәгъде илләренең гаскәрен җыеп ала барырмын. Илле кеше илән атланып, юлда Хәбеш солтан илән Илбарыс солтанга тарафдар булырдай илләргә кереп, гаскәрләрен алган вә тарафдар булмастай илләргә асла кермәгән. Шул көннәрдә халыкның барчасы атланып, Әсфәндияр солтанның килгәнен хуш күреп, атларын белмәгән золымнардан Ходай коткарды дип, кәррә-кәррә булып Әсфәндияр солтанга барыр булганнар. Назыйр Хуҗа, өч йөз-дүрт йөз кеше ияртеп, илләрнең Әсфәндияр солтанга ярдәмгә бара торган олуг юлның өстендә дәрьяның якасына төшеп, бер тарафы дәрья вә икенче тарафына җәяүле вә атлы үтә алмастай итеп үр казытты. Әсфәндияр солтанга ярдәмгә килә торган кешеләрнең бәгъзесен сүз илән вә бәгъзесен көч илән үзенә кушып, болай әйткән: «Ходай Тәгалә күрсәтмәсен, Әсфәндияр солтан йортны алса, ирләрегезне үтерер вә хатын-кызыгызны Әбү-Әлхан вә Мангышлак төрекмәннәренә тапшырыр. Алар өлҗә кылып алып китәрләр, әгәр минем бу сүзем ялган булса, Тәңренең кәляме мине орсын», — дип, һәр кешенең алдында Коръәннән ант эчептер. Әсфәндияр солтанга килә торган кешенең җөмләсен катына җыеп алды. Бала-чагаларыңызны төрекмәннәр өлҗә итәр, дип ант эчкәннән соң, хайваннан фәрекъ[1] булмаган кара халык бик курыкты; бер аксакал сәед һәр көндә Коръәннән йөз кәррат[2] ант эчсә, мин сезләрнең кайгыгызны күрәмен, дисә, кем инанмас. Хәбеш солтан качып киткәндә, яхшы нөкерләрнең барчасы калып, һәрвакытта без синең хезмәтеңә таярбыз, дигән иделәр. Назыйр Хуҗаның өен җәмгъ кылганын ишеткәч, барчасы качып Назыйр Хуҗа катына бардылар. Әсфәндияр солтан, орышып, мәгълүб булып качып Мангышлакка барды, халыкның яхшылары күбесе артыннан барды. Төрекмәннән өч мең кеше кушылды, янә кайтып, Өргәнечкә килде. Үзбәкнең яхшылары, аерылып, аның катына бардылар. Өргәнечтә егерме ике көн үр казып орышты, егерме өченче көн галиб килде. Илбарыс солтанны тотып үтерде. Хәбеш солтан качып Сыр-Дәрья буенда утырган Каракалпакка барды, анда озак тора алмый.

Йим суының якасында Мангыт мирзаларыннан Шаник мирза дигән бар иде. Хәбеш солтан Өргәнечтә утырган мангыттан төшкән илләрне аңа биргән иде. Бар, атаңның йортында утыр, синең бу җиргә килгәнеңне ишеткәч: «Һәр тарафта таралып йөргән мангытлар сиңа җыелырлар, син һәрвакыт миңа ил булсаң. Хәбеш солтан бу йортка нигез салды дигән яхшы ат миңа калыр», — дип, Шаник мирзага ингам вә ихсан кылып озатып җибәргән иде. Үземнең яхшылык кылып сыйлап җибәргән нөкерем, дип, Йим суы буенда Шаник мирзага барды. Шаник мирза, солтанны кулга алып, Әсфәндияр ханга җибәрде. Әмма нөкерләренең атын вә тунын алып, үз ихтыярларына куйды. Әсфәндияр хан Хәбеш солтанны китергәч үтерде. Хәбеш илән Илбарыстан һич фәрзәнд булмады. Хәбеш солтанны үтергәч, ике айдан соң Әсфәндияр хан уйгур илән найманны кырды. Аннан соң барча үзбәк илән яу булды. Үзбәк өчкә бүленде: берсе мангыт, вә икенчесе казакъ, вә өченчесе Мавәраәннәһергә китте. Өч тарафка барганнан соң, Аму дәрьясының диңгезгә барып койган җиренә биш-ун өйлек килә-килә өч мең өйлек җыелды. Бохарадан кайтып Өргәнечтә торган сигез йөз өйлек үзбәк җыелып күчеп, Кять өстеннән өч мең өйлек үзбәккә кушылмакка бара торганда, Әсфәндияр хан, судан үтеп, ул үзбәкнең һәммәсен кырды. Тарих һиҗри мең утыз икедә, Дуңгыз елында Әсфәндияр хан хан булды. Уналты ел падишаһлык кылып, унҗиденче елның әүвәлендә, Елкы елында вафат булды. Инде моннан соңгы булган вакыйгат фәкыйрьнең дастаннарында зикер кылыныр, иншаллаһы Тәгалә.

## Сахибе заман вә хәлифәи дәверан Әбелгазый ханның дөньяга килгәне һәм ата вә бабаларының исемнәре

Өргәнеч вилаятендә тарих һижри мең ундүртенче, Таушкан елында вә Әсәд бөрҗендә[1] вә рабигыль әүвәл аеның унбишендә дүшәмбе көне афтаб[2] илән бергә толуг[3] кылыпмән. Мин дөньяга килердән утыз ел элгәре, Аму суы Хост манарасының югарыгы җирне Кара Айгыр тугае дирләр, ул җирдән юл ясап алып, Түк кальгасына барып, Сыр диңгезенә койган.

Шул сәбәптән Өргәнеч чүл булып калган. Халык, Өргәнеч чүл булса да, хан һәм сипаһи халкы, яз Аму суының буенда муафикъ җирләрдә иген игеп утырып, игенне җыйганнан соң, Өргәнечкә барырлар икән. Мин дөньяга килгән елның яз башында унҗиде кеше Урыс йортына сәүдәгә киткәннәр. Аларга Куш-Җаек дигәндә мең атлы урыс казагы очрап, икесен калдырып, калганын үтергәннәр. Калган ике кешедән Өргәнечнең хәбәрен сорашканнар. Икенең берсе төркестанлы икән, ул әйткән: «Өргәнечнең шәһәрендә сипаһидан бер кеше юк. Сипаһиның якын утырганы бер көнлек юл, шәһәрдә фәкать рәгыйять торыр, бер тарафы чүл. Әгәр чүл тарафыннан йөз мең гаскәр барса, шәһәргә килеп төшкәнче һичкем күрмәс». Ят йортның төркестанлы кеше теленнән килгән хуш өметне вә кулыннан килгән эшне һич аямаган. Урыс, моның сүзенә алданып вә кызыгып, төркестанлыны башчы кылып, мең кеше атлы казак килеп, Өргәнечнең Мирза дәрвазәсеннән кереп, әүвәл дөкяндә[1] торган бер кассабка[2] сөңге илән санчептер. Кассаб аны бер сипаһиның колы хыял кылып: «Нә пух җыясың, кәскәш әрмәне», — дигән. Гафиллек бу дәрәҗәдә булган, шул көнне атлы казак меңләп кешене үтермеш. Ахирел әмер атам урысны куалап, бер кеше куймый кырып бетермеш.

Ошбу вакыйгаттан кырык көн үткәннән соң, мин дөньяга килеп, мин атам әйткән бу газапта (сугыш) галиб булмакбыз. Бу углымның кодумы[3] вә юлы мөбарәк булдыгыннандыр, вә дәхи моның анасының өй җәмәгатьләрен газыйлар дип әйтерләр, ул ягы һәм бар дип, минем исемемне Әбелгазый дип куймыштыр. Атамның исеме Гарәб Мөхәммәд хан, аның атасы Хаҗи Мөхәммәд хан, аның атасы Акатай хан, аның атасы Аманәк хан, аның атасы Ядгәр хан, аның атасы Тимершәех, аның атасы Хаҗи Тули, аның атасы Гарәбшаһ, аның атасы Фулад, аның атасы Менгтимер хан, аның атасы Бадакол, аның атасы Җүчи Бога, аның атасы Баһадир хан, аның атасы Шибан хан, аның атасы Җүчи хан, аның атасы Чыңгыз хан, аның атасы Исүгәй Баһадир, аның атасы Бартан хан, аның атасы Кабул хан, аның атасы Төмәнә хан, аның атасы Байсонкар хан, аның атасы Кайду хан, аның атасы Дутумнән хан, аның атасы Бука хан, аның атасы Буданҗар хан, атасыз Аланкува исемле хатыннан туды. Аланкува Йолдыз ханның нәбирәсе иде. Атасы егетлектә үлде, атадан туып калды, олуг атасы Йолдыз кулында үсте, ул сәбәптән атасының исеме халык арасында мәшһүр имәс, Йолдыз ханның атасы Менгле Хуҗа хан, аның атасы Тимерташ хан, аның атасы Калмаҗу хан, аның атасы Сам Саучи, аның атасы Бука Бәндүн хан, аның атасы Күчүм Борул, аның атасы Кычый Мәргән, аның атасы Тимач, аның атасы Бичин Кыян, аның атасы Куймарал, аның атасы Бурта-Буртачина. Бурта-Буртачина илән Кыянның арасы дүрт йөз илле елдыр. Бу икесенең арасында үткән кешеләрнең исемнәрен беләем дип күп иҗтиһад кылдым, әмма мөяссәр булмады. Һичбер тарихта тапмадым. Әркинәкун эчендәге бозгынлык та булды, шуның өчен тарихлар да язмыйлар. Кыянның атасы Ил хан, аның атасы Диңгез хан, аның атасы Менгле хан, аның атасы Йолдыз хан, аның атасы Ай хан, аның атасы Угыз хан, аның атасы Кара хан, аның атасы Могул хан, аның атасы Әленҗә хан, аның атасы Киюк хан, аның атасы Дип Бакуй хан, аның атасы Илҗә хан, аның атасы Түтәк хан, аның атасы Төрек, аның атасы Яфәс, аның атасы Нух пәйгамбәр галәйһиссәлам, аның атасы Ләмәк, аның атасы Мәтәвешләх, аның атасы Идрис пәйгамбәр, аның атасы Бирд, аның атасы Мөһляил, аның атасы Кыйнан, аның атасы Әнүш, аның атасы Шиш пәйгамбәр, аның атасы Адәм Сафиулла. Инде анам тарафын әйтәем. Анамның исеме Миһербану ханым, аның атасы Хангазый солтан, аның атасы Ширгазый солтан, аның атасы Солтангазый солтан, аның атасы Илбарыс хан, аның атасы Бәркә солтан, аның атасы Ядгәр хан. Ядгәр ханда атам илән анамның атасы кушылыр.

Мин алты яшькә җиткәндә, анам Хак рәхмәтенә китте. Уналты яшькә җиткәнче, Өргәнечтә атам кулында тордым. Аннан соң атам кәдхода кылып, Өргәнечнең ярымын олуг агабыз Хәбеш солтанга вә ярымын миңа бирде. Бер елдан соң Хәбеш вә Илбарыс агаларыбыз илән безнең арабызда низаг чыкты. Шул сәбәптән Өргәнечтә тора алмый, Хивага атабыз катына килдем. Хивага килгәч, атам миңа Кятьне бирде. Яз башында Кятькә барып, алты ай торганнан соң, атамыз илән атланып Хәбеш илән Илбарыс өстенә бардык. Ул вакыйгатны тәфсир кылаем.

Сугышта хан ата төптә, ягъни уртада булды. Әсфәндияр ханны сулга вә мин фәкыйрьне уңга куйды. Олуг орыш булды. Фәкыйрь өч ат егылганчы орыштым. Барча халыктан соң киттем. Катымда бары алты кеше булды, артыбыздан яу куып җиткәч кайтып орыштык. Яу — кырык кеше — берьюлы һәммәсе безгә һөҗүм кылды. Без яу илән бергә аралашып киттек. Катымдагы бер кешем илән яудан качтым, башка кеше-

ләремнең һәркайсы бер тарафка китте. Ук илән атышкан вакытта яуның берсе ук илән авызыма орды. Яңагымның сөякләре парә-парә булып, авызым эче кан илән тулды. Дәрьяның яры биек иде, бераз дәрья буе илән баргач, яуның күзе мине күрми, үзгә кешеләрне кудылар. Шулай качып барганымда, атымның аягы тычканның өненә батып, шулкадәр каты егылып китте ки, мин атның өстеннән дүрт-биш адым ерак чәчрәп киттем. Ат, торып, яуның гауга салганыннан качып китте. Катымдагы кеше, миңа атын биреп, үзе җәяү калды. Ялгыз барганымда күңелемә бу килде: яу мине күрми калмас, һәр җиргә барсам да, артымнан бармый булмас, бәлки, мәгъкуле шул ки: суның якасына төшеп икенче ягына үтмәк җәһәтен күрмәк кирәк дип, су янына килдем. Яры бәләнд, һич җирдән төшмәгә юл тапмадым, янә югарыдан йөреп бер төштән су читенә төшеп идем, бер бәләнд ярның төбендә яшеренеп торган өч кешене күрдем. Безнең кешеләр икәнен танып, катларына бардым, һичкайсысын танымадым. Аларның берсе мине таныды, әмма һич файдасы тимәде, вә бер хезмәт кылмады, үз эше илән булды. Сөңге вә кылычымны чиштем, көбәмне[1] салдым, путамны чишәем дип торганда, ярның өстеннән биш-алты җәяүле кешеләр килеп, безгә ата башладылар. Теге өч кеше, киемнәрен салып, ялангач көе суга төшеп йөзә бирделәр. Яу ярдан төшәем дисә, юл юк. Ярның өстеннән ялгыз мине ата бирделәр. Көбәне иярнең каршына салып, башым вә аягым илән суга төштем. Чапканда кызып килгән ат су эчмәк илән булды. Кулымда камчы да юк иде. Йөз бәла илән атны суга салдым. Анамнан туганлы бирле ат ялдаганым юк иде. Ялдап йөри биреп артыма карасам, алты кеше һәнүз миңа атып торырлар. Ходай Тәгалә саклады, берсе дә тимәде. Борынгы ярадан авызымның эче тулы кан иде, төкерәдер идем, янә яңадан тула иде. Итекнең эченә су тулды, су тулгач, һәр аягым ун батман кеби авыр булды. Барча киемнәрем су булды. Суның урта җиренә җиткәндә, атымның колагы илән борыны гына күренде, башка җире батты. Бер карт кешедән ишетеп идем: һәркайчан яудан качарга тугры килеп кием илән ат өстендә судан үтәргә булсаң, бер аягыңны, аркасыннан үткәреп, атның койрыгына куй, икенче аягыңны өзәңгедә калдырып, үзең тик тор, бер кулың илән иярнең арткы тарафын тотып, икенче кулың илән атның җалавын күтәреп тартып тот. Болай кылмасаң, ат кием-салымлы кешене алып чыга алмас. Ат батып китә башлагач, шул кешенең сүзе исемә килде. Аның әйткәненчә эш кылдым. Атым түшенәчә судан югары күтәрелеп, аткан ук кеби, судан йөзде. Атым һәм үзем суның икенче тарафына сәламәт чыктым. Бәгъдә теге өч кеше яныма килделәр, ике көн булганда Кятькә кайттым.

Нөкерләребездән бер кеше моннан элгәре кайтып, мине үлде дип торганнар. Алар илән кушылганнан соң, ат вә азык алып, Мавәраәннәһергә киттек. Сәмәркандка барып, Имамколый ханны күрдем, гыйззәт вә хөрмәт кылды. Яхшы килдең вә хуш килдең, егет кеше, син, йортыңа кайтып барырсың, кайгырма, дип, күңелемә тәсәлла[1] бирде. Әсфәндияр хан качып кызылбашка барды. Минем кечек энем алты айдан соң Хәбеш вә Илбарысның яннарында тора алмый, качып минем катыма килде. Әсфәндияр барганда, Гаҗәмнең падишаһы Габбас Мазый дигән кемсә иде. Ул, Әсфәндияр ханга Дарун, Нисайга бар, Өргәнечкә кеше җибәр һәм Әбү-Әлхан төрекмәненә кеше юлла, дип рөхсәт биреп озатты. Әсфәндияр хан Дарун килде, безгә килсеннәр, йортны бергә сораек, дип, кеше җибәрде. Имамколый ханнан ике-өч кәррә рөхсәт теләдек, үзем гаскәр кушып ярдәм биреп, йортыңны үзем алып бирермен, дип, Әсфәндияр хан катына кайтырга рөхсәт бирмәде. Әсфәндияр хан Өргәнечтә атасының нөкерләре, вә үз нөкерләре, вә безнең нөкерләребез илән сөйләште. Әмма күбрәге минем нөкерләрем иде. Фәлән айның фәлән көнендә дип вәгъдә кылды һәм атланып йөри бирде. Үзенең катында өч йөз кешесе бар иде. Әбү-Әлхан төрекмәненнән йөз кеше кушылды.

Ул вакытта Илбарыс Хивада иде, Өргәнеч суы корып чүл булган иде. Шуның өчен Хәбеш Түк кальгасының тугрысында Аму-Дәрьяның якасында чылбыр кылып вә үр казып утырган иде. Сәхәр вакытында килеп чылбыр эчендә Хәбешнең өен басты. Хәбеш өендә юк иде. Моннан хәбәрдар булып шул хәл качып котылды. Әсфәндияр ханның дастанында бу вакыйгатларның барчасын әйттек. Әсфәндияр хан орышып мәгълүб булып, Мангышлакка китеп, кайтып килеп, йортны алды. Илбарысны тотып үтерде, Хәбеш качып китте. Без Имамколый хан катында ике ел тордык. Аннан соң, Әсфәндияр хан йортны алды, дип, кеше килде. Имамколый, яхшы, кайтыгыз, дип рөхсәт бирде. Шәриф Мөхәммәд илән Өргәнечкә килдек. Әсфәндияр ханны хан күтәрделәр. Хива вә Һәзарасыб һәм Кятьне ул алды, Өргәнечне миңа бирде, Вәзирне Шәриф Мөхәммәдкә бирде. Бу вакыйгат тарих мең утыз өчтә, Дуңгыз елы, Мизан бөрҗендә вакыг булды.

## Әбелгазый ханның егерме бер яшеннән егерме өч яшенәчә башыннан үткән вакыйгалары

Мин егерме яшемдә вакытымда, Сычкан елында игеннәрне җыеп алганнан соң, көз көне барча халык Әсфәндияр ханны барып күрмәкне мөнасиб күрделәр. Шәриф Мөхәммәд солтан илән Бәркә атланмак булганда, бер кичә Шәриф Мөхәммәдне өч яхшы кешесе илән үземнең ике яхшы кешемне чакырдым һәм әйттем: «Инде бармак булабыз, сез ни мәслихәт бирәсез?» — дигәч, һәммәсе: «Бармак мәгъкуль», — дип диделәр. Әсфәндияр ханнан: «Куркыныч бармы?» — дип сорадым. Алар: «Юк», — диделәр. Мин әйттем:

«Сез кешегә әйтмәскә шарт кылыгыз ки, мин күңелемә ни әйтәем». Алар: «Әйтмәбез», — дип ант эчтеләр. Мин әйттем: «Әсфәндияр ханның йортын килеп алганына бер ел булды. Кырдан килгән төрекмәннәрнең яхшыларын ни өчен җибәрми торыр? Әлбәттә, аларга кылган бер вәгъдәсе булмак кирәк. Без барганнан соң, үзбәкне кырыр». Алар әйттеләр: «Алай булгач, ничек эш кылаек?» Мин әйттем: «Әсфәндияр хан катына бармасак, Хивада торган үзбәкне кыра алмас, юк, бармыйк, әгәр бармакны охшатсагыз, Хивага якын җиткәндә үзбәк вә төрекмән һәм Әсфәндияр ханның барча нөкерләре безгә каршы килерләр, төрекмәннәрне шул вакытта кыраек. Аннан соң Әсфәндияр ханның алдына барып, болай әйтеп гарыз кылаек ки, төрекмән фикерсез вә гакылы аз халык һәм безнең илән каты дошмандыр. Җаныбызны коткармак өчен бу эшне синең рөхсәтеңнән башка кылдык, диербез», — дидем. Ул арада Шәриф Мөхәммәд киная итеп әйтте: «Әсфәндияр ханны үтерәек. Аның урынына Әбелгазый агамны хан күтәрәек». Утырган кешеләрнең барчасы минем сүземне яман күреп, Шәриф Мөхәммәднең сүзен «мәгъкуль» диделәр. Уйгур халкыннан Корбан Хаҗиның углы Колмөхәммәд дигән зат минем атам урынына ата кылган идем. Ул әйтте: «Мондый сүзне әйтмәгез, әгәр әйтер булсагыз, Әсфәндияр ханга әйтермен».

Моннан соң ихтыярсыз Әсфәндияр ханны күрмәккә килдек. Күргәннән соң, өч көн Хивада тордык, дүртенче көнне, ханның фәрманыдыр, уйгур, найманны үтерегез, үзгә илләргә тимәгез, дип, һәр җирдән яр салдылар. Шуннан табылганын үтерә бирделәр. Ул көнне шәһәр эчендә уйгур илән найманнан йөз вә гайре үзбәктән ун кешене үтерделәр һәм барча үзбәккә чап угыл дигәнне ихтыярлы кылдылар. Ул уйгур вә найман бәһанәсе[1] илән Һәзарасыбтан Тост манарасынача утырган үзбәкне чапты. Куып җиткән үзбәкне үтерде, җитә алмаганының малын алды. Уйгур илән найманның карт, вә егет, вә баланы бер айлыгынача үтерде. Шәриф Мөхәммәдне, һәр җирдә уйгур, найман булса үтер, дип, Өргәнечкә җибәрде. Мине үз янына алып калып, берничә кешене сакларга боерды. Өргәнечнең үзбәге, үзара утырып, Әбелгазыйны үз кулыбызга алаек, дип киңәш кылганнар. Бу эш тизлек илән мөяссәр булмас, бәлки бер тәдбир кылаек, шаять, тәкъдиргә муафикъ төшәр, дип, Шәриф Мөхәммәд илән кушылып барган төрекмәннең яхшы кешеләрен чакырып әйткәннәр ки: «Барчабыз, бу йортны ташлап, Бохарага күчәбез. Әгәр безне Әсфәндияр хан китмәсен дисә, Әбелгазый солтан илән Мөхәммәд Хөсәен бәкне җибәрсен. Солтан агасының йөгенә кереп вә бәк барча төрекмәннәрнең йөгенә кереп, яманлык асла итмәбез, дип кыйсем итсәләр, урыныбызда калырбыз, әгәр алай итмәсәләр, Шәриф Мөхәммәдне алып киттек», — дип, бераз җир күчеп киттеләр. Илнең алды дүрт күчеп, арты ике күчкәннән соң, төрекмәннәр, инанып, бер яхшы кешесен Әсфәндияр ханга чаптырмышлар.

Өйлә намазын укып утырып идем, Өргәнечтән Тәңребирде килде, диделәр. Ул килгән төрекмәннең исеме Тәңребирде иде. Төрекмәннең инабәтле кешеләреннән саиле[1] иде. Шулай булса да, үзе бик куркак иде. Аның куркаклыгы минем җитмәгән әҗәллемгә[2] сәбәп булды, ханны һәм төрекмәнне куркытты. Шул заман, Әбелгазый илән Мөхәммәд Хөсәен бәк барсын, дип, хан хөкем кылды.

Без атланып йөри бирдек һәм барып Өргәнечкә җиттек. Ул вакытта Өргәнечнең кальгасы чүл булганлык сәбәпле, Аму суының кыйбла тарафындагы якасында Түк кальгасының каршысында кальга салып, шунда утырган идек. Кальгада үзбәктән һич кеше юк иде. Мин барып өемә төштем. Шәриф Мөхәммәд минем катыма килде. Мөхәммәд Хөсәен бәк бер сартның өенә төште. Шәриф Мөхәммәд илән бергә барган төрекмәннәр һәм бәк илән барган төрекмәннәр җитмеш-сиксән кеше бәк катында булдылар. Үзбәкнең һәммәсе суның аргы ягында анча эшкә ярарлыкларыннан утыз кеше мине күрергә килде. Бу әйтә торган сүзләребезнең барчасы бер көн эчендә булган вакыйгадыр. Намаз гыйшаины укыганнан соң, барчасы җыелып минем катыма килеп, йорт киңәшен кылдылар. Шәриф Мөхәммәд солтан, башлыклар һәммәсе әйттеләр: «Бу кичне дүрт якка кеше җибәрәек, таң атканда мең кеше дәрвазәдә хәзер булсын. Мөхәммәд Хөсәен бәк башлыкны ошбу төрекмәннәр илән бергә кылаек, соңра Хивада утырган төрекмәнне чабаек, бу кыш Хиваның кальгасын камап ятаек, яз башы илән алырбыз», — диделәр. Мин әйттем: «Бу төрекмәнне кыра алмассыз, ишетеп, барчасы качар. Кышта төрекмәннең барчасы Хива өстендә булыр, аны һәм ала алмассыз. Әгәр Хивага барып торсагыз, өегез илсез калыр, калмык килеп, бала-чагаларыгызны алып китәр. Мөхәммәд Хөсәен бәк башлык төрекмәннәрне яхшы сыйлап җибәрик, Шәриф Мөхәммәд Көюк кальгасында кышласын, үзбәкнең һәммәсен, үз вакыты җиткәч, Шәриф Мөхәммәд илән безнең арабызга китерәек, һәрберсе йөз өйлек вә мең өйлек бер чиб салып кышласын. Калмыкның ике юлына каравыл куяек, хутның ун көне булганда, бер кешене өйрәтәек, атын тирләтеп чабып алдыма килсен һәм әйтсен, әтрафка һәм юлларга куйган каравыллардан киләмен, төнәге көн кич илән калмыкның Олуг Тулинең утын күрдек, йолдыз кеби ялтырыйдыр иде. Каравыллар, моны күреп, үзләре дә качтылар; миңа өч ат биргән иделәр, икесен юлда ташлап киләмен, дисен. Шул заман мин бу җирдән атланаем. Шәриф Мөхәммәдкә кеше барсын, ул һәм шул заман атлансын, бер җиргә җыелаек. Күп булса, эчебездә биш-алты йөз төрекмән булыр, ул җирдә аны кыраек һәм Хива өстенә йөрәек. Бу вакытта Әбү-Әлхан вә Мангышлакның төрекмәне ашлык алмак өчен Хивага килмешләр. Барчасы җылы өенә таралыр. Язын куй-кузыйларга Хивада ут-үлән булмас, раң[1] чыгар.

Хива төрекмәне комга китәр. Сарт иген икмәк өчен үз-үзенә китәр. Хива эчендә Әсфәндияр хан катында күп булса — йөз, аз булса — илле кеше калыр. Гафил булып торганда барып, дәрвазәнең авызына төшәрбез», — дидем.

Әмма минем бу сүземне кабул кылмадылар. Минем башыма һәм үзләренең башларына күп мәшәкатьләр салдылар. Мөхәммәд Хөсәен безнең касд кылганыбыздан хәбәрдар булып ил йоклап булгач (торгач. — *М.Ә.*), дәрвазәдән чыгып качты. Безнең килергә вәгъдә биргән нөкерләребез намаз вакытында килделәр. Мөхәммәд Хөсәен бәк ул вакытта ике мәнзил җир киткән иде. Һич файда кылмады. Олуг-кечек утырып киңәш кылдылар. Мин әйттем: «Әсфәндияр ханга болай әйтеп кеше җибәрәек: Мөхәммәд Хөсәен бәк үзе курыкты, шул сәбәптән качып китте. Әгәр безнең касдыбыз булса иде, без олуг йорт утыз-кырык кешене шәһәрнең эченнән чыгарып җибәрер идекме? Әгәр дәрвазәне бикләсәк, ни җирдән чыга алырлар иде, дип. Әсфәндияр хан бу сүзгә ышанып, төнәген әйткән сүземдер ки, яз булгач, калмыктан хәвефебез китәр, калмыкка атланган булып гафиллеккә барып, Хиваның дәрвазәсенә төшәек». Шәриф Мөхәммәд башлык, барча халык минем сүземне кабул кылмадылар.

Атланмакны мөнасиб күреп, Хива өстенә йөрделәр. Яман эш кылдыгыз, йортны боздыгыз, дип әйтә-әйтә, ике көн соңлап артларыннан бардым. Ханкяһның арыгының буенда Таш-Күпрүк дигән җиргә барып төштек. Төрекмәннең ачлыктан йөдәгән арык илен табып үтердек, сартларга тимәдек. Башка кәндләрнең барчасы Хивага күчеп киткәннәр иде. Ханкяһтан бер өйлек тә күчмәгән иде. Һәр көндә базар булып торды. Кырык көн булганнан соң, калмык килде, дәхи җөмлә илебезнең биштән берен алып йөри бирде. Халыкның намуслысы калды, кара яман халык өенә китте. Бу хәбәрне төрекмән ишетеп, Әбү-Әлхан вә Мангышлактан күмәге килгәч, Хивадан чыгып, чишмәнең өстендә безнең илән орышты.

Безнең гаскәребез торган җир төз җир иде, аларның гаскәр торган җиренең артында алты вә җиде арык бар иде. Орыш йөзмә-йөз килгәндә: «Алла, Алла!» — дип йөгердек. Яу качты. Яуның тугы алты арыкның уртасында иде, пиядә гаскәр тугның янына ятканчы үтерә-үтерә барды. Аннан соң яу качты, инде өлҗәдән коры калмыйк дип, һәркем атына йөгерде. Килеп, атларына менгәч карасалар: яу җиде арыкның уртасына бер җиргә җыелып торыр, безнең хәрәкәтебезне карап торыр, безнең хәбәребез булмады. Шул заманда яуның бер өлеше калып, икенче өлеше качып киткән, имеш. Ул серне безнең кара халык белмәде. Икенче мәртәбә орышмакка тәкать тота алмый качып китте. Шәриф Мөхәммәд илән икебез мәйданда калдык. Гаскәребезнең барчасы киткәнче, төрекмән карап торды. Аннан соң арыкларны үтеп аһәстә[1] йөри бирде. Шул вакытта минем катымда һичкем калмады, күңелемнән әйттем: бу халык куышка барып, аттан төшеп берексә яхшы булыр иде, әгәр алай итмәсә, бүген көн батканчы яу куар булса, җан калмас дип, һәммә җиргә чабып барып, халыкка, чибкә керегез, чибкә керегез, әгәр кермәсәгез, токымыгыз калмас, дип, чибкә килдем. Утыз-кырык кеше керми китте. Дүрт-биш йөз кеше моннан элгәре килеп, куыштан ары һәммәсен чибтән чыгарып алып барганда, җитеп орып кайтардым, килгәнен чибкә кергездем. Атларның иярләрен алдырдым. Безнең кешеләрнең соңгы илән яу бергә килде. Чибтән пиядә чыгып кичкәчә орыштык. Төрекмән мылтык җитмәстәй җиргә килеп төште һәм чиб ясады. Алты көн орыштык, җиденче көнне солых кылаек дип, кеше җибәреп яраштык. Безгә касәм әйттеләр вә, Әсфәндияр хан һәм безгә ант эчте, яманлык кылмам, дип. Без әйттек, сез күчеп көнтугыш тарафына китегез, без һәм өебезгә китәрбез, дидек. Алар күчеп киткәч, без һәм, чибтән чыгып, дәрья якасына барып кундык.

Иртә илән боз өстеннән үтеп өебезгә киттек. Чабылганнан калган дәрьяның ике тарафында утырган үзбәкнең һәммәсе куйларын багып Өргәнечкә күчте.

Инде Әсфәндияр ханны әйтәек. Аның ярашканының хыялы бу иде: ант эчеп, үзбәкне чибтән чыгарыйм, чыкканнан соң, шул сәгать дәрья буена җиткерми артыннан җитеп басаем дип. Бу хыял илән күчеп, безнең югары тарафыбызга чыкты. Төрекмәнгә, торыгыз, үзбәк чыкканнан соң, артыннан бараек, дип, Әсфәндияр хан чакырыптыр. Әмма төрекмән, аның сүзен тыңламый, Ханкяһның сартына чап угылны калдырып кайтып китә биргән, хан катында фәкать йөз кеше калган, өч көндә Ханкяһны чабып, өлҗәне бүлешеп, бер җиргә җыелмыш. Аннан соң Әсфәндияр хан Аму дәрьясының бозыннан үтеп, безнең артыбыздан йөри биргән. Безнең артыбыздан күчеп килә торган илнең бер кешесе, Хуҗа күлендә яуны күреп илгә хәбәр биргән, ил, моннан өркеп, Биштүбәнең кыры өстендә бер ягы су вә икенче ягына арбадан күрән тартып кояш ике сөңге буе менгән вакытта яу илән орышканнар, һәр ике тараф җәяү барып. Үз күзем илән күрдем: үзбәк дүрт йөз илле кеше вә төрекмән биш мең кеше икенде намазынча орыштылар. Үзбәктән егерме кеше үлде, йөз кеше яралы булды. Төрекмәннән җитмеш кеше үлде, ике кеше яралы булды. Ул кичәне һәр ике тараф ятып, иртәсе көн ике якның һәркайсы йортына кайтып китте. Ул язны Әсфәндияр хан Хивада вә Шәриф Мөхәммәд илән фәкыйрь (Әбелгазый. — *М.Ә.*) Өргәнечтә булдык.

## Өргәнеч үзбәгенең бозылганы

Ил халкы йорттан күңелен суытты. «Китәек» димәктән гайре сүзне әйтмәде. Ялтыравык йолдызы туганнан соң, җыелып-җыелып Бохарага вә Төркестанга китте. Бер киткән төбнең төркеме артыннан кудыра кеше җибәрдем, аны кайтарып алып килгәнче, ике-өч бүлеге китте. Минем катымда торган яхшы халык кара, яман халыкка әйтте: «Бу йорт булмас, ник торасыз, китегез, без һәм артыгыздан тиз барырбыз», — дигәч, халык аз-аз күчә-күчә мизанның ахыры вә гакрәбнең әүвәлендә өч кәррә булды. Берсе — Бохарага, вә икенчесе — Казакъстанга, вә өченчесе Мангытка йөреп китте. Шәриф Мөхәммәд Бохарага китте, вә мин Казакъстанга киттем. Төркестанда Ишим хан катында өч ай тордым.

Ул вакытта казакъның ханы Торсун хан иде. Ташкентта ул Төркестанга килгәч, Ишим хан аны күрергә барды, мине өендә калдырды. Үзе, Торсун ханга күренеш кылып кайтып килеп, минем кулымнан тотып алып барып, күренеш кылдырып әйтте: «Бу Ядгәр хан углы Әбелгазыйдыр, һичбер вакыт бу җәмәгатьтән безгә килеп кунак булган кеше юк иде. Бездән барган күп булды. Инде бу сезнең хезмәтегезгә килде». Торсун хан: «Яхшы әйтәсең, шулай булсын», — дип, мине үзе илән бергә Ташкентка алып китте. Ташкентта Торсун хан катында ике ел тордым. Ике елдан соң Ишим хан Торсун ханны үтерде, Катыгыйнны кырды. Ишим ханга әйттем: «Сез ике ханнан файда тияр микән дип килгән идем, сезнең эшегез болай булды. Инде, рөхсәт итсәгез, Имамколый хан катына китәр идем», — дидем. «Яхшы әйтәсең, шулай кыл», — диде.

Аннан соң килеп, Имамколый ханны күрдем. Минем Бохарага килгәнемне ишетеп, төрекмән кеше җибәрде, Әбелгазый солтан килсен, ят йортта йөрмәсен, дип. Торсун хан Имамколыйның дошманы иде. Ул үлгәннән соң, Имамколый хан катына тормакка ошатмадым вә дәхи Имамколый хан ике кәррә Торсун хан катында йөреп килгәнемне киная илән әзһәр кылды. Үзбәк халкына әйттем: «Мин бу йортта тора алмыймын, бу турыда сезләр ни әйтәсез?» — дигәч, алар әйттеләр: «Хәзерге заманда төрекмән эченә бармакың мәгъкуль күренәдер. Кайчан булса да синең күңелең бездән суынып дигән гөманыбыз юктыр, әмма Шәриф Мөхәммәдкә ышана алмыйбыз, күңеле бездәме вә йә төрекмәндәме?» Бәгъдә төрекмәннән янә кеше килде, төрекмән Әбелгазыйны китерә, миңа канәгать кылмый, дип. «Әсфәндияр хан качып Һәзарасыбка барды», — дип хәбәр бирде.

## Әбелгазый ханның Хивага төрекмән эченә килгәне

Аннан соң мин биш-алты кеше илән Хивага килдем. Шәриф Мөхәммәд миннән ике айдан соң Һәзарасыбка Әсфәндияр хан катына килде. Аларның икесе бер булып минем илән орыштылар. Мин җиңдем, солых кылдылар. Алты айдан соң Хивада гафил утырганымда икесе тиз йөреп дәрвазәгә якын төштеләр. Тышкары утырган төрекмәннәрнең кара яман халкы Әсфәндияр ханга иелделәр. Алар биш мең кеше булды вә минем катымда алты йөз кеше булды.

Беркөн егерме кеше Һәзарасыбка йорт-угыл җибәрдем. Ил чабып, мал алып кайтып килгәндә, мал иясе, йорт-угылдан элгәре килеп, Әсфәндияр ханга хәбәр бирде. Ул, Шәриф Мөхәммәдне атландырып, йорт-угылны Әбелгазыйга кушылмастан мөкатдәм ал, дип җибәрде. Йорт-угылдан миңа каршы чыгыгыз, дип, кеше килде. Мин Шәриф Мөхәммәднең атланганыннан һич хәбәрем юк иде. Йорт-угылга йөз кеше җибәрдем. Хиваның Гөлбанбаг кәнденең кыйбла тарафында Шәриф Мөхәммәд йорт-угылга очрап, шул вакытта һәм безнең җибәргән йөз кеше барып җиткән. Шәриф Мөхәммәд, Әсфәндияр ханга кеше җибәреп, ярдәмгә гаскәр сораган. Йорт-угылдан һәм миңа ярдәм сорап кеше килде. Безнең кешебез орышып Хива тарафына йөргән, шул вакытта икесенең һәм ярдәмгә килгән гаскәрләре җитешеп, шул җирдә олуг орыш булды. Бер ит пешкәнче орышкач, яу качып китте. Әсфәндияр ханга килеп җиткәнче кудык. Сүз күп иде, һәммәсен язсак озын буладыр. Шуннан соң яраштык.

Шул вакытта ике йөз җәяүле үзбәкнең яхшысы Бохарадан күчеп Кять өсте илән Аралга барды. Аны ишеткәннән соң, Әсфәндияр хан Шәриф Мөхәммәд илән (мин. — *М.Ә.*) фәкыйрьне чакырып, Шәриф Мөхәммәдкә хөкем кылды ки: «Син бу кичә качып үзбәк эченә бар, без һичнәрсәне белмәгән булаек», — диде. Шәриф Мөхәммәд качып китте. Сабах төрекмәннең яхшылары, Әсфәндияр хан катына барып: «Энегезнең киткәнен белермесез?» — дип сорадылар. Әсфәндияр хан: «Бу эштән һич хәбәрем юктыр, — дип ант эчептер, — әлбәттә, бу Әбелгазыйның шомлыгыдыр», — диде. Барча төрекмәннәр ханның бу сүзенә инандылар.

Беркөн иртә сәхәр илән Әсфәндияр хан төрекмәннең яхшы кешеләрен берәм-берәм чакырып алып әйтте: «Әбелгазый Бохарадан үзбәкне, кеше җибәреп, Аралга китертте. Моннан Шәриф Мөхәммәдне җибәрде. Моның мәслихәтен кылаек. Минем бу эштән асла хәбәрем булмады, йоклап ятар идем», — дигән. Таң атканчы шәһәрдә булган төрекмәннәрнең барчасын үзенең катына әрк эченә кергезеп, дәрвазәгә кеше тәгаен кылып, бер кешене әрктән чыгартмаган. Минем катымда биш-алтыдан артык кеше юк иде. Таң атканнан соң, мине тоттырды, үзенең инабәтле кешеләреннән егерме кешегә мине тапшырды, кызылбашка илтеп

бирдерде. Кайсы кешеләр мине Абъюрд хакименә илтеп кайттылар, ул, илтеп, мине Хорасан бәкләр бәгенә тапшырды. Ул Гыйракка алып китте. Ул вакытта Шаһ Габбас Мазый вафат булып, урынына нәбирәсе Шаһ Сафи дигән зат падишаһ булган иде. Аны Һәмаданда күрдем, ул мине Исфаһанга җибәрде, бер аерым җай[1] бирде, вә ашамак-эчмәгемә һәр елда ун мең тәңкә акча бирде, вә, качмасын дип, кеше тәгаен кылды.

## Әбелгазый ханның Гыйрактан качып хан булганчы булган вә кылганнары

Гыйракта Исфаһан шәһәрендә ун ел тордым. Катымда өч кешем бар иде. Аларга әйттем: «Инде качамын, сезләр миңа һәмраһлык кылыгыз». «Яхшы, мәгъкуль», — диделәр. Җиймәк өчен безгә бирелгән эре акча бар иде. Шуны мине саклый торган кызылбашка биреп: «Тизлек илән ватып китер, — дидем һәм: — Үзең өчен бер кол хатын-кыз сатып ал». Бераз үзенә акча бирдем. «Әгәр акчаң артса, кайтарырсың, артмаса — синеке булыр», — дидем. Ул сарыфка китте.

Без, сәхәр илән торып, ат базарыннан сигез ат алдык. Берәм-берәм китереп, йортта кеше күрмәстәй өйләрдә яшерттем. Ил ятканнан соң, барчасын йөгәрләттем. Эчебездә фарсы вә төрки белә торган кеше бар иде. Аны бәк кылдым, бер егетне дәстәрханчы кылдым вә дәхи бер егетне хезмәткәр сурәтендә кылдым. Үзем ат бага торган кешенең киемнәрен кидем. Аннан соң бер-беребезнең сакалыбызны алдык һәм атларны берәм-берәм тышка чыгардык. Олуг шәһәрләрдә ярым кичә булганда нәкарә[2] кагарлар. Ул вакытта нәкарәханәдәге нәкарәгә агач куйдылар. Атланып йөри бирдек. Дәрвазәгә якын килгәндә, шылтыр-шылтыр итеп дәрвазәнең йозагын ачты да дәрвазәне ике тарафка ачып җибәрде, аннан чыгып, Бистамга киттем. Бистамга җитәр алдыннан өч атыбыз йөрмәде. Кич өйлә вакыты иде, юл өстендә Бистамның Бөеш дигән кәнденә килдем. Мазарстанда өч кешене мәет дәфен кылганнарын күреп: «Кем сез?» — дип сорадым. Берсе җавап биреп әйтте: «Сәедмен», — диде. Карарга бик фәкыйрь кеше иде. «Без Мәшһәдкә барабыз, атларыбызга җим алып бирсәнә», — дип, аның кулына ун тәңкә акча бирдем. Өч атыбыз, симезлек кылып, йөрмәде. «Кәнд халкына хәбәр ит, ошбу атларыбызны атка алышырбыз», — дидем. Сәед илән өенә бардык. Диварның саясында[1] зилүҗә[2] салдылар, бәгебез түшеп анда утырды. Бер егет аның алдында кул кушырып торды. Бер егет атларны тотып торды. Мин, өч йөри алмаган атны кулыма алып, атка алышмак илән мәшгуль булдым. Сәед, арбаны алып кайткач, халыкка яр салды. Бер сәгатьнең эчендә ике йөз кеше җыелып килеп, кырык-илле ат китерделәр. Базар булды. Ике атыбызны алыштырдым, бер атыбыз калганда, озын буйлы, ак сакаллы җитмештән узган бер кеше яныма килеп торды.

Бистамның ике юлы булыр, бер юлы кәрван йөри торган вә икенчесе тау эченнән китеп ике көндә олуг юлга кушылыр. Аны үзенең җирле халкыннан башка кеше белмәс, дип ишетеп идем. Халыктан сорадым: «Моннан Магаз дигән кәндкә бара торган туры юлны миңа әйтсәгез лә», — дидем. Баягы ак сакаллы карт кеше кычкыра бирде: «И халык угыллары, өйлә намазыннан бирле мин сезгә ике-өч кәррә әйттем, минем сүземә инанмадыгыз, әлхәмделиллаһ вә әлмәнтә, минем сүзем раст булды. Безнең бу кәндебезнең кешеләре уннан бере Магаз юлын белмәс, олуг юл илән китми, Магаз юлын бу кеше ни өчен сорыйдыр? И халык угыллары, бу кеше үзбәк шаһының тоткыннарыннандыр, камаудан чыгып, качып Сәмәрканд барырлар. Шул көн сабах моның артыннан шаһның куучысы килер, һәркем моңа ат сатса, гөнаһкяр булыр. Кулыгыздан килсә, моны, тотып, Бистамга хаким алдына илтегез. Әгәр ул эш кулыгыздан килмәсә, фәкать моңа ат бирмәгез», — диде.

Барчасы таҗик сөйлидер, һич төрки белгән кеше юк. Мин гарәп, фарсысының телен яхшы белер идем, мин шул тел илән әйттем: «И монафикъ карт, өйлә вакытыннан бирле йөз һәзәян вә бөһтан[3] гөман илән сөйләдең, мин сүзеңә илтифат итми тордым, шаять, бу юк сүзен куяр дип. Син аның саен арттырдың, кис кылмадың». Моннан мөкатдәмдә әйткән идем ки, бер нөкеремне бәк кылып, калын өстендә утыртып, алдында бер егет кул кушырып торды, дип. Магаз юлын сораганымның мәгънәсе бу ки: Хорасаннан шаһка кеше барды, Чыгтай Кандаһарны камады һәм, үтеп китеп, Пәст кальгасының өстендә Гыйрак вә Хорасан гаскәре илән орышты да галиб булды, дип. Шаһ хөкем кылды, колдан вә кара халыктан һич кеше калмасын, барчасы ярдәмгә барсын, дип. Ул утырган кешене Мөхәммәдколый бәк чиркәс дирләр, йөз башыдыр. Мин Исфаһаный Хәсәнә мәхәлләсеннән. Минем атам мин туган вакытта вафат булыптыр. Анам әлхәл бардыр, әмма сачы агарыптыр. Өч елдан бирле Мөхәммәдколый бәккә нөкермен. Бәк Хорасанга киткән вакытта мин һәм бергә китмәк булдым. Ул вакытта анам әйтте, улым, атаң үлгәннән соң, бер талиб әлгыйлемне угыллыкка алдым, сиңа хәер-дога кылсын, дип. Һаман аның азыгын биреп вә киемен тегеп, керен юар идем. Бистамның Магаз исемле кәнденнән мин дир иде. Егерме ел Исфаһанда гыйлем тәхсил кылып кайтып китте. Үзем һәм белермен, әүвәл һәр елда хаты анама килеп торыр иде, өч елдан бирле һич хат-хәбәре булмады. Анам әйтте, ничек углым буласың, ул мелла һәм синең кеби углымдыр, аның өенә бар, те-

рек булса, хатын вә хәбәрен алып кил, үлгән булса, минем өчен фатиха укы, әгәр моны кылмасаң, сиңа сөтем хәләл булмасын, диде. Төнәге көн Мөхәммәдколый бәктән рөхсәт теләдем. Ул, бар, диде. Шул сәбәптән Магазның юлын сорыймын, дидем. Мин бу сүзне әйткәч, җәмәгатьнең барчасы: «Дөрес әйтәдер, мелланың ике елдан бирле хат җибәрмәгәне хактыр, зирәки аның аттан егылып аяклары сынган иде. Ошбу көннәрдә таяк илән тышка вә эчкә чыгып-кереп йөри башлады, газиз вә тәбәрәк кешедер, һәмишә әйтә торган иде, Исфаһанда бер угыллы тол хатынны ана кылдым, егерме ел минем керемне юып, хезмәтемне кылды, дип. Һәмишә хат вә бүләк җибәрәдер. Аны мелла Шаһ Гали дирләр». Гөман кыла торган аксакалга һәммәсе игътираз[1] кылдылар. Ул карт, минем сүзем туры килгәнлектән, һич сүз катмады, тик торды. Мелла Шаһ Галинең бәһанәсе илә туры юлны яхшылап сорап алдым. Кәнднең дәрвазәсенең бер колы бар икән. Теге мине качып барадыр дигән аксакал аны җибәргән икән, ике атны алышып, өченчесен алышып алаем дигәндә, артымнан килеп, путамнан бер кеше тотып тартты. Йөзенә бакмадым. «И угры, шаһның дошманы син», —дип дәхи тартты һәм сөйрәде. Йөзенә әйләнеп багып: «Кызулык кылма, сабыр ит. Миңа шаяртасыңмы яки чынлап әйтәсеңме?» — дигәч, «Чынлап әйтәм», — диде. Мин әйттем: «Борыныңнан аерылаем дип торырсың».

Ул утырган чиркәс Йосыф аганың энеләре Мөхәммәдколый йөзбашы дигәндер, бу чаккача һич бала-чагасы булмагандыр. Шаһ аңа җефете өстенә бармакка хөкем кылды. Зәгыйфәсе[1] әйтте, бу вакыткача Мәшһәдтә имам кадименә барып, син вә без Ходай Тәгаләдән фәрзәнд теләсәк, хуш булыр иде, дип. Өч-дүрт кәррә әйтеп идем, син кылмадың, инде әлхәл юл уңае килде, мине дә ала бар, имамның зиярәтенә башораем, диде. Ага хәримен[2] ала килде. Шул сәгатьтә юл илән күп төя илән кәҗәбә[3] үтеп бара иде. Кулым илән күрсәттем, ул бара торган күп төяләр безнең аганың төяләредер, яшел кәҗәбә хәрименекедер, сары кәҗәбә бер якыннары бардыр, аны һәм ала барырлар. Аһәстә сөйлә, ага ишетмәсен, әгәр ишетсә, сине Бистам хакименең катына алып барып, борыныңны вә колагыңны кистерер, дигәч, килеп аркамны какты. Мин сиңа мотаябә[4] кылып әйтсәм, син чынга алып ачуың килде. Күп гозерләр әйтеп, бер табак йөзем китереп бирде. Аннан соң калган атны алышып, туры юлны яхшы сорашып белгән идем, шул юлга төшеп йөри бирдем. Барып, Хорасанның Мәһин дигән кәнденнән чыктым. Мәһиннән карап күрдем ки: ком итәгендә ике авыл торадыр. Мәһин кәнденең эчендә дәхи бер авыл күренде. Кәнд эчендәге өйләрнең сурәте Хорасанда ясалган вә ком итәгендә утырган өйләрнең сурәте Төрекмәндә ясалганын таныгач, катымдагы егетләргә әйттем: комда утырган ике авыл Әбү-Әлхан яки Мангышлак төрекмәнедер вә кәнд эчендә утырган бер авыл кызылбашка рәгыйятьтән булган төрекмәннәрдер. Өйләреннән таныймын. Шул ике авылга барыйк дип йөри бирдем. Бер авылның алдына килеп җиткәч, бер яшь углан чыкты, аңардан: «Бу утырган халык ни илдер?» — дип сорадым. Ул углан: «Кызыл ыругыбыз», — дип җавап бирде. «Сез Мангышлакта утырадыр идегез, ни сәбәп илән монда килдегез?» — дидем. Ул әйтте: «Безне калмык чабып, малыбыз вә башыбыздан аерды. Калганыбыз пиядә яшь угланнарыбызны аркабызга күтәреп, өч ел булды, монда килдек. Бу елны өйләр ясадык. Моңача алачык кылып утырыр идек». «Ошбу якын-тирәдә ил бармы? Кемнәр бар?» — дип сорадым. Ул төрекмәннең Ирсары дигән ыругыдан үзем таный торган биш-алты кешенең исемен тотты, өенең ераклыгы ике фәрсәх булыр, диде.

Ул арада өй иясе һәм катыбызга килеп җитте. Аннан хәбәр сорадым, ул һәм шулай диде. Аннан соң ул турыдан, күңелем тынычлангач, бу төрекмәннәремне кызылбашка тотып бирә торган җөмләдән имәстер, бәс, үземнең кем икәнемне аларга әйтәем дип әйттем. Аннан соң алар таныдылар һәм әтрафта утырган илләргә хәбәр әйттеләр, барчасы ишетеп җыелып килделәр һәм әйттеләр. Көз вакыты иде. Бу кыш монда торыгыз, яз илән бер мәслихәт кылырбыз. Ул кышны анда тордым, яз булганнан соң, безнең җиребез тар, кызылбаш вилаятендә утырганбыз, дип, Әбү-Әлханда Тәкә халкы утырган иде, анда барыгыз, диделәр. Әбү-Әлхан тавына барып, ике ел Тәкә халкының эчендә тордым. Аннан китеп, Мангышлакка бардым. Ул вакытта Мангышлак төрекмәне бозылып, җиде йөз өйлек калган иде, ул һәм калмыкка табигъ булып торыр иде. Калмыкның падишаһы, минем барганымны ишетеп, яхшы кешеләрен җибәреп, мине алып китеп, бер ел тотып, Өргәнечтә утырган үз халкыбызның эченә җибәрде.

## Әбелгазый ханның падишаһ булганы

Тарих һиҗри мең илле икедә, Елан елында йортыбыз вә илебезгә килдем. Алты айдан соң Елкы елының әүвәлендә Әсфәндияр хан вафат булды. Әсфәндияр хан үлгәннән бер ел үткәч, Аму дәрьясының диңгезгә койган җирен Арал дирләр иде, тарих һиҗри мең илле дүрттә, Куй елының әүвәлендә фәкыйрьне хан күтәрделәр. Аннан ике ел борын Барс елының ахырында вә Хут йолдызының әүвәлендә кечек энебез Шәриф Мөхәммәд солтан вафат булган иде. Әсфәндияр ханнан ике угыл калган иде: олысының исеме Юшан солтан, кечегенең исеме Әшрәф солтандыр. Ул вакытта Имамколый хан үлеп, урынына энесе Надир

Мөхәммәд хан хан булган иде. Мин, төрекмәннән кайтып, агабызның угланнарын вә вилаятен теләдем, дәхи Надир Мөхәммәд ханның исеменә хөтбә укып, Әшрәф солтанны җибәрде. Мин, яу булып, Хиваны ике кәррә чаптым. Аннан соң Надир Мөхәммәд хан Хива илән Һәзарасыбка хаким җибәрде. Әсфәндияр ханның углын вә кызын һәммә өй эче илән күчереп үз каршында утыртты. Хива илән Һәзарасыбның зәкят алмагын Әсфәндияр хан кемгә биргән булса, Надир Мөхәммәд ханның килгән элгәреге бәкләре һәм шул кешедән алмады, элгәреге бәкләренең һәркайсы бер вилаятьнең хакиме яки кырларының башы иде. Һичберсен, син фәләнчә ләвазимга[1] хаким йә баш бул, дип, тәгаен кылып җибәрмәс иде. Ул вөҗүдән вилаятьнең зәкяты вә гайре хасыйле төрекмән кулында торды. Мин, Аралдан атланып, Хиваны күп мәртәбә чаптым.

Бу вакыйгаттан биш ай үткәннән соң, Надир Мөхәммәд хан Хөсрәү солтан исемле углының углы Касыйм солтан дигәнне Хивага җибәрде, ул һәм Хиваның зәкят вә махсулатына[1] дәхел кылмады, әүвәлгечә төрекмән кулында торды. Касыйм солтан килде, дип ишеткәннән соң, мин фәкыйрь, Аралдан атланып, кичәсе йөреп намаз вакытында Хиваның дәрвазәсенең авызында Кәндемканд дигән кәнденә килеп, хәбәр җибәрдем һәм әйттем: «Таш-Күпрүккә җыелыгыз. Таш-Күпрүктән ары киткәнегез Ханкада-Су буена, Аралдан көймә китереп идек, көймә торган җиргә җыелыгыз», — дидем.

Чабар китте, минем катымда яхшы йөз кеше калды. Атсыз вә сөңгесез яшь угланнар вә яуга зарары тимәгән карт вә зәгыйфь кеби кешеләрдән артык атларны вә куышта нәрсәләрне сакламак өчен ике йөз кеше калды. Чабарның артыннан барганыбызда Хивадан яу чыкты. Хивага килгән Олуг Арыкның шималь тарафыннан йөрдек. Кыйбла тарафыннан яу йөрде. Яу җитмәстән мөкатдәм Олуг Арыктан үтеп, яуга каршы йөзмә-йөз булдык. Безнең яхшы, яманыбыз өч йөз кеше, йөз егермесе сөңгеле, үзем җәяү булдым. Алтмыш кеше минем илән бергә төште. Ике йөз сөңгесезне гаскәрнең уртасына куйдым, егерме сөңгелене ираул[2] вә егерме сөңгелене уң якның алдында куйдым. Болардан башка егерме мылтыкчыбыз бар иде. Үтеп чыккан Олуг Арык уң кулда булды. Мылтыкчыларны җәяүле кылдык. Алар, барып, безнең илән бәрабәр тордылар. Без гаскәрне тәнзыйм[3] кылгач, яу килде. Безнең кеби, гаскәрен бүлеп-бүлеп тәнзыйм кылмады.

Пиядә гаскәре сугышка кермәде. Гаскәренең күплегенә таянды. Бер бүлеге каз канаты кеби тезелеп килде һәм бераз килгәч туктап торды. Барчасы меңләп кеше бар иде. Әмма җиде-сигез йөзе савутлы вә куяклы[4] вә күзеннән башка ачык җире юк иде. Шундый кешеләр бар иде. Бездә биш савутлы кеше бар иде. Әүвәл биш егет безнең ираулга чапты. «Тайма, Баһадур, тайма!» — дип кычкырып, безнең бер-ике егет илән чәнчешеп кайтты. Ул кайтып урынына бармастан мөкатдәм янә безне унбиш кешеләре чапты. Безнең ираул аны да кайтарды. Ул кайтып урынына барганда, янә йөз кешеләре чапты. Ул килеп җитмәстән мөкатдәм безнең ираул качты һәм пиядә эченә керде. Пиядәнең алды мин идем. Өйрәтеп куеп идем ки, бер күзегез яуда булса, икенче күзегез миндә булсын дип. Яу утыз адым килгәнче утырдым. Аннан соң урынымнан торып, килгән кешеләрне укка тоттык. Шул вакытта арык эчендә яткан безнең мылтыкчы берничәсе безгә һөҗүм кылган яуны ата бирде вә берничәсе яуның һөҗүмчеләрен ата бирде, шул сәбәпле яуның безгә таба һөҗүмен тоттык, безгә аралаша алмады. Шуннан соң чыдый алмый кача бирде. Акрын-акрын артларыннан йөрдек. Уң яктагы илән сул яктагы ираул һәммәсе минем катыма килделәр. Без җәяү йөрдек. Теге тарафның тугын арык эчендәге мылтыкчы мылтыкка тотты. Без атлысын җәяү укка тоттык. Яу тарафының гаскәре какшый башлады. Безгә бер ун адым йөргәннән соң, бозылып китә бирде. Бездә атлы гаскәр булмадыкыннан, яуның артларыннан куып, кешеләрне алмадык. Яу качып беткәнче карап тордык. Аннан соң, атларыбызга атланып, Таш-Күпрүккә килдек. Китмә-вә-тор дигән җирдә бер әльәман[1] юк иде. Аннан су буена көймә туктаган җиргә килдек.

## Ханның бу сәхифәгәчә бу вакыйгаларны үз мөбарәк кулларының хатыдыр (язуы)

Әльәманның барчасы өлҗәсе илән җыелып торыр вә берничәсе ит пешереп, җийеп утырыр, ханны вә аксакалларны күңелләреннән чыгармышлар. Ул көнне су якасында яттык, иртә илән судан үтеп, берничә көннән соң өйгә бардык. Мәгълүм булсын ки, Әбелгазый хан (җәннәте мәкян[2]) бу китапны тасниф кылып, шул урынга җиткәндә хаста булды. Ул вакытта угылларына, бу китапны тәмам итми куймагыз, тәмам итәргә сәгый кылыгыз, дип васыять кылды. Ул сәбәптән Әбү әл-Мазфир вә әл-Мансур Әнүш Мөхәммәд Баһадир хан бине Әбелгазый хан мәрхүм вә мәгъфури[3] бәндәи би базагать вә кәминәи би иститагатькә бу китапны тәмам итәргә хөкем кылды. Әгәрчә бәндә бу әмер мөшкелгә лаек вә сәзавар[4] имәс идем, шулай һәм булса бу шаһиншаһ Гали Җаһ хөкеме илән белгәнем микъдар бу китапның тәмамына тәвәҗҗеһ[1] кылдым. Надир Мөхәммәд хан Касыйм солтанны, янындагы бәкләре илән чакыртып, Бохарага алды, дәхи Якуб Тупит башлык берничә халыкны Хәрәземгә җибәрде. Ул килгәннән соң, хан янә килеп, Хиваны чапты. Якуб Тупит ханга йөзмә-йөз килеп каршы тора алмый карап калды, һич тәгъриз кылмады.

Әлкыйсса: Бохараның бәкләре Надир Мөхәммәд хан илән ачуланышып, Надир Мөхәммәд ханны Бохарадан куалап җибәрделәр вә Надир Мөхәммәд ханның олуг углы Габделгазиз ханны Бохарада хан кылдылар. Ханның Хивада торган халкы Хиваны ташлап качып киттеләр.

Аннан соң хан Аралдан гаскәр илән тарих һиҗри мең илле дүрттә вә Тавык елының әүвәлендә атланып килеп Хивага кереп ата йортына ия булды һәм, һәр җирдә качкан вә поскан төрекмән булса, кайтып килсеннәр, калганнарының канын кичтем, дип нида[2] кылдырды. Ул вакытта төрекмәннең Голям баһадир, Динмөхәммәд унбәги, Ырыс унбәги дигән сәрдарлары бар иде. Болар төрекмәнне өе, иле илән алып качып, Һәзарасыбның артындагы комда утырган иделәр. Боларның җасусы ханның нида кылдырганын ишетеп, барып, ул төрекмәннәргә хәбәр бирде. Аннан соң ул төрекмәннәрне биш-алты аксакал килеп, ханны күрделәр һәм гарыз кылдылар ки: «Безнең сездән башка әкәбез юк һәм бара торган җиребез юк», — диделәр. Хан әйтте: «Мин инде сезнең килгәнегезнең вә килмәгәнегезнең гөнаһларын үттем вә дәхи шул ки, мин Һәзарасыбка барырмын. Аксакаллар һәм гайре башлыклар, барча халкыгыз илән килеп, безне күрешсеннәр вә биргән ингам вә бүләкләребезне алсыннар», —диде. Һәм берничә көннән соң хан атланып Һәзарасыбка бардылар.

Һәзарасыб кальгасының тышкы ягында бер мәйдан җир бар иде. Анда чатыр тегеп утырдылар вә төрекмәннәрнең аксакалларына әйттеләр ки: «Бер иртә илән олуг мәҗлес кылып аш бирербез. Сез төянең катыгы илән әйләнеп җыеп алып килегез», — диделәр. Төрекмәннәр: «Хуш, булыр», — дип, өйләренә кайттылар. Сабах булганда төрекмәннәр гөруһ-гөруһ җыелып мәйданга килә башладылар. Әмма хан киңәш кылып әйтте ки, төрекмән тәмам җыелып бетеп, аш куяр алдыннан һөҗүм кылып кыраек, дип иттифак кылдылар. Төрекмән халкы җыелып булганнан соң, аларга һөҗүм кылдылар, шул җирдә ике мең төрекмәнне үтерделәр һәм атка менеп, төрекмәннең өйләрен чабып, бала-чагаларын өлҗә вә әсир алып, фәтех вә носрәт илән кайтып Хивага төште.

## Ханның Тосанга барганы

Хан, Хивага кермәстән, мөкатдәм әүвәл Хивадан Куп дигән урыннан күчеп, Тосан дигән җиргә барып, чиб кылып утырмыш иде. Хан җәннәте мәкян Эт елының ахырында Кәҗәмөгез бөрҗендә атланып, Тосанда утырган бер парә төрекмәннәрне чабып вә бала-чагаларын өлҗә вә әсир алып, фәтех вә носрәт илән Хивага кайтып килделәр.

## Ханның, Бами-Бормага барып, күп төрекмәнне кырганы

Аннан соң Тосаннан качкан, вә Хивада барган, вә Бәлхтән килгән төрекмәннәр, барып, Бами-Борма дигән җирнең әтрафында утырырлар дип хәбәр тоттылар. Сычкан елының эчендә аларның өстенә атланып бардылар. Ошбу төрекмәннәр, ханның килгәнен ишетеп, өйләрен Каракасты дигән җиргә җибәрделәр вә, Каһер Хуҗаны баш кылып, пиядә Бами-Бормада җыелып, таштан кальга кылып, хан илән орышмага җыелып тордылар. Ул вакытта хан җәннәте мәкян һәм гаскәр илән килеп, аларның каршысына төштеләр һәм бер-берсе илән илчеләр йөртештеләр. Әмма илче илән эш бетмәде. Ахирел әмер төрекмәннәр саф тартып орыштылар. Мәзкүр таштан салган чибнең эченнән чыгып, пиядәләп сөрән салып йөгерделәр һәм, килеп, мылтыкчыга аралашып, дәхи аннан үтеп, төп гаскәргә аралаштылар. Әмма төрекмәннәргә курку төште. Ул вакытта ханның сул тарафындагы илә уң тарафындагы бүлек гаскәре, качма-качма, дип, ат өстендә һөҗүм кылдылар. Куркудан төрекмәннәр, кайтып, чибкә кача бирделәр. Әмма чибкә җитмәстән борын бер төрекмәнне коткармый үтерделәр. Аннан соң үзбәк баһадирлары, барып, төрекмәннең чибенә кереп, калган төрекмәннәрне кырып, хан каршына кайттылар. Хан, һәм шул заманда атланып сабах-садыйк вакытында Каракастыга барып, мәзкүр үлгән төрекмәннәрнең авылын чабып, төрекмәннәрнең малын алып вә бала-чагаларын өлҗә вә әсир итеп, фәтех вә носрәт илән Хивага кайтты.

## Ханның калмык илән орышканы

Сыгыр елында калмыкның Кушут ыругыннан Күлдәлең Дурҗи Тайши дигән кемсә, килеп, Кять вилаятен чабып, кулына кергән өлҗәне алып кайтты. Ул вакытта калмыкның Торгаут ыругыннан Буян дигән түрәсе Бисүдәгә килгән иде. Аны йортына озатып, калмыкның артыннан куалап унбишенче көн булганда Йөгерекбаш дигән җирдә өйлә намазы вакытында итеп орыш башладылар. Ул кичне шул җирдә ятып, иртәсе калмык орышка тәкать тота алмый качып китте. Хан шул җирдә төшеп, аш пешереп ашап-эчеп, ат вә төя-

ләрне тугарып, калмыкның артыннан кудылар. Никадәр аты вә төясе булса, шуны ташлап качты исә дә, алай да хәляс була алмады. Ахирел әмер котылмасын белгәч, барчасы җыелып бер чокыр җирдә яшеренеп торып, елдам ат өстендә безгә һөҗүм кылдылар. Ул вакытта хан бераз кеше илән элгәре вә башкалары соңгарак калып, ханның артыннан җиттеләр. Аттан төшеп җыелырга форсат булмады. Ахирел әмер лягыйлаж[1] алдан килгән егетләр кире тормый ат өстендә калмык илән орыштылар. Ходай Тәбарәкә вә Тәгалә боларның тәвәккәл кылганнарына фәтех вә носрәтне рузи кылды. Калмыкны җиңделәр, шул җирдә түрәсенең кулына мылтык орды, тугчысын, вә тугын, вә берничә калмыкны кулга төшерделәр, калганы качты, артыннан ястү намазынача кудылар. Ул кичне шул җирдә ятып, иртә илән кайтып, берничә көннән соң шәһәргә төштеләр.

Аннан соң төрекмәннең Байраҗ дигән бер кабиләсе бардыр. Аның олугының исеме Байраҗ иде. Шул Байраҗ җәннәте мәкянгә итагать кылмый ягы булып иде. Ул сәбәптән Таушкан елы хан дәүләте илән аның өстенә атланды. Ул халыкның өе Әтрәк-Күргән дигән суның буенда иде. Ханның бу сәфәре гаҗәп сәфәр булды. Берничә көннән соң илгә якын килдем дип, хан куышны, вә азыкны, вә җимне бер җирдә калдырдылар. Өч көнлек азык вә җим алып, илне монда табарбыз вә шунда очрарбыз дип иде. Сигез көн йөрделәр. Илне таба алмадылар. Халык эчендә шулкадәр ачлык булды ки, бер атка бер нан таба алмадылар, вә дәхи гаскәр һәр җирдә бүленеп-бүленеп калды. Ахирел әмер хан янында ун мең кешедән дүрт йөз кеше калды. Ошбу дүрт йөз кеше илән бара торганда, нагяһ Тәкә халкыннан берничә сәүдәгәр очрады һәм качтылар. Шул җирдә бер-икесен тотып үтерделәр. Әмма бер йөгерек атлысы качып котылды. Аның артыннан куып барганда, Ханмирзаның өенә очрап килделәр һәм ул авылны алдылар, аны алып кайтып килгәндә нагяһ каравыллар Байраҗның авылыннан сәүдәгә бара торган Тәкә Әвәниш дигәнне тотып алдылар. Ул әйтте ки: «Байраҗның авылы монда утырыптыр», — диде. Бу хәбәрне ишеткәч, хан шул тарафка йөрделәр. Якын җиткәндә яннарындагы кешеләр чабарга киттеләр, яннарында утыз гына кешесе калды.

Әлкыйсса: хан бу утыз кеше илән килеп ат салды. Шундый орыш булды ки, моның кеби һич булганы юк иде. Нагяһ ханның бер колы Байраҗны мылтык илән орып екты. Аннан соң бу утыз егет күтәрелеп ат өстендә һөҗүм кылдылар. Шунда барча төрекмәннәрне үтереп, бала-чагаларын өлҗә вә әсир итеп, ханга алып бардылар. Хан һәм бу егетләргә ингамнар биреп, берничә көннән саф фәтех носрәт илән кайтып Хивага төштеләр.

## Ханның Имриле вә Сарыйк халкын барып алганнары

Аннан соң Елан елында Имриле халкын, барып, Фуҗ дигән җирдә табып чаптылар һәм аларны өлҗә вә әсир кылып кайтып, Динар дигән кодыкның өстенә төштеләр. Шул заман аңсыздан Сарыйк халкы безнең өстебезгә төштеләр. Тәңренең гыйнаяте илән боларны һәм углан-ушаклары вә маллары илән алып, җиңеп, Хивага кайттылар. Аннан соң төрекмәнне күп мәртәбә барып чаптылар һәр барганда күп өлҗә илән кайттылар. Аның барчасын бәян кылсак, сүз озын буладыр, шул сәбәптән мохтәсар кылдык.

## Ханның калмык илән икенче мәртәбә орышканы

Ләү елында калмыкның Торгаут ыругыннан Мәргән Тайши вә Акчуртәпә вә Тогул дигән түрәләре, баш булып килеп, Һәзарасыбның берничә кәндләрен чабып, Содурга барып, аннан халкының малы Даруганда, имеш, дип барып, мәзкүр җирләрдән кулларына төшкән өлҗәне алып кайтып китмешләр хәбәрен ишеткәч, хан, Һәзарасыбка килеп, калмыклар ихтимал Бохарага барырлар дип, Ядгәр инакны Габделгазиз ханга илче җибәрде ки, хәбәр ит, гафил тормасын, дәю. Ул җибәргән илче Даруган турысына җиткәндә, күңеленә килде ки: дәрьядан үтеп хәбәр алаем дип үтеп хәбәр алса, калмык кайтып китептер. Кайтканын белгәч, җәһәтләп килеп, бу вакыйгатны бәян кылды.

Ул вакыткача арада ун көнләп вакыт үтте. Хан, бу хәбәрне ишеткәч, бәкләре илән киңәште. Бәкләре калмыкны кумакны мәгъкуль күрмәделәр вә әйттеләр ки: «Калмык киткәнгә ун көн булды, аның артыннан җитмәк мөмкин түгел». Әмма хан һичкайсының сүзен кабул кылмады. Атланып калмыкның артыннан йөрделәр. Берничә көннән соң Ирдар тавында бер бүлек бүленеп калганын җитеп алдылар да хәбәр сордылар. Кулга төшкән калмыклар әйттеләр ки, ерак түгел алдыгызда барып торырлар. Бу калмыкларны үтереп, алга йөри бирделәр. Шул кичә бер парәсен, җитеп, янә алдылар. Аннан соң калмыкның түрәләре котылмасларын белгәч, ни эш кылгач котылырбыз дип, үзара киңәш иттеләр. Барчабыз бер булсак, бер кешене куймай алырлар дип, берничә гөруһка бүленделәр. Бәхетлебез котылып вә имгәклебез тотылырбыз дип, Мәргән Тайши — бер бүлек, Акчуртәпә — бер бүлек вә Тогул бер бүлек булып арыган вә талганына карамый

качтылар. Хан дәхи кичә вә көндез дими йөреп Сәкин Рабат дигән җирдә Акчуртәпә илән Тогулның артыннан җиттеләр һәм орыша бирделәр. Калмык орышка тәкать кыла алмый Сәкин Рабатка камалып, кеше җибәреп гарыз кылдылар ки: «Без Әбелгазый ханның йорты икәнен белмәдегебездән килгән идек, Габделгазиз ханның йортына барганыбызда адашып килепбез. Инде үтерсәгез дә, сез, падишаһ, үзегез белерсез вә калдырсагыз да — үзегез белерсез. Без бер гөнаһкяр колларыгыз», — дип, Өргәнечтән алган малларын алдына салып, сөңге вә кылычларын муеннарына асып килеп, ханның аякларына егылдылар һәм ант итеп вә шарт кылып әйттеләр ки: «Бу көннән соң сезгә вә сезнең йортыгызга яманлык кылмас. Калмыктан вә гайре халыктан һәркем яманлык кылаем дисә, көчебез тигән кадәр каршы торырбыз вә, көчебез җитмәсә, сезгә хәбәр кылырбыз», — диделәр. Хан әйтте: «Сезнең ата вә агаларыгыз безгә яманлык кылганнары юк иде. Сез бу гөнаһны белмәгәнлегегездән кылдыгыз», — дип, гөнаһларын гафу кылып, ингам вә һәдияләр биреп, йортына озатып, фәтех вә ярдәм илән кайтып Хивага төште, вә Ядгәр инакка инаклыкны биреп, Һәзарасыбтан Хивага китереп, күп ингам вә бүләкләр бирде.

## Ханның Бохарага әүвәл мәртәбә барганнары

Әлкыйсса: тәмам төрекмәнне тәхет тасрафларына кергезеп, берничә ел гыйш вә фәрагатьтә утыргач, нагяһ Бәлх ханы Собханколыйдан илче килде ки. «Агам Габделгазиз хан мине үтермәгә касд кылып, Бәлхне алмак ниятендә, имеш. Инде минем атам да сез вә агам да сез. Минем сездән башка пөштипәнаһым[1] юктыр. Әгәр сез аның илән яу булып Бохараны чапмасагыз, ул, килеп, Бәлхне алмый калмас һәм мине бигөнаһ үтерми калмас», — диде.

Собханколый хан Әбелгазый ханның туган энесе Шәриф Мөхәммәд солтанның кызын алган иде, хан аңа кияү иде. Ул сәбәптән бу сүзләрне әйтеп җибәрде вә дәхи Габдулла ханның килеп, Хәрәземне алып, утыз икегә якын карендәшләре падишаһзадәләрен үтереп, бала-чагаларын әсир кылып алып киткәненең ачуы һәм мөбарәк хәтерләрендә торып иде. Бәлх ханының сүзе аның өстенә булды һәм Куй елында Бохараның өстенә атланды. Күкертлек дигән җиргә җиткәндә, Бәкколый инакны мең егет илән Каракүл өстенә җибәрде, үзе Сөенеч-баланың өстенә йөрде, барып, Сөенечне вә дәхи утыз-кырык кәндне Бохараның дәрвазәсенәчә чапты, күп мал, өлҗә вә әсир алып кайтып, Күкертлеккә төште. Өч көннән соң Бәкколый инак һәм Каракүлне яхшы чабып, күп мал алып вә өлҗә вә әсир итеп ханга кушылды. Берничә көннән соң хан дәүләт илән кайтып килеп Хивага төште.

## Ханның Каракүлне алганы

Аннан соң шул елны Каракүл өстенә атланды, янә барып, Каракүлне чабып кайтып, Күрдиш дигән җиргә төште. Әмма Габделгазиз хан ул вакытта Каршы вилаятендә иде. Бохараның эчендәге бәкләр, Каракүлнең чабылганын ишетеп, биш мең кеше илән атланып, Күрдиштә ханның артыннан җитеп, йөзмә-йөз булдылар. Орышка тәкать тота алмый кача бирделәр. Биш мең кешедән фәкать йөз кеше качып котылды, аннан үзгәсенең тәмамамын үтерделәр вә берничәсе халык качып килеп, Каракүлнең кальгасына кереп камалдылар. Хан Китистан һәм кайтып килеп, Каракүлнең кальгасына ябышты һәм кальганы алды, тар-мар итеп, эченә ут салды. Бәгъдә халкын өлҗә вә әсир кылып, Өргәнеч тарафына мөтәвәҗҗиһ булды. Берничә көннән соң хан фәтех вә җиңү илән кайтып Хивага төште.

## Чәһар-Җуйга барганнары

Аннан соң Пичин елында атланып Чәһар-Җуйны чабып, өлҗә вә әсир кылып, Хивага кайтты.

## Ханның Җайчыга барганнары

Тавык елының башында, март аенда, атланып барып, Җайчыны та Нәрзәмгәчә бу тараф Каракүлгәчә чабып өлҗә алып кайтты. Габделгазиз хан вә Касыйм хан ишетеп, Бохарадан атланып Күкертлеккә килеп, качкан кешеләрдән хәбәр алып, йөзмә-йөз килеп сугышмакка тәкать кыла алмасларын белгәч, куркып, атларын кырып, азык вә җимнәрен ташлап кире кайттылар. Аннан соң шул елны Кәрминә өстенә бардылар һәм Кәрминәне тәмам чабып, кальгасын алып, тар-мар кылып, өлҗә вә әсир кылып дәрьяның күпереннән үтеп төштеләр. Иртә илән безгә яу килер дип, һич кешенең күңелендә юк иде. Кичне шулкадәр тыныч ят-

тылар ки, үз өйләреннән яхшырак булды. Әмма сәхәр вакытында күп халык йөкләрен йөкләп кулына төшкән ат, вә төя, вә сыгыр, вә куйны алдына салып, элгәре киттеләр вә дәхи таң атканда барча халык күчеп өлҗәсе илән бергә йөреп киттеләр. Гаскәрләренең саны бары унбиш мең иде.

Кояш чыгып, көн яктыргач, ханның янында унбиш мең кешедән йөз кеше дә калмаган иде. Хуҗамбирде аталык килеп ханга әйтте ки: «Гаҗәп, гафил ятасыз, торыгыз, атланмак кирәк», — диде. Анда хан әйтте: «Яу кайда? Без кайда? Курка торган эш юктыр», — диде. Барган вакытта Тамлык-Ата дигән җиргә җиткәндә, Әүлия уйгурның куышыннан бер кеше югалды, дип килеп әйттеләр. Тога-Болак дигән җирдә салык салган иде, хан һәм барча халык гөман кылдылар ки, ул кеше адашып салыкга барды, дип. Әмма ул кеше, бездән өч көн мөкатдәм барып, Габделгазиз ханга бу халыкның килгәненнән хәбәр бирмеш иде. Ул эштән боларның һич хәбәре юк иде. Нагяһ Бохара тарафыннан гөруһ-гөруһ яу чыга башлады. Аны күреп, хан Кишварстанга атланды һәм киткән халкының артыннан йөри бирде. Киткән халкының алдында бер олуг арык бар иде, төяләре ул арыктан үтә алмый җыелып торалар иде. Шул вакытта ерактан кырык-илле мең кешенең карасы микъдары күренә иде. Мәзкүр арыкка якынлап килгәндә, ханның артыннан меңләп егетләр җитте ки, барчасының өсте тимер вә корычка баткан иде. Аларны күргәч, хан, җәннәте мәкян, атыннан төште, вә ханның янындагы халыклар һәм төштеләр. Әмма ул вакытта хан катында йөзгә җитәр-җитмәс кешесе бар иде. Хан берничә кешене арык янында җыелып торган төягә һәм халыкка ярдәмгә җибәрде, вә карнай[1] илән байракка һәм төягә җибәрде, вә әйтте ки: «Сез, анда барып җиткәч, карнайны тарта-тарта торыгыз, яу ул төяләрне гаскәр хыял итеп, безне йаравыл дип зан кылсын», — диде. Аннан соң Ядгәр аталыкны баш кылып, янындагы егетләрдән утыз егетне яу тарафыннан килгән мең кешенең алдына җибәрде, үзе калган пиядәне алларына катар-катар итеп гаскәр тезде. Ошбу утыз егет барып: «Алла яр», — дип, ул мең кешегә ат өстендә һөҗүм кылдылар. Нагяһ ул мең кеше кача бирде. Берничә сәгатьтән соң ул мең кеше кайтып, бу утыз кешегә ат өстендә һөҗүм кылдылар, вә бу утыз кеше һәм кача бирде. Килеп, гаскәр янына җитмәстән борын бу утыз кеше, янә кайтып, яу тарафына ат салды. Әлкыйсса: болар җиде мәртәбә бер-берен алдына салып куаладылар. Әмма төя торган җирдән бишләп-унлап күмәк килеп артып торды. Шулай итеп, хан катына биш-алты йөзләп кеше җыелды, вә орышып йөри торган атлылар һәм ике-өч йөз булган иде. Арада Габделгазиз хан олуг гаскәрен тезеп мылтыкны ата башлады. Аның төтененнән кеше кешене күрә алмады.

Вә мәгълүм булсын ки, Әбелгазыйның углы Әнүшә Мөхәммәд атасы Кәрминәгә атланганда ундүрт яшьләрендә иде, шул сәфәр әүвәл сәфәрләре иде. Мин һәм шул сәфәрдә юлдаш булдым. Артыбыздан бердән яу җитте. Хан, җәннәте мәкян, Ширзиян Кишварстан Әнүшә Мөхәммәд ханны киткән кешеләрне кайтар дип җибәрде. Ул киткәннән соң, Хуҗамбирде аталык, вә Дәүләт аталык, вә Бәкколый инакны һәм җибәрде. Әмма ул, җәмәгать киткәннән соң, яу гайрәт илән килеп, хан, җәннәте мәкяннең, этраф вә җәванибен[2] шундук ихатә кылды ки, аннан качып котылмакның һич әмкяне юк иде. Әмма мин бәндә чамалап карасам, яу безнең чаклы йөз хисса артык бар иде. Ахирел әмер яу бу халыкны бик куркытты. Янә бер сәгать үтсә, яу бу халыкны күтәреп алырлык иде. Хан алдыннан алтмыш егет ат салды. Ул вакытта Әнүшә Мөхәммәд Баһадир хан, ике йөз егет илән килеп, яуның бер тарафыннан ат салып һөҗүм кылдылар һәм шул дәрәҗә орыштылар ки, барча халык: «Афәрин!» — диделәр.

Ахирел әмер Габделгазиз ханның олуг төп гаскәре алтмыш мең кеше иде. Аның арасына йөреп-йөреп керделәр. Ул вакытта Әбелгазый ханның алдында җитмешсиксән пиядә кешесе бар иде. Шул пиядәләр, яу качты, дип сөрән салып, Габделгазиз ханның олуг төп гаскәренә йөгерделәр. Аны күреп, уңдагы һәм сулдагы өч йөз пиядә һәм сөрән салып йөгерде вә, аларны күреп, дәхи ике-өч йөз атлы бер тарафтан ат салып һөҗүм кылды. Тәңре Тәгаләнең фәрманы илән ханның гаскәре таралып кача бирде. Хан, җәннәте мәкяннең, баһадирлары яуны артыннан куып орып ега-ега дәрьяга җиттеләр. Яуның бәгъзеләре дәрьяга төшеп һәлак булды вә бәгъзеләре күпердән чыгып китте.

Әлкыйсса: берничә баһадирлар, җитеп, Габделгазиз ханны сөңге илән чәнчә башладылар. Аларның арасында Габделгазиз хан, йөз мең михнәт илән качып, үзен дәрьяга ташлады. Дәрьядан йөзеп чыгып котылып китте. Хан, җәннәте мәкян, мозаффар булып, хәд вә ниһаятьсез өлҗә вә әсир илән кайтып Хивага төште, дәхи барча халыкны чакырып әйтте ки, углымның әүвәл сәфәре иде, аягы вә юлы мөбарәк булды. Габделгазиз кеби олуг падишаһны бастык, җиңдек һәм орыш көнендә кылган эшләренә тәхсиннәр әйтеп, олуг туйлар кылды, дәхи мин бәндәгә туг биреп вә гаскәр кушып Һәзарасыбны бирделәр.

## Ханның Вәрданзига барганы

Аннан соң Эт елында атланып Вәрданзины чабып, бениһая өлҗә вә бигаять[1] әсир илән кайтып Хивага төште.

## Бохарага соңгы баргансы

Аннан соң Барс елында атланып барып, Бохараның әтраф вә җәванибен чабып, Намазгяһ дигән дәрвазәсенә төште һәм ун көн таләп вә тараҗ кылды. Әмма кальга эченә кермәделәр, аның өчен ки Габделгазиз хан Сәмәркандта иде вә Бохараның эчендә берничә таҗик илән берничә хатыннан башка кешеләр юк иде. Вә әйтте ки: «Әгәр без кальгага керсәк, галәм халкы тагын[1] кылыр ки, Әбелгазый хан Бохараны берничә хатынның кулыннан алды, дип. Әгәр Тәңре Тәгалә боерса, Габделгазиз хан кальганың эчендә торса, аның кулыннан алырмын», — диде. Дәхи малны вә әсирне ниһаятьсез алып, Хәрәзем тарафына мөтәвәҗҗиһ булды. Берничә көннән соң фәтех вә җиңү илән Хивага кайтты, дәхи әйтте: «Яшем алтмышка җитте. Инде моннан соң мөселман халкына яманлык кылмакның мәгънәсе юктыр. Дин карендәшләребез арасында низаг вә җәнҗалга бәгъзе сәбәпләр чыгып орышып идек. Анда һәм Хак Сөбханә вә Тәгалә фәтех вә өстенлек биреп, һәмишә җиңү кылды. Инде калган гомеремне Тәңре Тәгалә бәндәлегендә вә кяфер вә калмык сугышында сарыф кылырмын», — дип, падишаһлыкны угылларына биреп, тәүбә вә инабәт кылып, Мавәраәннәһергә илче җибәрде. Вә Габделгазиз хан илән солых кылып, тарих мең дәхи җитмеш дүрттә вә Таушкан елында вә рамазан әл-мөбарәк аенда дарелфанидан дарелбакыйга рихләт әйләде.

Мөддәт падишаһлыгы егерме өч ел булды. Ошбу «Шәҗәрәи төрек» тарих мең җитмеш алтыдан вә Елан елында Хива вилаятендә язылып тәмам булды. Әмма хәзрәти Адәм заманыннан бу вакыткача һичбер падишаһ вә өмәра үз тарихын үзе әйткән имәс иде. Өргәнеч халкының бивакыйфлыгы сәбәбеннән әйтмәккә зарур булып, ошбуны вөҗүдкә чыгарды. Чын хакыйкатьне бер Алла белер.

Тәмам

## Исемнәр, атамалар күрсәткече

Абабәк, Уклы халкы бәге 175, 176
Абай, Үз Тимер углы 132
Абак хан 31, 128
Абак хан, Аргын ханның атасы 31, 128
Абак хан, Кинҗайту атасы 121
Абак хан, Мәхмүдәк хан углы 131
Абак хан, Һөләкү хан углы 121
Абъюрд, шәһәр 94, 150, 153, 166, 170, 171, 174, 184, 199, 217
Ава, Диңгез хан углы 26, 27
Аганай солтан, Амәнәк хан углы 149, 150
Агиш солтан, Суфиян хан углы Адәм 153, 154, 165
Адәм Сафиулла, пәйгамбәр 8, 9, 10, 11, 19, 56, 58, 207, 233
Азәрбайҗан, ил 22, 53, 91, 102, 122, 124, 129, 130
Аймак, ыруглык-кардәшлек бүленеше термины, сөяк дигән синонимы да бар 22, 30
Айналҗаек (Гаюр хан), антропоним 33
Ай хан, Угыз хан углы 23, 26, 27, 56, 207
Акатай солтан, Амәнәк хан углы 149, 152, 159, 160, 161, 162, 165, 166, 167, 168, 169, 170, 178, 182, 206
Акашин (Тангут), вилаять 70
Акбаба солтан, Мәхмүд солтан углы 178, 188
Ак Мангыт, кабилә, бүгенге татар халкын калмыклар Ак Мангыт дип атап йөргәннәр 119
Аксак Тимер, Аксак Тимер би бине Әмир Тургай 52, 114, 115, 120, 137
Ак Су, елга 188
Ак Урда, вилаять 128
Акчуртәпә, калмык юлбасары 227, 228
Алак ноян, калмык 77, 81, 82
Алак 60
Алакош бәк 40, 63
Алакчин, шәһәр 38
Аланкува 42, 47, 50, 51, 54, 55, 206
Аланнар, этноним 91
Алатау, топоним 53, 115, 116

Алаюнәтле 26, 27
Алгу, Алтайда 110
Алгу, Байдар углы, Чыгтай хан нәселе 110, 112
Алка-Өйле, Көн хан углы 26, 27
Аллаколы солтан, Акатай хан углы 168, 170, 178
Алмалык, топоним 77
Алматы 71
Алтай таулары 110
Алтай суы 64
Алтан хан, Хытай (Кытай) шаһы 67, 68, 69, 70, 71, 103
Алып хан 83
Амәнәк хан (Әмин хан), Мәхмүд солтан Акатай хан углы 137, 146, 147, 149, 150, 152, 159, 160, 161, 165, 174, 178, 182, 206
Аму-Дәрья, (кара: Аму дәрьясы), елга 15, 22, 139, 150, 151, 153, 168, 205, 209, 215, 221
Аму суы, Аму-Дәрья елгасы 89, 97, 110, 134, 194, 203, 205, 211
Анатолига, Төркия җире 115
Анкара-Муран, елга 37, 38
Ануширван, антропоним 40
Араком, топоним 134
Арал, диңгез 216, 221, 222, 224
Арал, Кадан углы 57
Аргын ага, Хорасан хакиме 121, 138
Аргын ыругы, татар ыругы 138
Аргын бине Абак хан бине Һөләкү хан 31, 128
Арду, Батый хан энесе 126
Аркайчун баһадир, Илдүркин ыругыннан 61, 62
Арслан хан, Карлык илендә 34, 66
Арыйз бәк, Илек төрекмән бәге 41
Арык 182
Арык Бога, антропоним 109, 110, 122
Арка 144, 146
Арпа хан, Арыйк Бога углы 122
Астрабад, шәһәр 155, 156, 174, 175, 189, 192, 193
Астрабад төрекмәне 175, 189
Атабай, антропоним 177
Аталык, социаль термин 200, 230, 231
Атлы хан 15
Атсыз хан 15
Атсыз шаһ 41
Ачы, диңгез 37
Әбәк, Ядгәр хан углы 137
Әбелгазый Баһадир хан 196
Әбелгазый хан 223
Әбелгазый, Ядгәр хан углы 215
Әбелмәгалә Кятиб 89
Әбел солтан, Акатай хан углы 169
Әбелхәер солтан 178, 196
Әбелхәер, Тимер солтан углы 178, 188
Әбелхәер хан, Дәүләтшәех углы 135, 137, 140, 141, 142, 161
Әбескун җәзирәсе, Каспий диңгезендәге Әбескун утравы 90, 92
Әбир, вилаять 37
Әбү әл-Мазфир вә әл-Мансур 223
Әнүш Мөхәммәд Баһадир хан бине 231
Әбелгазый хан 195, 200, 201, 205, 206, 210, 211, 215, 216, 217, 221, 228, 229, 231, 232, 233
Әбү Әлмөхәммәд 184
Әбү Әлхан, Әбү әл-Мөхәммәд Динмөхәммәд хан углы 172, 173
Әбү-Әлхан 147, 148, 150, 151, 203, 204, 209, 212, 213, 220, 221
Әбүкән 112, 113
Әбүләк, Ядгәр хан углы 137, 146, 147, 149
Әбүсәгыйд, Барак хан углы (кушаматы — Җанибәк) 132
Әбүсәгыйд, мирза 137, 138, 139
Әбүсәгыйд, Туктамыш хан углы 131
Әбүсәгыйд хан бине Өлҗәйтү хан 122, 123, 129
Әвәниш хан, Амәнәк хан углы 149, 152, 154, 156, 157, 158, 159, 160, 161, 166, 168, 174, 184
Әдаклый таифәсе 153, 162, 163
Әйдикот, уйгур түрәсе 35, 77
Әйнал (Инал), кыргыз түрәсе 37
Әкри-Муран, елга исеме 38
Әленҗә хан 14, 17, 56, 207
Әл-Җингиз кара Чыңгыз

Әлканут, этноним 43, 57
Әлмансур Әнүш Мөхәммәд Баһадир хан бине Әбелгазый хан 223
Әмин хан 149
Әмирага, Туклык Тимер хатыны 119
Әмир Аксак Тимер 114, 119
Әмир әл-Мөэминин 76
Әмир Габдулла 113
Әмир Козгын 113
Әмир Пуладчи Дуглати 116, 118
Әмир Тугаҗар 128
Әмир Ходайдад 119
Әмир Хөсәен бине Бисалай 113, 114
Әмир Турагай 114
Әмир Чупан Сөлдус 122
Әмир Чурас 118
Әмир Шәех Хәсән Күчүк 123
Әмлак 13
Әмуя, Хорасандагы бер өлкә 93
Әндиҗан, шәһәр 21, 33, 41, 117
Әндираб, шәһәр 86
Әнүширван хан, Һөләкү хан нәселеннән 123
Әнүшә Мөхәммәд, Әбелгазый углы 231, 232
Әнүш (Садыйк) 11, 56, 207
Әрәпче таифәсе 153
Әрганә хатын 112
Әрк, шәһәр үзәге
Әркинәкун 30, 31, 42, 49, 53, 56, 207
Әрмән, этноним 22
Әсәгарәб 134
Әснаш, шәһәр 80
Әсфәндияр солтан, хан, Гарәб Мөхәммәд хан углы 188, 192, 193, 194, 196, 199, 200, 201, 202, 203, 204, 205, 207, 209, 210, 211, 212, 213, 214, 215, 216, 221
Әсфәндияр 81
Әсфәраин, вилаять 153, 189, 191
Әсфәраин юлы 90
Әтрәк-Күргән, елга 226
Әүлия уйгур 230
Әфган солтан, Гарәб Мөхәммәд хан углы 196, 202, 203
Әфрасияб 41
Әхмәд хан бине Һөләкү хан 121, 128
Әхнух 11
Әшкәст, күл 164
Әшрәф солтан, Әсфәндияр хан углы 221
Баба мирза, Хөсрәү солтан энесе 195
Баба солтан, Пулад (Булад) солтан углы 178, 184, 186, 189, 190, 191, 192
Бабел (Вавилон) 11
Бавырчык әйдикот 36
Баг-Абад, шәһәр 150, 166, 168, 184
Баг-Абад, өлкә 168
Багдад, шәһәр 73, 122, 123
Багу, Киюк углы 107
Бадай, антропоним 45, 46, 60
Бадакол, антропоним 206
Бадахшан, өлкә 22, 72, 111, 119
Баинда-Мөхәммәд солтан 172
Баиндар, этноним 26, 27
Байдакол, Җүчи Бога углы 131, 134
Байдакол, Хуҗа углы 132
Байдар Чыгтай хан углы, Мавәрәәннәрердә падишаһ 112, 127
Байду бине Торагай бине Һөләкү хан 121
Байнал, Шибан хан углы 134
Байраҗ, этноним 226, 227
Байсонкар хан, Кайду хан углы 51, 52, 55, 206
Байтимер, антропоним 59
Бакырган Ата, шәһәр 144, 197
Бакырган астәнәсе 203
Бакырган, вилаять 144
Бакырган, шәһәр 144, 198
Бала ноян 88

Баласагун 41
Балка, Шибан хан углы 134
Балчуна болагы 60, 61
Бами-Борма 225
Бамиян (Вәлиян?) 86, 96
Банду хан 15
Барак хан, Коерчык хан углы 132
Барак хан Ясунту углы, мөселманлык кабул итеп Гаясетдин исеме белән мәгълүм 112, 113, 114, 119, 161
Баргутай 52
Баргутай-Кырылтыйк 52, 57
Баркучин-Тукум, монгол этнонимы 39
Барлас, этноним 34, 52, 114
Бармас даруга, Мәрвә шәһәрендә 94
Барс елы 232
Барсаҗар 13
Бартан хан 206
Бартан хан бине Кабулхан 42, 53, 54, 55, 57, 206
Барыйн, антропоним 47
Барыйн иле 47
Бат-Кәлки 52
Батый Саин (Батый хан) 109, 126
Батый хан, Җүчи хан углы 104, 107, 108, 109, 127, 128, 133
Баһадир солтан, Ураз солтан углы 131
Баһадир хан бине Шибан хан 128, 131, 134, 206
Баһадир, Шибан хан углы 206
Башкорт 104, 127, 133
Баянҗар, Шибан хан углы 134
Баян-Колый хан бине Сургу 113
Баят, этноним 26
Бәдерхан, бәк 175, 176
Бәк Баклы баһадир 195
Бәкдуз, этноним 26, 27
Бәкҗедай 50
Бәки, Сарман углы, Чыгтай хан оныгы 112
Бәктимер, Җүчи Бога углы 134
Бәкколый инак 229, 231
Бәккунды бине Миңтимер хан 134
Бәлдәши бине Чыгтай хан 112
Бәликәч (Билбарыс) солтан, Бәркә солтан углы 145, 148, 149, 160
Бәлх шәһәре 21, 86, 89, 91, 111, 114, 139, 225, 229
Бәркә солтан, Ядгәр хан углы 137, 138, 139, 140, 141, 142, 143, 207, 210
Бәркә хан, Җүчи хан углы 109, 110, 126, 127, 128
Бәркиҗар, Батый хан энесе 126
Бәүкәй, уйгур түрәсе кызы, Чыңгыз ханның һәм аның углы Үгедәйнең хатыны була 36
Бәшкәнд Углан 138
Бәһаэлмөлек, Мәрвә шәһәре хакиме 92, 93
Бибичә, Мәрвә шәһәрендәге урам хатыны 173
Биҗнә, этноним 26, 27
Бикдәли, этноним 26, 27
Бикҗедай, Дубун-Баян углы 50
Биккунды Углан, Мөнкә Тимер углы 131
Билбарыс, Бәркә солтан углы 143, 144
Билгә 54
Билгедай ноян бине Дубун Баян 50, 102
Билгүтай-Утчикин 54
Билкенут 50
Бил-Күпри, топоним 174
Билал бине Хәсәнколый хан 149, 150
Бирд 11,56, 207
Бирдебәк хан бине Җанибәк хан 130
Бирем Углан 164
Бисалай бине Әмир Козгын 113
Бистам, шәһәр 122, 175, 189, 192, 193, 217, 218, 219, 220
Бисүдә 226
Бисылун, Чыгтай хан хатыны 111, 112
Бичин Кыян, Куймарал углы 46, 49, 56, 207
Бишбалык, шәһәр 35, 77
Биштүбә 214
Бият кыры, Вәзир шәһәрендә 161

Бият ыруы, төрекмән этнонимы 187
Бияут, этноним 47
Бияут иле 47, 58
Бога Тимер бине Кудагай бине Бузай бине Мутукан бине Чыгтай хан 112, 113
Боерык хан, Найман ханы 39, 59, 64, 65, 66
Бозук, этноним 24, 26
Бокадай 60
Бокадай-Кинҗат 60
Бора 37
Боргул ноян 71
Болгар иле, мәмләкәте 104, 126, 127, 128, 133
Болгар хәвызы, топоним 23, 26
Болгарый 23
Борылчи(дан) 195
Борындык, антропоним 192
Бохара, шәһәр 21, 22, 76, 77, 78, 79, 80, 83, 97, 98, 115, 116, 117, 127, 138, 150, 153, 160, 161, 162, 163, 165, 166, 168, 170, 172, 173, 183, 184, 187, 188, 190, 191, 193, 202, 205, 211, 214, 215, 216, 224, 227, 229, 230, 232, 233
Бохара халкы 97
Боюрнавыр, топоним 37
Бөеш кәнде, Бистам шәһәрендә 217
Бөзрек, Рум хакиме 122
Бөйрәк ыруы 134
Бөкәвел 60
Бөркүт ыруы, могулдан 47,
Бөрмә, Хорасандагы бер җир атамасы 160
Буданҗар (хан) 51
Буданҗар Мунак, Аланкува углы 51
Буданҗар углы Бука 55
Буданҗар углы Тука 51
Будан Кыят 53
Будат ыругы 52
Буҗага хан, Амәнәк хан углы 149, 152, 153, 154, 159, 166, 168, 170
Бука бине Бәндүн хан бине Күчүм Борул бине Кычый Мәргән 49, 56, 207
Бука, Буданҗар хан углы 51, 206
Бука Төрекмән 92
Бука хан, Татар углы 15
Бука хан 110
Букун Катыгыйн, Аланкува углы 51
Булгаҗин, могол ыруы 39
Булдумсаз, шәһәр 150
Булҗар-Дуглан, Төм(ә)нә хан углы 53
Булун Елдык 55
Буран бине Дуй Тимер 112
Бурлу кыры 168
Бурта Кучин 71, 125
Буртачина 31, 56, 207
Бурум (Иш-Дус), Буҗага хан углы 154, 168
Бурхан-Калдун, Чыңгыз хан күмелгән урын 100
Бурчыгыйн (коңгырат) 42
Бурчыгыйн Кыят 42, 54
Бускыйн Җалҗы, Аланкува углы 51
Буян, калмык түрәсе 226
Бүкәҗирән 60
Бүкән тайши 54
Вәзир, шәһәр 143, 144, 145, 146, 147, 148, 150, 159, 160, 161, 162, 165, 166, 167, 168, 169, 170, 180, 182, 183, 185, 186, 187, 193, 196, 197, 198, 199, 203, 209
Вәлиян (Вамиян?), кала 87
Вәзирдә Мөхәммәд солтан 186, 192
Вәрданзи, Бохара якынындагы шәһәр 232
Габбас, Габбас Мазый, шаһ 174, 188, 192, 203, 209, 217
Габделгазиз солтан бине Габид хан, Өргәнечтә 161, 163
Габделгазиз хан, Надир Мөхәммәд ханның олуг улы, Бохарада 224, 227, 228, 229, 230, 231, 232, 233
Габделгазиз хан бине Нурмөхәммәд хан 132
Габделлатыйф мирза 138
Габделмөэмин хан бине Габдулла хан 135, 142, 184, 188, 191, 192, 193
Габдулла бине Әмир Козгын 113
Габдулла хан 132, 173, 174, 178, 179, 182, 183, 184, 185, 187, 188, 189, 191, 192, 193, 229
Габдулла хан бине Искәндәр хан бине Җанибәк хан бине Бәркә солтан 135, 142
Габдулла хан бине Мәхмүд солтан 135

Габид хан, Бохарада 153, 161, 162, 163, 164, 165, 171, 182
Гадел солтан бине Мөхәммәд 114, 115
Гаҗәм (Иран) 13, 22, 209
Газан хан бине Аргын хан бине Абак хан бине Һөләкү хан 31, 121
Газизә ханым, Пулат солтан хатыны 180
Газнин, шәһәр 21, 87, 88, 96, 111
Газраил галәйһиссәлам 10, 11
Газый башлык, Бәркә солтан нәбирәсе 150
Газыйм Әлшан хан 114
Гайшәбикә Суфиян хан кызы 154
Гали әл-Мөлек сәед 76
Гали бине Әмир Гали Кошчы, Хорасан хакиме 122
Гали Җаһ 223
Гали иле, авыл 151, 153
Гали Ойрат 122
Гали солтан, Әвәниш хан углы 154, 155, 156, 162, 164, 166, 169, 170, 174, 175, 176, 177, 182, 187, 202
Гали солтан, Мәхмүд солтан углы 178, 186, 188
Гали солтан 113
Гали Суфиян хан углы 153, 159, 165
Гали Углан, Биккунды Углан углы 131
Гали Хуҗа Бохари 74
Гали Хуҗа Гаҗдувани 80
Галияр бәк 189
Гарәб 38
Гарәб, Мәхмүд хан углы 178
Гарәб Мөхәммәд солтан бине Хаҗи Мөхәммәд хан 184, 185, 189, 192, 193, 194, 195, 196, 197, 199, 202, 203, 206
Гарәб Мөхәммәд хан 188
Гарәб солтан, Мәхмүд солтан углы 178, 188
Гарәбстан 33
Гарәб, этноним 143, 145
Гарәб хатыны 123
Гарәбшах 134, 136, 206
Гафил Чилпук, кальга 191
Гаюр хан (Айналҗаек) 33
Гаязетдин хан, Таштимер углы 132
Гаяр хан, Солтан Мөхәммәд агасы 73, 74, 76, 79, 80
Герм-Руд сахрасы 122
Гилян, өлкә 36, 90
Голям баһадир 224
Гомәргазый солтан, Солтангазый углы 160, 161
Гомәр казый, Вәзир шәһәрендә 143, 144
Гөлбанбаг кәнде 216
Гөрҗестан (Грузия) 53, 87
Гөрҗи 122
Губалык 41
Гур, вилаять 21
Гур, таулар 21
Гүр хан 41
Гыйбадулла, Сөенеч Мөхәммәд солтан углы 188, 193
Гыйваз-Кызыл үгез 146
Гыйрак 8, 12, 22, 36, 92, 96, 128, 146, 176, 188, 191, 193, 217, 218
Гыйракыйн 96
Дабистан шәһәре 147, 150
Дагстан 53
Данишмәнд Хаҗиб 77
Данишмәндчә хан бине Кайду хан 113, 114
Даритай Утчикин 64
Даруга җибәрде 143
Даругалар 139
Даруган шәһәре 227, 228
Даруган-Ата коесы 197
Даруган-Ата шәһәре 185
Дарун шәһәре 147, 150, 153, 155, 161, 162, 174, 182, 184, 185, 186, 187, 193, 203, 209
Дәүләтшәех Углан бине Ибраһим Углан 134
Дәрваза-и Суфи 79
Дәүләтъяр, Хаҗи Гәрәй углы 132
Дәүләт аталык 231
Дәште Кыпчак 9, 21, 89, 98, 107, 108, 109, 110, 120, 124, 125, 126, 127, 128
Дәште (Дәште Кыпчак) 98

Дербенд, шәһәр  91
Диб Бакуй хан  13
Динар дигән кодык  155, 227
Динмөхәммәд солтан, Әвәниш хан углы  154, 155, 156, 157, 158, 159, 162, 163, 164, 165, 166, 170, 171, 172, 174, 182, 184
Динмөхәммәд солтан, Җани солтан углы  132
Динмөхәммәд Унбәги, сәрдар  224
Динмөхәммәд хан (Булад солтан углы)  188
Диңгез хан, Угыз хан углы  23, 26, 28, 56
Диңгез хан, Менгле хан углы  207
Дияр бәк  102
Дон елгасы  20, 33
Дөрбай, илче  67
Дөрбай ноян  88
Дөрбәнай  54
Дөрҗи бине Илчектай  114
Дөрләгин, этноним  42
Дөяче халкы  151
Дубун Баян, антропоним  49, 50
Дуглан, этноним  53
Дудырга  26, 27
Дуй Тимер хан, Дуй Чичән углы  112
Дуй Чичән хан, Барак углы  112, 113, 114, 115
Дурбан, этноним  46, 47
Дурман, этноним  53
Дурман Меңлиш би  187
Дурман халкы  53, 162, 169
Дусмөхәммәд, Буҗага хан углы  154
Дуст, Буҗага хан углы  166, 168, 169, 170, 182
Дуст Бурум хан, Буҗага хан углы  154, 168
Дустым би Аргын  186
Дутумнән хан, Бука углы  48, 51, 55, 206
Дүкәр  26, 27
Егъма, Кашмир шаһы  21, 22
Елдык, топоним  55
Җаббарбирде, Туктамыш хан углы  131
Җабику (Җакимбу?)  59
Җабни  26, 27
Җавык, Әбүсәгыйд (ләкабе Җанибәк) углы  132
Җавылдар  26, 27
Җаек елгасы  13, 20, 33, 53, 134, 136
Җайчы, топоним  230
Җалайыр иле  48, 51
Җалайырлар  49
Җалайыр халкы  51
Җалайыр ыругы  49
Җам, топоним  174
Җамалетдин, антропоним  116, 117
Җамчы  26
Җанибәк бине Бәркә солтан  142
Җанибәк бине Хуҗа Мөхәммәд солтан  135
Җанибәк хан  124, 129, 130
Җани солтан, Ярмөхәммәд солтан углы  132
Җаниш (ләкабе Җанибәк) Әбүсәгыйд углы  132
Җан Сәед, хан нөкере  162
Җантә бине Миңтимер хан  134
Җантимер нөкер  80
Җапун  13
Җачарам  174
Җаучин  52
Җәбраил галәйһиәссәлам  10, 12
Җәвәнмәрд хан, Ташкентта  161, 165
Җәйхун суы, Аму-Дәрья елгасы  84, 110
Җәләл, Әбү-Әлмөхәммәд хан углы  173
Җәләледдин солтан  76, 87, 97
Җәләледдин Туктамыш хан углы  131
«Җәмыйгъ әт-тәварих»  32
Җәнд шәһәре  77, 80
Җәнекши  112, 113
Җинанҗ түрә, Текрин хуҗасы  36

Җирмагун бәк 102
Җиһаннамә 190
Җиһан-Тимер хан бине Алафирәң бине Кинҗайту хан бине Абак хан бине Һөләкү хан 123
Җомбай, Батый хан энесе 126
Җорлык мәргән 43
Җөдаин, елга 47
Җөдаин-Бияут, этноним 47
Җөдә тавы 12, 13
Җөнүби Хорасан 147
Җөрҗан, Каспий диңгезенең көньягындагы өлкә 174
Җуак солтан, Мөхәммәд хан углы 132
Җуйрат (Җәҗерат), этноним 47, 57, 59
Җурчит (Кара Чөрчет) 19, 20, 41, 67
Җутак, топоним 151, 152
Җүчи, Җүчи хан 9, 44, 58, 64, 71, 75, 76, 77, 80, 83, 84, 85, 98, 99, 102, 104, 107, 119, 125, 126, 127, 129, 131, 132, 133, 136
Җүчи-Бога, Баһадир хан углы 131, 134, 206
Җүчи иле 129
Җүчи-Касар 54, 64, 122
Җүнүк, топоним 169
Җүрҗә Муран 38
Җылаун 65
Забил шәһәре 87
Замин каласы 193
Зарнук кальгасы (кара: Котлык-Балык шәһ) 77
«Зафәрнамә» китабы 16
Зәнбил бәк 160
Зәһ дигән арык 185
Зинбур, нөкер 95
Зыя-Эддин, Мәрвәдән 94
Зыя әл-Мөлек 89
Зөһрә ханым, Солтангазый солтан кызы 160
Иблис 11
Ибраһим солтан, Хаҗи Мөхәммәд хан углы, Өргәнечтә 185
Ибраһим, Фулад хан углы 134, 136
Идегәй, Идегәй Мангыт 119, 120
Идегәй, Котлык Коба углы 119
Идел елгасы 13, 20, 33, 53, 120
Идуркин, этноним 52
Идрис пәйгамбәр 11, 12, 56, 207
Икдәр, антропоним 26, 27
Икдәр-Чавылдыр, этноним 153
Икенче-Ком 202
Илбарыс, Бәркә солтан углы 143, 144, 145, 146, 147, 148, 149, 155, 159, 160
Илбарыс солтан, Гарәб Мөхәммәд хан углы 196, 198, 199, 201, 202, 203, 204, 205, 207, 209
Илбәк бине Миңтимер бине Байдакол 134
Илдүркин иле (ыругы) 46, 61
Илдүркин Сөлдустан аерылган 46
Илек хан, Баласагун шәһтәрендә 41
Илек елгасы 134
Илек төрекмән 41
Илек хан 41
Илҗә хан 13, 56, 207
Илилтер, уйгур түрәсе 35
Ил хан 16, 28, 29, 56, 207
Илхуҗа хан (ләкабе Исәнбога) 115
Илчедай ноян 102
Илчигән 44
Илчигән иле 44
Илчиктай 114
Илчиктай ноян 96
Илчи, Шибан хан углы 134
Ильяс Хуҗа хан бине Туклык Тимер 114, 116
Имал, Киюк хан Урдасы, Үгедәй балалары йорты 106
Имамколый хан 209, 215, 221
Имил 40, 41
Имир 26, 27
Имриле 227
Инак, инаклык 228
Инал, кыргыз түрәсе 37

Иналчык, Гаяр ханның кушаматы 74
Инат, антропоним 39
Инәлҗи, антропоним 38
Ингәрәс иле, этноним 43
Индибай, уйгур 180
Иран 9, 12, 22, 31, 53, 73, 96, 102, 105, 121
Иран йорты 120, 121, 122, 129
Иранчы, Әбүсәгыйд (Җанибәк) углы 132
Ирдар тавы 228
Ирек кальгасы (Өргәнечтә) 149
Иркә Кара 59, 60
Иркин, уйгур түрәсе 35
Иркол Хуҗа 24, 25
Ирсары, төрекмән ыругы 151, 152, 189, 190, 192, 220
Иртәгин иле 52
Иртыш елгасы 35, 66
Ирүмче Барлас 52
Исау, гаскәр үзәге 176
Исәнбога хан бине Дуй Чичән 115, 116
Ис-Бога, Җүчи Бога углы 134
Исем-Мәхмүд Ата 183
Искәндәр, Гали солтан углы 177
Искәндәр, Туктамыш хан углы 131
Искәндәр хан, Җанибәк углы 135, 142
Исмәгыйль би, Нугай Урдасы әмире 166
Исрафил галәйһиссәлам 10
Истанбул, шәһәр 183
Исүгәй 54
Исүгәй Баһадир хан 42, 54, 55, 56, 57, 59, 60, 125, 206
Исүгән, татар кызы исеме 71
Исфаһаный Хәсәнә, мәхәллә исеме 219
Исфаһан, шәһәр 217, 219
Итбрак хан 20, 21
Итик, Әбүсәгыйд (Җанибәк) углы 132
Итмас 102
Ихтыяр-Эддин, Хорасандагы шәһәр 93, 139
Ихтыяр-Эддин, Әмуя хакиме 93
Ихтыяр-Эддин, Төрекмән 93
Ичин Урда, Җүчи хан углы 133
Иш, Буҗага хан углы 149, 168, 169, 170
Ишим би, Сагрыҗ хакиме 187
Ишим хан, Төркестанда 215
Ишмөхәммәд, Буҗага хан углы 154
Иш солтан 166, 182
Йим (Җим) елгасы (Эмба) 205
Йисен-Тимер 112, 113
Йолдыз хан, Угыз ханның углы 23, 26, 27, 206, 207
Йолдыз хан, Менгле Хуҗа хан углы 49, 50, 56
Йортчы 26
Йөгерекбаш, топоним 226
Йылдырым Баязид солтан 115
Йосыф ага 219
Йосыф Отрарый 74
Йосыф, Суфиян хан углы 153, 162, 164, 165
Кабанак, топоним 183
Кабаноян, Коңгырат падишаһы 111
Кабли, елга исеме 75
Кабул шәһәре 21, 87
Кабул хан, Кыят нәселеннән 42, 43, 52, 53, 55
Кабул хан, Төмәнә хан углы 206
Кабул солтан бине Дөрҗи 114
Кадан Баһадир 53
Кадан Тайши 52, 57
Кадербирде солтан, Тимер солтан углы 178, 188
Кадыйкан 82
Кадыйрбирде, Туктамыш хан углы 131
Кажулы, антропоним 52
Казгорт, Угыз хан оныгы 26
Казакъ, халык 9, 132, 166, 192, 195

Казакълар, урыс казакларының Өргәнечкә һөҗүме 194
Казакъстан 215
Казан Солтан хан бине Орук Тимер 113, 114
Казан ханнары 132
Казвин шәһәре 89, 154, 170, 171, 189, 192
Казвинлык Хуҗа Рәшид 31
Казый Әшрәф 97
Казый Мөхетдин 124, 129
Кайду хан, Дутумнән углы 48, 51, 52, 55, 57, 206
Кал, Амәнәк хан углы 149, 152, 159, 161, 165, 166, 182
Каланҗа, топоним 183
Калач ыругы 22, 33, 62
Калҗау, мәзәкче кеше 87
Калмажу хан, Сам Саучи углы, калмык, этноним 49, 56, 206
Калый, Көн хан углы 26
Камаҗ елгасы 75
Камак, Киюк хан йорты 106
Камәретдин Дуглати 118, 119
Канбар, Әбүсәгыйд углы 132
Кангълы (Каныклы), этноним 33, 34, 41
Кандаһар, шәһәр 218
Кандучина, Чиркаланком углы 52
Кара-Айгыр тугае 205
Карабах, вилаять 128
Карабүкәвел, төрекмән ыругы 170
Каракалпак, этноним 204
Каракасты, топоним 225
Кара-Кичет, топоним 151
Караком, топоним 16, 134
Кара-Корома шәһәре 39, 104, 109, 110, 126
Каракүл, шәһәр 229, 230
Каранут, этноним 44
Кара-Муран, елга 103
Кара Су 171, 173
Кара-Усун, елга 38
Кара-Өйле, этноним 26, 27
Кара хан, Могул хан углы 16, 17, 18, 19, 56, 207
Кара Хытай иле 20, 40, 41, 67, 69, 70, 72
Карача Хаҗиб 79
Карачык 26
Кара Һөләкү хан бине Мутукан бине Чыгтай 112
Карачар, Үгедәй ханның дүртенче углы 107
Карел йорты 127, 133, 134
Каркыйн 26, 27
Каркыйш, антропоним 39
Карлык, этноним 21, 33, 34, 66, 76, 134
Кармүҗин, могол ыругы 39
Карнай, труба, музыкаль уен коралы 231
Каршы, шәһәр 113, 229
Карындаз, шәһәр 89, 90
Каспий, дәрья 90
Касыйм, Әбүсәгыйд (Җанибәк) углы 132
Касыйм солтан, Хөсрәү солтан углы 222, 224
Касыйм солтан бине Юныс хан, Өргәнечтә 167, 168, 182
Касыйм хан 230
Катыгыйн, антропоним, этноним 57, 215
Кафа шәһәре, Кырымда 128
Каһер Хуҗа, антропоним 225
Качун, Исүгәй Баһадирның өченче углы 54
Кашгар йорты 9, 111, 114, 115, 116, 117, 119
Кашин, Тангут вилаяте исеме 107
Кашин, Үгедәйнең бишенче углы 107, 113, 114
Кашмир, өлкә 21
Каюмарс 13, 22
Кәгъбәтулла, Мәккә шәһәрендәге мөселманнарның иң зур табыну йорты 10
Кәндемкәнд кәнде, бистә исеме 201, 222
Кәрден-Хаст, топоним 164
Кәримбирде, Туктамыш хан углы 131
Кәрминә, шәһәр 138, 139, 230, 231

Кәх, елга 96
Келкит 45
Келкит иле 45
Келуран, Чыңгыз хан туган йорт урыны 107, 108
Кемкемҗөт, вилаять 36, 37
Керәйлү, шәһәр 174
Кер тавы (Кече Тау) 16
Кийком, Удур-Баян ыругыннан 53
Кимәри 13
Килдиш, Кырым ханы Хаҗи-Гәрәй хан углы 132
Кинҗайту бине Абак хан бине Һөләкү хан 121
Кинҗә 53
Кирәет, этноним 39, 61, 62, 63
Кирәет Уң хан 44, 45, 59
Кирәйли, Угыз хан оныгы 26
Кирман таулары 88
Кирман шәһәре 102
Китек, топоним 117
Китмә-вә-тор, топоним 223
Кишварстан, вилаять 67, 68, 69, 73, 77, 82, 83, 86, 96, 97, 230
Киюк хан, Үгедәй хан углы 13, 14, 56, 104, 106, 107, 108, 120, 126
Киюк хан дип Бакуй хан углы 207
Кобай Ширә 43
Кодак, Шибан хан углы 134
Коерчык хан, Ырыс хан углы 132
Козгын, әмир 113, 114
Койгын, топоним 198
Кола суы 61
Колмөхәммәд би, Найман ыругыннан Корбан хаҗи углы 177, 178, 210
Комкальга, шәһәр 169, 183
Ком кальгасы 203
Комкәнд, шәһәр 160
Комый, Угыз хан әүляды 26
Коңгырат иле 43, 47, 53, 61
Коңгырат, этноним 111
Коңгырат Тугачар 70, 87, 89
Коңгырат ыругыннан Көнтугар баһадир 164
Корбан хаҗи 197, 198, 200, 210
Корлас ыругы 31, 42, 44, 49, 53
Кортга, Шибан хан углы 134
Кот 34, 66, 67
Котан йорты, Тангут иле 107
Котан, Үгедәй хан углы 107
Котлык Балык (Зарнук), шәһәр 77
Котлык Бога бине Баһадир бине Шибан 134
Котлыкзаман, Кырым ханы Хаҗи-Гәрәй углы 132
Котлык Коба, Ак Мангыт кабиләсе кешесе 119
Котлык Тимер 120
Котлык хан, Томган углы 132
Кот падишаһ 66, 67
Кот тау 34
Котука бикә 38
Котукту Мәнгү, Кабул хан углы 53
Кутуку ноян 70, 87, 88
Кош бәги 186
Кошчы, татар ыругы 134
Көбүд-Җама, шәһәр 174
Көйсу, Тияң хан хатыны 71
Көмеш, Киюк хан хатыны 107
Көн, Угыз хан углы 24, 25, 26
Көнкит 46
Көнә, Угыз хан нәбирәсе 26
Көнжу, Алтан хан кызы 71
Көнтугар баһадир 164
Көн хан 23, 24, 25, 26, 27
Көрдестан 102
Көчлек (Көчлүк), Найман Тияң хан углы 64, 65, 66, 72, 75
Көчлекхан, бәк 77
Көчлүк, хан углы 39, 70

Көюк кальгасы  212
Кубилай ноян  34
Кубилай хакан  108, 109, 110, 121
Кублә Каан  53
Кудагай (Кугай)  112, 113
Куду  70
Кужаш мирза  139, 140
Куй елы  229
Куймарал, Буртачина углы  49, 56, 207
Кулгый, топоним  168
Кулҗи солтан, Пулад (Булад) солтан углы  186, 188
Кунаш мирза  142
Кунҗи, Шибан хан углы  134
Кунканавар суы  61
Куныклут, Тосбодай углы  44
Куныкмар  44, 57, 63
Курайҗы солтан, Пулад (Булад) солтан углы  178
Курлавыт  47
Курчакор  39, 59
Курый, этноним  38
Кустымай, монгол, этноним  39
Кутур Калҗау  88
Кучин  125
Куш-Җаек, гидроним  194, 206
Кушут, калмык ыругы  226
Куырчык  26
Күбек бине Дуй Чичән  112
Күҗү, Үгедәй ханның өченче углы  107
Күз хан, Могул хан углы  16, 18
Күкертлек, топоним  229, 230
Күклән иле, төрекмән ыругы  153, 182
Күк, Угыз хан углы  23, 26
Күкле  26
Күк-Муран  38
Күк Сарай  80
Күк Урда, Дәште Кыпчакның бер өлкәсе  127
Күк (Күк хан), Бохара хуҗасы  33, 77
Күкчә  45, 63
Күлдәлең Дуржи Тайши, калмык бәге  226
Күл Иркин, уйгур түрәсе  35
Күлүк Миңтимер, Байдакол углы  134
Күнә, Угыз хан нәбирәсе  26
Күниш, вилаять  170
Күнчек хан бине Дуй Чичән  112, 114
Күнчек Углан, Сарыйча углы  131
Күп, топоним  225
Күпәк, Туктамыш хан углы  131
Күр хан, Могул хан углы  16, 18, 60, 66, 70, 72
Күрән, тау  189, 193
Күргән, елга  175
Күрдиш, топоним  189, 191, 229
Күрдиш, шәһәр  158
Күркүз, уйгур түрәсе  36
Күрмаргуз хан, Маргуз углы  59
Күр хан  66
Куфин, шәһәр  138
Күчем хан, Мортаза хан углы  131, 132
Күчүк мирза, мангыт  191
Күчүк, Туктамыш хан углы  131
Күчүм Борул  56, 207
Кыелдар  57
Кызылбаш  146, 148, 155, 156, 170, 171, 173, 174, 175, 176, 177, 184, 188, 189, 217, 220, 221
Кызыл Рабат  162
Кызыл ыругы, төрекмән  220
Кыйнан  11, 56, 207
Кыйшлык иле  45
Кылыч Кара, Хотан хакиме  62
Кынык, этноним  26, 27
Кыпчак иле  33, 53, 91

Кыпчак, этноним 20
Кыран кыры 198
Кыргыз иле 36, 40, 41, 66
Кыргыз, этноним 26, 36
Кыргыз йорты 36, 37, 38, 39
Кыргыз-казакъ ханы 28
Кырнык 26, 27
Кырылтыйк 52
Кырым 9, 128, 131, 132
Кычый Мәргән 46, 49, 56, 207
Кыйшлык 45, 60
Кыян 29, 30, 43, 53, 207
Кыян хан 42
Кыян ыругы 49
Кыят 30, 42, 43, 53, 54, 57
Кять 82
Кять, шәһәр 147, 150, 166, 168, 170, 174, 183, 187, 190, 193, 202, 205, 207, 209
Кять, вилаять 154, 165, 194, 201, 207, 226
Ләү елында 182, 227
Ләмәк 12, 56, 207
Лүли бәтчә 173
Лүли бичә 184, 188
Мавәраәннәһер 9, 22, 33, 36, 53, 74, 86, 96, 111, 112, 113, 114, 115, 116, 117, 120, 132, 134, 137, 138, 139, 143, 161, 165, 182, 184, 192, 195, 205, 209, 233
Магаз кәнде 218, 219
Магаз юлы 218
Мажар 65
Мажар иле 127, 133
Мажар, Шибан хан углы 134
Мазандаран, өлкә 36, 90, 93, 122, 138, 155
Мазандаран, диңгез 151
Мамишай, Курчакор углы 59
Мангыт Куелдар чичән 61
Мангыт 52, 205
Мангыт (Манкот) 154, 155
Мангыт мирзалары 155, 191, 204
Мангыт халкы 57, 131, 155, 166, 189, 191, 215
Мангышлак 147, 148, 150, 184, 189, 193, 204, 209, 212, 213, 220, 221
Мангышлак солтан, Җуак солтан углы 132
Мангышлак (Мангышлак) төрекмәне 221
Манжур, этноним 13
Маргуз, антропоним 39, 59
Мау-Балык (Яман Кала) 87
Маһирәбану ханым 196
Мәздаһкян 198
Мәзият әмир 138
Мәккә, шәһәр 10, 97, 202
Мәлик Әбүбәкер хаким 95, 96
Мәлик Әшрәф бине Тимерташ 123, 124, 129, 130
Мәлик Әшрәф Сөлдус 123
Мәлик Гажим 119
Мәлик Мөбариз хаким 96
Мәлик Шәмседдин Мөхәммәд 95
Мәнгү хакан, Тули хан углы 104, 107, 108, 109, 121, 126, 127
Мәнгүтай (Мингутай), уйгур түрәсе 35
Мәнгү Тимер хан бине Тукай Тимер бине Җүчи хан 128
Мәрвә, шәһәр 41, 91, 92, 93, 94, 95, 143, 171, 172, 173, 174, 184, 188, 193
Мәргән Тайши 227, 228
Мәрдәшуй 26
Мәскәү, шәһәр 133
Мәтәвешләх 12, 56, 207
Мәхмүд Әбүсәгыйд (Җанибәк) углы 132
Мәхмүд, Әвәниш хан углы 154, 174
Мәхмүдәк хан, Хаҗи Мөхәммәд хан углы 131
Мәхмүд солтан Акатай хан углы 168, 170, 178, 182, 186, 190
Мәхмүд солтан бине Шаһбадак солтан бине Әбелхәер хан 135
Мәхмүд солтан углы Гали 178
Мәхмүд хан, Мөхәммәд Ибраһимнең атасы 185
Мәхмүд Ялавыч 72, 73, 103

Мәһди солтан 161
Мәһин, Хорасан кәнде 220
Мәшһәд, шәһәр 171, 173, 217, 220
Мекрин Бияут, этноним 47
Мекрин, гидроним 47
Мекрин (текрин), ил, ыру, төрекмән этнонимы 97
Менгле (Мингле) хан 27, 28, 56
Менгле (Мингли) — Хуҗа хан 49, 206, 207
Менгтимер (Мингтимер) хан 206
Мең (Минг) (Г.Фәезханов текстында юк, урыс, үзбәк басмаларында бар.)
Меңлек (Минглек) Ичигә 44, 45, 57, 60, 63
Меңлиш (Минглиш) би, Хивада 187, 190, 191
Меңлиш (Минглиш) би, Дурман ыругыннан 187
Меркит, ыруг 43, 57, 58, 64, 65
Меркит Туктабики 65, 70
Мизан йолдызы 198, 209, 215
Микаил галәйһиссәлам 10
Мимикай каан 51, 57
Мингәсәр ноян 108
Минкән баһадир 69
Миңлегәрәй хан, Хаҗи Гәрәй хан углы 132
Миңле, кәнизәк 115
Миңле, хатын 115, 116
Миңтай, даруга 95, 96
Миңтимер, Байдакол углы 134
Мир 44
Мирза дәрвазәсе, Өргәнеч шәһәрендә 206
Мисылун, татар кызы 71
Мисыр 22, 23, 110
Миһербану 207
Могул иле 20, 21, 36, 42, 47, 50, 63, 67, 70
Могул йорты 9, 19, 32, 38, 55
Могул-Татар иле 31, 36, 73, 126
Могул Хаҗиб 83
Могул хан 9, 14, 15, 16, 56
Могул, могуллар 15, 17, 28, 29, 31, 33, 37, 38, 43, 45, 46, 49, 54, 56, 59, 76, 77, 78, 79, 81, 82, 83, 84, 87, 88, 92, 93, 94, 95, 102, 103, 105, 118
Могулстан 22, 31, 34, 66, 96, 115
Молка, антропоним 87
Монга, Үгедәйнең өченче хатыны 106
Мортаза хан, Мәхмүдәк хан углы 131
Мосул, шәһәр 12
Мөбарәкшаһ бине Кара-Һөләкү бине Мутукан бине Чыгтай хан 112
Мөҗирелмөлек, Мәрвә хакиме 92, 93, 94
Мөкран 96
Мөлай ханзадә, Кужаш мирза кызы 140, 142
Мөнәкә, нөкер 141, 142
Мөнграк, Үгедәй каган балалары йорты 106
Мөнграк, Киюк хан ставкасы 106
Мөнгүдәй 54
Мөнкә Тимер, Бадакол углы 131
Мөнулун, антропоним 48
Мөнһә, шәһәр 150
Мөңкә, угыл 108
Мөргаб, елга 171
Мөхәммәд Әмин, Мәхмүд углы 178
Мөхәммәд Бакый би, диван бәге 186
Мөхәммәд бине Юл Котлык 122
Мөхәммәдгазый солтан, Илбарыс хан углы 148, 155, 156, 157, 158, 159
Мөхәммәд Җүки мирза 138, 139
Мөхәммәд Ибраһим солтан, Хаҗи Мөхәммәд хан углы 183, 185, 186, 188, 192
Мөхәммәдколый бәк чиркәс 219
Мөхәммәдколый солтан, Хаҗи Мөхәммәд углы, Мәскәүгә озатыла 188, 189, 191
Мөхәммәд Мәзият 138
Мөхәммәд, ләкабе Шаһ Бәхет Гали әр-Рәхмәти, шагыйрь 135
Мөхәммәд Мостафа, пәйгамбәр 97, 105
Мөхәммәд Солтан Әвәниш хан углы 162, 166
Мөхәммәдхан солтан, Хаҗи Мөхәммәдханның кече углы 183, 188
Мөхәммәд Солтан хан, Сөюргатмыш хан углы 114

Мөхәммәд солтан, Мәхмүд солтан углы 178, 188
Мөхәммәд солтан, Тимер солтан углы 178, 188
Мөхәммәд Тинтәк солтан 167
Мөхәммәд хан, Тимер солтан углы 132
Мөхәммәд хан, Эчкеле Хәсән углы 131, 132
Мөхәммәд Хәрәзми 74
Мөхәммәд Хөсәен бәк 211, 212
Мөһинә топоним 147
Мөһляил 11, 56, 207
Мөһер язучы 158, 170
Муҗи, Чыгтайның икенче углы 112
Муркаду Күчнә 51, 57
Муса бәк 139
Муса би 139, 140
Муса хан бине Гали бине, Байду 122, 123
Мутукан, Чыгтайның олы углы 112, 113
Надир Мөхәммәд хан 221, 222, 224
Назыйр Хуҗа 203, 204
Найман, татар ыругы 134, 137
Найман иле 39, 59, 62, 63, 64, 65, 70, 169, 210, 211
Найман йорты 70
Найман Кәһрә 63
Найман суфый мирза 195
Найман 137, 171, 177, 193, 195, 210, 211
Намазгяһ, Бохара дәрвазәсе 232
Намә 171
Насретдин Әбү әл-Габбас хәлифә 76
Насретдин, Солтан Мөхәммәд вәзире 90
Насыйр хәлифә 73
Нахичеван, өлкә 91, 123
Нәҗметдин Көбра 167
Нәрзәм 230
Нәркән, Шибан хан углы 134
Нәхшеб, шәһәр 86
Немец, этноним 127, 133
Никочар, Җүчи-Бога углы 134
Никудәри, шәһәр 114
Никчигә, шәһәр 150
Нирун 42, 51, 52, 58
Нисай, шәһәр, вилаять 150, 153, 166, 169, 170, 174, 177, 183, 184, 185, 193, 209
Нишапур, шәһәр 89, 90, 94, 95
Нөкүз, этноним 29, 30, 37, 42, 49, 52
Нур Дәүләт хан, Хаҗи Гәрәй хан углы 132
Нурмөхәммәд хан, Бибичә углы Мәрвәдә хан 173, 174
Нурмөхәммәд хан, Динмөхәммәд солтан углы 132
Нунаш ханым 160
Нутакыйн 52
Нурым хан 184, 193
Нухваст, шәһәр 183
Нух пәйгамбәр 12, 14, 56, 207
Ойрат иле 38, 39, 66, 106
Ойрат йорты 47
Ойрат халкы 121, 122
Ойрат ыругы 122
Олуг Арык 222
Олуг Тау 16
Олуг Түбә 160, 170
Олуг Түбә Зәнбил бәк 160
Олуг Тули 212
Олунигә 57
Олун Кучин, Чыңгыз хан анасының исеме 43, 57
Онгут иле 40, 63
Он-Муран, гидроним 38
Онон, топоним 48
Ор, елга 134
Оргыз елгасы 134
Оры дәрвазәсе, Вәзир шәһәрендә 180
Орут, антропоним 52
Оскунлык Тирәм, тау 34

Отрар, шәһәр  74, 76, 77, 79, 80, 83, 115
Өлҗәйтү хан бине Аргын хан бине Абак хан  122
Өргәнеч, шәһәр  33, 41, 83, 84, 85, 98, 143, 145, 146, 147, 149, 150, 151, 152, 153, 155, 157, 158, 159, 160, 161, 162, 163, 165, 166, 168, 169, 170, 173, 174, 175, 176, 179, 182, 183, 184, 185, 186, 187, 188, 189, 190, 191, 192, 193, 194, 195, 196, 197, 198, 199, 201, 203, 204, 205, 206, 207, 209, 211, 214, 221, 228, 230, 233
Өргәнечкә урыс һөҗүме  194
Өркир  26
Өрүк Тимер бине Бога Тимер  113
Өчук, этноним  24, 26
Өч (Өч ыруг), төрекмән этнонимы  153
Пәст кальгасы  218
Пәһлеванколый, Пулад (Булад) солтан углы  178, 179, 186, 189
Пәһлеванколый, Суфиян хан углы  153, 165
Пишкяһ, шәһәр  163
Пишкяһ дигән кодык (кое)  196
Пулад (Булад), Акатай хан углы  180
Пулад Җөнкәсаң баһадир  32
Пулад солтан, Акатай хан углы  168, 170, 178, 179, 182, 183, 184, 185, 186, 187, 188, 189
Пулад солтан углы Баба солтан  186
Пулад солтан углы Кулҗи солтан  186, 188
Пулад солтан, Хивада  182
Пуладчи әмир  116
Рахманколый даруга, Вәзир шәһәренә куелган  143, 145
Рәшидетдин, Шәех углы  117
Рәй, шәһәр  90
Рәкыйн эд-Дин  89
Ришау Ходайбирде, уйгур нөкере  156, 157, 158
Риш-Табан Ата  199
Рөстәм  81
Рум  41, 122, 123, 183, 188, 193
Румлы  184
Рум пайтәхете  33
Рус  98
Рухия, шәһәр  138
Сабиктигин әүляды  96
Сабин Бәлкә, Чыгтайның дүртенче углы  112
Сава иле (Йаса шәһәре)  89
Сагча кодыгы  179, 199
Сагырыҗ, вилаять  187, 188
Сагырыҗ хакиме Ишим би  187
Садыйк (Әнүш)  11, 56, 207
Саелган, Шибан хан углы  134
Саин (Батый) хан  110, 126, 130
Саир  26
Саклаб, этноним  13
Салә шаһ, илче  183
Салих солтан  195
Салурлар, Өргәнеч сартлары ыругы  150
Салур (Хорасан салуры)  26, 27
Сам  12
Сам Саучи хан  49, 56, 207
Самука баһадир  69
Сарайчык шәһәре  127, 129, 130
Сарман, Чыгтайның бишенче углы  112
Сарт, этноним  145, 146, 167, 169, 174, 183, 190, 212
Сартак углан Батый ханның углы  127
Сархин би  186
Сарыйча, Үз Тимер углы  131
Сарыкол  72
Сарык (Сарыйк), төрекмән ыругы  152, 203, 227
Сары Мәхмүд, Әвәниш хан углы  174
Сары Углан, Өргәнеч, Вәзир иясе  166, 187, 190
Сатыйбикә хатын бинте Солтан Мөхәммәд Хор-Бәндә  123
Сатылмыш хатын  115, 116
Сахраи Герм-Руд  122
Саш мирза, уйгур  195
Сәбни-Кун елгасы  38
Сәгъдетдин  182
Сәед  217, 218

Сәед Ата  44, 203
Сәед Гыйззетдин  94
Сәйфетдин мәлик  87, 88
Сәкин Рабат  228
Сәмәрканд, шәһәр  21, 22, 41, 75, 80, 82, 83, 86, 88, 97, 98, 115, 116, 117, 119, 120, 138, 139, 161, 162, 165, 186, 195, 209, 218, 232
Сәнҗәр, Гали солтан углы  177, 178
Сәнкүн, Уң ханның олуг углы  59, 60, 61, 62, 65
Сәрәнҗам  194
Сәрхәс шәһәре  93, 94
Сибир, вилаять  37
Сиктү Бога  77, 81, 82
Сикәки мелла  111
Силенгә (аргы як)  38
Симкачун  52
Синд суы  88, 111
Сирам иле  21, 23
Сиръяни, сирияле  11
Собханколый, Бәлх ханы  229
Собханколый даруга, Өргәнечтә, гарәп нәселеннән  143, 145, 146
Содур 227
Сокыт, этноним  47
Солтан Җәләлетдин  87, 88, 95, 96, 102
Солтангазый солтан, Солтан Илбарыс хан углы  148, 149, 159, 160, 161, 165, 196, 207
Солтан Гаязетдин  89
Солтания  123
Солтанлы  26
Солтан Мөхәммәд  41, 70
Солтан Мөхәммәд хан Сабиктигин  96
Солтан Мөхәммәд хан Сөюргатмыш углы  114
Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһ  33, 53, 72, 73, 74, 75, 76, 77, 78, 79, 81, 82, 84, 87, 90, 91
Солтан Сәнҗар Мазый  41
Солтанхаҗи, Бәликәч солтан углы  148
Солтан Хөсәен мирза  143
Сорачык  26
Сөбни-Кун, гидроним  38
Сөләйман әрбаб, Өргәнечтә  167
Сөләйман солтан, Акатай хан углы  168, 170, 178
Сөләйман хан бине Мөхәммәд бине Сөнкә бине Йәшмүт бине Һөләкү хан  123
Сөләнгер елгасы, Кыргызда  37
Сөлдус иле  46
Сөлдус Чупаны, әмир  122, 124
Сөенеч бине Миңтимер хан  134
Сөенеч Мөхәммәд, Мәхмүд хан углы  185
Сөенеч Мөхәммәд солтан  185, 188
Сөенеч Мөхәммәд солтан, Хаҗи Мөхәммәд ханның олуг углы  188, 192, 193
Сөенеч хан  15, 28, 29
Сөенечхан, бәк  77
Сөюмөнкә, Чыгтайның алтынчы углы  112
Сөюргатмыш хан бине Данышмәндчә хан  114
Сөюркүктай бикә, Тули ханның хатыны  38, 107
Суҗли  26
Сургу хан  113
Суркый (Сурхый)  26
Сус шәһәре  11
Суфиян хан, Амәнәк хан углы  148, 149, 150, 151, 152, 153, 154, 159, 162, 165, 166, 168
Суфый мирза, найман  195
Сүбүдәй баһадир  70, 87, 89, 91
Сыгнак шәһәре  77, 80
Сыйрак, могулча «таҗик» дигән сүз  34
Сыр-Дәрья елгасы  16, 139, 141, 204
Сыр диңгезе  205
Сыр суы (кара: Сыр-Дәрья)  134, 136, 138
Сычкан елы  210, 225
Табайду  15
Тавык елы — 1006 ел  230
Тагабад, Хорасан вилаяте  182
Таг-Бадахшан өлкәсе  119
Таг, Угыз углы  23, 26
Тагрыл  39

Таифә, шәһәр 10
Таҗик халкы 19, 32, 34, 38, 81, 88, 117, 218
Таҗик, этноним 82, 92, 218
Тайҗут иле 51, 52, 58
Тайҗут ыругы 56, 57, 58
Талкан 86, 96
Тамлык-Ата 230
Тангут (Тибет) 20, 65, 70, 107
Тангут хакиме 99
Таника бәк 62
Тарих, антропоним 13
Тарма Ширин бине Дуй-Чичән 112
Татар гаскәре 19, 20, 103
Татар иле 15, 21, 28, 29, 30, 31, 37, 58
Татар, этноним 14
Татар хан, Әленҗә хан углы 14, 15
Татар ыругыннан Найман 137
Татар ыругыннан Уйгур 137
Татула-Сукар, антропоним 39
Таушкан елы 233
Таһир, Иш солтан углы 170
Таһмасыб шаһ, Хорасан падишаһы 170, 175, 176, 177
Ташкент (Ташкенд шәһәре) 21, 41, 97, 117, 138, 139, 161, 215
Таш Күпрүк 213, 222, 223
Ташлы Ярмыш 202
Таштимер, Мөхәммәд хан углы 116, 132
Таяң хан (Тияң хан), Найман ханы 39
Таярсун 106
Тәбриз 102, 122, 123, 130
Тәвәче иле (Төяче ыруы), төрекмән ыругы 153, 181
Тәҗнә, антропоним 49
Тәкә Әвәниш 227
Тәкә ыругы, төрекмән 152, 189, 190, 193, 203, 221, 226
Тәңре 10, 11, 16, 21, 28, 30, 36, 45, 53, 62, 63, 68, 78, 97, 134, 162, 184, 201, 204, 232, 233
Тәңребирде 211
Тәңренең йөзе 45, 63
Тәңре Тәгалә 12, 36, 53
Тәршиз, топоним 174
Тәхтепыл, мәйдан исеме 187
Тегәнләлә, этноним 26
Текәҗәк, антропоним 87
Текеш хан, Өргәнечтә 33
Текрин (Мекрин), төрекмән ыругы 36
Теләш, ил 21
Теләш, елга 33, 34
Теләш, шәһәр 22
Тениш, Әбүсәгыйд (Җанибәк) углы 132
Теркән хатын, кангълы кабиләсеннән Бисылунның сеңлесе, Чыгтай хан хатыны 33, 76, 83, 112
Термиз шәһәре 76, 86, 89
Терсәк, шәһәр 145, 150
Тибет (Тангут) 20, 65, 70, 107
Тибет йорты 62
Тигеш падишаһ 41
Тимач, Бичин Кыян углы 49, 56, 207
Тимер бәк Углан 119
Тимер би (Аксак Тимер) 119, 120, 154
Тимер Капы (Тимер Капка), топоним 40, 53
Тимер Котлык хан, Котлык Коба кызыннан туган 119, 120
Тимер Котлык Углан (Тимер Котлык хан) 120
Тимер Мәлик 81, 82, 116
Тимер солтан, Акатай хан углы 168, 170, 178
Тимер солтан, Котлык хан углы 132
Тимер солтан, Пулад солтан энесе 178, 179, 180, 181, 182, 183, 185, 186, 188
Тимерташ хан 49, 56, 206
Тимер Төнкә бине Миңтимер хан 134
Тимер Шаһ бине Йисен Тимер 113
Тимершәех, Хаҗи Тули углы 136, 206
Тимин (Темән?), шәһәр 69
Тимучин (Чыңгыз хан) 54, 63

Тимүкә 54
Тингали нөкер, Дурман ыруыннан, Иш солтан нөкере 169
Тинүрә, Хәрәземдәге бер бистә 84
Тирит, топоним 174
Тияң хан (Таяң хан), найман ханы 39, 59, 62, 63, 64, 65, 70, 71
Тога-Болак 230
Тогул, этноним 227, 228
Томган, Абай углы 132
Торгаут, калмык ыругы 226, 227
Торкак ыругы 42
Торсун хан 215
Тосан 225
Тосбодай 43, 44
Тост манарасы 211
Торсун Мөхәммәд, Баинда Мөхәммәд солтан углы 172
Торумчы 26
Торумчы бәк, төрекмәннең Лайна ыругыннан 172
Төләс, этноним 38
Төмәнә 52, 53, 206
Төрек Әмәл 61
Төрек падишаһ 13
Төрекмән, этноним 33, 92, 93, 94, 147, 148, 150, 151, 152, 174, 175, 182, 183, 189, 191, 210, 211, 212, 214, 215, 220, 224, 227, 229
Төректай бәк 128
Төркестан 21, 33, 41, 66, 70, 75, 139, 214, 215
Төя-муен, топоним 163
Тугай Тимер 122, 123
Тугачар Коңгырат 70, 87, 89
Тугчы, байракчы 177
Тугыз Сай 35
Тугыз уйгур, этноним 35
Туда Мөнгү бине Тукай Тимер 128
Туйхуҗа Углан, Тукколхуҗа углы 131
Тука, Буданҗар углы 51
Тукай бәк 128
Тукай Тимер, Батый ханның кече энесе 126, 127, 131, 132
Тукколхуҗа Углан, Күнчек Углан углы 131
Туклык Тимер хан 114, 115, 116, 118, 119
Тукрату бозлык, тау исеме 34
Туктабики 43, 65, 66
Туктагу хан бине Мәнгү-Тимер хан 128, 129
Туктамыш хан, Туйхуҗа Углан углы 119, 120, 131
Тули хан 9, 31, 38, 71, 77, 86, 91, 92, 94, 95, 96, 102, 103, 104, 107, 109, 121, 122, 126
Тулук хан, Абак хан углы 131
Тумат иле 39, 71
Турбатлы 26
Тургаут, этноним 38
Тур шәһәре 77
Туракинә, Үгедәйнең икенче хатыны 106
Туракчин, Үгедәйнең олы хатыны 106
Турамыш, антропоним 66
Туран 9, 21, 73, 96, 97, 104, 105
Туран вилаяте 131
Туран йорты 131
Туси Тайфыр бәк 41
Түк шәһәре 166, 169, 194, 195, 198, 203, 205, 209, 211
Түләк Тимер, Тукколхуҗа энесе 131
Түләнгүт, этноним 39
Түмнә хан 55
Түрәлҗи, ир-ат исеме 38
Түтәк хан 13, 56, 207
Тышкы Салур, этноним 152
Убрат, ыру 64
Угыз угланнары 26
Угыз хан 16, 17, 18, 19, 20, 21, 22, 23, 24, 25, 26, 27, 33, 34, 36, 56, 207
Углан ыруы 163
Угырҗә 151
Удур-Баян, антропоним 53
Уйгур(лар), этноним 19, 169, 195, 210, 211
Уйгур иле 33, 34, 36, 137

Уйгурстан  115, 116, 117
Уйгур каласы  111
Уйгур ыругы  33, 35, 36, 66, 136, 147, 195
Уймаут (Урмаут), этноним  44
Уйшун Баклы  195
Уйшун иле  46
Уйшун сөяге могул  46
Укар Калҗау  87, 88
Уклы, этноним  26
Уклы-Күклән, этноним  175
Уклы халкы, этноним  175
Уку, Киюк углы  107
Улакчы Батый ханның углы  127
Улкин Баргак  53
Ун уйгур (этноним)  35
Уң хан, Кирәет падишаһы  40, 44, 45, 46, 59, 60, 61, 62, 65, 125
Ураз солтан, Шәмәй солтан углы  131
Урал таулары  134
Уран Тимер бине Тукай Тимер  128
Урасут, этноним  39
Урда  136, 137
Урду  15
Урманкот, этноним  37
Урмаут иле  44
Урмаут ыругы  44
Уртак-Кодык, топоним  189
Урыс, этноним  104
Урыс йорты  91, 126, 127, 133, 206
Урыс казагы  206
Урысның атлы казагы  194
Урыс-улак  20
Урысның Өргәнечкә һөҗүме  194
Утчикин  126
Үз хан, Могул хан углы  16
Үзбәк, этноним  134, 135, 167, 173, 175, 176, 183, 187, 202, 205, 210, 211, 215, 216
Үзбәк иле  38, 52, 59, 129, 132, 139, 145, 146, 147, 152, 153, 154, 162, 165, 195, 210, 214, 225
Үзбәк хан бине Тогрул хан бине Мәнгү-Тимер хан бине Батый хан бине Җүчи хан  129
Үгедәй хакан  77, 78, 80, 82, 83, 84, 85, 96, 98, 99, 103, 104, 106, 107, 111, 113, 114, 121, 126, 133
Үгедәй хан  9, 36, 102, 105
Үзкәнд шәһәре  80
Үз Тимер бине Тукай Тимер бине Җүчи хан  131, 132
Үз Тимер, Хаҗи Гәрәй хан нәселеннән  132
Үз хан  16, 17
Үклән иле  47
Үлкәчинчина  52
Үркир  27
Үр Муран  38
Үсүк, Әбүсәгыйд (Җанибәк) углы  132
Үшәр  26, 27
Фарсы теле  33
Фатыйма хатын тугае  168
Фәридун Гури  83, 84
Фил күпере  153
Фәнакәнд  77, 81
Фуҗ, топоним  227
Фулад (Булад) бине Миңтимер  134, 136, 206
Фулад (Булад, Пулад)  134, 185, 186
Фулад Тимер бине Миңтимер  134
Хабат, Багу углы  107
Хаҗәнд  75, 77, 81, 82, 153, 154, 165, 176
Хаҗи би, Сәмәрканд хакиме  186
Хаҗи Гәрәй, Гаязетдин хан углы  132
Хаҗи Котас  184
Хаҗи (Корбан хаҗи)  197
Хаҗиколый Кош бәги  186
Хуҗамколый (Хуваҗәмколый), Габдулла хан сипаһәсе  185, 187, 191
Хаҗи Мөхәммәд (солтан) хан, Акатай хан углы, Өргәнечтә  162, 164, 168, 170, 178, 180, 181, 182, 183, 184, 185, 186, 187, 188, 189, 190, 191, 192, 193
Хаҗи Мөхәммәд хан Гали Углан углы  131

Хаҗи Мөхәммәд хан углы Гарәб Мөхәммәд солтан 184, 185, 188, 192, 193, 194
Хаҗим (солтан) хан, Хаҗи Мөхәммәд Акатай хан углы 132, 162, 164, 165, 166, 168, 169, 170, 173, 174, 177, 181, 182
Хаҗи Тули, Гарәбшаһ углы 136, 206
Хазар 153
Хазар Яфәс углы 13
Хазар таифәсе 153
Хакколый Пәһлеван (Хакколый Баһадир) 169, 170
Халаҗ (Калач), этноним 22
Халык угыллары 218
Хам, антропоним 12
Хаммар-Тегин 83
Хан-Балык, Пекин шәһәре 68, 69, 70
Хангазый солтан 196, 207
Ханкада-Су, елга 222
Ханкяһ арыгы 213
Ханкяһ, шәһәр 190, 191, 214
Ханмәлик солтан 87, 88
Ханмирза 227
Хан чоңгылы, топоним 168
Хафиз Коңгырат 164, 165
Хачин, Үгедәй каганның дүртенче хатыны 106
Хәбеш солтан, Гарәб Мөхәммәд хан углы 196, 197, 198, 199, 200, 201, 202, 203, 204, 205, 207, 209
Хәзрәте Пәхлеванның мазары 185
Хәйдәр хан, Хаҗи Гәрәй хан углы, Кырымда 132
Хәким ата 44
Хәмәр, Теркән хатынның бертуган агасы, хан углы 33
Хәмзә, Пулад (Булат) солтан углы 178, 186, 189
Хәмзә солтан, Хисардан 161, 190, 191
Хәрәзем, өлкә һәм шәһәр 8, 9, 41, 53, 72, 78, 80, 82, 83, 84, 86, 98, 102, 111, 143, 224, 229, 233
Хәрәзем шаһ солтан, Гарәб Мөхәммәд хан углы 196, 202, 203
Хәркерд, топоним 174
Хәсән иле 153
Хәсән Күчүк 123
Хәсәнколый хан, Әбүләк хан углы 149
Хәсәнколый Бәликәч солтан углы 149, 150
Хәсән Углан (Эчкеле Хәсән), Хөбинә углы 131
Хәсән Хаҗи 80
Хәсән Хуҗа нәкыйб 186
Хәсәнә мәхәлләсе 219
Хәстәкян бистәсе, Хива шәһәрендә 199
Хәстәкян касәбәсе (шул ук бистә), Хивада 199
Хива шәһәре 146, 147, 150, 153, 161, 163, 166, 168, 169, 170, 179, 180, 182, 183, 184, 185, 186, 187, 189, 190, 191, 193, 194, 195, 196, 198, 199, 200, 201, 202, 203, 207, 209, 210, 212, 213, 214, 215, 216, 221, 222, 224, 225, 227, 228, 229, 230, 232, 233
Хивада бер даруга 143, 163
Хисаметдин Китал, Бакырганда 144
Хисар 161, 165
Ходайбирде нөкер (кара: Ришау Ходайбирде) 156, 157, 158
Ходайдад, антропоним 118
Хозыр иле, этноним 151
Хозыр халкы, үзбәкләр 163
Хозыр Хуҗа бине Туклык Тимер хан бине Исәнбога бине Дуй Чичән бине Барак хан 119
Хой, Азәрбайҗандагы бер урын 124
Хорасан, өлкә 22, 33, 36, 86, 91, 92, 94, 96, 121, 122, 123, 138, 139, 143, 144, 146, 147, 149, 150, 153, 154, 155, 157, 160, 165, 168, 173, 174, 175, 176, 177, 179, 182, 183, 184, 188, 191, 197, 198, 203, 217, 218, 219, 220
Хорасан Салуры, төрекмән ыругы 151, 152
Хоррам багы 84
Хотан 62
Хост (Хәваст) манарасы 202, 205
Хөбинә Түләк Тимер углы 131
Хөрәсәнле 26
Хөҗүт 57
Хөсәен мирза 143
Хөсәен Хаҗи, аталык, Корбан хаҗиның энесе 200
Хөсрәү солтан, Надир Мөхәммәд хан углы 222
Хөсрәү солтан Илбарыс хан углы 195
Хөсрәү солтан углы — Касыйм солтан 222, 224
Хуҗа Габид 139
Хуҗагыл анасы — Көмеш 107
Хуҗагыл, Киюк хан углы 107

Хуҗагым Тинтәк  135, 142
Хуҗа күле  194, 214
Хуҗа Мәүдүд Чиштий  196
Хуҗамбирде аталык  230, 231
Хуҗамколый (Хуваҗәмколый), Габдулла ханның сипаһисе  185, 187, 191
Хуҗа Мөхәммәд солтан бине Әбелхәер хан (шул ук Хуҗагым-Тинтәк)  135, 142
Хуҗа, Үз Тимер углы  132
Хункар  154
Хуры Сумаҗу  62
Хытай йорты  36, 39, 40, 48, 71, 72
Хытай мәмләкәте  19, 20, 37, 40, 41, 66, 67, 68, 70, 96, 99, 103, 104, 109, 115, 126
Хытай халкы  40, 70
Хытай Яфәс углы  13
Хытай падишаһы Алтан хан  67, 68, 69, 70, 71, 103
Һәзара, өлкә  114
Һәзарасыб, шәһәр  146, 147, 150, 161, 163, 166, 168, 170, 174, 180, 182, 183, 185, 190, 191, 192, 193, 194, 199, 201, 202, 203, 209, 210, 215, 216, 221, 224, 227, 228, 232
Һәзарасыбның даругасы  143, 163
Һәмадан, шәһәр  217
Һерат, шәһәр  89, 95, 96, 104, 143
Һибәтулла (Шиш) пәйгамбәр  11
Һинд, ил, өлкә  19, 102
Һиндстан  8, 12, 20, 21, 33, 88, 183
Һөләкү хан  31, 107, 108, 109, 110, 121, 122, 123
Һүшәң падишаһ  22
Чаган-Муран, елга  38
Чаксун  52
Чакырлар, төрекмән ыругы  182
Чамука чичән  59, 60, 65
Чантай, антропоним  53
Чантай Утчикин  53
Чәпәноян, Чыңгыз һәм Батый ханнарның гаскәр башлыгы  53, 64, 72, 87, 89, 90
Чәчә (Ташкент), өлкә  150
Чәһардә, өлкә  150
Чәһар-Җуй, шәһәр  191, 230
Чәһар, елга  93
Чигил, төрки кабиләләрнең берсенең исеме  13
Чижут иле  52
Чин вә Мачин  109
Чин вилаяте, Кытай дәүләте  110
Чин йорты, Кытай иле  82, 109
Чингысан, Алтан ханның вәзире  69
Чирик, Шибан хан углы  134
Чиркаланком  51, 52, 57
Чиркәс  53, 104, 126
Чишт, Һерат өлкәсенең бер шәһәре  196
Чөм-Муран  70
Чокыр Хуҗа, Чыңгыз ханның Алтан ханга барган илчесе  67, 68
Чөрчет, топоним  19, 20, 41, 67
Чу елгасы  34
Чуда елга  33
Чуйрат (Җуйрат) ыругы  64, 65
Чурас бәк (Әмир Чурас)  118
Чыгтай, Чыңгыз хан углы  79, 126
Чыгтай биләре  139
Чыгтай гаскәре  138, 139, 218
Чыгтай иле  138
Чыгтай хан  9, 71, 77, 80, 83, 84, 85, 86, 96, 97, 98, 102, 103, 104, 110, 111, 112, 113, 115, 116, 118
«Чыңгызнамә» кулъязмалары  32
Чыңгыз хан  9, 16, 20, 34, 36, 38, 39, 40, 42, 43, 44, 45, 46, 48, 49, 51, 52, 53, 54, 55, 56, 57, 58, 59, 60, 61, 62, 63, 64, 65, 66, 67, 68, 69, 70, 71, 72, 73, 74, 75, 76, 77, 80, 81, 82, 83, 85, 86, 87, 88, 89, 90, 91, 95, 96, 98, 99, 100, 101, 102, 105, 107, 111, 125, 132, 133, 136, 154, 206
Чыңгыз хан һәм могул  31
Шадикум  66, 67
Шам шәһәре  22, 82, 110, 121
Шаник мирза, мангыт, Җим елгасы буенда  204, 205
Шаһбадак солтан, Әбелхәер хан углы  135
Шаһ Бәхет гали әр-Рәхмәти, шагыйрь  135
Шаһ Бәхет солтан, Мәхмүд солтан углы  178, 188

Шаһ Бәхет хан 141, 142, 143
Шаһ Габбас 174, 189, 192, 193, 203
Шаһ Гали мелла 219
Шаһ Гали солтан, Мәхмүд солтанның углы 178, 188
Шаһ-Җиһан, вилаять 171
Шаһ Исмәгыйль 143
Шаһ Исмәгыйль мәзһәбе, шыйгый тәрикасе 144, 146, 147
Шаһколый, Иш солтан углы 170
Шаһназар, Кал хан углы 165
Шаһ-Рухия, шәһәр 139
Шаһ Сафи 217
Шаһ Таһмасыб 170, 171, 175
Шәех Гали бине Әмир Гали 123
Шәех Җамалетдин 116, 117
Шәех Җәлил тавы 194
Шәех Күчүк (Шәех Хәсән бине Тимерташ) 123
Шәех Мәҗиделдин Багдади 76
Шәех Мөхәммәд, Кал хан углы 165
Шәех Нәҗметдин Көбра 76
Шәех Нәҗметдин Көбраи Галия әр-Рәхмәти зыярәте 85, 167
Шәех Рәшидетдин 117, 118
Шәех Хәсән (Күчүк) 123
Шәех Хәсән Җалайыр 122, 123
Шәех Хәсән Сөлдус 122, 124
Шәех Хәсән бине Тимерташ бине Әмир Чупан Сөлдус (аңа Шәех Күчүк диярләр) 123
Шәмәй солтан, Тулукъ солтан углы 131
Шәмәй солтан, Ураз солтан атасы 131
Шәмәха, өлкә 40, 91
Шәрәфетдин Йезди, тарихчы 16
Шәриф Мөхәммәд солтан, Гарәб Мөхәммәд хан углы 196, 199, 201, 202, 203, 209, 210, 211, 212, 213, 214, 215, 216, 221, 229
Шәһре Сарай 119
Шәһрестан, шәһәр 93
Шиба (Шаһ Бәхет Шиба) 178
Шибани Гали әр-Рәхмәти 135
Шибан хан, Батый ханның энесе 9, 58, 126, 131, 132, 133, 134, 135
Шидерку, Тангут иле хакиме 99
Шики, антропоним 87, 88
Шираз, шәһәр, өлкә 102, 174
Ширамун Вәли әл-Гаһди 106, 108
Ширә угыл, могул 115, 116
Ширван, өлкә, шәһәр 91, 183, 184, 193
Ширгазый солтан, Солтангазый солтан углы 160, 196, 207
Шир Зиян Кишварстан 231
Шиш пәйгамбәр 11, 56, 207
Ырыс Әйнал (бәк) 37, 66
Ырыс унбәги 224
Ырыс хан, Байдакол углы 119, 132
Эр тавы 16
Эрлат 45
Эрлат иле 45
Эссе күл 13, 33
Эчке Салур, төрекмән этнонимы 153
Юлым би, Найман ыруыннан 171, 172
Юныс хан, Суфиян хан углы 153, 162, 165, 166, 167, 168, 182
Юныс ханның хатыны Мангытның Исмәгыйль би кызы 166
Юшан солтан, Әсфәндияр солтан углы 221
Ябир, антропоним 26, 27
Ядгәр аталык 231
Ядгәр инак 227, 228
Ядгәр хан, Тимершәех углы 137, 140, 143, 146, 147, 148, 149, 177, 196, 206, 207, 215
Ядгәр хан 57
Язир, антропоним 26, 27
Язир, Мәрвә янындагы шәһәр 92, 93
Якуб Тупит 224
Якуб Шаһ, сарай чиновнигы 123
Ялтыравык йолдызы 188, 191, 214
Ямгырчы, Хаҗи Гәрәй хан углы 132
Ямут, төрекмән ыругы 152, 189, 190, 203
Яңа Арык, топоним 179, 183

Яңа Шәһәр 145, 148, 150, 160
Яркәнд, шәһәр 115, 116, 117, 119
Ярмөхәммәд солтан, Мангышлак солтан углы 132
Ярымшир Буканчу 52
Ясунту, Мутукан углы 112, 113, 115
Ясут ыруы 53, 72
Яфәс, пәйгамбәр 13, 14, 16, 56, 207
Яэҗүҗ-мәэҗүҗ, легендар образ 40

## Эчтәлек

Әбелгазый Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрек» әсәре турында.
*М.Әхмәтҗанов* ........ 3

### Кереш

### Әүвәлге баб

Ходай Тәгалә Адәм галәйһиссәламне яратканының зикере ........ 10

### Икенче баб

Татар ханның зикере ........ 15
Могул ханның зикере ........ 16
Кара ханның зикере ........ 16
Угыз хан дөньяга килгәненең бәяны ........ 16
Угыз ханның хан булганының зикере ........ 19
Угыз ханның Туран вә Һиндстанга барганының зикере ........ 21
Угыз ханның Иран, вә Шам, вә Мисыр тарафына барганының зикере ........ 22
Угыз ханның, йортына кайтып, туй кылганының зикере ........ 23
Угыз ханның олуг углы Көн ханның падишаһлыгының зикере ........ 24
Угыз ханның угланнары, нәбирәләренең исемнәренең зикере ........ 26
Ай ханның падишаһлыгының зикере ........ 27
Йолдыз ханның зикере ........ 27
Менгле ханның зикере ........ 27
Диңгез ханның зикере ........ 28
Ил ханның зикере ........ 28
Кыян илән Нөкүзнең, Әркинәкунга барып, йорт итеп утырганнарының зикере 29
Могулның вә башка төрек ыругларының бәяны һәм асыллары, вә атлары, һәм ләкабләре ни икәненең зикере ........ 31
Карлык иленең зикере ........ 34
Уйгур иленең зикере ........ 34
Текрин иленең зикере вә аны Мекрин һәм диләр ........ 36
Кыргыз вә Кемкемҗөт иленең зикере ........ 36
Урманкот иленең зикере ........ 37
Татар иленең зикере ........ 37
Ойрат иленең зикере ........ 38
Тумат иленең зикере ........ 39
Найман иленең зикере ........ 39
Кирәет иленең зикере ........ 39
Онгут иленең зикере ........ 40
Хытай иленең зикере ........ 40
Торкак ыругының зикере ........ 42
Могул илләренең зикере ........ 42
Меркит иленең зикере ........ 43
Коңгырат иленең зикере ........ 43
Ингәрәс иле вә Әлканут иленең зикере ........ 43
Каранут иленең зикере ........ 44
Корлас иле илән Илчигән иленең зикере ........ 44
Урмаут иленең зикере ........ 44
Куныкмар иленең зикере ........ 44
Эрлат иленең зикере ........ 45
Келкит иленең зикере ........ 45
Бадай вә Кыйшлык иленең зикере ........ 45
Уйшун иленең зикере ........ 46

Сөлдус иленең зикере ........ 46
Илдүркин иленең зикере ........ 46
Көнкит иленең зикере ........ 46
Дурбан иленең зикере ........ 46
Барыйн вә Сокыт иленең зикере ........ 47
Үклән иленең зикере ........ 47
Бияут иленең зикере ........ 47
Җалайыр иленең зикере ........ 48
Могул падишаһларының зикере ........ 49
Аланкуваның гаҗәиб вә гараиб хикәяте ........ 50
Аланкува балаларының зикере ........ 51
Аланкува әйткән иде ки: миңа килеп җефет була торган
кемсәнең күзләре ак-сары ........ 54

**Өченче баб**

Чыңгыз ханның дөньяга килгәненең зикере ........ 55
Чыңгыз ханның унөч яшеннән кырык яшенәчә кылган эшләренең зикере . 57
Чыңгыз ханның Кирәет Уң хан илән орышып җиңүче булганы ........ 59
Чыңгыз ханның хан булганы ........ 63
Чыңгыз ханның Найман илән орышып галиб булганы ........ 63
Чамука чичәннең үлгәне ........ 65
Чыңгыз ханның Меркит иле вә аннан соң, барып, Тангут йортын алганы.. 65
Чыңгыз ханның Найман Боерык хан өстенә йөргәне ........ 65
Кыргыз халкының ил булганы ........ 66
Чыңгыз ханның атланып Көчлүк илән Туктабикинең артыннан барганы... 66
Уйгур халкының ил булганы ........ 66
Чыңгыз ханның Хытай, вә Кара-Хытай, вә Чөрчет вилаятьләрен алганы ... 67
Чыңгыз ханның Алтан хан илән ярәшеп кыз алып кайтканы ........ 68
Боргул ноянны Тумат иле өстенә җибәргәне ........ 71
Чыңгыз ханның угланнары, вә хатыннары, вә кәнизәкләре ........ 71
Көчлүк өстенә Чәпә ноян дигәнне җибәргәне вә аның Көчлүкне үтереп кайтканы 72
Чыңгыз ханның Мәхмүд Ялавыч дигән кемсәне Хәрәзем
шаһы Солтан Мөхәммәдкә илче кылып җибәргәне ........ 72
Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһының Гаяр ханның әмере илән Чыңгыз ханның илче вә сәүдәгәрләрен үтергәннәре 73
Җүчи ханның Солтан Мөхәммәд Хәрәзем шаһы илән сугышканы ........ 75
Солтан Мөхәммәднең дәүләте кайтканының сәбәбе ........ 76
Чыңгыз ханның Бохара тарафына йөргәне ........ 76
Үгедәй хакан вә Чыгтай ханның, Гаяр хан илән сугышып, Отрарны мөсәххәр кылганнары 79
Җүчи ханның Җәндкә барганы ........ 80
Алак ноянның Сиктү Бога илән Фәнакәнд вә Хаҗәндкә килгәннәре вә Хаҗәнд хакиме Тимер Мәлик зикере 81
Чыңгыз ханның Кишварстанның Сәмәркандны алганы ........ 82
Чыңгыз хан угланнарын Хәрәземгә җибәргәне ........ 83
Чыңгыз ханның Нәхшеб, вә Термиз, вә Бәлхкә барганы ........ 86
Чыңгыз ханның Солтан Җәләлетдин илән орышканы вә аның Синд суыннан кичеп качканы87
Чыңгыз ханның Солтан Мөхәммәднең артыннан гаскәр җибәргәне........ 89
Чыңгыз ханның Тули ханны Хорасан өстенә җибәргәне ........ 91
Тули ханның Нишапурга барганы ........ 95
Тули ханның Һератка барганы ........ 95
Чыңгыз ханның эне вә угланнары илән Могулстанга кайтмакны киңәш кылганы 96
Чыңгыз ханның үз йортына кайтканы ........ 97
Чыңгыз ханның, хаста булып, угланнарына нәсыйхәт
кылып дөньядан үткәне ........ 99
Чыңгыз ханның бәгъзе мисаллары, вә белекләре, вә рәсем, вә кагыйдәләре100

**Дүртенче баб**

Чыңгыз ханның өченче углы Үгедәй ханның вә Чыңгыз хан
нәселеннән Могулстанда падишаһлык кылганнарының зикере ........ 102
Үгедәй хаканның Хытайга барганы ........ 103
Үгедәй хаканның шаһзадәләрне Урыс, вә Чиркәс, вә Болгар, вә Туран, вә Башкорт, вә гайре вилаятьләрне фәтех кылырга җибәргәне ........ 104
Үгедәй хаканның үлгәне ........ 104
Падишаһе Иран вә Туран хаканының бәгъзе холык вә фигыльләре........ 105
Үгедәй хаканның хатыннары һәм угланнары ........ 106

Мәнгү хаканның зикере ............................................................................. 107
Мәнгү хакан Кубилай хаканны мәшрикъ тарафындагы мәмләкәтләргә вә Һөләкүне мәгъриб тарафындагы мәмләкәтләргә җибәргәне ............................................................................. 109
Кубилай хаканның хан булганы ............................................................................. 109

**Бишенче баб**

Чыңгыз ханның икенче углы Чыгтай ханның вә аның әүлядыннан Мавәраәннәһер вә Кашгарда падишаһлык кылганнары ............................................................................. 111
Чыгтай ханның хатыннары вә угланнары ............................................................................. 111
Чыгтай ханның угланнары Мавәраәннәһердә падишаһлык кылганнары... 112
Туклык Тимер ханның мөселман булганы............................................................................. 115

**Алтынчы баб**

Чыңгыз ханның кече углы Тули ханның нәселеннән Иран йортында падишаһлык кылганнары 121
Һөләкү хан нәселеннән Иран мәмләкәтендә Әбүсәгыйд ханнан соң әмирләр хан кылганы 122

**Җиденче баб**

Җүчи хан әүлядыннан Дәште Кыпчакта падишаһлык кылган ханнар ....... 125
Батый хан бине Җүчи хан ............................................................................. 125
Бәркә хан бине Җүчи ханның Дәште Кыпчакта хан булганы ..................... 127
Мәнгү Тимер хан бине Тукай бине Җүчи хан, аннан соң Туда Мөнгү бине Тукай бине Җүчи хан, аннан соң Туктагу хан бине Мәнгү Тимер ханнарның бәяны............................................................................. 128
Үзбәк хан бине Тугрул хан бине Мәнгү Тимер хан бине Батый хан бине Җүчи хан бине Чыңгыз ханның хан булганы 129
Җанибәк хан бине Үзбәк ханның хан булганы............................................................................. 129
Бирдебәк хан бине Җанибәк ханның хан булганы............................................................................. 130

**Сигезенче баб**

Җүчи хан бине Чыңгыз ханның бишенче углы Шибан ханның әүлядыннан Туранда, вә Казакъта, вә Кырымда, вә Мавәраәннәһердә падишаһлык кылганнары ............................................................................. 131
Тукай Тимер нәселеннән Кырымда падишаһлык кылганнары ................... 131
Тукай Тимер нәселеннән Казакъта падишаһ булганнары ............................ 132
Җүчи ханның өченче углы Тукай Тимернең нәселеннән Мавәраәннәһердә падишаһ булганнары 132
Җүчи ханның бишенче углы Шибан хан әүлядының зикере ...................... 133
Икенче углы Баһадир хан атасы урынында утырды; аның ике углы бар иде: олугының исеме Җүчи Бога, кечегенең исеме Котлык Бога............................................................................. 134
Шибан хан нәселеннән Мавәраәннәһердә падишаһ булганнары ............... 134

**Тугызынчы баб**

Җүчи хан бине Чыңгыз ханның бишенче углы Шибан хан әүлядыннан Хәрәземдә падишаһ булган кемсәләр 136
Ядгәр ханның олуг углы Бәркә солтан гаҗәеп булдыклы ир-егет иде ....... 137
Мангыт Муса бәкнең Бәркә солтан ишегенә килеп булышлык теләгәне... 139
Ядгәр ханның вафаты һәм Бәркә солтанның шәһид булганы ..................... 140
Бәркә солтанның угланнары Илбарыс илән Билбарыс ................................ 143
Инде Илбарыс ханның Өргәнечне ничек алганын бәян кылаем ................. 143
Илбарыс ханның Өргәнечне алганы............................................................................. 145
Әбүләк хан вә Амәнәк хан угланнарының, Өргәнечкә килеп, Хива, вә Һәзарасыб, вә Хорасан итәген алганнары вә Әбү-Әлхан, вә Мангышлак, вә Дабистанда утырган төрекмәннәрне тәбгы кылганнары............................................................................. 147
Әвәниш ханның падишаһ булганы ............................................................................. 154
Габид ханның Өргәнечне алганы............................................................................. 161
Динмөхәммәд солтанның Габид хан илән орышканы ................................ 162
Динмөхәммәд солтан бәяны............................................................................. 170
Хаҗи Мөхәммәд хан башлык Акатай ханның угланнары ........................... 178
Пулад (Булад) солтанның сыйфаты............................................................................. 179
Энесе Тимер солтанның сыйфаты ............................................................................. 180
Мөхәммәд солтанның сыйфаты ............................................................................. 181
Хаҗим ханның зикере............................................................................. 182
Хаҗи Мөхәммәд ханның хан булганыннан вафат булганынача булган әхвәле 182
Габдулла ханның килгәненең сәбәбе............................................................................. 183
Хаҗи Мөхәммәд ханның Гыйрактан килеп Өргәнечне алганы вә Габдулла ханның өченче кәррә Өргәнечкә килгәне 189

Хаҗи Мөхәммәд хан углы Гарәб Мөхәммәд хан илән Сөенеч Мөхәммәд солтанның, килеп, йортка ия булганнары 192
Гарәб Мөхәммәд ханның падишаһ булганы ........ 194
Казакъның әүвәл килгәне ........ 195
Казакъның икенче килгәне ........ 195
Моннан ун ел үткәч, калмыкның икенче кәррә килгәне ........ 196
Атабыз Гарәб Мөхәммәд хан тәхеткә утырганнан соң ундүрт ел булганда Хәбеш вә Илбарысның яу булганнары 196
Гарәб Мөхәммәд ханның шәһид булганы вә Әсфәндиярнең хан булганы 203
Сахибе заман вә хәлифәи дәверан Әбелгазый ханның дөньяга килгәне һәм ата вә бабаларының исемнәре ........ 205
Әбелгазый ханның егерме бер яшеннән егерме өч яшенәчә башыннан үткән вакыйгалары 210
Өргәнеч үзбәгенең бозылганы ........ 214
Әбелгазый ханның Хивага төрекмән эченә килгәне ........ 215
Әбелгазый ханның Гыйрактан качып хан булганчы булган вә кылганнары 217
Әбелгазый ханның падишаһ булганы ........ 221
Ханның бу сәхифәгәчә бу вакыйгаларны үз мөбарәк кулларының хатыдыр (язуы) 223
Ханның Тосанга барганы ........ 225
Ханның, Бами-Бормага барып, күп төрекмәнне кырганы ........ 225
Ханның калмык илән орышканы ........ 226
Ханның Имриле вә Сарыйк халкын барып алганнары ........ 227
Ханның калмык илән икенче мәртәбә орышканы ........ 227
Ханның Бохарага әүвәл мәртәбә барганнары ........ 229
Ханның Каракүлне алганы ........ 229
Чәһар-Җуйга барганнары ........ 230
Ханның Җайчыга барганнары ........ 230
Ханның Вәрданзига барганы ........ 232
Бохарага соңгы барганы ........ 232

Исемнәр, атамалар күрсәткече ........ 234

Литературно-художественное издание

***Абелгази*** *Бахадур хан*

**Родословное древо тюрков**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Әбелгазый*** *Баһадир хан*

**Шәҗәрәи төрек**

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.08.2007. Форматы 84x108 1/32. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 14,28 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 15,54. Нәшер-хисап табагы 13,88 + форз. 0,36. Тиражы 1000 д. Заказ С-687.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420059. Казан, Бауман урамы, 19.

http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.